ISSN 0206-4189 12+
Индекс 73210

# Казан утлары

6.2013



*Казан Универсиадага әзерләнә*



















# Казан утлары
# Qazan utlari

2013

6
(1088)

*ГАМӘЛГӘ КУЮЧЫ:*
*«ТАТМЕДИА»*
*ачык акционерлык җәмгыяте*

татмедиа

*БАШ МӨХӘРРИР*

**Равил Габдрахман улы**
**Фәйзуллин**

*ИДАРӘ:*

**Рабит Батулла**
**Разил Вәлиев**
**Мөдәррис Вәлиев**
**Тәлгат Галиуллин**
**Рәдиф Гаташ**
**Алмаз Гыймадиев**
*(җаваплы сәркәтип)*
**Дания Заһидуллина**
**Дамир Исхаков**
**Рафис Корбан**
**Хатыйп Миңнегулов**
**Гәрәй Рәхим**
**Айрат Сибагатуллин**
**Рафикъ Юныс**
*(баш мөхәррир урынбасары)*

---

*Мөхәррирләр:* **Гөлзадә Бәйрәмова, Марат Закир, Әлфәт Закирҗанов, Камил Кәримов.**

*Гамәли хезмәткәрләр:* **Лилия Гатауллина, Элеонора Җамалиева, Флера Сабирова.**
*Исәп-хисап бүлеге:* **Гөлнара Галиева** (баш бухгалтер).

---

✉✉: Редакция һәм нәшер адресы: *420066, Казан, Декабристлар урамы, 2.*
☎☎: *Баш мөхәррир — 562-10-62.*
*Җаваплы сәркәтип, компьютер үзәге — 222-09-83 өст. 1612.*
*Исәп-хисап бүлеге — 222-09-80.*

✆: **Факс** — (843) *222-09-83 өст. 1612.*

🖳: **E-mail:** kazanutlari@yandex.ru

# КАЗАН УТЛАРЫ

ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ЖУРНАЛ

1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА

## Бу санда

**ШИГЪРИЯТ ҺӘМ ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР**

Нур ӘХМӘДИЕВ. Хатирәләр үлми, искерми. *Шигырьләр.* ....... 5
Марат ӘМИРХАНОВ. Ир-мамай. *Тарихи бәян.* ....... 10
Рифә РАХМАН. Ә сагышым – моңлы жыр икән. *Шигырьләр.* ....... 67
Вәрис ГАЛИ. Гомер челләсе. *Бәяннан өзек.* ....... 71
Гөлзада ӘХТӘМОВА. Изгелектә безнең бар ният. *Шигырьләр.* ....... 84

**ТАТАР ХИКӘЯЛӘРЕ ХӘЗИНӘСЕННӘН**

Флүс ЛАТЫЙФИ. Өч хикәя. ....... 87

**ХӘТЕР**

Азалия БАДЮГИНА. Рушад абый чын көрәшче һәм әйбәт кеше иде. ....... 107
Рушад ХИСАМЕТДИНОВ. Җәлилче булуым белән горурланам. ....... 108
Хисаметдин ИСМӘГЫЙЛЕВ. Кырым татарлары фаҗигасе. ....... 141
Факил САФИН.Чын иҗат үксез булмый ул. ....... 164
Венера ИХСАНОВА. Иртәдән кичкә кадәр. ....... 176

**ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ**

Айдар ХӘЛИМ. Без аны көтә идек... ....... 132

**ФӘН**

Фирдәвес ГАРИПОВА. Авылларыбыз тарихы. ....... 156
«Татар энциклопедиясе» битләреннән. ....... 159

**ПЕЧӘН БАЗАРЫ**

Люция ӘБЛИЕВА. Парчалар. ....... 187

**ШӘХЕСЛӘР ҺӘМ ШӘРЕХЛӘР**

Әсгать САЛАХ. «Ошадың әле...» ....... 188

Рифкать ЗАКИРОВ. Без уянсак кына. *Шигырьләр.* ....... 171

«Казан утлары» архивыннан. .......
Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан. ....... 190

## В ЭТОМ НОМЕРЕ:

*Журнал выходит один раз в месяц*

«Проза и поэзия»: историческая повесть М.АМИРХАНОВА «Мамай»; отрывок из повести В.ГАЛИ «Пик жизни»; стихи Н.АХМАДИЕВА, Р.РАХМАН, Г.АХТЯМОВОЙ, Р.ЗАКИРОВА.
«Из сокровищниц татарских рассказов»: рассказы Ф.ЛАТЫФИ.
«Память»: А.БАДЮГИНА. «Рушад абый был настоящим бойцом и хорошим человеком»; Р.ХИСАМУТДИНОВ. «Я горд, что принадлежу к джалильцам»; Х.ИСМАГИЛОВ. «Трагедия крымских татар»; статья Ф.САФИНА о творчестве Ф.ЛАТЫФИ; В.ИХСАНОВА. «С утра до вечера» (о Л.ИХСАНОВОЙ).
«Литературная критика»: статья А.ХАЛИМА, посвященная творчеству М.ВАЛЕЕВА.
«Наука»: Ф.ГАРИПОВА. «История наших деревень».
Страницы из «Татарской энциклопедии».
Из фотоархива журнала.
Дневник общественно-культурной жизни.
На наших обложках: картина Ф.ХАЛИКОВА «Сабантуй»;
писатель Ибрагим БИЕКТАУЛЫ.

## IN THIS ISSUE:

«Prose and poetry»: historical novel by M.AMIRHANOV «Mamay»; excerpt from story by V.GALI «Peak of life»; poems by N.AHMADIEV, R.RAHMAN, G.AHTYAMOVA, R.ZAKIROV.
«From treasures of Tatar Stories»: stories by F.LATYFI.
«Memory»: A.BADYUGINA. «Rushad Aby was a real fighter and a good man»; R.HISAMUTDINOV. «I am proud I belong to Dzhalils»; H.ISMAGILOV. «Tragedy of Crimean Tatars»; article by F.SAFIN about creativity of F.LATYFI; V.IHSANOV. «From morning till evening» (about L.IHSANOVA).
«Literary Criticism»: article by A.HALIM devoted to creativity of M.VALEEV.
«Science»: F.GARIPOVA. «History of our villages».
Pages from «Tatar Encyclopedia».
From photo archives of magazine.
Diary of the social-cultural life.
On our covers: picture by F.HALIKOV «Sabantuy»;
writer Ibrahim BIEKTAULY.

*The magazine edits monthly*

★Авторлар фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.
★Редакциягә килгән кульязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
★Басмаханә гаебе белән киткән житешсезлекләр өчен редакция җавап бирми, брак журналларны алыштыру мөмкинлеге юк. Алар хакында 519-44-61 телефоны белән басмаханәнең техник контроль бүлегенә хәбәр итәргә кирәк.

Журнал редакциянең компьютер үзәгендә җыелды һәм битләргә салынды.
Басарга кул куелды 03.06.2013, график буенча 03.06.2013.
Офсет ысулы белән басылды. Кәгазь форматы 70Х108 $^{1}/_{16}$.
Нәшер-хисап табагы 14,2. Басма табак 12 (16,8). Заказ С-1199. Тираж 4047.
Журнал Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм гаммәви коммуникацияләрне күзәтү буенча Федераль хезмәтендә 2011 елның 23 мартында теркәлде.
Теркәлү таныклыгы ПИ № ФС77-44362.
Индекс 73210 (физик затлар өчен), 16262 (юридик затлар өчен). Бәясе иркле.

«ПИК «Идел-Пресс» ААЖ «ТАТМЕДИА» филиалы типографиясендә басылды.
Казан, Декабристлар урамы, 2

© «Казан утлары», 2013 ел.



Нур
Әхмәдиев

# ХАТИРӘЛӘР ҮЛМИ, ИСКЕРМИ

## Шомлы җилләр

*Көчләремне мин кара көннәргә*
*саклый алмадым.*

Г.Тукай, «Кыйтга.»

**Әй остазым, кыска гомереңдә**
**Якты көнең күпме булгандыр.**
**Тормыш бит ул, садә күренсә дә,**
**Акыл ирешмәслек болгавыр,**
**Кабахәтлек белән тулгандыр.**

**Бу сүзләрең әйтелгәннән бирле**
**Гасыр узган — Вакыт туктамый.**
**Дөнья әле һаман ап-ак түгел,**
**Шагыйрьләрең тыныч йокламый.**

**Ничек тыныч йоклый алсын шагыйрь,**
**Милләтеңә уклар атылгач?**
**Ирек турындагы хыяллары**
**Челпәрәмә килеп ватылгач;**
**Алтыннардан өстен моңлы телем**
**Бакыр бәясенә сатылгач...**

**Сиратларны аз кичмәде татар,**
**Алда тагынниләр бар икән.**
**Инкыйразы әгәр килә калса,**
**Кемнәр булыр соңгы могикан?**

**Гасыр узды, әмма туктамады**
**Гарасатлы җиле, давылы.**
**Татарымны саклап калды дине,**
**Саклап калды аны авылы.**

---

Нур ӘХМӘДИЕВ (1946) — *шагыйрь, прозаик; «Аһәң», «Амбирак», «Абага чәчәге» һ.б. китаплар, шул исәптән дүрт томлык «Сайланма әсәрләр» авторы. Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе. Әлмәттә яши.*

Әй Тукаем, хәлләр үзгәрмәде,
Инде гасыр узды югыйсә.
Якалардан Мәскәү буып алган,
Мәскәүләрдән шомлы җил исә...

## Бүгенге хәлләр

Чукынганга патша җир өләшкән,
Биргән дәрәҗәләр, өстенлек.
Чукынмаган татар морзаларын
Хәерчелек көткән, мескенлек.

Чукынганнар...
Татар хисабына
Никадәрле урыс үрчегән.
Үз нәфсеңне тыя алмаганда,
Акыл алып булмый күршедән.

Чукынганнар...
Чукынмаганнары
Урман, далаларга качканнар.
Качканнар да татар тарихының
Яңа сәхифәсен ачканнар.

Чит җирләрдә корган оясында
Бабайларның рухын саклаган.
Чабаталы морза булса булган,
Телен, динен, денен сатмаган.

Бүген исә хәлләр нык үзгәрде,
Уйлаганнар шаклар катарлар:
Патша да юк, чукынып та тормый,
Урыслашып бетте татарлар.

## Сагыну

### *1. Әнкәемне сагындым*

Була көннәр — үткән онытыла,
Ике ятып, төшкә бер керми.
Була көннәр — үткәннәрем һич тә
Бүгенгене якын китерми.
Ходай биргән хәтер исән икән,
Хатирәләр үлми, искерми.

Ни сәбәптер, кайттым балачакка,
Истәлекләр чират торалар:
Әнкәемне күптән күргәнем юк –
Алар кырда урак уралар.

Мин йокыдан торсам — ул басуда,
Мин ятканда — әле кайтмаган.
Кояш юкса вакытында чыккан,
Вакытыннан алда батмаган.

Әнкәй эштә, әткәебез эштә,
Әле ярый өйдә әби бар.

Авырый ул, ләкин аягында
Үзен йөретерлек хәле бар.

Җим болгата, безгә чәй эчерә,
Тәмам арыганчы йөренә.
Намаз укый, намазлыгы исә
Һәрвакытта өйнең түрендә.

Үз алдына нидер көйләп йөри,
Кайчак миңа дога өйрәтә.
Әбкәемнән откан догаларым
Җылы биреп тора йөрәккә.

Әбкәй булу бәхет,
Тик әнкәйне
Алыштыра алмый әби дә.
Әнкәй кайта алмый — ул уракта,
Барып күрмәскә соң ә нигә?
Мин зур инде — алты яшем тулган,
Алтым тулган, әле җиде юк.
Бүген шундый эссе, сулыш каба,
Әз генә дә хәтта җиле юк.

Сагынуым чиксез–чамасыз ла,
Бүтән басар чара тапмадым,
Әбигә дә әйтеп тормый гына,
Кырлар кочагына атладым.

Бүз тургайлар җырлап каршы алды,
Күбәләкләр миңа иярде.
Агач атым хыянәтсез юлдаш,
Без, малайлар, һәрчак «иярле».

Таяк «ат»ны әле «юырттырам»,
Әле тыям — барам акырын.
Җанәй кулы бик үк якын түгел,
Ким дигәндә өч–дүрт чакырым.

Әти белән анда барганым бар,
Печән чапкан идек малларга.
(Дистә еллар кирәк булган икән
Шушы хозурлыкны аңларга!)

Такыр юлдан барсаң, ерагая,
Урган басу аша атладым.
Минем әле кыска ыштан белән
Яланаяк йөргән чакларым.

Йә басыла шайтан таягына,
Бертуктаусыз камыл кадала.
Еласа да гаеп булмас иде
Аяклары канлы балага.

Юк, еламыйм, үҗәтләнеп атлыйм,
Сөрлектем дә ничә абындым.
Егылсам да кабат торып киттем —
Әнкәемне өзелеп сагындым.

**Шул сагыну миңа канат куйды,**
**Шул сагыну миңа көч бирде.**
**Канлы аяк, кипкән авыз белән**
**Җәнәй кулга илтеп җиткерде.**

**Уракчылар шундук күрмәделәр,**
**Ничек күрсен — башлар иелгән.**
**Керт-керт итеп алар урак ура,**
**Көлтәләре күпме өелгән!**

**Әнкәм кырыена килеп җиткәч,**
**Көтмәгәндә, кинәт хур булдым:**
**— Әнкәй! — диеп ничек дәшкәнмендер,**
**Хәлем бетеп аннан егылдым.**

**Шул көенчә күпме ятканмын да**
**Ничек килгәнмендер аңыма,**
**Куануның чиге-чамасы юк,**
**Әнкәемне күргәч янымда.**

**— Нәрсә булды, ничек эзләп таптың?**
**Әнкәй күзләрендә яшь иде.**
**Тургайлар да шулчак, җиргә төшеп,**
**Безнең каршыбызда баш иде.**

**— Бик сагындым сине, и әнкәем! —**
**Буам ерылды бит, түзмәдем.**
**Бүтән хатыннар да, эштән туктап,**
**Сөртеп алды яшьле күзләрен.**

**Аларның да бар шул балалары,**
**Аларның да бәгыре өзелә.**
**Бик кайтырлар иде, законнар бар,**
**Ә законнар кырыс — түзелә.**

**Әнкәй алды мине кочагына,**
**Чытырдатып тоттым күлмәген.**
**Әйтте әнкәй:**
**— Үз балаңны күрми**
**Узсын инде озын көннәрең!**

**Нинди тормыш,**
**Бу каһәрле тормыш,**
**Булыр микән берәр азагы?**
**Балаларны күрми торуыңнан**
**Җиңелрәктер тәмуг газабы!..**

**Киттек, улым, өйгә кайтабыз, — дип,**
**Ай-урагын алды иелеп.**
**Кайтып киттек, арганымны сизмим,**
**Янәшәдән атлыйм, сөенеп.**

**Әнкәй белән бергә нинди рәхәт,**
**Бик кадалмый икән камыл да.**
**Җитәкләшкән кулны ычкындырмый,**
**Кайтып кердек икәү авылга.**

**Капка ачып, эчкә үтү белән,**
**Әнкәй алды мине кочакка.**
**Бездән бәхетлерәк җан иясе**
**Булмагандыр җирдә ул чакта.**

**Кояш инде кичкә авышса да,**
**Бөркү кимемәде, җиле юк.**
**Әнкәемә кырык тулып узган,**
**Мин алтыда, хәтта җиде юк.**
**Мин бүген дә аны сагынудан**
**Бер чарасыз, кысам тешемне.**
**Зиратлар бит бары ала гына,**
**Кире бирми алар кешене.**
**Кире кайтармыйлар кешене...**

## *2. Авылны сагыну*

**Күптән инде аңа кайтканым юк,**
**Тормышларым — оҗмах сыенда.**
**Хәтта оҗмахта да туган авыл**
**Гел уемда минем, уемда.**

**Телисезме, бүген әйтеп бирәм**
**Кемнең кайсы йортта торганын?**
**Ничек онтыйм, алма урлаганга**
**Гайсә картның колак борганын.**
**Бернәрсә дә каплый алмый икән**
**Үсмер чакның хәтер урманын.**

**Булды инде кыяр чәлдерү дә,**
**Капка кучеру дә калмады.**
**Явызлыкны гадел хөкем итте,**
**Шуклыкларны авыл аңлады.**

**Әхлак дәресләрен анда алдым,**
**Эш сөяргә анда өйрәндем.**
**Әй авылым, әнкәм сөте белән**
**Бар дөньяны миңа бирәлдең.**

**Олыларны олы итә беләм,**
**Кечеләргә бабай, агай мин.**
**Авыр килсә бер дә чит итмәдең,**
**Мин һәрвакыт сиңа таяндым.**

**Авылымда, беләм, беркайчан да**
**Рәнҗетергә ирек бирмәсләр.**
**Туган җирнең мин бит үз сөяге,**
**Чыпчыклар да күптән сердәшләр.**

**Карга, чәүкәләре танып тора,**
**Ә этләрен хәтта әйткән юк.**
**Кайтам, кайтам!**
**Ләкин, ни кызганыч,**
**Каршыларга әнкәм—әткәм юк...**

Марат
Әмирханов

# ИР–МАМАЙ

ТАРИХИ БӘЯН

***

– Хан галиҗәнаплары!

Диван-бинең үгез үкерүенә охшаш калын тавышы яңгырауга, тәхет залының киң ишекләре киерелеп ачылды.

Кулларына ышаныч таныклыкларын тотып баскан илчеләрнең гәүдәсыннары тураеп катты. Ләкин хан һаман керми дә керми. Йөзләргә гаҗәпләнү чаткылары кунды, терсәкләр уйнап алды.

– Мин сиңа ханны күз уңыннан төшермәскә куштым, ник үтәмәдең? – дип Мамай яшелле-зәңгәрле карашын ясавылбашка текәде.

– Аның юлы еланныкы кебек җир астыннан йөри бит, бәк, әллә күз буа инде.

– Акыл сатма, бар, табып китер!

Ясавыллар эз иснәп, тирә-якка таралышты.

Хан җанвар-җәнлеккә мөкиббән. Аны шулар тирәсеннән эзләргә кирәк. Тик ул җанвар-җәнлек дигәннәре дә дүрт аяклы,урыннарын алыштырып кына торалар. Шуңа күрә галиҗәнапны күрми дә каласың. Әле дә, кай арада житешкәндер, илчеләр янына керү вакыты җиткәч кенә, затлы хан камзулын идәнгә салып ташлаган да, сарайдан чыгып качкан. Сизми дә калганнар.

Эзләүчеләрнең табаннары кызышып бетте. Нишләтәсең, юк хан, исе дә килми.

– Ат менгән бу, – диде ясавылбаш, хафасына тиенеп, – ерак киткәләгәнче эләктерергә кирәк. Җәт!

Ясавыллар бер ыргымда ат өстендә иде инде. Ләкин тезгеннәрне бушатырга өлгермәделәр, булышчы углан туктады да:

– Кушчы әсир ым кага анда, – диде, – белеп килимме?

– Шул гына житмәгән иде, – диде ясавылбаш ачу белән, – кузгалдык!

Ыргылдылар.

Бераздан ясавылбаш атын тыйды да ярдәмчесенә әйтте:

– Бәлкем, кушчы әсир хан турында бер-бер хәбәр житкерергә теләгәндер, бар, белеш әле, – диде.

Кирмәннән арырак бер ташландык өстуан[1] бар иде, кушчы әсир сүзсез генә шуңа төртеп күрсәтте.

Хан дөрестән дә дөньясын онытып, әлеге хәрабә арасында эт көчекләре

[1] Өстуан – павильон.

*Дәвамы. Ахыры киләсе санда.*

белән әш-мәшә килә иде. Көчекләр дә ияләшкән, күрәсен, битен, иреннәрен ялыйлар. Ана эт аларның уенын канәгать кыяфәттә читтән генә күзәтеп ята, ырылдамый да, өрми дә, тәмам туганлашып беткәннәр.

Ханның шушы гадәтен искә алып, Мамай Урдада киекханә булдырды. Анда бүредән алып әрлән-йомран ише җәнлекләргә кадәр бар иде. Тик хан көннәрдән бер көнне, иртә таңда, тоткыннарның читлекләрен ачты. Тегеләр күз ачып йомганчы таралышып беттеләр.

Бүре кайда да бүре инде ул, төсен үзгәртер, әмма холкын үзгәртмәс. Сорыкай үзе кебек әсир мыймылдык бер казюланы[2] да кыстырып китте. Әбәте унгандыр, мөгаен.

— Мөхтәрәм хан галиҗәнаплары, сине илчеләр көтә, тәхет залына рәхим ит, — диде ясавылбаш, башын келәт астына сузып, — көтәләр анда.

— Көчекләремә тисәгез, башыгыз очар, — дип кисәтте хан.

Ул кыска бармаклы юантык куллары белән күлмәген рәтләгәндәй итте дә, чалбар кесәсеннән табыннан чәлдергән пешкән ит кисәге алып, артыннан иярген көчекләргә ыргытты. Көчекләр шуның белән юанып калдылар.

Хан алагаем зур тәхеттә тәлинкәгә кунган чебен кебек кенә булып калды. Илчеләргә яна ханның балигълык яшенә житмәве мәгълүм иде, әлбәттә, тик үзен күргәч, янә бер хәйрани хис кичерделәр: бала гына ич әле! Итчән анысы, әнә, иреннәрен жыя да алмый, йөзе суга салган борчактай бүртенгән, почык борыны күренми дә. Хәер, хикмәт яшьтә түгел, хикмәт башта. Ә бу дәүләттә баш — бәкләрбәге Мамай мырза. Димәк, аңа бала хан кирәк.

Илчеләр үз хакимнәре исеменнән яңа ханга рәсми теләктәшлекләрен белдерделәр дә таралыштылар. Мәҗлескә кадәр вакыт бар, таянып тору да мәслихәт булыр.

Ханны да житәкләп алып чыгып киттеләр. Бүлмәдә Мамай белән Толымбикә икәүдән-икәү генә калды.

— Мөхәммәдкә хан бүреге кигезеп хаталанмадык микән? — дип Толымбикә икеләнүен белдерде, — илчеләр дә сәерсенде, ахры.

— Тәшвишләнмә, — дип тынычландырырга ашыкты Мамай, — Мөхәммәд кануни хан, Үзбәк хан нәселеннән кан дәвамчысы.

— Сигез яшь кенә ич әле...

— Шуңа күрә васый зарур, — дип ялгап китте бәкләрбәге, — хәзер безгә шул хакта уртак фикергә килергә кирәк.

— Үзең инде.

Мамай иреннәрен кысып уйланып торды да әйтте:

— Кануни ханга кануни васый[3] зарур, андый жәнабе гали зат бездә берәү генә. Ул — бөек Үзбәк ханның оныгы, мөхтәрәм Җанибәк ханның кызы, әһле вафа Бирдебәк ханның туганае, шәрәфле дәрәҗә иясе Толымбикә тәнәкә.

Толымбикә керфек тә какмыйча иренә карап бакты.

— Ни әйтәсеңне беләм, ханәкә, шөкер, ныгыдың, элеккедән дә чибәрләндең, ошбу җәһәттән шөбһәләрем бетте.

— Юзекәй мосафирга рәхмәт.

— Әйе, әйе, ләкин, әйдә, ханәкә, сүзнең жебен югалтмыйк әле, мине болай да Алтын Урданы яулап алуда гаеплиләр. Бу буш гайбәтләргә яңа жирлек тудыру үзең утырган ботакка балта чабу белән бер ич. Сиңа ризалык бирүдән башка юл юк. Акчаларың сугыла, ул жепне һич тә өзәргә ярамый. Мөхәммәд хан исеменнән дә сугарбыз. Шулай гаделрәк булыр.

---

[2] Казюла – тау тәкәсе.

[3] Васый – регент, опекун.

***

Мансур угланны ашыгыч рәвештә олуг кенәз катына чакырдылар. Альгирдас һәр гамәлен төптән уйлап, уйлаганын җиз иләк аша үткәрергә күнеккән олпат ил агасы иде. Ашыгу-кабалануны өнәми. Шуның белән бергә, карарын өлгергән дип саный икән, аны инде туктата алмыйсың: кисә-кыра, таптый-изә — барыбер үзенекен эшли.

Күрәсең, хәзер дә шундый халәттә иде олуг кенәз. Чыннан да, ул зур бүлмәсен инләп, ишекле-түрле йөренә иде. Аны дикъкать белән аяк йөзенә кадәр төшеп торган озын кафтанлы, утырма якалы, көрәктәй мул сакаллы боярлар күзәтә. Мәскәү илчеләре икәне әллә каян күренеп тора.

— Менә, углан, кенәз Московский миңа ишарәле бүләк җибәргән: чакма ташы, чакма корычы, янә дә кылыч.

— Балалык ич бу, — диде Мансур, җилкәләрен сикертеп, — кенәз гамәле түгел.

— Бу балалыкның төбендә бик җитди таләпләр ята, углан.

— Ягъни...

— Ягъни кенәз Литвадан Витебск, Полоцк, Киев җирләрен тартып алмакчы. Әгәр ирекле рәвештә ризалык бирмәсәм, Вильнога яу чабып, мине пасха атнасында Ут вә Корыч астыннан үткәрмәкче. Илчеләре аша шуны белдерә.

Көрәк сакаллар бер-берсенә карашып, баскан урыннарда таптанышып алдылар.

— Син нинди карарга килдең, кенәз? — дип сорады Мансур.

— Углан, кенәз Дмитрий аягына киенгәләгәнче мин гаскәремне кузгатырга хәл иттем. Сине көчләмим...

Мансур җиһангирны тыңлап бетермәде, үзе тезеп китте:

— Кенәз, татар өчен яу җан чакыруы, кан коткысы ул. Яу чабуның дуслыкка да, туганлыкка да катнашы юк. Яу барыннан да өстен. Ә антын бозган татар — җир чүбе. Мин синең белән!

— Бу чын углан сүзе, — диде Альгирдас, канәгатьлеген белдереп, — һәр сүзем минем үземә дә кагыла. Кенәз Дмитрий белән без кодалар ич. Кызым Елена аның якын туганы вә таянычы Владимирның хәләл җефете. Әмма, үзең әйтмешли, дәүләти мәнфәгатьләр барыннан да өстен.

Литва явы Рәсәй өстенә көтмәгәндә ябырылды. Альгирдас урыс отрядлары белән кылыч чәкештереп вакыт уздырмады, туры Мәскәүгә юл тотты. Нияте пасхага җитешү иде.

Можайск каласын узгач, ул әлеге утырма якалы урыс илчеләрен чакырып китерде дә әйтте:

— Ошбу кабынулы филтәмне һәм дә язма җавабымны кенәзегезгә тапшырыгыз, — диде, — калганын күзгә-күз җиткерермен.

Хатка түбәндәге җөмләләр теркәлгән иде: «Кенәз, мине Вильнода эзләп йөрү мәшәкатеннән азат итүемне бәяләрсең, дип өметләнәм. Ошбу филтә янып бетәргә өлгергәләгәнче, кызыл йомырка кыстырып, Мәскәүгә мин үзем килеп җитәрмен. Җиһангирлар кичектерүне сөйми, ниятләнгән — эшләнгән!»

Бәлале илчеләр пасха башланган көнне кайтып керделәр. Олуг кенәз якын туганнары һәм даирәсе белән иртәнге гыйбадәткә барырга чыккан иде. Йөзләрендә шатлык балкый, күңелләре тулып ашкан, туктаусыз сәдака өләшәләр. Һәммәсе риза-бәхил.

Мәскәү изге бәйрәм хозурына чумган иде. Башта Дмитрий аңышмый торды. Аннан үзен-үзе белешмичә кычкырып җибәрде.

— Күземнән югалыгыз, бу Альгирдасның усал шаяртуы гына...

— Олуг кенәз, литвалылар калада!

Күзләр Поклон тавы тарафына юнәлде. Офыкта — яз кояшы. Ул әле бәллүеннән күтәрелеп кенә килә, шулай да нурлары инде бөтен җиһанны биләп алырга өлгергән. Якты, җылы, иркен...

Һәм шушы илаһи матурлыкка кара бизәк булып кунган атлы гаскәриләр өере. Кыр чирүедәй ишле, Поклонны чебен урынына сарганнар.

Дмитрий читкә тайпылды. Башына килгән беренче уй — качып китү, кайдадыр яшеренү иде.

Бояр Мстиславский аркылы төште.

— Олуг кенәз, Альгирдасны Кремльдә каршы алу отышлырак булыр, корал күтәрүнең дә, яшеренүнең дә мәгънәсе калмады, мәсхәрәгә генә калырсың, — диде.

Альгирдас Кремльгә дөп-дөп басып, җиңүчеләргә хас дуамаллык вә тупаслык белән килеп керде. Керде дә сөңгесен стенага очыртты. Шунда ук стенаның карга оясыдай зур бер кисәге идәнгә ишелде.

Дмитрий артына ава язды, таш кисәге түгел, гүя йөрәге өзелеп төште.

Ярдәмчесе Альгирдаска кызыл төскә буялган йомырка китерде.

— Кенәз, вәгъдәмне үтәдем, менә сиңа пасха йомыркасы, үземнең алдымда авыз ит! — дип, Альгирдас аны олуг кенәз кулына тоттырды.

Мәшһүр литувяйның калын тавышы Кремль диварларында кайтаваз булып яңгырады.

— Кенәзгә шәраб бирегез! — диде ул, — тамагына күкәй утырмасын.

Дмитрий бу хурлыкны да йомырка сарысы белән бергә йотып җибәрде.

Альгирдасның йөзендә зәһәрлек катыш тәкәбберлек дулкыннары уйнаша. Мәскәү башлыгын кимсетүдән ул ләззәт таба, сүрелмәс канәгатьлек ала иде булса кирәк.

— Минем бер угланым синең ун воеводаңа бәрабәр, — дип, инде Мансурны түргә тартып чыгарды, — аның зөлфәкар кылычы бихисап дошманнарының умырткасын икегә ярды. Әле тагын ярачак!

Дусларның күзләре очрашты. Дмитрий чарасызлыктан тәмам алҗыган, карашы сүнәр-сүнмәс учак күмерен хәтерләтә иде. Үзе түгәрәкләнебрәк киткән, итләчләнгән. Шуңа күрәдер, мөгаен, болай да таманча буй-сыны җиргә үк сеңеп беткән.

— Мин хәзер Бөек Литваның олуг кенәзе Альгирдас җиһангиргә антлы, — дип, Мансур хәл-хәлатен ирештерүне кирәк тапты, — мине антым йөртә.

— Алтын Урда белән мөнәсәбәтләребезнең кискенләшә баруын да шәхсән миңа гына сылтау урынлы булмас, олуг кенәз вазифасы шуна этәрә, — дип, Дмитрий да үз чиратында Мамай бәк алдында аклануын белдерде.

Аны бу минутта бөтенләй башка нәрсә борчый иде. Бу — әсирлек. Ул теләсә-нинди кабалалы ташламаларга да барырга риза, бары әсирлектән генә котылсын. Бер көнлек әсирлек тә олуг кенәз дәрәҗәсенә зур зыян китерәчәк.

— Олуг кенәз, мин солых сорыйм, җиңелүемне таныйм, — диде ул ашыгычлык белән, — ризалыгыңны бирерсең дип ышанам.

Альгирдасның кыяфәте үзгәрде, йөзенә гадәти акыллы җитдилек кайтты.

— Мәңгелеккә дип килешенгән солыхларыбызның да хикмәте булмады бит, кенәз.

Залдагылар җиңел сулап куйды, чөнки җиһангир юк дип өзмәде, сөйләшүгә урын калдырды.

— Алайса, әүвәл өч айга килешик, аннан күз күрер, — диде Дмитрий.

— Минекеләр күп ганимәт таләп итәчәк.

— Алдан ук ризалыгымны бирәм.

***

Варвара әллә кайдан килгән татар угланының куенына керергә һич тә атлыгып тормый иде. Әле чын-чынлап сөеп караганы да юк. Мәхәббәт дигән серле вә тылсымлы хис нигәдер аны урап уза. Уналты яшьлек кызның капкасын ул күптән кагарга тиеш иде инде. Югыйсә тирәсендә күпме кавалер бөтерелә. Бәлкем, ишлелек комачаулыйдыр? Хәер, татар угланы бу төркемне дә таратуга иреште, хәерсез. Ин лаеклы кияү егетләре саналган затлы ыру вәкиләре Витаутас белән Ягеллоны бер кизәнүдә юлыннан алып ташлады. Бәйгедә өстен чыккан, имеш. Һәр икесе дә хәзер читтән генә баш иеп, сәламләп уза. Бу аны хафага сала. Шул ук вакытта, угланның үҗәтлеген, тәвәккәллеген ошата да. Җебек кешене аның җене сөйми:егет булса — ут булсын, ут булмаса — юк булсын.

Княгиняларның тәкъдир каләме язмыш иясендә түгел шул. Варварага да сайлау мөмкинлеге куймадылар. Олуг кенәз үзе яучы булып килде. Атасына түгел, турыдан-туры үзенә мөрәҗәгать итте.

— Мин, хөрмәтле княгиня, сине затлы нәсел-нәсәпле, бик шәрәфле Мансур угланга димләргә килдем, — диде, кыз алдына башын иеп, — әле генә Мәскәүне тезләндереп, күп байлыклар белән яудан кайттык. Үзен хак каһарман итеп күрсәтте. Ул — минем уң кулым, дәүләтебезгә кирәкле воевода. Мәһәре дә мулдан булыр.

— Олуг кенәз туй бүләге сыйфатында Полтава һәм Черкас төбәкләрендә ике зур биләмә тәгаенлый, — дип шатлыгын уртаклашырга ашыкты атасы кенәз Гавриил. Күренеп тора, ул ризалыгын биргән иде инде. Әлеге сөйләшү фәкать дәрәҗәле кәләшкә ихтирам билгесе генә иде. Варвара моны шундук аңлап алды.

Күр, бу карт төлкеләрне, биләмә белән юмаламакчылар. Булдыклы воевода, имеш. Хатын-кызның хыялында исә биләмәләр дә түгел, воеводалар да түгел, гомергә терәк булырдай ышанычлы, яраткан затында гыйшык уты дөрләтергә сәләтле азамат егет солтаны яшәгәнен белмиләр шул алар.

— Мөхтәрәм олуг кенәз, — диде кыз үзенә бер нәзакәтле итагатьлелек белән, — сездәй бөек җиһангирның яучы булып килүе минем өчен бик зур мәртәбә, рәхмәтем чиксез, тик әлегә бу тәкъдим генә бит, шулаймы?

— Кызым, сүз көрәштермә, олуг кенәзнең һәр сүзе боерык, — дип арага керде ата кеше.

Кызның тәвәккәллеген, киресенчә, Альгирдас ошатты.

— Кенәз, княгиняларның хокукларын кысма, — дип Гавриилга бармак янады. — Ни әйтмәкче иден, княгиня, тыңлыйм.

— Мансур углан үзе кая соң, тәкъдим әүвәл аның авызыннан чыгарга тиеш иде дип саныйм мин, — диде Варвара, — бәлки ул таләпләрем-шартларым белән танышкач, ниятеннән ваз кичәр.

Альгирдас кызның аркасыннан сыйпап алды.

— Сиңа ир-ат булып туасы калган, княгиня, дәүләт тотардай зирәклек үзеңдә.

— Йоласы шулай, кызым, — дип янә Гавриил сүз кыстырды, — кара халык кына аралашып никахлаша. Сайланган кыз утырып та кала ул.

— Хак, — диде Альгирдас көлемсерәп. —Ләкин безнең чибәркәйгә андый язмыш янамый. Мансур углан бәхет кошын кулыннан ычкындыра торганнардан түгел. Тәкъдимен дә ясар, сүзен дә әйтер. Әнә, килеп тә житте.

Дөрестән дә ишектә Мансур күренде. Күрше бүлмәдә яучысының ым кагуын гына көтеп торгандыр, ахры.

Мансур йөгерә-атлый Варвараның алдына килеп тезләнде дә:

— Княгиня, мин синең өчен утка да, суга да керергә әзер, — диде.

Кыз моны ук көтмәгән иде, бер генә мизгелгә югалып калды. Шулай булмыйча, татарларның кыргый дигән яманаты таралган лабаса. Ә ул, күр, аурупалыларны да уздырды. Килеш-килбәте дә ким-хур түгел. Гәүдәсе тыгыз, җилкәләре киң. Маңгаендагы ярасы аны тагын да күркәмрәк итә. Бу – баһадирлык билгесе. Олуг кенәз дә юкка гына мактамыйдыр...

– Хөрмәт иясе княгиня Варвара Гаврииловна, олуг кенәз Альгирдас галиҗәнаплары безнең никахка хәер-фатихасын бирде, – дип дәвам итте егет, – шулай ук атаең мөхтәрәм Гавриил кенәздән дә ризалыгын алдым. Чык мина кияүгә, Варвара Гаврииловна, ышанычлы вә тәпле ирең булырмын, кадер-хөрмәттә генә яшәрсең.

Варвара як-якка күз төшерде. Баксаң, бүлмәдә алар икәүдән-икәү генә торып калганнар икән ич. Менә монысы – дөрес! Аның элекке тынычлыгы белән бергә, табигый тәкәбберлеге дә кайтты.

– Углан, мин сезгә кәнәфигә утырырга рөхсәт итәм, – дип, үзе яныннан урын күрсәтте, – сүз озынга китәргә охшап тора.

Мансур кызның киң җиңе эченнән кош теледәй генә күренеп куйган ак нәфис кулын шәйләп алды. Ул шундый ымсындыргыч, шундый нәфис иде ки, мизгел эчендә барча күзәнәкләре ләззәт белән тулышты.

Варвара моны сизмәде, ул кияү егетенә пәрәвез кору белән мәшгуль иде.

– К-княгиня, җавапны кайчанрак көтәргә мөмкин? – дип сорады Мансур, әсәрләнүеннән арына төшеп.

Варвараның керфекләренә кылтаюлы наян елмаю эленде. Ул егетнең теле көрмәкләнүдән чын канәгатьлек таба иде, күрәсең.

– Углан, әле соң түгел, бу җилбәзәк уйларыгыздан кире кайта аласыз, мин искиткеч дәрәҗәдә киребеткән эгоист зат, тормышыгыз тормыш булмаячак, үкенергә туры килер, – дип, ул киеренкелекне тагын да куертарак төште.

Бу сүзләр Мансурның баш өстеннән генә очып узды. Чөнки ул кәләшенең үзенә мөкиббән: сөттәй пакь ак битенә, кош канатларыдай кыйгачланып сызылган нәзек кашларына, кабарынкы татлы иреннәренә, былбыл томшыгыдай кечкенә күркәм борынына, моң тудыручы серле озын бармакларына...

– Углан, сез мине тыңламыйсыз да, ахры, сөйлим-сөйлим...

Варвара иреннәрен турсайтып, сылу гәүдәсен кәнәфинең эченәрәк шудырды. Үпкәле халәттә ул тагын да сөйкемлерәк иде. Мансурның ирексездән күзе йомылды.

– Углан!

– Мин барысына да риза, – диде Мансур, ниһаять, – риза!

– Әле мин никахка мөнәсәбәтле фикерләремне әйтмәдем ич.

– Әйт син, ягъни дә әйтегез...

Кыз башын артка чөеп, көлеп җибәрде. Аның көлүе егеткә челтер-челтер аккан чишмә челтерәве булып ишетелде.

– Тыңлагыз, алайса, никахлашкан очракта да мин христиан динендә калачакмын. Сез үз динегездә, мин үз динемдә. Җә?

– Мин риза...

– Бүлдермәгез, әйтеп бетергәнне көтегез.

– Көтәм.

– Балаларыбызны да чиркәүдә чукындырабыз. Улыбыз анаем, мәрхүм княгиня Ксениянең мәшһүр бабасы Глинка исемен йөртәчәк.

– Кан бит минеке була, княгиня, Кыят ыруы каны, – дип уянып китте Мансур.

– Әйе, кан сезнеке, ә ыру Глинскийлар булып дәвам итәчәк.

– Җә, хуш...

– Янә дә иң мөһиме, гаилә өчен мәхәббәт зарур. Сездә бу хис бармы?

Мансур карчыгадан калган тавык хәленә төште.

Бу халәтне биш йөз елдан соң татар шагыйре болай тасвирлаячак:

Яртым яна, яртым туңа,
Яртым үлде яртылаш.

Моның сәбәбе бик гади иде: ул княгиня авыз суларын корытып әйткән әлеге тылсымлы хиснең ни-нәрсә икәнен белми. Тик шунысы көн кебек ачык, әгәр Варвара юк дигән нәтиҗә чыгара икән, димәк кавышу да юк дигән сүз. Бу инде — фаҗига.

Кызның күзләре тегәрҗеп калынлыгында гына калып кысылган, җавап көтә.

– Княгиня, мин тугрылыкка ант эчкән җиһангирымның хакын хаклап, гомеремне өзәргә дә әзер; дәһшәтле яуда кулдаш кылычташымны үземә караганда да ныграк саклыйм; анаем Толымбикә ханәкәгә тел тидергән адәм минем мәңгелек дошманым, әмма мәхәббәт нәрсә ул – белмим. Дала башка камырдан укмашкан, күрәсең. Атаем Мамай мырза мине илем өчен илсенеп, җирем өчен җилпенеп яшәргә өйрәтте. Хәзерендә болар барысы да күләгәдә калды. Ник дисәң, мин үз иркем белән туган-үскән җиремне синең җиргә алыштырдым.

Онытканчы шунысын да әйтим, әйе, мин мөселман өммәтеннән, тик тәкъвә түгелмен. Ислам бездә җәелеп кенә килә әле, монда исә, күрүемчә, дин инде шактый нык тамыр җибәргән. Тагын...

– Мансур (кыз беренче тапкыр аңа исеме белән дәште), минем мангаендагы җөйне сыйпап карыйсым килә, – дип, Варвара аның фәлсәфи нотыгын бүлде, – ул җөй мине нигәдер дулкынландыра...

***

Урдага Мансурдан атчабар килде. Шатлыгы белән уртаклашкан. Беренчеләре туган икән.

– Менә оныклы да булдың, – дип шаяртты Толымбикә, – урының түр башында, утыр шунда сакалыңны селкетеп.

Яшь бабайның авызы колагында.

– Малай алып кайткан киленебез. Варис! Кыят ыруы янә бер баһадирлы булды, Афәрин!

– Кыятын – кыят, исеме генә Глинка.

– Ничек Глинка?

Толымбикә ялгышын төзәтергә ашыкты.

– Мамуч, сырт йонынны кабартма, хикмәт исемдә түгел, хикмәт – канда!

Мамайның ризасызлыгы үтенә үк үтеп кергән иде инде, бу җимгә алданмады.

– Хатын олтанына әйләнгән икән Мансур, мәсхәрә, валлаһи!

Толымбикә үзе дә сөенеч кичерми иде, йөрәге чеметеп-чеметеп куя. Чит милләттән килен төшерү гаеп түгел анысы, андыйлар аксөякләр арасында да, кара халык арасында да аз түгел. Ләкин ул белгән һәммә киленнәр дә ирләренең диненә күчте, шуна тин рәвештә исем-атларын алыштырды. Аралашу да ир сөйләшкән телдә бара.

Мансурның хәле, билгеле, башкачарак. Ул хәләл җефете җирендә, чит мәмләкәттә. Бу инде йортка керү белән бер, кеше җырын җырларга мәҗбүрсең. Тик Мансур күренекле шәхес, танылган углан, дәүләт әһеле.

Җәмгыятьтә тоткан урыны гаилә мәнфәгатьләреннән күпкә югары. Монда икенең берсе: җә, Литвада хатын-кыз сүзе алдан йөри, җә, Мансур үз гыйшкына үзе әсир төшкән, мәхәббәт колына әйләнгән. Гашыйк зат — сукыр зат, дип юкка гына әйтмәгәннәрдер, мөгаен.

Хәзер соң инде, буласы булган, аткан ук кире кайтмый.

— Мамуч, бу безнең тәүге оныгыбыз, — диде Толымбикә, — бу Урда өчен дә зур шатлык. Хәзер шул хөрмәткә гомуми тантана үткәрү хәстәрен күрә башларга кирәк, минемчә. Тузынуның да, үпкәнең дә мәгънәсе юк.

Мамай йөрүеннән тукталып, әнәле карашы белән хатынына текәлде.

Толымбикә моны уенга бормак булды (киеренкелекне йомшарта, янәсе): «Матурмы хатының? — дип гәүдәсен уйнаклагандай итенде, — Генуя түткәләренә торырлыгым бар әле, шөкер».

Бу Мамайның Италия сәүдәгәрләре белән мәҗлес коруларына ишарәләп, чеметеп алуы иде. Ләкин угы төзәгән җиргә тимәде.

— Ханәкә, зинһар, мине тилегә санама, мин Мансурны үземә кирәк булсынга үстердем, түгел орыш хәлләрен хатыныннан ишетеп яшәргә. Хатын да үзе язмаган бит, сансыз.

— Алай бәхәскә киткәч, ачыктан-ачык сөйләшик, — диде Толымбикә, — алай зур өметләр баглагач, нигә улыңны Литвада калдырып кайттың соң?

Бу юлы ханәкәнең угы нәкъ төзәгән урынына килеп кадалды.

Мамай җавап эзләп, өнсез калды. Ике мәмләкәт арасында дуслык элемтәләрен ныгыту өчен дисә, беркадәр хаклыкка туры килә-килүен, тик ике арадагы мөнәсәбәтләрне улы бәрабәренә көйләргә омтылган атай нинди атай була инде ул? Дөресендә, Мансур кырт торды. Бу да аның файдасына түгел. Нишләп малаеңа койрык булдың, диячәк.

— Баланың эт күлмәген монда салдырсыннар! — диде, чигенүен бөер тавышы белән капларга тырышып, — кырыклама бәйрәмен Урдада уздырырбыз.

— Җүләрем, — дип көлемсерәде Толымбикә, — христианнарда нарасыйга эт күлмәге кигертмиләр, аннан ары монда килгәләгәнче оныгыбыз инде үчтеки итәрлек булыр.

— Дөрес әйтәсең, ул якларга түләмә котыра, юл арчыганчы шактый вакыт узар.

***

Варвара килгән көнне үк каенатасының да, каенанасының да һушын алды. Югыйсә күрешү-очрашу мизгелләре икесенең дә күңеленә май кебек яткан иде. Киленнең дала ханымнарыннан үзгә ак матурлыгы, мәһабәт буй-сыны, озын, төз аяклары ифрат та килешле вә дәхи карап кына тормалы иде. Шуңа күрә Мансурның, бизмән герәдәй, хатынына тагылып йөрүенә дә артык исләре китмәде. Тәтәй әйбер шулай кызыктыргыч була инде ул дип үзләрен юаттылар.

Киленнең берниндн ятсынусыз чишелеп сөйләшүе дә әйбәт тәэсир уятты. Ул аларны якын итеп, күрешкәндә үк «папа», «мама» дип кочаклап алды. Түбәләре күккә тиде.

— Папа, ошбу сәяхәткә чыгар алдыннан мин татарларның гореф-гадәтләре турында шактый гына мәгълүмат җыйдым, — диде Варвара, табынга утыргач, — менә бу чүмәләдәй өелгән ит калҗаларын күргәч, шуларның берсе хәтергә төште. Гарәп илчесе Ибне Фадлан түбәндәгеләрне теркәп калдырган: «Ханның соравы буенча, алдына табын хәзер кылынды. Анда куырылган ит бар иде. Хан аннан өч мәртәбә кисеп алып, берсе артыннан берсен ашап, янадан бер кисәк кисеп Сәмсән эр-Расибигә бирде. Шулай һәркем алдына

бер табын ясалды. Гадәт-йолалары шулай икән, һичкем патша авыз итмичә торып ашка кулын сузмый. Һәркайсыбыз үз табыныбыздан үзенә ашап, калган өлешебезне өйләребезгә алып кайттык».

– Афәрин, княгиня, гыйлемең белән дә сөендердең. Йолаларга байлыгыбыз бар, шөкер. Әйтик, «Барымта карулы, сый сатулы» дигән борынгы йолабыз да онытылып бетмәде әле.

– Ah! Папа, бу бик кызыклы, сөйләгез, зинһар.

– Бик рәхәтләнеп, – диде Мамай, – Барымта кучмә кабиләләрнең берсе өстенә икенчесе талау өчен һөҗүмгә барып, терлек-малларны әйдәп алып китүен аңлата. Таланган кабилә бер көнне үзе җавап һөҗүме ясый, ягъни. Кару кайтара. Күрәсең, безнең ата-бабаларыбыз эшләп ашаган. Ә сиңа, яраткан киленемә, тәүге калҗаны бирәм. Иң симез, иң майлы җирен. Кабуга эреп китәр.

Варвара күзе белән өлеш тәлинкәсе эзләде.

– Килен, бездә итне кулга тотып ашыйлар, – дип Толымбикә ярдәмгә ашыкты.

– Рәхмәт, мама, без үз ризыкларыбыз белән генә тукланабыз, – диде Варвара, көләч йөзен балкытып, – ә сез житешегез-житеш, безгә карамагыз.

Өлгер килен алдан хәстәрен күреп куйган иде, аш-суы да әзер, савыт-сабасы да, кашык-чәнечкеләре дә. Лакей егет шундук Варвара белән Мансур алдына бәллүр тәлинкәләргә салынган яшелчә салаты, кабыклы килеш пешерелгән ике йомырка куйды, кашык, пычак, чәнечкеише приборлар урнаштырды.

Мамай бу тамашага карап-карап торды да зәһәрләнеп идәнгә төкерде. Яңак җепселләре биешеп алды, тешләре кысылды. Нииндидер усал сүз әйтергә теләп, авызын ачмак итенсә дә, теле аны тыңламады.

Һуш алыну шушы инде ул.

Менә шартлыйм, менә шартлыйм дип торган бу куркыныч әчке киеренкелек ялкынын Варвара үзе сүндерде. Юк, белеп-сизенеп түгел, дөресен генә әйткәндә, әлеге киеренкелекнең укмашуын ул гомумән тоймады, чөнки гадәти тормыш рәвеше шундый, ошыймы ул кемгәдер, ошамыймы – бу аны кызыксындырмый.

– Һо, папа, мама, нинди затлы Италия шәрабе, рәхмәт, бу минем күптәнге хыялым, – дип тәтелди-тәтелди бүксәле кара шешәне кулында әйләндергәләде. – Мансур, бокалларга үзең агыз, синең кулың татлы.

Мансур болай да кыенсыныбрак утыра иде, җәт кенә бокалларга шәраб койды.

– Папа, мама, сезнең исәнлегегез өчен, мин сезне бик яратам, озак еллар безне шатландырып яшәргә язсын.

Варваранын тосты ачу-үпкәләрне юып төшерде.

Шәраб тәннәрне кыздырып, тамырларны киңәйтеп җибәрде. Телләр ачылды. Мансур Альгирдас белән Мәскәүгә яу чабулары турында сөйләде. Кремльгә басып керүләре, Дмитрий белән очрашуларын бәян итте.

– Кансызлар, шулкадәр рәнҗетмәсәгез булмый идемени? – диде Толымбикә, – бергә уйнап үстегез ләбаса.

– Анаем, Дмитрий – Мәскәү кенәзе, аның үз мәнфәгатьләре, – диде Мансур, – яуда җә син җиңәсең, җә сине җиңәләр. Башкача була алмый.

– Мәскәү кенәзенә кылыч астында пасха йомыркасы ашатканнары өчен Мансурга кияүгә чыгарга ризалык бирдем дә инде, – дип, Варвара ирен үбеп алды, – ул инде хәзер минеке. Фәкать минеке генә! Рәхмәт, улыгызны чын каһарман, чын азамат ир итеп тәрбияләгәнсез. Без кенәз Глинканы да шул рухта үстерәбез...

— Шуна күрә суда тончыктырасыз икән, — диде Толымбикә каенаналарга хас чәпчү белән, — күргәч, өнсез калдым.

— Ни хакта сүз? — дип белеште Мамай.

— Папа, без бит дингез ягы кешеләре, — дип, әңгәмә тезгенен Варвара янә үз кулына алды, — утта янмаган, суда батмаган углан чын рыцарь булып җитешә алмый. Шуна күрә унбиш көннән Глинканы ялгашка салдык.

— Батмас өчен җан тырмаша, бәбкәем, — диде Толымбикә, яшьле күзләрен корыта-корыта, — юл тузанын каккалаганчы баланы суга салдылар.

— Мама, режимы шулай анын.

— Ә мин бу гамәлегезне тулысынча хуплыйм, — диде Мамай, канәгать елмаю белән, — гафу, княгиня, башта җилбәзәк булып күренгән иден, юк икән, фикеремне үзгәрттем.

— Минем менә, киресенчә, сина дәгъва белдерәсем килә, папа, — диде Варвара, уены-чыны белән, — монарчы Мансур ни сәбәпле теләсә-кайда төкеренә икән дип баш вата идем, баксаң, синең арттан куа икән ич. Бәкләрбәгенең идәнгә төкеренүе минем башка сыймый.

— Дала кешесе кайда ни тели, шунда шуны эшли, княгиня, аннан китереп, төкерек ул — яугирнең дәвасы. Яра-җәрәхәтләрне бәвел белән төкерек ала.

— Ә мышнау?

— Татар атын куәтләп мышный, яуда бу бик мөһим.

— Княгиня, Мансурга биш-алты кат камзул кидерсән дә аннан литувяй ясый алмассың, ул барыбер татар булып калыр, — дип сүзгә кушылды Толымбикә, — кәкре турыны төзәтми, кияүгә чыкканда болар хакында да уйлагандырсың, шәт.

— Бу Варвара белән мина гына кагыла, әйдәгез, тирәнгә кермик, — диде Мансур, — сүз беткәнмени?

— Дөрес, — дип элеп алды Толымбикә, — мине, шәхсән, оныгыбыз мәсьәләсе борчый, балага мәрхәмәтлерәк булырга кирәк.

— Мама, бу бит бик яхшы, — диде Варвара, — менә папаны гына ал, ул Алтын Урда дигән дәһшәтле дәүләтне үз кулында тота, аңа ханнар баш ия, аның белән бөтен дөнья исәпләшә, аннан куркалар, хөрмәт итәләр. Глинка да турыдан-туры тәхеткә утыра алмый, чөнки чыңгызыйлардан түгел. Әмма бабасы үрнәге барча үрнәкләргә дә үрнәк. Мамай оныгы күләгәдә калмас. Алай гынамы, Глинканың офыклары күпкә киңрәк. Бөек Литва абруе да аңа киң юл ача.

Бу сөйләшү-бәхәсләрнең, бу фаразларның баш каһарманы Глинка мырза үзе әлегә битарафлык саклый. Анын үз дөньясы, үз шөгыльләре. Әнә, нәнәсе кече хаҗәтен үтәсен дип озак кына чүлмәк өстендә тотты. Юк, исе китмәде. Иплән урынына яткырган гына иде, чаптырып та җибәрде, караучысының битен, ирендәрен чылатты. Булдырдым, дип уйлады, ахры, авызын тутырып көлеп тә җибәрде.

— У-гу-гу-, у-гу-гу...

— Бу һич тә рыцарьлык түгел инде, кенәз, — дип сөйләнә-сөйләнә нәнә астын алыштырырга керешге, — көлүең әйбәт анысы, бала кешегә йомык авызлык килешми. Андыйлар усал булып үсә. Ә мин синең мәрхәмәтле, шат күңелле булуыңны телим.

Глинка кашын җыерырга гына тора, тибенергә маһир. Үзсүзле, киреләнеп еларга тотынса, тамагы карлыкканчы елый.

— Исеменә иркәле, сөйкемле сүзләр өстәп мөрәҗәгать итсәм, бәлки болай тузынмас та идең инде, кенәз, — дип юата нәнә, — әйтик, Алексей булсаң, Саша, Сашенка, Сашуля дияр идем, Глинканы ничек йомшартырга да белмим. Икенче яктан, Ходай сине атаең сыман баһадир зат итеп

яртакан. Күр инде, туп шикелле тупылдап торасың бит. Күз тимәсен. Сиңа ул «Сашулялар» килешмәс тә иде әле. Глинка воевода — менә монысы суйган да каплаган.

Глинка Мансурович шулай итеп җир биләүче статусына лаек булды: хан вазифасын башкаручы васия әбисе Толымбикә ханбикә белән бабасы, бәкләрбәге Мамай гурген имзалары төшкән Таныклык алды. Биләмәсе Солхат төбәгендә. Рәсми аты Солхат мырза.

— Дингездән еракмы биләмә? — дип белеште княгиня.

— Биләмәнең чиге диңгезгә тоташа.

Мансур ата-анасын берьюлы киң күкрәгенә кысты.

— Ә кайчан күрәбез? — диде килен түземсезләнеп.

— Кайтышлый сугылып, бер-ике атна яшәп, танышып китәрсез, — диде Мамай, — анда барысы да әзер.

— Папа, йөзләгән бүләк мал-туар да бар ич әле, без аларны Литвага куа алмыйбыз бит инде, — дип, Варвара янә үз мәнфәгатен алга сөрде, — акчага әйләндерү кулайрак булыр, минемчә.

Мансур хатынының чама хисен югалтып җибәрүен уенга бормак итеп, көлә-көлә бер мәзәк сөйләп алды.

— Берәүгә безнең шикелле ишле кунак килгән ди. Хуҗа бик зур кадер-хөрмәт күрсәткән. Өч көн, дүрт көн сыйланганнар болар, һич китәр исәпләрне күренми ди. Хуҗа ишарәт белән:

— Арбагызны майлыйммы әллә? — дип сораган. Тегеләр ләм-мим.

Тагын бер көн үтеп, икенчесе тугач, хуҗа түзмәгән, әйткән:

— Җә, җәмәгать, мин сезне дүрт көн дә, биш көн дә кунак иттем, үзегез белеп китмисез, бу ни хәл? — дигән.

Олы кунак кырын яткан җиреннән генә әйткән:

— Әй, тәрбиясез адәм! Кая синең күңел-хәтер таба белүең? Кунаклар кирәк икән, биш көн, кирәк икән, ун көн дә ятар...

Шул әдәпсез кунаклар хәленә калмасак иде, Варвара...

Көтмәгәндә Мамай килен ягына авышты.

— Княгиня, ул мал-туарны бик теләсәгез дә Литвага куа алмыйсыз, — диде, — ник дисәң, түләмә афәтенең кызган чагы. Бүләк бирүчеләргә гозеренне житкерермен. Тик сәмән булсынга башта аларны сатарга кирәк бит әле. Чир вакытында һәр төрле багланышлар тыела. Шуңа күрә бераз көтәргә туры килер. Шикләнмә, барысын да син кушканча эшләрбез.

Варвара башын борып, иренә телен күрсәтте.

Варвараның житез вә зирәк акылы алдагы гамәлгә күчеп өлгергән иде инде.

— Папа, ак дөя мәсьәләсе ни хәлдә? — дип, Мамайга текәлде.

Каената урта бармагын иренена тигезеп алды.

Һай, кыланышлары, дип эчтән генә елмайгандай итте Толымбикә.

Алдагы гамәл дигәнебез, Кыят ыруының төпчек вәкиле Глинка мырзаны халыкка тәкъдим итүгә бәйле иде. Бу — ике атна дәвам иткән бәйрәм тантанасының таҗы.

Тантана йола буенча ата кешенең улын алдына утыртып, асыл ташлар сибелгән дирбияле ат өстендә җыен әйләнүе белән башлана.

Соңгы чиктә генә Варвара кәҗәләмәсенме.

— Мин улым янында булырга тиеш, — дип кырт кисте.

— Син атка атланмыйсың бит, — диде Мансур.

— Минем көймәле арбам бар.

— Арба чыгарып, адәм көлдермибез, — диде Мамай, — минем оныгым шәрәфле ыру вәкиле.

— Ярар сон, — диде Варвара үпкәле тавыш белән, — Глинка өчен бу яхшы гына, тынычлап йоклар...

— Ат кына димәгән, дөя үркәченә зур бишек элərгә дә мөмкин иң, — диде Толымбикә, — анда бик иркенләп биш-алты кеше сыя.

— Браво, мама, — дип кулларын чәбәкләде Варвара, — браво, ак дөя, кызыл бишек, сары япма.

Каената белән килен каш астыннан гына бер-берсенә карашып алдылар.

— Заговор удался, — дип пышылдады Варвара.

Куанышыгыз инде, хәчтерүшләр, миннән булсын яхшылык, дип Толымбикә эчтән генә елмаеп куйды.

Варвара нәнә туташны читкәрәк чакырып алды да, пышылдап кына нindидер күрсәтмә бирде.

— Бәк, мин өстемне алыштырам, бераз гына көтәргә туры килер, — дип, үз катына кереп китте.

Күкне ярып быргылар тавышы яңгырады. Аларга шунда ук аерым көч вә үҗәтлек белән төрледән-төрле дөбертек барабаннар килеп кушылды. Җиһан тантанага төренде. Аның төп бизәге ике үркәчле бинһая зур ак дөя иде. Асылма бишектә — Мансур мырза, княгиня Варвара һәм тантана-бәйрәмнең каһарманы Глинка мырза. Кече мырза әлегә үзенең бала бишегендә юанып ята. Урыны жайлы, уңайлы. Нәнәсе бишеген әнә ничек оста томалаган. Өрфә чыбылдык кояштан да саклый, җиләслек тә биреп тора.

Халык дәррәү күтәрелде. Мәйдан мизгел эчендә тоташ ташкынга әверелде. Сәламләүләр, котлаулар, мәдхия...

— Гали мырзага дан!

Глинка дигән ят һәм сәер сүзгә күнекмәгән авызларга «Гали» менә дигән җим булды. Мәйдан аны бертавыштан күтәреп алды да, бәйрәм тәгәлләнгәнче авызыннан төшермәде.

— Гали! Гали! Гали!

— Глинканы кешеләргә күрсәтер вакыт житте, — диде Мансур, — чиш чыбылдыкны.

Варвара башын гына чайкады.

— Без монда шуның өчен чыктык!

Халык ашыктыра.

— Гали! Гали! Гали!

Мансур чарасызлыктан нишләргә белмичә итәк астыннан гына хатынның ботыннан умырып тотып алды.

— Чиш чыбылдыкны!

— Анда бала юк!

— Ничек? Нигә?

— Нигә, нигә, татарларның күзе каты, менә нигә, ә улыбыз миңа бик кадерле, юкка ярсыма, ботымны күгәртсәң, кара аны, — диде Варвара тыныч кына.

— Гали! Гали! Гали!

Мансур хатынын читкә этеп җибәрде дә, курчак салынган бала бишеген баш очына күтәрде.

Мәйдан алкыш эчендә калды.

— Гали! Гали! Гали!

Варвара ничек кенә сак кыланмасын, бу кырын эш барыбер тишелеп чыкты. Ханәкәнең йомышчы гасәбәсе княгиня катыннан узышлый елаган бала тавышына тап булган. Хәйранга төшә туташ: яшь мырза мәйданда лабаса!

Түзми, ишек япмасының бер очын күтәреп карый бу. Ә анда, җә, Ходай, литувяй нәнә мырзаны күкрәгенә кысып, ишекле-түрле йөри, юата булса кирәк.

Гасәбә бу хәлне ханәкәгә җиткерде.

— Телеңне тешләргә антыңны бир, туташ, бу икебез арасында гына калырга тиешле сер, — дип кисәтте гасәбәсен Толымбикә, — үзем дә авызыма су кабам.

Толымбикә шул рәвешле бу күңелсез вакыйганы йолып калды. Аны ачу сүз-гайбәттән башка бернинди дә файда китермәячәк иде. Дүрт аяклы ат та абына, яшь чакта кем генә дуамаллык эшләмәгән дә, кем генә хәйләгә бармаган.

Яшьләрнең инде китәр вакыты да җитте. Кызганыч, вакыт тәгәрмәче тиз тәгәри шул, сизелми дә көн артыннан көн үтә, бер-бер артлы атналар, айлар алышына.

Киленен ошатты ул. Җилбәзәк. Анысы хак. Кыланчык. Монысы да хак. Иркә. Дәртчән... Тик болар бит чибәр, назлы, һавалы җефетләргә хас сыйфатлар. Андыйлар анадан туганда ук мәхәббәткә уралып туа. Ә мәхәббәт өер ул, гарасат. Гарасат эчендә ни булмас дисең? Яшәеш исә үзгәрәк кануннарга нигезләнә. Ул кануннарның башында — акыл. Адәмне тормыш дәрьясында акыл батырмыйча тота да инде. Мәхәббәтнең гомере кыска, акыл — гомерлек.

Ни гаҗәп, Варварада акыл да мулдан иде. Хушлашу мәҗлесендә янә таң калдырды.

Бәрә тәртәгә, тия чәркәгә, кыр инешедәй салмак кына аккан әңгәмәне урталай бүлеп, Мамайга бакты да:

— Папа, миңа хан ярлыгы кирәк, — диде.

Тагын нинди мөгез чыгара инде бу дигәндәй булмәдәгеләр бер-берсенә карашып куйдылар.

— Миңа хан ярлыгы кирәк, — дип тәфсилләбрәк кабатлады княгиня.

— Ни-нәмә, ниткән ярлык?

— Кисәк кенә үзебезнең Полтава һәм Черкас өлкәләрендә Урданың рәсми вәкиллеген ачу уе башыма сукты, папа, — диде Варвара кош тоткандай сөенеп. — Бу бит ачышка тиң табыш! Здорово, иеме. Аурупага тәрәзә! Менә нинди уңган сезнең киленегез, уч төбендә генә йөртерлек. Вәкиллек Аурупа белән икътисади һәм сәүдә мөнәсәбәтләрен җайга салачак.

Мамай авызын ачып катып калды.

— Яхшылыкка — яхшылык, папа, мин моны Солхат бәрабәренә эшлим.

— Вильнода бар безнең андый вәкиллек, ничектер тулы куәтенә эшләп кенә китә алмый, — диде бәк ниһаять.

— Олуг кенәз Альгирдас ул яу чабуны гына белә. Гомумән, сез, иратлар, орыш камырыннан изелгән. Бүгенге көн белән яшисез. Сугыш ул кансызлык, яндыру-кыру, талау дигән сүз. Әлегә мәмләкәтләр тәгаенләнеп бетмәгән, чикләр төгәл билгеләнмәгән. Яу чабу шуңа күрә кыенлык тудырмый. Ләкин тиздән, папа, үзең әйткән «Барымта кару»лар бетеп, башка халыкларны талау исәбенә яшәү мөмкин булмаячак, үзенне-үзең туйдырырга туры киләчәк. Моның өчен чынлап торып икътисадны үстерү, сәүдәне кинәйтү, күрше илләр белән дустанә ярдәмчел мөнәсәбәт урнаштыру зарур.

— Әллә пәрәвез оясы коруың инде, княгиня, — диде Мамай астыртын елмаю белән, — борчылма, ярлыкка мин дүрт куллап риза. «Барымта»га килгәндә, мин синең фикеренне хупламыйм. Җиһанны сугыш тота. Сугыш — адәмнең сулышы. Әмма акыл бар үзеңдә. Сөбханалла.

— Варвара анама ошаган — диде Мансур горур кыяфәттә, — икесе бер сынар.

— Хак, углан, акыллы хатын — зур бәхет, тик бу бәхеткә ия булу — әһле жөнүн[4].

## Капкасы биек таш Казан

*Идел белән Җаектан, татарның*
*туль йортыннан...*

«Идегәй» дастаны

— Бәк, бармак белән бармак тиң түгел, ботак белән ботак тиң түгел. Дөресен генә әйт әле, күктән караганда да күз колачы житмәс биләмәләрең арасында муллыгы белән кайсысы аерылып тора?

Юзекәйнең бу соравына Мамай жавап бирергә ашыкмады, чөнки мосафир авызыннан чыккан һәр жөмлә эчендә нindидер яшерен мәгънә, кинаяле ишарә ята.

— Бу тагын нинди бияләй эчендә бармак уйнату инде?

— Туры сорауга туры жавап, бәк, бармак уйнату соңыннан.

— Сорап та торасы түгел, Кырым әлбәттә. Кырым!

— Кырым күркәм бизәк, бәхәсләшмим, зәңгәр кашлы йөзек. Ә мине муллык кызыксындыра.

— Әйттем бит бармак уйнатасың дип...

Юзекәй баш бармагын тырпайтып, чигәсе тирәсендә әйләндерде дә әйтте:

— Кеше карбыз түгел, эчен ярып карый алмыйсың шул.

— Мосафир!

— Ярар, ярар, башта хикәятемне тыңла, шуннан соң нәтиҗәсен үзең чыгарырсың.

Киев. Кенәз Святославның чибәрдән-чибәр сарай хадимәсе Василиса белән гыйшык уены жимеше — Владимирның хаким вакыты. Билгеле инде, алма агачыннан ерак төшми. Яшь кенәзнең дистәгә якын жәмәгате өстенә, өч йөздән артык кәнизәге дә бар. Бу хәтта иң дәртле солтаннарның да төшенә кермәгәндер, шәт.

Владимирны ике генә нәрсә кызыксындыра: чибәркәйләр һәм орыш. Христосның тууына 985 сәнә тулган елда ул Идел Болгарстанына яу чапты. Бик күп әсир алдылар, ганимәт...

Кулдашы, мәшһүр сәргаскәр Добрыня кенәзнең кабыргасына төртте дә:

— Воевода, әсирләргә күз төшер әле, барысы да күн итектән, безгә чабаталылар кулайрак булмасмы? — дип сорады.

— Хәлләләрдән күбрәк улжа каерырга була лабаса.

— Юк, воевода, болар, киресенчә, үз мал-байлыклары өчен утка керергә дә, суга төшәргә дә әзер, буйсынуга караганда алар үлемне артыграк саный. Үзең дә күрәсең ич инде, болгар орышта — арыслан.

Владимир сүзсез генә хан мөһере сугылган Гаһеднамә[5] кәгазен сузды.

Сәргаскәр: «Ошбу килешүнең фәкать колмак суга батканда, таш судан калыкканда гына бозылуы ихтимал», дигән жөмләне укып, мыек астыннан гына елмаеп куйды: арыслан гына түгел, төлкеләр дә икән ич әле болгарлар.

Дөрестән дә, Болгарның аерым мәсләге бар иде. Бу мәсләк Владимирны

[4] Әһле жөнүн – акылдан язу.
[5] Гаһеднамә – килешү.

ислам диненә тартуга бәйле иде. Чөнки кенәз мәҗүсилектән арынган, бер Аллалык ягына авышкан иде инде. Әмма кайсы динне кабул итүе әле тәгаенләнмәгән. Сайлану бара.

Ул Исламның сафлыгын, пакьлеген, гадилеген бик ошатты. Ә менә сөннәт, бигрәк тә хәмер мәсьәләсендә йөзен чытты.

– Шәраб – урыслар өчен күңел күтәренкелеге ул, – диде, – без хәмердән башка яши алмыйбыз.

Бу — Владимирның православиегә өстенлек бирүе иде. Һәм моның нигезе еракта кылә иде. Моннан йөз ел элек Владимирның мәшһүр әбисе княгиня Ольга Константинопольгә барып, чукынып кайткан иде инде.

– Димәк, Болгар Урданың иң бай төбәге, шулаймы? – диде Мамай, – рәхмәт, бик файдалы мәгълүмат бирдең.

– Шулай, бәк, Болгарда күптәннән утрак тормыш хөкем сөрә, анда мичтә ипи пешереп ашыйлар, һөнәрчелек остаханәләре күп. Алыш-биреш алга киткән.

– Шәһәрләре көчле, алайса.

– Капкасы биек таш Казан үзе генә ни тора!

Байду хан мирасы. Ә тарихы болай.

Җиһангирның Рәсәйгә яу чабарга җыенуын ишетеп, урыс кенәзләре шөр җибәрә. Тиз-тиз генә зиннәтле бүләкләр туплап, шәрәфле вәкилләрен Батуның туктаган урынына, Болгарга озаталар.

– Берсүзсез сиңа буйсынабыз, салым түләргә әзербез, – дип, илчеләр җиһангирның аягына егыла, – барысын да син кушканча эшләрбез, җирләребезне генә хәрәбәгә әйләндермә.

Эретәләр тәки ханны.

Шушы хәлләрдән соң Бату илчеләргә, йомышлы кешеләргә тукталыш булсын өченгә бер шәһәр бина кылырга карар итә. Идел буенда, урыс җиренең нәкъ кырыенда кулай урын да табыла. Бу урын терлек-туарга, кош-кортка, һәр төрле орлыкларга, һәм дә балыкларга бик бай була. Тик бер кимчелеге бар, анда еланнар мыжгып ята икән, алардан арыну өчен шактый көч түгәргә туры килә.

Күп тә үтми, шушы гүзәл урында ифрат та матур шәһәр бина кылына. Бу шәһәр Казан була.

– Байду хан файдасын күрәме соң?

– Кызганыч, шәһәрнең мөккәмәл булып оешкан чагын күрү аңа насыйп булмый, гомере кыска була аның. Кайберәүләр Бату ханны 1248 елда Буда каласы янында Польша короле Владислав чәнчеп үтергән дип саный. Ләкин бу дөреслеккә туры килми.

Монгол иле һәм Алтын Урда буйлап сәяхәт иткән Аурупа мосафиры Рубрук әфәнде 1254 елда Бату хан белән очрашуы турында тәфсилләп язып калдырган: «Ул ятактай киң вә озын, тоташы белән алтынланган тәхеттә утыра иде. Янында бер ханым да (хатыны Боракчин булырга тиеш) бар иде. Батуның йөзе тимгел-тимгел булып кызарып чыккан иде».

Мәшһүр җиһангирыбыз аннан соң да бер ел яши әле. Фалиж[6] башына җитә. Казан әле бу вакытта күтәрелеп кенә килә.

Мамай Болгар, Урта Идел хәлләреннән Юзекәй дәрәҗәсендә үк хәбәрдар түгел иде. Шул ук вакытта, төбәккә битараф дип тә әйтә алмыйсың. Тәхеткә Мөхәммәд ханны утырткач, вәкаләт мәсьәләсе куерып алды. Нәкъ шул вакытта Болгар әмиренең яшь ханны танырга ашыкмавын житкергәннәр иде аңа. Бу ашыкмауның сәбәбе шунда – Хәсән Сарай тәхетендә дә утырып алган кеше. «Гадел хөкем иясе солтан Хәсән хан» исеме белән акча да сукты.

[6] Фалиж – паралич.

Тәхеттән ул Мамай катнашы белән очты. Алай да югалып калмаган, Казанны пайтәхете итеп, Болгарны үз кулына алган. Шуна чыгынчылап маташуы булса кирәк.

Мамайнын бу вак-төяк низагка кул тыгасы килмәде, кенәз Дмитрий Суздальскийга ярлык җибәрү белән канәгатьләнде. Ярлыкнын фәрман өлешендә ике генә җөмлә бар иде: «Казанга яу чабып, Хәсән әмирне акылга утырт. Мина Мөхәммәд Буләк ханнын вәкаләтләрен тануы турында рәсми ярлык җибәрсен».

Хәсән әмир үзеннән алда хакимлек иткән Булат Тимер кебек үк Болгарнын мөстәкыйльлеген алга сөрә иде. Шул дулкында күршеләр белән даими рәвештә бәрелешүләр булып тора. Аларны Болгарнын унайлы урыны, бай табигате, мул яшәеше кызыктыра. Бер яктан Иделдә юлбасарлык итүче урыс ушкуйлылары тынгы бирми, икенче яктан, башкорт, нугай кабиләләре зур зыян сала. Сансыздыр мал-туарлар, чебен-черкидән күп кешеләре. Болын-көтүлекләрне генә түгел, иген басуларын да таптап изәләр. Анысы бер хәл, мөселман рухын хурлаулары аеруча зур ризасызлык тудыра. Потка табынучылары муеннарына ир-атнын агачтан юнып ясалган җенес әгъзасын асып йөри. Имеш, тормыш чыганагы.

Куып та җибәрә алмыйсын. Бу халыклар Алтын Урдага карый. Олыстан-олыска күчеп йөрү чик бозу булып саналмый. Шуна күрә хан үз вассаллыгындагы хакимнәрнен бу «шаярулар»ына бармак аша гына карый. Ишле гаиләдә ызгыш-талаш чыкмый тормый инде ул. Арттырыбрак җибәрә башласалар, сыптырып аласын да, шып тыналар.

Хәсән әмир үзенен ышанычлы шымчылары аша кенәз Суздальскийнын яу чабарга җыенуы турында хәбәрдар иде. Яуда Мамай бәкнен илчесе Сарайәкә дә катнашачагын белгәч, аптырабрак калды. Күрәсен, аны чын-чынлап арканларга телиләр.

Хәсәннен, табигый ки, ошбу чирүне тыярдай чамасы юк. Әмма каршылык шундый котылгысыз төс алган икән, ул яуны дауга әйләндерү әмәлен табарга кирәк.

Уйлана торгач, тапты әмир әмәлен. Орыш кырына иртә таннан чыгып басты да, иравыл[7]* яугирларга сөнге-кылыч урынына бакыр казан, тас, чиләк, мис ише иске-москы тараттырды. Икенче рәттәгеләр дум-думбак, давылбаз, далбай-быргы белән коралландылар. Чагдавылдагылар[8] атларын дөягә алыштырды.

Кәмит гаскәр орышка әзер иде инде. Күз күремендә новгородлылар шәйләнүгә, әлеге барабаннар, быргылар барысы бергә уптым илаһи телгә килде. Бер тында бу иләмсез мәхшәргә дөяләрнен дә бакыруы килеп кушылды. Ахрызаман.

Һөҗүмчеләрнен алдан килүче атлары өркеп, як-якка тайпылышты. Җәяүлеләр дә каушап төште. Гаскәр ыгы-зыгы эчендә калды. Шунда йөрәкне ярып кемнендер яшелле-зәнгәрле тавышы янгырады:

– Нечистая сила! Спасайтесь!

Илче Сарайәкә җыерылган калын кашлары астыннан гына воеводага карап алды.

– Кенәз, ни-нәмә астыгызга җибәрдегез әле, бу сон татар хәйләсе генә ич, әмирнен көченне тануы. Көлкегә калганчы яугирләренне җый җәтрәк.

Воевода әлеге күнелсез әнгәмәнен шаһитлары Борис туганы белән улы Василийга күз атты. Тегеләр шундук урыннарыннан купты.

– Мин калага керергә тиеш, – диде Суздальский, – бу Мамай бәкнен боерыгын үтәү өчен зарур.

[7] Иравыл – ал гаскәр.
[8] Чагдавыл – арт гаскәр.

— Ул шамакайның шуклыгы думбак кагу белән генә, ай-һай, бетәр микән?

Сарайәкә эчке бер астыртын наянлык белән җәлпәк битенә ямаулыктай ябышкан кыска сакал-мыегын сыпыргалап алды.

Тәти зат ул Сарайәкә. Ыспай. Кичә кигәнне бүген кимәс. Кая барса да, бер йөк кием-салым алып йөри, сәфәр өчен махсус тегүче тота.

Әле дә йомышчысы колагына нидер пышылдаган иде, йөгертеп энәдән-җептән генә чыккан яшел җилән белән кырма бүрек алып килделәр.

— Агач җирнең зиннәте, кием ирнең зиннәте, казанлылар бик затлы, хурга калырга ярамый, — диде илче.

— Казанны аласы бар әле башта.

— Монын хажәте булмаска охшый, кенәз, — дип, Сарайәкә учын кашына терәде, карашын кала ягына төбәде.

Нәкъ эзенә басты илче, воеводага ханның йөгенергә килүен җиткерделәр.

Шунда ук калкулык өстендә Хәсән әмирнең чонтык койрыклы көрән аты күренде. Даирәсе нибары егерме-утыз җайдак, арттан чүмәкәй төялгән берничә кузалак арба да тәгәри.

Әмир түбәнчелек белән бүләкләрен тапшырды. Бүләкләре затлы иде: көмеш саплы бизәкле булат кылыч, асыл ташлар белән ашланган ат дирбиясе, зиннәтле мех кием, көмеш савыт-саба. Каеш нукталы ак толпар исә гомумән һушларын алды.

— Мәрхәбә! — дип соклануын белдерде Сарайәкә.

Хәсән кенәзгә Мөхәммәд Буләк ханның вәкаләтен тануы турындагы рәсми ярлыгын тапшырды. Шуның белән яу дәгъвасе хәл ителде, сарык та исән, бүре дә тук. Мамайга — ярлык, Хәсәнгә — тәхет.

***

Түбән Новгородта кич-кырын саклап торып, Сарайәкә илченең йөрәгенә пычак кададылар. Мәскәү, Владимир, Суздаль, Рәзән кебек шәһәрләрдә Алтын Урда мәнфәгатьләрен яклаучы бик белекле вә абруйлы вәкил иде ул: кенәзләр белән уртак тел таба белде, дәгъвасез генә салымны тиененә кадәр түләтте. Төп коралы — сүз иде. Сүз белән дәүләти максатка ирешүче мондый мырзалар меңгә бер дә юк.

Мамайның бу хәбәрдән зәһәре чыкты, котырган бүредәй утка керер хәлгә җитте, үзен-үзе белешмичә: «Минем түрәләремә кул күтәрергә җөрьәт иткән кавемгә үлем!» дип кычкырды. Гарәпшаһ угланга да эләкте.

— Кем рөхсәте белән түмәненне ялга тараттың? — дип акырды, — башыңны казыкка элгәнне көтәсеңме?

Гарәпшаһ сүзгә кермичә генә (ә төмәнгә бәкләрбәге үзе ял биргән иде), буранның аз-маз тынуын көтте дә сорады:

— Ни боерасын, бәк?

Мамайны бу сорау айнытып җибәрде.

— Төмәненне сугышчан дәрәҗәгә җиткерергә күпме вакыт кирәк?

— Ун көн.

— Нәкъ ун көннән Түбән Новгородка яу чабасың. Кенәз Дмитрий Суздальский гафу ярлыгы җибәргән-җибәрүен, тик гаепле як барыбер җәзасын алырга тиеш, — диде Мамай, сүзләрен бастырыктай бастырып, — Сарайәкәнең үчен бише белән кайтаруны сиңа йөклим, калганын үзең беләсең.

— Аңлашылды, бәк, җиде буыннарына төшәрмен.

Гарәпшаһ гамәл кешесе. Эшендә һичнәрсә белән исәпләшми. Әле дә баш күтәрми чапты да чапты. Ялга таралган унҗиде мең яугирне җыю, бер

йодрыкка туплау, бәкләрбәге әйткән «сугышчан дәрәҗәгә житкерү» уен эш түгел. Атларны, коралларны да барларга кирәк. Туклануны оештыру да аерым игътибар сорый. Дөрес, азык-төлек өчен йөзбашлар җаваплы, ләкин яуның уңышы күп вакыт орышның үзенә кагылышсыз шушы «вак-тояк»ларга барып терәлә.

Гарәпшаһның яу алдыннан үти торган тагын бер үзгәрешсез йоласы бар. Бу — хәләл җефетләре белән хушлашу. Ул әлеге йоланы бөтен шартларын китереп башкара.

Яу хушлашуында гадәттәге хатыннар чатырына чират буенча йөрүдән үзгә буларак, ул аларның барысын бергә үзенә җыя. Дөрес, баштагы мәлдә бичәләрнең гомум тәртә арасына керәсе килмәде, киреләнеп маташтылар. Никах иясенең сүзе сүз икәнен тәфсилләп аңлатырга туры килде. Аннан соң, Гарәпшаһ кыз-хатынның күңел халәтен бер күз сирпеп карап алуда тәгаенли белүче зат. Хатын-кызның кылын гына тарта бел: сугып алсаң — чыгымчылый, сыйпап алсаң — йөри, сөеп алсаң — юрта, үбеп алсаң — чабып китә. Әле дә:

— Җәүзә, Шәһия, Хөррә, Тәмлия, асыл кошларым, бәгырь кисәкләрем, сагынуыма чыдый алмыйм, җәтрәк яныма килегез, — дип, чатыр япмасын такмаклый-такмаклый ачты.

Бичәләр көттермәде, берсе бүреген салдырып чөйгә элде, икенчесе итеген салдырды, өченчесе юындырды, дүртенчесе тастымал белән битен корытты. Аннары дүртесе дүрт ягыннан җитәкләп, табын янына алып килде.

Табын кысыр табын (монысы да йола) иде. Итсез. Аның урынына җиләк-җимеш күп, алма, шәфтәл, анар, әфлисүн, йөзем, инҗир таудай өелгән. Тәбәнәк өстәл өстенә шәраб мичкәсе дә менеп кунаклаган. Төрледән-төрле төнәтмәләр... Мәхәббәт уены кайнар булырга охшый. Тук кеше — ялкау кеше, йокыга һәвәс. Аннан наз өмет итмә. Усаллыгы артсынга этне дә ачлы-туклы тоталар.

— Зөбәрҗәт кашлы затлы балдак минем учымда, — дип, арада иң яше, Тәмлия беренчеләрдән хәләле муенына асылынды. Үзе астыртын гына көндәшләренә каш сикертеп алды. Тегеләре шаулаша-шаулаша ач черкиләр кебек сырышты.

— Минем учымда да балдак...

— Минеке матуррак...

— Минекенә житми...

Гарәпшаһ хатыннарының бу чыр-чу килеп чытыклануларын ошата иде. Куллары әле итәк астына кереп китә, әле түшкә үрелә, әле билгә ята...

Балдак мәрәкәсе хәзерендә уенга әверелсә дә, теге вакытта ник уйлап тапканына үкенеп тә йөргән иде.

Тәмлияне төшергәч кузгалган терсәк төртешүләргә чик кую максатында уйланылган гамәл иде ул. Башка хатыннарының барысы да бәк-мырза карлыгачлары, затлы нәселдән. Яшь кәләше исә һөнәрче кызы, анасы бөтенләй кара халыктан. Шуңа күрә шәрәфле бичәләр Тәмлияне үз араларына кертергә теләмәделәр, чеметү, кимсетү ягын гына карадылар. Өлкән җәмәгате Хөррә бикә мәсьәләне кабыргасы белән куйды.

— Кайсыбызны күбрәк яратасың, үзең әйт, безне тынычландыр, — диде.

Гарәпшаһ гадәттәгечә: «Тәүге хатын мал асрарга, соңгы хатын җан асрарга», — дип уен-көлкегә борып кына котылмак иткән иде дә, бичәләренең күзенә тәгәрәп кереп китәрдәй нәүмизләнеп карап торуларын күргәч, фикере үзгәрде.

— Ярар, сәфәрдән кайткач әйтермен, — диде.

Ул Генуя сәүдәгәрләреннән дүрт хатынының дүртесенә дә буләккә бер иштән

затлы күлмәкләр, бер төрледән алка-йөзек, беләзек-муенсалар сатып алды. Бүләкләрен аерым-аерым аулакта гына өләште. Һәммәсенә бер үк сүз:

– Менә зөбәрҗәт кашлы балдак, артыграк яратканым өчен аны сиңа бирәм, берсенә дә күрсәтмә, ашап бетерерләр.

Рәхәткә чыкты хәзер. Сораугa җавабы әзер:

– Зөбәрҗәт кашлы балдагым кемдә, мәхәббәтем – шунда.

Һәр хатынның йөзендә рәхмәтле елмаю, чөнки балдак аның учында. Бернинди тавыш-гауга юк. Тик яшь кәләше, мактанасы килепме, бәлки, үчен кайтарасы килгәндер, көннәрдән бер көнне иренең әлеге тылсымлы җөмләсен өзеп:

– Балдак миндә, – дип килешүне өзмәсенме.

Калганнары да учларын ачты...

Ул чакта үпкәләре зур булды.

Шөкер, бу хәлләр инде артта калды. Ләкин барыбер үзенекен итте. Хәзер, әнә, бергәләшеп сөешәләр.

– Өлкән хатыным Хөррә бикәгә юл куй инде, чибәрем, беләсең ләбаса, син иң яратканым, – дип, Тәмлиянең колагына пышылдап өлгерде Гарәпшаһ, – әүвәл аны чишендерегез.

Тәмлияне ул дөресендә дә аерым ярату белән ярата иде. Төпчеге матурның матуры. Озын керфекле кара күзләре алсу йөзендә асыл таштай нур чәчә, атлап киткәндә ефәктәй йомшак чәч толымнары дулкынланып-дулкынланып куя. Кашлары уйнаклап-уйнаклап ала... Бал кашыгына сал да йот...

Мәхәббәт уенында алар үзләре генә, ир дә хәләл җефетләр. Көнен-төнен өзлексез яннарында әвәләнүче иң якын гасәбәләренә дә монда урын юк. Бар гамәлләрне дә үзләре башкара.

Беренче булып, чыбылдык эченә Хөррәне алып кереп киттеләр. Бу якта Җәүзә калды. Аның вазифасы ирне хәзерләү. Башта кәнәфиенә кырын яткырып, эчке киемнәренә кадәр чишендерде. Аннан соң җылы су белән иплəп кенә ирлеген юды да, йомшак тастымалга төреп, бик җентекләп корытты.

– Мә, шушы төнәтмәне эчеп куй.

– Мине шаярт, – диде Гарәпшаһ.

Җәүзәнең кайнар теле иренең шәрә тәненә тиде...

Карт бичә өчен аны һаман шулай кыздырып алалар. Чөнки уен шуннан башлана. Аннан соң монын хаҗәте калмый, янгыр чуалчаннарыдай ятакта барысы бергә уралыша...

Гарәпшаһ сыгып ташлаган чүпрәк кебек сәләмәгә әйләнеп, таң алдыннан гына йокыга талды. Ул бәхетле иде.

***

Мең өч йөз житмеш жиденче елның җәе коры килде. Дым җитмәү сәбәпле, игеннәр тамырында ук янып-көеп бетте. Чыкканнары да былтыргы кура шикелле кукраеп утыралар, кагылуга сынып та китәләр. Ни чыдам бәбкә үләннәре дә төсен җуйды, җирдә эт эчәгеләредәй чуалышып яталар. Мал-туар сөяккә калды.

Гарәпшаһ дала кешесе, яугирлары да даланыкылар. Шуңа күрә аны корылык куркытмады.

Түбән Новгородка хәбәре чабышкы тизлегендә килеп ирешә. Үз чиратында кенәз аны Мәскәүгә ирештерде. Дмитрий шунда ук бабасына ярдәмгә гаскәр туплап, үзе үк шлемен киде.

Алар әзер, ә гарәпшаһныкылар күренми дә күренми. Түземлеге төкәнде олуг кенәзнең, воеводаларын җыйды да әйтте:

— Татарларның көче чамалы булырга охшый, көтеп ятмыйк, куа чыгыйк, — диде, — ошбу гадәти вазифаны миннән башка да булдырырсыз, шәт.

Дмитрий гаскәрен калдырып, Мәскәүгә кайтып китте. Аның гаскәренә кенәз Суздальскийның улы Иоанн һәм Симеон воевода житәкчелегендәге дружиналар кушылды.

Үзе юкның күзе юк — гаскәр олуг кенәзнең фәрманын үтәргә ашыкмады. Юк дошманның кемен куасын ди. Бу үзеннән-үзе килгән җиңү ләбаса!

Гарәпшаһ углан Харәземдә туып-үскән шаһзадә. Атасы Йосыф солтан улын зур хөрлектә тәрбия кылып, аңа киң иркенлекләр бирде, тыймыйча үстерде. Мамайга хезмәткә китүен дә хуплады. Чөнки бәкләрбәгенә күп падишаһлар баш ия. Аның кул астында йөрү — үзе бер тәрбия мәктәбе.

Гарәпшаһ ата-бабадан калган кадими кагыйдәләргә генә ябышып ятмый. Хөр шәхес — хөр фикер. Кыйбласы шушы. Аның бу «йөгәнсез»леге шәхси гамәлләрендә дә, орыш кәсафәтен коруында да олы чагылыш таба иде. Әйтик, татар явының төп сыйфаты — тизлек. Яуны татар ат өстендә килеш һөҗүм халәтенә китерә, дошманына бернинди махсус әзерлексез килә-килешкә ябырыла. Офык читендә ту-байраклар җилфердәгәнне абайландымы, бетте — качып котылырмын димә.

Гарәпшаһ исә тизлекне хәйләкәрлек белән сугара белә иде.

Ул әле дә тизлек белән мавыгып, төмәнен мәрхәмәтсез чиллә кояшы табасына ташларга ашыкмады, акылын эшләтеп бакты. Шуннан соң гына:

— Бер-ике атна Идел һавасын сулап, тәннәребезне ныгытып алыйк, яу качмас, — дип карарын житкерде.

«Һава сулау» һич тә ял хозурында ләззәт кичерү дигәнне аңлатмый иде, әлбәттә. Киресенчә, көнегүләр үткәрделәр, кара тир түгә-түгә осталыкларын чарладылар.

Гарәпшаһның һәр гамәлен шулай төптән уйлап, тәфсилле эш итүенең сәбәбе бер яктан хөрлек булса, икенче яктан, төмәненең вазифасында иде. Ул — кыргын яу башлыгы. Ә кыргын яу — кырып кисә торган яу. Үч явы.

— Толпарларыңның тояк эзе мөһерләнгән урында үлән арасындагы бөҗәкләр дә синең кылыч йөзеннән үтәргә тиеш, — диде аңа Мамай, угланлыкка фатиха биргәндә, — һөҗүмең үтергеч булсын!

Ул арада ар кенәзе Никомед җәнабыннан атчабар хәбәр китерде. Бик мөһим хәбәр иде ул. Урыс гаскәре яу көтми икән ләбаса. Тугарылып кәеф-сафа коралар ди.

— Бес сесгә урман эченнән аулак юл күрсәтербес, — дип атчабар хуҗасының иң кирәкле ниятен икәүдән-икәү калгач кына җиткерде.

— Атларны иярләргә!

Төмәнне ай күрде, төн йотты. Эт агач төбен юешләгәнче урыннары су сипкәндәй бушап та калды. Учак урыннарына кадәр тигезләделәр. Шулай булмыйча, вакытында поса бел, поссаң, торып баса бел.

Никомед җәнаб татарларны колач җәеп каршы алды. Бу — Мамай каршындагы гаебен юарга тырышуы иде. Хәлбуки, әлеге гаеп аның үз күнелендә генә, гөнаһын фәкать үзе генә белә. Урда сатлыкка санаса, бәкләрбәге бүләкләр җибәрер идеме? Углан кулына көмеш аеллы, зәңгәр якут ташлы дирбияле аргамак тезгенен тоттырды ич. Мондый асыл бүләк урыслардан тәтеми. Болгарларның да борыны югары, үзләрен әллә кемгә куялар. Тик урыс-болгар арасында яшәгәч, аларны читкә тибә алмыйсың.

Узган ел Дмитрий Московскийдан чапкын килде дә әйтте:

— Олуг кенәз Казанга яу чабарга ниятли, кешеләренә житкер, гаскәр сезнең жир аша үтәчәк. Бу серне бирәү дә белергә тиеш түгел. Бел, башың белән җавап тотасың, — диде.

Җан кадерле, билгеле, Никомед телен тешләде. Соңыннан гына ачыкланды, Дмитрий Сарай ханы Каһанбәк таләбен үтәгән икән. Хәсән ханны Сарайны танырга мәҗбүр иткәннәр. Аннан элек кенә кенәз Суздальский аны Урдага тугры булырга ант эчергән иде.

Әгәр Никомед әлеге һөҗүм хакында вакытында Мамайга хәбәр ирештергән булса, бу хәл килеп чыкмаячак иде.

— Кенәзнең сиңа хөрмәт күрсәтәсе килә, — диде ул чепи күзләрен челт-челт йомгалап, — көмешкә капмасаң, гайрәт тә юк. Гайрәт — көмешкәдә.

— Рәхмәт, кенәз, орыш чорында мин хәмер ише эчемлекләрне авызыма алмыйм, тыгынганчы ашамыйм да, — диде Гарәпшаһ, — ваемсыз баш дошманга ярдәм генә ул.

— Ай-һай, шаһзадә, кенәзне рәнҗетәсең бит, әйе, — дип, Никомед теле белән калын иреннәрен ялмап алды, — анда шәрәфле кунакны ястыктай мул тәнле ар сылулары көтә, әйе, хе-хе-хе...

— Кенәз, минем олы түшлеләргә мөкиббән икәнемне үземнән дә яхшырак белгәнең бик яхшы мәгълүм, — диде Гарәпшаһ, — авызыңа баллы җофар җау, әмма дә ләкин татар өчен беренче урында — яу! Бигайбә. Ә менә озатучыдан баш тартмыйм.

— Чәлүбәй!

Алыптай зур вә таза гәүдәле, нык бәдәнле бер углан баскан урынында таптанып куйды. Ул әле яшь. Сакал-мыек урынындагы купшы төкләре дә нәни Бохар пескәенең нәфис йоннарын гына хәтерләтә. Баһадирның баһадиры мәгәр. Учына салсаң, юлпычны да йомып кына куяр иде.

— Кенәзнең һәр адәме өчен җавап тотасың, — дип, Никомед авызындагы насваен жиргә төкерде.

— Жигүлегә карулыбыз[9], кенәз, — диде Чәлүбәй, яугирларча төгәллек белән, — егетләрем әмер генә көтә.

— Кузгалдык!

Симеон воеводага алар һич көтмәгәндә тап булдылар. Башта гади аучылар дип белеп, комачауламаска да уйлаганнар иде. Хәрби киемнәре булышты.

— Углан, урыс орышчылары ич болар, күр, барысы да очлы башлыктан, — диде тән яугиры.

— Камалышка алырга!

Чәлүбәй үзе атын чатыр тарафына борды.

Анда учак көйри иде, өстендә имән колгага кигертелгән болан түшкәсе. Берничә кеше озын таяклар белән ут тамагындагы куз өемен пышкый. Шунда ук табын хәстәрлиләр. Тыз да быз. Һәрберсе үз шөгыле белән мәшгуль. Шуңа күрә чатыр янында әле генә өннәреннән чыгып баскан сак йомраннардай үрә каткан яугирларны абайламый тордылар. Абайлагач та исләре китмәде, шөгыльләрендә булдылар, үзләренеке дип уйладылар, күрәсең.

Шунда Чәлүбәйнең күкрәк төбеннән ургылган ярсулы калын тавышы яңгырады.

— Жиргә аварга!

Бу көтелмәгән сәер әмерне урыс гаскәриләре шаяртуга санады, ахры, халәт-торышлары үзгәрмәде. Кайсыдыр көлеп тә җибәрде.

— Хе-хе-хе...

[9] Җигүлегә карулы – хәрәкәткә әзер.

Чәлүбәй кылычын кынысыннан суырып чыгарды да, селтәнү белән берсенең башын да тәгәрәтте. Кисек баш белән бергә исәннәр дә җиргә ауды. Хак чынбарлык, ниһаять, чигәләрен тишеп узды: алар дошман кулында лабаса!

— Воеводагыз кем? — дип кычкырды Чәлүбәй.

— Мин ул воевода, Симеон Михайлович, — дип алгарак чыгып басты кенәз. Аны әле генә болан аулаган җиреннән тотып китергәннәр иде. — Баш углан янына алып барыгыз, — дип дәвам итте ул тәкәббер кыяфәттә, — мондый юлбасарлыкны мин түбәнчелеккә саныйм...

Чәлүбәй сүз көрәштереп вакыт уздырмады, фәкать кылычын гына уйнатты: Симеонның гәүдәсе әрдәнә шикелле икегә ярылып төште, аһ итәргә дә өлгермәде.

— Углан, безне әсир ит, ни кушсаң, шуны үтәргә әзербез, — дип ялварышты йөзләреннән кан качкан орышчылар.

— Юл яручылар без, әсир алучылар түгел, — дип Чәлүбәй атына типке бирде. — Гамәлегезгә керешегез.

Соңгы җөмлә үзенекеләргә аталган иде. Алар исә үз вазифаларын яхшы белә. Тавышсыз-тынсыз гына урысларны чапкалап бетерделәр дә, угланга иярделәр.

Асылмадагы яшь болан кара күмергә әйләнгәнче янды-көйде дә, үләр-үлмәс пыскыган учакка төшеп таралды.

Чәлүбәйнең тупланы ар урманнарын артта калдырып, ачык яланга килеп чыкты. Монда якты, киң вә иркен иде. Аяусызланып үзен-үзе көйдерә-көйдерә тәс-рәвешен югалткан зәһәрле кояш рәхимсез утын чәчепме-чәчә. Ләкин җайдакларның кояшта эше юк. Чәлүбәй кыр уртасында ялгыз ләкләк сыман тырпаеп каткан ике катлы йортны шәйләп алды да шунда элдертте.

Яшь воевода Иоанн кенәз тояк тавышларын ишетмәде. Ул әле ятакта. Кайнар тәнле, йомшак куллы, дымлы иренле мәгъшукасы түше астына кереп чумган гына иде. Чибәркәйнең дәрте эссе кояштан да кайнаррак. Ләззәтле мәхәббәт уены кабынып китте.

Ярсулы наз арасыннан: «Милый, сөйгәнең бүләк көтә...» — дип мыгырданды чибәркәй.

— Ни теләсәң, шул булыр...

— Милый, мина...

Чәлүбәй бернинди каршылыксыз йортның болдырына үтеп керде. Чалкан төшеп йоклаган ике исеректән башка бер җан иясе дә күренмәде. Аларын да шундук теге дөньяга озаттылар.

— Өйдә кем бар, барысын да минем каршыма китереп бастырыгыз, — диде углан.

Ишек тупса-яңаклары белән идәнгә очты.

Пешекче хатын кавалерының күкрәк алмаларына береккән кулларын читкә алып бәрде дә, ярым шәрә килеш воевода катына килеп керде.

— Кенәз, татарлар!

Иоанн мәгъшукасы өстеннән очып кына төште. Куркуыннан җаны тамагына тыгылды. Сагы да юк ичмасам. Кичә нindидер бәйрәмгә сорап киткәннәр иде.

Воевода тәрәзәне терсәге белән төртеп ватты да, икенче каттан җиргә сикерде.

— Милый, а как же я?

Мәгъшукасының юрган эченнән башын чыгарып әйткән бу өзгәләнүен кенәз инде ишетмәде.

— Углан, кара әле, кара, бер шәрә кеше... елгага таба чаба...

— Ук җибәр!

Иоанн бил тинентен суга кереп өлгергән иде инде. Шунда эссе көннәрдә кузгала торган урын өермә кубып алды да, укны үз эченә суырды. Тик кенәз барыбер сыгылып төште. Анын йөрәге тоткан иде.

Өйлә тирәсендә төп көчләр килеп җитте. Гарәпшаһ тукталып та тормады, туры елга тамагына юнәлде — юл ачык иде.

Чәлүбәй үз бурычын үтәде. Күнел ачып та алдылар. Үзе кенәзнең мәгъшукасы белән юанды, егетләре чиратлашып, пешекче марҗа кочагына керде.

Пьяна тау башыннан караганда чуалган дилбегәне хәтерләтә иде. Бормалы-бормалы: бара-бара бөжраланып, түгәрәк рәвешенә кереп дә кушылам дигәндә генә, кырт эзен үзгәртә. Әллә ни кин түгел, әмма чонгыллы, кире акмалары күп. Күбекләре күнелгә шом сала.

Пьяна өлкән апасы — Сура елгасын су белән туендыра. Ә Сура Иделгә коя. Жирле халык күпләп-күпләп каек-көймә тота, алардан хәрбиләр дә файдалана.

Гарәпшаһта булган мәгълүматларга караганда, урысларнын төп көче Пьяна — Сура тамагы төбәгендә урнашкан булырга тиеш иде. Ләкин манлайбаш яугирлар анда эре гаскәр төркеменә тап булмады.

— Тавык күзе булгандыр сезгә, — дип ризасызлыгын белдерде Гарәпшаһ.

— Углан, беләсең, без күз үткенлегендә карчыга белән дә ярыша алабыз.

— Алайса, урыслар кая югалган соң?

— Алар югалмаган, углан, тынлап бетер, — диде яугир көлемсерәп, — бәгъзеләре якын-тирә авылларда кызлар коча, әче бал эчеп хозурлана, бәгъзеләре күләгәдә сафа кора, бәгъзеләре су коена, балык тота, бәгъзеләре — ауда...

— Ә кораллары?

— Кораллары? Кораллары да шунда. Таудай өеп куйганнар. Бу кызуда көбә киеп, сөнге-калкан тотып йөрмәссең бит инде, һы-һы-һы...

— Ярый, алайса, үзләренә үпкәләсеннәр. Мәгальурра вә билбанзай!

Кырын яу сукыр чебен күчедәй Мәскәүнең болай да таркау, пыжламас гафил гаскәре өстенә ябырылды. Берәү дә һөҗүм көтми иде. Татарлар аларга күк капусынын җимерелеп төшүе шикелле тәэсир итте. Башта үз күзләренә үзләре ышанмый тордылар. Аннан айнып китеп, абына-сөртенә елга тарафына ташландылар. Бу исән калунын бердәнбер мөмкинлеге иде. Ләкин шәпле атлар белән тинләшеп буламы соң?

Көн кичкә авышып, офык челтәренә ал төс кунганда Пьяна да урыс каныннан алсуланган иде.

Ошбу фаҗига урыс халык иҗатында да эзсез калмады. «За Пьяною люди пьяны» әйтеме шул җирлектә туа.

Гарәпшаһ углан өчен Пьяна юлнын яртысы гына иде. Ул явын Түбән Новгородка, кенәз Дмитрий Суздальскийның башкаласына таба юнәлтте. Анда өч кенә көн булды. Кенәз үзе качып киткән иде. Шуңа күрә берәү дә сөнге күтәрергә җөрьәт итмәде. Иң беренче эш итеп, Изге Спас чиркәвен ут төртеп яндырдылар. Чөнки Сарайкә илченең гәүдәсен, кул-аякларыннан, башыннан аерып, түмәр хәлендә шушы чиркәү бакчасына китереп ташлаганнар иде. Аннан каланы ничек кирәк, шулай таладылар.

— Үченне кайтардык, Сарайкә илче, тыныч йокла, — диде Гарәпшаһ киткәндә, — тизрәк Мамай бәкне сөендерим.

Углан берочтан Рәзәнгә дә сугылып, юл ялына шактый ганимәт туплады.

***

Альгирдасның үлеме Мамай мырзага кайчандыр үзенең үлеп терелүенә караганда да ныграк борчу салды. Ул хәвефле хәлләргә инде корым сарган. Ә бу әле яна гына булган бәхетсезлек. Әйе, бәхетсезлек. Җиһангир башын яуда салырга тиеш. Башка үлем аның өчен түбәнчелек. Дусты исә күзен йомшак түшәктә йомган. Әле теттереп сөңге атар чагы иде бит. Кырыгы да тулмаган.

Олуг кенәз Мансурны якын итә иде. Хәзер хәлләр кайсы якка үзгәрер — берәү дә әйтә алмый. Мондый вакытта көрәш аяусыз була. Династиягә мөнәсәбәтле караганда, тәхет мәрхүмнең бертуган абыйсы кенәз Кестутиска тиеш.

Кестутис коеп куйган воевода. Бу яктан ул Альгирдасны да уздыра иде. Тевтон орденын күп тапкырлар тезләндергән воевода. Тәвәккәлнең тәвәккәле: түбәннән керер, табаныннан чыгар.

1372 елда Переяславльгә һөҗүме үзе генә ни тора!

Яз иде. Кар эреп беткән чак. Елгалар ярларына сыймастай мөлдерәмә тулышкан. Юллар өзек. Кешеләр дә үшән, кышкы йокымсыраудан арынып кына киләләр. Кыскасы, яу мазасымы соң?

Кестутиска гына болар сәбәп түгел, су ташкыны да, юлсызлык та... Ул зилзиләдәй капылт, җилдәй житез, төлкедәй хәйләкәр. Кирәк икән, күз буып, сынын да югалтыр. Югыйсә ничек Рәсәйнең үзәгенә кадәр килеп житәр иде?

Билгеле инде, җиңү аның ягында. Бәхәссез, Кестутис тәхеткә лаек. Олуг кенәзнең уллары Андрей һәм Дмитрий да. Воеводаның үз улы кенәз Витаутас та кануни дәгъваче.

Мамай уттай кызулык белән, гадәттән тыш вәкаләтләр биреп, Вильнога илчеләр чыгарып җибәрде. Аларның бурычы — Урданың сәүдә үзәкләре эшчәнлеген һәм дә Мансур мырзаның биләмәләре иминлеген тәэмин итү иде. Әлеге шартлар үтәлмәгән очракта, дәүләти кисәтү каралган иде. Бу исә яу чабу дигән сүз. Мәскәү-Вильно мөнәсәбәтләренең кискен төс ала баруын исәпкә алганда, Литваның хәле күпкә мөшкелрәк, ул берьюлы ике кулга түзә алмаячак.

Болары соңгы сүз. Тәхеткә Альгирдасның үз ыруы утырган очракта соңгы сүзне әйтүнең хаҗәте бетәчәк, сәясәт үзгәрешсез калачак.

Ләкин Литвадагы хәлләр көтелмәгән юнәлеш алды. Кенәз Ягелло тамырларында аккан шляхта-поляк каны литувяйларныкына караганда дуамалрак булып чыкты: олуг кенәзнең матәм чаралары төгәлләнүне дә көтмичә, ул төнлә белән Кестутисның өенә бәреп керде.

— Кенәз, сиңа ирек бирәм, күз алдымда җыенып, кайда телисең, шул илгә чыгып китә аласың, — дип ультиматум куйды.

— Тәхет иясе буларак, ультиматумны мин куям, күземнән югал, ачуымны чыгарма.

— Тәрәзәгә күзеңне төшер, кенәз!

Ишек алды Ягелло кешеләре белән тулы иде. Кулларында факел. Жилфер-жилфер, әйтерсең лә бөтен дөньяны ут чорнап алган.

— Бу башбаштаклыкның ни белән бетәсен чамалыйсыңмы соң, тинтәк!

— Чамалыйм, — диде Ягелло һәм хәнҗәрен воеводаның күкрәгенә батырды. Бу юлы Кестутисның гаярьлеге ана ярдәм итмәде.

Чират Витаутаска житте. Әмма егерме җиде яшьлек яна династия вәкиле элекке ахири дустын утарда очрата алмады. Улы атасының язмышын кабатларга теләмәде, фетнә турында хәбәр алуга, Пруссиягә юл тотты, анда яклау тапты.

Тәхетне яулап алуга, Ягелло Мансур угланны чакыртты.

– Әллә миңа да кылыч күтәрмәк буласыңмы? – дип турыдан бәреп сорады Мансур.

– Варвара өчен мин сине буып ташлар идем, – диде Ягелло, тел яшереп тормады, – тик һич тә Мамай бәкнең дошманы буласым килми. Бу шәхсән үзенә генә түгел, бөтен Литвага кабер казу дигән сүз булыр иде. Киресенчә, мин дуслыкны ныгыту ягында.

Мансур сөзеп кенә әңгәмәдәшенә багып алды. Шул ук ташкабактай шоп-шома озынча йөз, элмәкле зур борын, тешләренә сыланган юка ирен...

Үзгәреш күзләрендә – алар ничектер аларган, терәкләрен югалткан, урыннарында түгел. Бәлки, шулай тоеладыр гына, хафалы чагы ич.

Янында сак адъютанты. Көбәсе, калканы, кылычы да шунда гына. Үзен чын рыцарь итеп танытасы килүе инде бу.

– Сиңа таяныч кирәк бугай? – диде Мансур.

– Кирәк!

Литвадагы тәхет чуалышы Алтын Урдага зыян салмады, элекке статус-кво сакланып калды. Мәскәү исә, киресенчә, басымын бермә-бер арттырды. Альгирдаснын уллары Андрей белән Дмитрий да Мәскәүгә сыенды. Бу хәл дәгъваларга кануни көч өстәде. Ә дәгъвалар бар иде. Беренче чиратта, элек Литва басып алган Стародуб белән Трубчевски калаларын янәдән Рәсәйгә кушарга кирәк иде.

Трубчевскида хакимлек иткән кенәз Дмитрий Ольгердович урыс гаскәрен Ратуша каршында кулына чәчәкләр тотып, җәмәгате һәм балалары белән үзе каршы алды. Рәхмәт йөзеннән, олуг кенәз аңа салым җыю хокукын да кертеп, Переяславль шәһәрен бүләк итте.

Ягелло бу югалтуны киреләнмичә генә йотты. Югалтуларны ишәйтмәс өчен хезмәттәшлектән дә йөз чөермәде. (Мәсәлән, 1410 елның 15 июлендә Грюнвальд авылы янында поляк-литва-урыс төркемнәреннән оешкан армиясе белән бөтен Аурупаны кымтырыклап торган Тевтон ордены гаскәрләрен башка-баш тар-мар итте. Тевтон алманнары әлеге җиңелүдән соң урыс биләмәләренә башка борын төртмәде. Бу искиткеч зур ярдәм иде.)

Литвадан, ниһаять, матур хәбәр килде. Мансур, литвуяйлар өчен кайгырып ятма, монда барысы да көйләнде, дип язган иде. Ягеллоның шәхси ярлыгы исә моны ал тасма белән бәйләп, ныгытып ук куйды.

Мамайның бер борчуы кимеде.

– Ханәкә, мин атна-ун көн югалып торсам, гаеп итмәссең бит? – диде ул хәләленә, – нишләптер буыннар тубырланып каткан.

Толымбикә җавап бирергә ашыкмады, башта алдындагы ширбәтен авыз итеп куйды. Шуннан соң гына сукранулы аһәң белән:

– Италияннар һаман үзара тыныша алмый, салымнары да кимеде, бер-бер чарасын күрергә кирәк ич инде, – диде.

– Хакимият синең кулыңда, ханәкә, – диде Мамай, – син ханның хокукый васибикәсе.

– Бу бәкләрбәге вазифасы.

– Бәйләнергә сәбәп эзлисең инде, мысык, ә? – дип Мамай хатынына елышты, – италияннар качмас, алар Кара дингезгә чат ябышкан. Иренә менә түл җыю комачауламас.

– Кеше үз кадерене белми, кадәрдән кадерене белмәс; былбылдан үзгә кошлар гөлстан кадерене белмәс...

– Шулай булгач сон?

– Ярар, ярар, ханны да үзең белән ал, кул астында әвәләнә торсын, вазифасына керер вакыты да җитә, унбишенче яше белән бара бит инде.

– Баш өсте, ханым-солтаным!

Толымбикә янә дә рөхсәт-фатихасын тулырак шәрехләмәк итеп авызын ачкан иде дә, ире алданрак өлгерде.

– Ни-нәмә әйтәсенне беләм, ханәкә, – диде, – әйе, мин далага юл тотам, бөтен кырык мәшәкатьләремне кырык якка ташлап, коланнар белән көч сынашырга исәп.

– Шул коланнар арасында бер...

– Анладым, ханәкә, чапкан атка гына жил янрык...

Мамай Мөхәммәд ханны үзара шаяртып, «пигамбәр» дип йөртә иде. Хәзерендә теле әйләнмәде. Сабагыннан тартып үстергән көнбагыштай сузылган икән ич егетебез. Әле кайчан гына маэмайлар тирәсендә әш-мәшә килеп юана иде. Инде кыз ярәшер вакыт житкән ләбаса. Ханның башлы-күзле булуы зарур.

– Хан, бугалак тотуга ничек карыйсың? – дип сорады бәк.

Мөхәммәднең сөякчел какча йөзе жилпенеп алды, муен астындагы төере астан-өскә күтәрелеп менде.

– Рөхсәтме соң?

– Васиян тәкъдиме бу.

– Миңа тулы ирек биреләме?

– Гадәттән тыш хәлләр генә килеп чыкмаса, тыючы булмас.

– Ми-и-и-нем теләсә-нинди шартларда да үз кө-ө-өчемне сынап каррыйсым ки-и-и-лә, – диде Мөхәммәд, утырып бетмәгән яшелле-зәнгәрле тавышына төртелә-төртелә.

– Хан дәүләт дигән сүз ул, ә дәүләт саклауга мохтаж, – дип, Мамай кулларын үсмернең жилкәсенә салды, – кайгырма, һәр гамәлнең үз жае бар. Хәерле сәгатьтә.

Колан көтүе тыныч кына уртлап йөри. Аларны әле бимазаларга ярамый, ташлап китүләре ихтимал. Иң мөһиме, өербаш айгырга карата үтә саклык таләп ителә. Аның холкы көйсез кияүнекеннән дә яманрак, керәле дә чыгалы.

Зур көтүне әле дә булса кайчандыр Мамайны дала стихиясендә йомычка урынына дулаткан мәшһүр Алаяк нәселе елгырлары тота. Монысы яшь әле. Шуңа күрә дуамал, койрыгы һаман сыртта. Кушаматы да үзенә туры килә: Сәмум! Йөгәнсез утлы жил. Дала мәхшәре.

– Сәмум ничек анда? – дип сорады Мамай.

– Кияү егете, – дип көлдә Актачы-би, – башын югалткан көннәре, әнә, назланышалар...

– Аралары суынганчы ханны атка атландырыгыз!

Мөхәммәднең юка гәүдәсе ияр белән беркешеп бетте диярлек, хәтта башы да ялга сыланды.

– Хәерле ау, хан!

Кушчы адәм кыл әләмне баш очына күтәрүгә, ат куучы жайдаклар төрле тавышлар чыгарып көтүне кузгаттылар, өер эчендә ыгы-зыгы башланды: кыргый атлар үзләренә тыкшынуны өнәми.

Мөхәммәднең тустаган күзле туры алашасы томырылып өер арасына килеп керде. Бик күп коланнарның билен бөккән аргамак ул. Шунда ук, тезген тартуны да көтмичә, сөлектәй шома бер бурлы тайның эзенә килеп тә басты. Тегесе үзен эзәрлекләүне сизде булса кирәк, читкә тайпылып, эзен бутамак итенде. Ләкин Тустаган күз аның ниятен алданрак абайлаган иде, юлына аркылы ятты.

– Һоп!

Мөхәммәд форсатны ычкындырмады, бугалагын селтәп, колан тарафына очырды...

— Һоп!

Мөхәммәднең ымлыгы Сәмум өербашның кешнәве арасында йотылып калды.

— Ио-ха-ха-ха!..

Көтү чабыш уңаена һөҗүмгә кузгалган гаскәр сыман яу рәвешенә керде. Иң алда — Сәмум, аннан койрык тиңелте генә ара калдырып, бер йомгакка төренгән өер тәгәри. Тустаган күз шулар арасында. Бугалак тайның муенына яттымы-юкмы, Мөхәммәд әле белми, чөнки тизлек бер үк.

— Өер ханны үз эченә алды бит, нишлибез? — диде Мамай.

— Көтү тынычланмыйча, ай-һай, аерып алып булырмы икән, — диде Актачы-би, — хәер...

Ул тотлыгып калды. Сәмум көтмәгәндә көтүен чатырлар ягына борып куймасынмы, хәлбуки, алар да ур белән әйләндереп алынган иде. Тик котырык айгыр өчен ур ни, киртә ни, ышан син аңа, басып та керер. Бу инде гомуми фаҗига!

Бәхетенә күрә, өер читтәнрәк үтте. Агым ярына сыеша алмаган коланнар гына урга эләкте.

Мөхәммәд тайның бугалакта икәнен әле генә аңлап алды. Тарттырып кысарга җай гына чыкмый. Өерне дә ерам димә, тыгызланып тулган. Хәл мөшкел. Әмма ул үзенә дә, даирәсенә дә буш куык түгеллеген исбатларга тиеш. Абруй шулай бөртекләп җыела.

Тай да, Тустаган күз дә ур өстенә бер ыргымда очтылар. Җиргә төшкәндә генә тай сөртенеп китте. Шулай да егылмады, әмма тизлеге шактый кимеде. Һәм Мөхәммәд бугалакны бар көченә үзенә суырды...

Унлаган тояк кубарган тузан өермәсе таралганда да баш бирмәс тай тыпырчынып өзгәләнә иде әле. Мөхәммәд аны янына Мамай бәк килеп туктагач кына ычкындырды. Колан коймакларын коя-коя өерне куып китте.

— Сөбханәлла, хан, мин булдырмастайны булдырдың, котлыйм, — диде бәкләрбәге.

Калганнар да хуплауларын белдереп гөрләшеп алдылар.

Үз хөрмәтенә җыелган мәҗлестә Мөхәммәд тәүге тапкыр сары балдан авыз итте.

— Төнгә чатырына җария кертегез, — дип күрсәтмә бирде Мамай, — ошбу һөнәргә дә өйрәнә торсын.

Ханның балык куыгыдай былт итеп су өстенә калкып чыгуы бәкләрбәген уйга салды. Чөнки Мөхәммәднең балигълык яшенә җитүе идарә өлкәсендә үзгәрешләр кертүне дә таләп итәчәк.

— Бәндәнең бәхете алга киткәндә, кулына туфрак алса, алтын була, ханның җире җирендә, җилкәне суда торырга охшый, — дип уен бүлде нинди дер эчке тавыш.

— Әллә маңгаена язылганмы?

— Маңгаена язылмаган, борынына язылган.

— Ничек?

— Ханның борынында миңе бар. Борыны миңлеләргә Ходай уңыш тәгаенли.

Мамай капылт кына башын күтәрде. Ул эчке тавыш белән түгел, Юзекәй мосафир белән гәп кора икән ич.

— Тагын ни-нәмә чокып чыгарырга исәбең?

— Гарәпләр әйтмешли: «Ләйсә ли хөбби би Галиен бәл ли гадуин би Могавия», ягъни Галигә дуслыктан түгел, Могавиягә дошманлыктан. Мин бит синең этең, бәк. Бүреләрең уламый башлады, шуңа хәсрәтләнеп килүем.

Мамай, иелеп кулына таш алды да, аны озак кына учында әйләндергәләп, кыя очында кайнашкан кара кошчыкка томырды. Кошчык өзелеп төште.

— Менә шулай, мосафир, барча дошманнарымны да шушы язмыш көтә.

— Тик нигәдер ташларын Идел-суның сулъяк ярына барып житми.

— Син, мосафир, моның авырткан жире чи жәрәхәткә әйләнсен өченгә угыңны юри шунда кадыйсың инде, — диде Мамай таш бәрә-бәрә, — ләкин ялгышасың, Сарайның мина хажәте калмады. Кирәк чакта ханнарым Абдуллаһ та, Мөхәммәд Буләк тә, Толымбикә ханәкә дә Сарай мөһере белән акча сукты. Хәзерендә Алтын Таш[10]* ханнары безнен катнашсыз да бер-берсен чаян урынына чагыша. Тугыз бөртеге, әнә, башын югалтты. Арт барыр жирләре дә калмады. Ә син бүреләрен уламый башлады дисең. Авызыңны үлчәп ач.

Юзекәй, һәрвакыттагыча, йонны кирегә сыпыруын дәвам итте:

— Йә, хуш, ә Мамайның биләмәләре кибәргә элгән дөя тиреседәй көннән-көн бөрешә бара дип гайбәт сатучыларга ни әйтерсең?

Бәкләрбәгенең йөзендәге сеңерләре тартышып куйды.

— Минем кул астында бөтен Идел буе, Кавказның төньяк өлеше, Дәрбәнд тарлавыгы, Кырым-Солхат, Кара диңгез төбәге. Мәсләгем Байду хан дәүләтен тулысынча торгызу.

Мамай аңлы рәвештә Күк Урда атамасына тел тигермәде. Ник дисәң, Күк Урда элегерәк тәгаенләнә. Орду Ичен мәшһүр атасы нигез салган Жучи олысында энесе Байду кебек үк иң шөһрәтле ханзадәләрнең берсе була һәм алданрак житешә. Алтын Урда оешкач та Байду хан агасына күп иркенлекләр биреп, дәүләте белән үзе теләгәнчә идарә итәргә мөмкинлекләр ача. Үзләре бакыйга күчкәч кенә арадан кара мәче уза, тора-бара бүленеш тирәнәеп, килешмәстәй каршылыкка әверелә. Орду токымы үз кануннары буенча яши.

Алтын Урданың әлеге ике кыйтгасы — Ак Урда белән Күк Урда — фәкать Үзбәк хан вакытында гына бер канат астына кереп ала. Ул чакта Үзбәк хан көч кулланып, Орду нәселен хакимияттән читләштереп, дилбегәне Кыят ыруы вәкиле, Мамайның ерак туганы Исатай гургенга тоттыра.

Үзбәкнең вафатыннан соң шаһзадәләр баш күтәрә һәм барысы да элекке эзенә кайта. Ырыс Мөхәммәд чорында Күк Урда бербөтен дәүләти берәмлек булып укмаша, ныгый һәм көчәя.

Мамайга исә Күк Урданы үз кул астына алырга Исатай гургенның канлы мирасы комачаулый. Анда кыятлыларны әле булса дошманга саныйлар. Бердәнбер юл Үзбәк үрнәгендә тәхеткә үз кешеңне утырту. Ләкин хәзерге катлаулы вәзгыятьтә бу мөмкин түгел.

— Сыгнакка әмир Бырлас Шаһ Тимер нәфесен суза икән, — дип, Юзекәй төртмә сүзләрсез генә хәбәрен житкерде.

— Кит аннан, шул чонтыкмы?

***

Нәкъ шушы дәкыйка[11] мизгелдә Шаһ Тимер дә әңгәмә корып утыра иде. Гариплеге өстенә буйга да таман иде ул. Шуңа күрә мәһабәтрәк күренү өчендер, мөгаен, тәхетен биек аякка утырттырды. Аңа хәзер һәммәсе астан өскә карый. Әле дә әңгәмәдәшенең башы чөюле, гүя Алып батыр алдында басып тора. Хәлбуки үзе шактый фырт күренә. Яшь әле, чырае күкәйгә изгән күмәч кебек шоп-шома. Шушы шома йөзне камыт биятедәй бик

[10] Алтын Таш – Сарайда хан бистәсе.
[11] Дәкыйка – минут, төгәл.

килешле кара сакал-мыек уратып алган. Хәрби киемнән: көбә, чылбыр муенсалы, очына каурый беркетелгән тимер башлык, әледән-әле асыл ташлы бизәкләре ялык-йолык килеп ала. Ә аеллы каешка бил түбәнтен тагылган көмеш токкалы кылычы ана дәхи дә бер күркәмлек өсти иде.

Шаһ Тимер калын кашларын җыерып, озак кына әңгәмәдәшенә карап торды. Күзе без — үтәли тишеп керә. Углан алай да чыдады, башын читкә бормады.

Ул нинди дер гөпелдәүгә айнып китте. Шуннан соң ук тәхет хуҗасының ачулы тавышы яңгырады.

— Күземнән югал, җаһил!

Яшь әңгәмәдәш әлеге ачуны үзенә кабул иткән иде дә, кара колның сыгылып төшкән гәүдәсен һәм дә келәм өстенә сибелгән җиләк-җимеш вә касә ватыкларын күргәч, җиңел сулап куйды. Күрәсең, әмир колының ниндидер гамәлен ошатмаган иде.

Шаһ Тимер кальян мөштеген иреннәре арасына кертеп, аерым бер үҗәтлек белән тар күкрәгенә челем төтене тутырды да озак кына ләззәт кичереп торды. Аннан янә инде кырык тапкыр җавап алган таушаулы соравын кабатлады:

— Атаң, Мангышлак хакиме Туйгуҗа әмирнең башын син үзең чабып өзденме?

Без күз янә хәнҗәрдәй кадалды.

— Юк, җәнабе гали, атаемны Ырыс Мөхәммәд хан үтертте.

— Сәбәбе?

— Баш бирмәгән өчен дип беләм.

— Ә син?

— Мин хәзерендә синең аягыңа килеп егылдым, мине дә атаем язмышы көтә иде.

Кальянның суы янә гөбердәп алды.

— Карга ни кадәр югарыга күтәрелмәсен, барыбер үләксәгә куна, — диде Тимер мөштеге арасыннан гына, — синең дә чын йөзеңне ачу авыр булмас. Гаһедне[12] бозасың икән, бел, эчәгеңнән агач ботагына асып куярмын, үлә алмыйча газап чигәрсең.

Шаһ Тимер ыруы Җучи токымына тоташкан бу яшь мырзага эченнән генә зур өметләр баглый иде. Алтын Урданы буйсындыру өчен иң элек Сарай тәхетенә үз кешеңне утырту зарур. Аннан җайлана ул. Мырза исә бөтен таләпләргә дә туры килә. Ул аны шушы олы максаты хакына кабул итәргә булды.

Әмир мырзага беренче тапкыр зурлап, исеме белән мөрәҗәгать итте. Әллә уен, әллә чын — белмәссең.

— Мөхтәрәм Токтамыш[13] углан, иртәгәдән гаскәр алырсың, әләме дә булыр, сине Сыгнакка идарәбаш итеп куям, — диде нәсариныкыларга охшаш салынкы мыек очлары белән генә елмаеп, — тик әлегә Сыгнак Күк Урда кулында, күрсәт егетлегеңне. Шунда сүзләреңнең хаклыгына ышанырмын.

Аргы атасы Чыңгыз хан,
Бирге атасы Туйгуҗа,
Аннан туган Токтамыш –
Ул Токтамыш мин булам.

Шаһ Тимер турында далада «Балыкчы» дигән кушамат йөри, ягъни

[12] Гаһед – килешү.
[13] Тарихи чыганакларда: Токтамыш, Тохтамыш, Туктамыш.

балык тотыйм дисән, әүвәл суны болгат. Токтамыш яшендә ул Монгол ханы Туглак Тимер канаты астына кереп сыенган иде инде. Хан аны уч төбе кадәрле генә бер өлкәсенә баш итеп билгеләде. Анын исә мөстәкыйль хаким буласы килә. Туглак ханның вафаты бу максатны күпкә якынайтты. Моның өчен тәхеткә утырган Ильяс ханны бәреп төшерергә генә кирәк. Сәмәрканд әмире Хөсәен солтан да булышырга сүз бирде.

Ләкин... нияте барып чыкмады, җинелде. Качып китәргә туры килде.

Качып китте, әмма хыялына барыбер турылыклы калды. Уйламаганда-көтмәгәндә сәмәркандлылар баш күтәреп, монголларны куып җибәрде. Су тагын болганды. Тот балык, иренмә генә. Һәм Тимерләнк янә форсат кочагында. Элекке дусты Хөсәен солтаннан да арыну җае чыкты. Ул инде тулы хокуклы әмир, бөтен Маверәннахрның хакиме.

Токтамышка сыендыручысының үҗәтлеге ошый иде. Шаh Тимер бик уңайлы кеше. Җиһангир, әмма чыңгызый түгел, зур тәхеткә дәгъва итә алмый. Аны тора-бара үз мәнфәгатьләрендә файдаланып булачак. Ә ул, иртәме-соңмы, Алтын Урданы үз кулына алачак. Аннан Һиндстан, Кытай, Аурупа...

Хыял татлы, әйтерең бармы. Әлегә ул Шаh Тимернең табанын ялый. Алда – Сыгнак. Исәбе генә исәпкә туры килмәде, йолкынып кайтты. Ырыс Мөхәммәд кебек карт төлкене тезләндерү өчен коры теләк кенә аз шул.

Шаh Тимер шаhзадәне мыскыллы елмаю белән каршы алды.

– Бабаң Чыңгызхан исән булса, сыртыңны сындырып, чүл бүреләренә ташлар иде, – диде кызмый гына, – мин сиңа тагын бер мөмкинлек биреп карыйм, күрсәт кемлегеңне.

Ул үзе бу яуның да уңышсыз чыгасын алдан ук белеп, белеп кенәме, шуңа йөз тотып тора иде. Моңарчы күләгәдәге бер төмән белән сыгнаклыларның ишле гаскәрен баш идерермен димә.

Әйдә, кикриге шиңсен, Чыңгызхан токымыннан мин дип һаваланмасын.

Әмирнең кара ниятен Токтамышның үзенә караганда, дусты вә уң кулы Киң Җанбай төшенеп алды.

– Бер кылычка – ун кылыч, Чонтык сине тагын хурга калдырмакчы, – диде.

Токтамыш уйланып торды да әйтте:

– Минем башка юлым юк, – диде, – йә таҗ, йә таш.

– Алайса, күрәләтә яугирларны үлем эченә кертмәскә кирәктер...

Токтамыш мизгел эчендә янып чыкты, күзеннән очкыннар чәчрәде.

– Ананның җәсәден өйрәт, җәме!

– Менә-менә, миңа шушындый гаюр[14] Токтамыш ошый.

– Җинү теләсә-нинди корбаннарны да аклый, уен тәмам, чынлап торып чакма чыгарыр чак җитте.

– Мәгальурра!

Чираттагы орышка углан ныклап хәзерләнде. Чөнки кешене бер кичерергә була, ике... Өченчесендә инде ул ышанычны тәмам югалта. Шаh Тимер аны үзе янында тотмаячак.

Монысында хәйлә юлына басты. Кала капкасы каршына гаскәренең чирегең генә тезде. Сыгнаклылар шуңа алданды: бу чирүне мәңге мантымаслык итеп тар-мар итәргә була лабаса!

Хан гаскәре ачык яланга чыкты. Шунда Токтамышның төп көчләре яшеренгән урыннан алга ыргылды.

– Мәгальурра!

Сыгнаклылар моны көтмәгән иде, югалып калдылар. Ыгы-зыгы

[14] Гаюр – кызу табигатьле.

башланды, бөтенлек чатнады. Бер ишләре хәтта яу кырын ташлап, кала ягына элдертте. Котыла алмадылар. Монда аларны Киң Җанбай яугирлары сөнге очына алды.

– Шул кирәк сезгә, табакбашлар... Их, анагызны...

Токтамыш ләззәтле сүгенү белән сүгенде дә, тезгенен бушатты. Тик китәргә өлгермәде, кулбаш углан аваз салды.

– Төмәнбаш, кара әле, хан чатырына эленгән ту-байракны җирьякка төшерделәр, – диде, – иелгән байрак тоткан коралсыз өч җайдак безнең якка чаптыра.

Байракны гадәттән тыш хәлләрдә генә ияләр. Димәк, ниндидер мөһим хәбәр бар.

– Кылычларны – кыннарына!

Чабышкылар да килеп җитте.

– Мөхтәрәм Төмәнбаш, – дип мөрәҗәгать итте акбүз ат өстендәге өлкән яшьтәге күсә сакаллы вәзир, – бездә матәм, орышны тәхеткә яңа хан утырганчы кичектереп торырга туры килер, солтаннарның солтаны, бәгырь ташыбыз, галиҗәнап хакимебез Ырыс Мөхәммәд, урыны оҗмах түрендә булыр, Аллаһы боерса, вафат...

Вәзирнең җилкәләре дерелдәп алды.

– Ничек вафат?

– Әле генә намазга оеган жиреннән күгәреп катты...

Адәм гөман кыла, язмыш көйли. Җину кулында иде ич инде. Кем әйтмешли, әбе килсә, җәбе килми, җәбе килсә, әбе килми.

Кичектерү елдан артыкка сузылды.

Бу Шаһ Тимернең фарсы якларына күз аткан мәле иде. Хулагуидларга әле аның теше үтми үтүен. Шуңа күрә үзен куркак эт кебегрәк тота: өрә дә койрыгын кысып, артка чигенә, өрә дә койрыгын кысып, артка чигенә. Әмма кашып карарга ярый, белмәссең, җае да чыгып куяр. Токтамышны чакырды да әйтте:

– Энҗүне[15] кичмә, башың бетәр, ә елганың уң ягында безнең тәртипләрне урнаштырырга тырыш, Тимериләргә күнегә торсыннар, – диде.

Ул шушы ук бурычны, аңа әйтми генә, икенче бер угланга да тапшырган булып чыкты. Чак-чак йөзгә-йөз бәрелешмәделәр.

Кояш офык читенә кунаклаган челтәр болытларны ал төскә манып, бишегенә төшеп бара иде инде. Күккә эленгән үтә күренмәле эссе һаваны ерып, җил дулкыны талпынгандай итте. Сулыш алулары җиңеләйгәндәй булды.

– Иравылны күзәтүгә җибәрегез, ялга туктыйбыз, – диде Токтамыш.

Төркем күздән дә югалмыйча әйләнеп тә кайтты.

– Елга буйлап безнең тарафка монголлар килә, – дип хәбәр салды яугир.

Әле ярый тугарылып өлгермәгәннәр иде.

– Ат өстенә!

Кылычлар кыныдан алынды, җәяләрнең җебе киерелде, калканнар күкрәккә ятты.

– Шаһ Тимер байрагы!

Баксалар, дөрестән дә алдамән кулында Шаһ Тимер байрагы җилферди иде.

– Җанбай, белешеп кайт, – диде Токтамыш, – сак булыгыз, байракның ялган булуы да ихтимал.

Мәсьәлә бик тиз ачыкланды. Ярты сәгать дигәндә, күрше углан Токтамышның чатырында иде инде.

[15] Энҗү – Аму-Дарья.

Кара тут йөзле, тыгыз һәм таза тәнле мөлаем егет. Токтамыш яна танышының хатын-кызларга хас нәзакәтлеген ошатып житкермәде. Авызына бармак тыксаң да тешләмәс бу, бик юаш күренә, дип уйлап куйды.

Ләкин угланның авызыннан чыккан тәүге жөмләсе үк әлеге тәэсирне какшатты.

– Идегәй яугир буламын, үскәндә Кобогыл идем, пәридән булган анам. Итектә сакланган табылдыкмын, шуңа күрә мин кызгану, оят, ярату-яратмау кебек тойгылардан азат, бердәнбер табынган нәрсәм – көч!

Токтамышны угланның сүзләре түгел (әхлак аның өчен чит-ят иде), авазы сискәндерде, әйтерсең лә, калканга калкан орынды.

– Син кем, ничек пәйда булдың монда?

– Якын-тирәдәге башкисәрләр Шаһ Тимергә килеп сыена. Чөнки үзе башкисәр, – диде Идегәй, – син дә, мин дә шул өердән. Әлегә без аңа кирәк, хажәтебез беткәч, жә, артыбызга тибәчәк, жә, буып ташлаячак. Ләкин мин аңа андый мөмкинлекне бирмәячәкмен.

– Тартар теленнән табар ди, артык кыюланасың түгелме?

– Мин аның күзенә бәреп әйттем, бүген әле без дус, дидем, туасы көн өчен вәгъдә бирә алмыйм, дидем.

– Ә ул?

– Ахмак дустан акыллы дошман артыграк, – диде.

Хәйләкәр икән егетебез, кармагына каптырмакчы, дип күңеленә беркетеп куйды Токтамыш, без дә кибәккә алдана торганнардан саналмыйбыз.

Бу күзгә күренмәс эчке карулашу аларга әшнәлек корырга комачауламады. Яшьләр ич әле, күңелләре дошманлыктан битәр ашкыну, кызыксыну, минминлек белән тулы.

– Мин бер кизәнүдә кемсәнең гәүдәсен буйдан-буйга ярам, – дип башта Идегәй мактанасы итте.

– Ат өстендә миннән өстен чыккан яугир юк, – дип шапырынды Токтамыш үз чиратында, – хәнжәр атып, Алып батырның үзен дә мәтәлдерә алам.

– Әйдә, әүвәл минем осталыгымны күр, – берәр колыңны бирерсең, шәт!

Токтамыш башын чайкады.

– Үтерү башка, орыш башка.

– Алайса, синең егетлегеңне дә тамаша кылып булмый инде, бик күрәсе килгән иде.

Ахыр чиктә угланнар мәргәнлектә көч сынаштылар. Әйтерең бармы, куллары каты, күзләре очлы, бар уклар да мәрәдә[16*] кадалып калды.

– Син жарияләр тотасыңмы? – дип белеште Токтамыш, – өлеш чыгара алам, гыйффәт иясе кәнизәгем дә бар.

– Жарияләр тотарга мин әле никахсыз, – диде Идегәй, – шулай да минем ике чибәркәй озатып йөри.

Аның йөзенә серле елмаю кунды. Аннан әйтте:

– Бәйрәм ашы кара каршы, углан, минем чатырыма да рәхим ит, – диде,– берочтан чибәркәйләремне дә багарсың.

– Бик рәхәтләнеп, – диде Токтамыш, – ул чибәркәйләргә үзләрен күргәнче үк гашыйк булдым инде.

Идегәйнең чатыры Энжү-суга каратып корылган иде. Урыны матур. Нәкъ шушы турыда елга тау сукмагыдай әлмәкле төен ясый да, үр якка борыла. Янә борылыш, янә төен, гүя чуалган дилбегә.

Дастарханны бинһая зур келәм өстенә жәйгәннәр иде. Әшнәләр ачык һавада, чигүле күн мендәрләргә кырын яткан килеш кенә тәгамләп

[16] Мәрә – мишень.

утырдылар. Алларында иртән генә суйган симез куй ите өелгән. Чатагы белән Кырым шәрабы. Аны икесе дә үз итә икән. Хәмер телләренә йөгерде. Әле бер-берсен узыша-узыша кемнең күпме эчә алуы турында бәхәсләштеләр, әле аргамаклары белән мактаныштылар.

– Минем Тимгел чуарым Борак[17] толпар нәселеннән, – диде чама жебеннән ычкынган хуҗа, – канатлары да...

Токтамыш аңы тыңламый иде инде, урыныннан сикереп торды да:

– Минем теге чибәркәйләрне күрәсем килә, – диде.

– Фәрһад белән Ширинны әзерләгез!

Идегәй яугирларга хас житезлек белән үзен тәртипкә китерде. Токтамыш та төзәнгән-ясанган.

Аларны сөттәй ап-ак озынча чатыр янында көтеп торалар иде инде. Кушчы аякларына укалы башмаклар кигезде.

– Мәрхәбә, хуш киләсез, – диде тоткавыл углан.

Токтамышның күз каралары чыбылдык эзләп уңга-сулга бөтерелде. Ә анда, түрдә, бәлҗир эчендә мыр-мыр мырылдап ике арыслан таптана иде.

– Вәлә куәтә...

– Минем чибәркәйләр шушы инде, җә, ничек?

– Сыгылма билле, мимылдык гәүдәле сылукайларың бер якта торсын...

Токтамыш бу сүзләрне мыскыл каһ-каһәсе кушып әйтсә дә, аларда дөреслек күбрәк иде.

Тәңре арысланнарны  чын мәгънәсендә матурлык алиһәсе итеп яраткан икән. Мондый нәфис вә ыспай буй-сынны бары чабышкылар белән генә чагыштырырга мөмкин. Бусында да арыслан арыслан булып калыр. Өстәвенә, шушы нәзакәтле буй-сын энҗе-мәрҗәннәргә, алтын-көмешләргә биргесез затлы киемгә төренгән. Күр, ничек чин ефәге бизәкләредәй ялык-йолык киләләр. Ул аяк басулары! Шып та итми, әйтерсең лә, судагы балык. Үзләре кылтык, горур, тәкәббер.

– Хәзер, хәзер, сыйланырсыз, – дип сөйләнә-сөйләнә Идегәй читлекнең тәләкәсен келәсеннән арындырды.

Сөнгеләр алга суылды. Шунда ук кара кол көрдән-көр җәйранны читлек эченә кертеп җибәрде.

Җәйран сикермәк булып, гәүдәсен аякларына бөгеп салган иде дә, бу кысанлыкта котылу ихтималының юклыгын аңлап алды булса кирәк, куркынган күзләрен аргы яктагы адәмнәргә төбәде, гүя тартып алыгыз мине бу бәладән, дип әйтергә тели иде. Адәмнәрнең үз мәшәкате.

– Фәрһад, ник катып калдың, хәләлеңне кунак ит, кара, каршыңда нинди симез җәйран басып тора, – дип, Идегәй кулындагы озын таягы белән арысланны кыймшатмак итте.

Фәрһад иренеп кенә җәйран янына килеп басты. Ширин аны хуплагандай җинелчә генә ырылдап куйды.

– Хәзер тамаша башлана.

Идегәй кулларын угалады.

Арыслан башы белән генә җәйранны аяк астындагы комга этеп екты. Җәйран бик торып басмакчы, чәбәләнеп тә карый, теге ирек бирми. Инде әнә комда әрле-бирле тәгәрәтеп уйната ук башлады. Әле унга авыштыра, әле сулга. Үзе мыр да мыр.

Фәрһад тычкан белән мәтәләнгән мәче шикелле шаярды-шаярды да, читкә барып ятты. Аннан соң Ширин күнел ачты. Җәйран ни үле, ни тере, язмышын кабул итте булса кирәк, каршылык та күрсәтми, бәгырь.

Калганы күз ачып йомганчы хәл ителде. Фәрһад ыргытылган таштай корбанына ташланды да тешләрен муенына батырды...

[17] Борак – Мөхәммәд пәйгамбәрнең Миграж юргасы.

Түшкәне ул Ширин алдына өстерәп китерде.

— Бу тамаша йөрәкне ярсыта, рәхмәт, — диде Токтамыш, — искиткеч мавыктыргыч, жарияләрен бер якта торсын.

— Чыңгызханның мәшһүр жиһангиры Сүбәдәй баһадурдан килгән шөгыль, — диде Идегәй, — йөзләгән олау йөрткән аның жанварларын. Бума еланнарына кадәр булган. Яу алдыннан аеруча усалларын үз кулыннан ашаткан. Кансызлык, аяусызлык, үжәтлекләрен үзенә сеңдергән. Бу аңа жиңү арты жиңү китергән.

— Миндә кансызлык ерткычларсыз да түбәдән ашкан, — диде Токтамыш.

Ошбу сүзләрне ул тулысынча раслады.

Шушы ике-өч көн эчендә Идегәй белән Токтамыш бергә борын жилеге киптереп үскән күрше малайлар кебек бик тә якынлаштылар. Дуслыкны сөт белән юган кылычларын чәкештереп беркеттеләр.

— Мин сиңа Сыгнак[18] тәхетен яуларга булышырмын, — дип сүз бирде Идегәй.

— Мин сиңа бәкләрбәге вазифасын тәгаенләргә вәгъдә бирәм.

***

Мәликтимер хан атасы Ырыс Мөхәммәд чорында шактый кипшенгән гаскәрен янабаштан карап-тикшереп чыкты. Баксаң, яугирларның яртысын өлкән буын тәшкил итә икән ләбаса. Аларны күбрәк гаилә, бала-чага хәлләре кызыксындыра булыр. Яшьләрне табу, оештыру да күп көч сорый.

Токтамыш, һич белмәстән, ифрат та уңайлы шушы болгавыр чорда һөҗүм итте. Үзе уң кулда, Идегәй — сулда. Каланы бөҗрага алдылар, керү-чыгу юллары киселде.

Шунда ук Мәликтимергә чапкын Токтамыштан кискен таләп язуы китерде: «Хан, үчемне кайтарыр чак житте. Килеп миңа баш орсаң, бәлкем, исән дә калдырырмын. Югыйсә сине эт үлеме көтә. Вакытың иртәгә кояш чыкканда тәгәлләнә».

Мәликтимернең иреннәре бүлтәеп, бият рәвешенә керде. Шул халәттә уйга калды. Шактый озак уйланды. Атлар да таптаныша, пошкырына башлады хәтта. Даирә генә түзем, тораташтай катты. Шулай булмыйча, аларның да язмышы хәл ителә ләбаса.

Ниһаять, хан жәт кенә атыннан сикереп төшеп, гаскәре алдында а-ай итте дә, ярлык белән артын сөртте.

— Ярлыкны иясенә кайтарыгыз, минем жавабым шул булыр.

— Дөрес, — дип хуплады ханның гамәлен Балтачи карачы.

Беренче булып Сыгнакның яшь яугирлары һөҗүмгә ыргылды. Аларның шау-шулы тәртипсез ыргымы токтамышныкыларны куркуга салды, чигенә башладылар. Идегәй сүзендә тормаса, өченче тапкырында да хурга калалар иде мәгәр.

Идегәй сыгнаклыларның арка ягына төште. Көтмәгәннәр иде, чөнки арттан сугу яу кагыйдәләрендә түбәнлек санала. Намус саклап тора торган чакмы соң? Жиңү барсын да юа.

Тиздән каршына Мәликтимерне китереп бастырдылар.

— Әссәламүгәләйкүм, хан, әһлән вә сәһлән![19]

Бу мыскыллы сәламләү Мәликтимернең ачуын гына кабартты.

— Мин Күк Урданың кануни хакиме, бөек Чыңгызхан токымы вәкиле, — диде тәкәббер генә, — үз дәрәҗәмдәге гали затлар белән генә сөйләшүләр алып бара алам.

---

[18] Сыгнак – Күк Урданың ул вакыттагы башкаласы.

[19] Әһлән вә сәһлән – хуш килдегез.

Идегәй игътибарлы карашы белән ханны күз очыннан үткәрде. Асыл ата баласы кара булыр ди, чырае, чыннан да тач күмер чүлмәге. Мин-минлеге хәдтин ашкан, әйтерсең лә ул түгел, Идегәй әсир иде.

– Мин шул гали зат инде, – диде углан шул ук мыскыллы елмаю белән, – нинди үтенечең бар, рәхим ит.

– Юк, – дип күзләрен чекрәйтте хан, – син Мангыт мырзасы Балтачи карачы углы, шәрәфле Чыңгыз нәселенә бернинди мөнәсәбәтең дә юк!

– Башыңны тәгәрәтәсең килмәсә, ул залим бәндәнең исемен башка кабатлама, – дип кычкырды Идегәй.

– Атаең Балтачи мырза Күк Урданың бәкләрбәге, минем уң кулым, – дип үзенекен тезде Мәликтимер.

– Әсирне шаһзадәгә илтегез!

Токтамыш хан сарае ишек алдына иде инде.

– Табанымны үбеп, гафу үтен, – диде сүзләрен теш арасыннан сөзеп кенә, – җәт бул, кире уйлавым бар.

– Мин хан, – диде Мәликтимер горурлыгын җуймыйча, – гаделлек фәкать гадел көч сынашуда гына тәгаенләнә, рәхим...

– Син инде хан түгел, – дип зәңгәрләнде углан, сине җәза көтә, җәһел[20] вә явыз гамәленә җәдир[21] җәза!

Тирән чокыр казылган иде инде. Ханны шунда төшерделәр дә аягүрә күмделәр, агач төбедәй башы гына тырпаеп калды.

– Ыштаннарыгызны төшерегез! – дип боерды Токтамыш.

Иң беренче хан башы өстендә ул үзе хаҗәтен башкарды. Аның артыннан чират тора-тора яугирлары бушанды.

– Сасыга сасы үлем!

Мәликтимер ләм-мим сүз чыгармады. Нәҗескә баткан җәсәден кичке якта яланга чыгарып ташладылар.

Токтамыш ханның якыннарына, булышчы-ярдәмчеләренә дә рәхим-шәфкать күрсәтмәде. Кайсын астырды, кайсысының башын кистерде, күпләр җәза базында җәфа чикте.

Бәкләрбәге Балтачи мырза үлемен дар агачында тапты.

Токтамыш шунда ук Идегәйне чакырып китерде дә әйтте:

– Син бүгеннән бәкләрбәге, вазифаңа кереш!

– Балтачи мырзаның кем икәне сиңа билгеле идеме? – дип сорады Идегәй.

– Моның бер әһәмияте дә юк, җинүченең ихтыяры ихтыяр.

– Балтачи мырзаның язмышын мин, фәкать мин генә хәл итәргә хаклы идем, ул минем атам иде, – дип, ут чәчте Идегәй, – син әлеге гөнаһлы гамәлең белән мине бик нык кимсеттең.

– Мин вәгъдәмдә тордым, – диде Токтамыш исе китмичә генә, – калганы чүп.

– Һәм бу чүп сине минем кан дошманым итте. Юлымда очрасаң, башың җиргә тәгәрәр.

Идегәй кылычын уйнатып алды да, камчысын шартлатты.

– Пеләбәй, – дип пышылдады Токтамыш аның артыннан, – карап карарбыз. Кемнең башы очар әле.

***

Мамай башта Күк Урдадагы үзгәрешләргә битарафлык саклады. Ник дисәң, ул элек тә аерым яшәде, баш бирмәде. Хан алышыну аларның эчке эше. Тик озак та үтми, Токтамышның Мамай карамагындагы Ак Урда

[20] Җәһел – томана.
[21] Җәдир – тин.

жирләренә нәфесен сузуы турында хәбәр алды. Кереп-кереп тә чыккалый, имеш. Бу инде шаяру гына түгел.

Ул йөгертеп кенә Гарәпшаһ угланны дәшеп алды.

— Өлгер вә житез гаскәр тупла, аз булсын — берәгәйле булсын. Туган-үскән якларына чыгып китәсең, андагы чын хәлне өйрәнәсең, мәгълүмат туплыйсың. Иң мөһиме, Токтамыш ханның ышанычына кер. Кирәк-кирәксез кылыч уйнатма. Калганы турында кайткач сөйләшербез.

— Бурыч үтәлер!

Угланның күләгәсе дә күмелергә өлгермәде, Идел буе Ар кенәзе Никомедтан чапкын килеп тезләнде.

— Бәла, кенәз, әвенебезгә ут төрттеләр...

— Аңлатыбрак сөйлә, — диде Мамай, — уратмый гына.

— Мәскәү бугаздан алды...

— ?!

Төпченә торгач, шул ачыкланды: Мәскәү, татарларга юл күрсәтүне сәбәп итеп, Пьяна буендагы жиңелүнең үчен арлардан ала икән. Чапкынның сөйләвенә караганда, Түбән Новгород кенәзе Борис, кыш уртасында берниндИ кисәтүсез-нисез Ар жиренә басып кергән. Кар чорында урман кешесе сүлпәнләнә, мәшәкатьләрен онытып, аю шикелле йокыга тала. Тормыш тына. Шуңа күрә баскыннарга каршылык күрсәтүче булмый. Урыслар котырган эт рәхимсезлеге белән ваемсыз илне ерткычларча таптап-изеп чыга. Урман иленең мондый да кансыз, мондый да зәһәрле вәхшилекне, мондый да төпсез талауны кичергәне булмый әле.

Мал-туарсыз, ризыксыз калган авылларның капка баганаларында, кибәргә эленгән каеры бүкәннәрен хәтерләтеп, ир-атларның гөнаһсыз гәүдәләре тибрәлә.

Мамай ярдәмгә Бигәч мырза төмәнен жибәрде. Төмән килә-килешкә Түбән Новгородның ташын-ташка аерып, каланы канга батырды. Кенәз Дмитрий Суздальский качып яткан жиреннән: «Барымтаны күпме сорасагыз да түлим, зыян гына салмагыз», — дип хәбәр жибәрсә дә, игътибарга алмадылар. Чөнки Мамай бәк: «Иясенә өргән этнең урыны — үләксәлек», — дип кисәтте. Бу исә әсир алмаска, мал-мөлкәткә кул сузмаска, урынында тар-мар итәргә дигән сүз иде.

Бигәч мырза күп орышларда катнашып танылу алган төмәнбаш иде. Аның яу елгасы гел уңайга ага. Андыйлар турында: «Эше ком тибә», — диләр. Ул үзе дә бу йолдызлы ырыскалдан[22]* үз-үзенә гашыйк иде.

Түбән Новгородтан туры Рәзәнгә юнәлде углан.

Дмитрий Московский борчуга төште. Чөнки Рәзәннән Мәскәүгә кул гына сузмалы. Татарларның Мәскәүгә һөжүме исә абруена сугачак. Чөнки ул болай да какшый башлаган иде инде. Үпкәли алмыйсың. Куркыныч янаган саен Кремльне ташлап кит әле?!

Ошбу хәлне бары жиңү, уңышлы орыш кына төзәтә ала. Шуңа күрә җиң сызганып гаскәр туплау хәстәренә кереште. Вакыт тар, өлгерергә кирәк. Шөкер, кайсын көйләп, кайсын чөйләп мәсләгенә иреште. Хәтта тискәрелеге белән даны чыккан Тверь кенәзе дә киреләнеп тормады, воеводасы беренчеләрдән яу сызыгына басты.

Олуг кенәзнең кыска гына арада мондый яхшы коралланган ишле гаскәр туплаганы юк иде әле.

Сентябрь урталарында Дмитрий Вож елгасы буена килеп урнашты. Көннәр коры иде, юллар ачык. Жылы. Сугышчыларның дә кәефе шәп.

— Ходай безнең белән, барысы да әйбәт булыр, — диде кенәз Пронский.

---

[22] Ырыскал – бәхет.

— Бирсен Ходай!

Бигәч тә озак көттермәде. Иң беренче ялан уртасында чиркәү гөмбәзедәй балкып утырган ак чатырны шәйләп алды.

— Олуг кенәз безне табын корып көтеп утыра икән ләбаса, — диде, — урыс хәмере гайрәтле була, баш тартмабыз, шулай бит, бөркетләр?

— Афәрин, түмәнбаш!

Яугирларның авызлары ерылды, углан вәгъдәле кеше, сүзендә торыр.

— Мырза, ян тупланны бу якта калдыру мәслихәт булмасмы? — диде уң углан, — тозакка эләкмәгәек, нигәдер күңелгә шик керде, чатырдан гайре ник бер җан иясе күренсен?

— Посып яталар, ха-ха-ха...

Яу бер ыргымда елгага ташланды.

— Һо-һо-һо!

Ул арада, тоташ дулкын булып, үзәнлектә яшеренеп торган урыс гаскәрләре күтәрелде. Ыжгырып киләләр, әйтерсең лә гарасат кубарган кара болыт. Алдавыч чатыр бөтенләй читтә калды.

— Алда мәҗлес көтә! — дип кычкырды мырза.

Мәскәүлеләр арага килеп кергән иде инде. Татарның үз алымы белән килгән шәпкә орышны үз кулларына алдылар: кыралар, изәләр, таптыйлар.

Түмән бүлгәләнде, аны янәдән бербөтен укмаштыру мөмкинлеге дә бетте. Чигенер иде, урын юк, артта — елга.

Татарлар инде мантымады. Бигәчнең минминлеге, тәкәбберлеге хурлыклы җиңелүгә китерде. Елга татар каныннан алсу төскә керде, өч көн, өч төн сал бүрәнәләредәй үле гәүдә акты.

Бу — 1377 елдагы Пьяна фаҗигасенең бер елдан соң Вожда кабатлануы иде. Рольләр генә алышынды.

Бигәч мырза гарьлегеннән булат хәнҗәрен күкрәгенә батырды.

Урысларның 1224 елда башланып, йөз илле дүрт елга сузылган дәвамлы җиңелүләреннән соң, Дмитрий, ниһаять, тәүге уңышка иреште, кечкенә генә булса да татар тупланын тар-мар итте.

— Ходай догаларыбызны ишетте, — диде олуг кенәз, — православиегә дан!

Арлар онытылды.

***

Казан дигән капкасы биек таш кала Мамайның колагына сөт анасы Карөлек сөйләгән риваятьләрдән кереп калган икән. Бихисап күп әкиятләр, кыйссалар, төрледән-төрле бәетләр белә иде. Ә ул, булачак яугир, билгеле инде, яу, орыш, җәя, ат, сугыш яраглары белән саташа иде. Шуңа күрә еллар үтү белән, сөт анасының әлеге мавыктыргыч хикәятләре дә онытыла барды.

Ни хикмәт, теге чактагы могҗизаи җеназа хәлләреннән соң хәтере ачылып китмәсенме.

Вакыт-вакыт уч төбендәге сырлары капылт кына җанланып куя да, күз алдына күптән хәтер төпкеленә төшеп югалган вакыйгалар янә күз алдына килеп баса.

Казан да шушы ачылышның бер буыны иде.

***

Габдулла хан катына нииндидер кыр кирмәне ягыннан килгән илчене керттеләр. Сакал-мыегы, чәче тоташтан җирән төстә, әйтерсең лә, башына бакыр чиләк кигергәннәр. Шуңа бәрабәр үзе дә тәкәббер икән.

— Бүгеннән безгә штат[23] түли башлыйсың, хакимебезнең фәрманы шундый, — диде тупас кыланчыклык белән, — әгәр риза булмасаң, Алатауга орышка кил.

Хан кешеләрен жыйды да сорады:

— Нишлибез, штат түлибезме, әллә сугышка чыгабызмы?

— Сугышсак, кырылып бетәрбез, көчебез чамалы, — дип жаваплады тегеләр.

Габдулла илченең борынын, колакларын кистереп, иленә озатканда әйтте:

— Бар, әйт хакименә, штат түләргә ризалыгым юк, килсен Алатауга, — диде.

Алатауда Габдулланы көтеп торалар иде инде. Санап бетергесез яу. Хан шүрләп калмады, дошманнары өстенә ыргылды. Яртысын дөмектерде, яртысы качты.

Арыган иде, атын бушатты. Ияр-тугымын башына, садак-укларын янбаш астына куеп, йокыга талды. Яугирлары да аңа иярде.

Бер заман уянып китте бу... һәм күрде, Тауны янә кыр-кирмәннәр камап алган.

Сугышырга караса, коралын алганнар. Аты да юк. Аны шундук тәртәгә бәйләделәр. Бераздан коега салып, авызын таш белән каплап куйдылар.

Бу көннәрдә Габдулланың анасы түшләнеп ята иде. Түшендә улының ике күзе юклыгын күрде. Габдулланың өлкән улы Алтынбәкне чакырды да әйтте:

— Жә, балам, — диде, — атаеңның ике күзе дә югалган. Кыркирмәнлеләр кулга төшергән булыр. Нишлибез? Шәһәребез Болгар да, адәмнәр дә ятим калды. Син әле бик яшьсең.

Алтынбәк әйтте:

— Мин барам!

Карчык:

— Барсаң, сиңа толпар бар, аны тотарга кирәк, — диде. — Әнә, сондыкта яу киеме, алып ки. Әнә ияр-тугым, атыңны иярлә. Әнә садак, аны ал.

Чыгып китте егет яуга. Алатауда бер адәмне очратты. Теге — борыны, колаклары киселгән бакырбаш илче иде бу.

— Кая минем атаем? — дип сорады Алтынбәк, — әйт, әйтмәсәң, мин сине үтерәм.

Илче әйтте:

— Табып бирәм атаңны, берүк үтермә мине, — диде.

Алып китте угланны теге кое янына.

— Менә шушында салдылар атаңны.

Алтынбәй иң элек кое авызындагы ташны алып ташлады. Аннан соң озын аркан төшереп, Габдулланы чыгарды һәм борынсыз илчегә әйтте:

— Ханны сарайга илтеп куй, — диде, — вазифасында булсын.

Алтынбәк үзе Кыркирмәнгә юнәлде. Керде бу Кыркирмәнгә. Хаким таныды Габдулланың улын. Качып китте.

Алтынбәкне хакимнең кызы каршы алды, аш бирде. Углан аны ашады да, хакимне куа чыкты. Тегесе атының башын борды.

— Бир кизәгемне[24] — диде.

Бирде кизәген углан. Хаким угын атты. Ук угланның тугыз кат киеменең жиде катына кереп туктады.

Алтынбәк әйтте:

— Инде кизәк минеке, — диде, — бир кизәгемне.

[23] Штат – ясак.
[24] Кизәк бирү – сугыш башлау йоласы.

Ук хакимнең сынын үтә чыгып, кара ташка барып кадалды.

Углан аның атын алып, кыз янына кайтты. Кыз атасының үлгәнен шуннан белде.

– Мине дә үтерәсеңме? – дип сорады.

– Мин сина өйләнәм, – диде углан.

Кыз аш бирде тагын. Аш ашап утырганда, хакимнең элекке теләктәшләре килде. Кызның Алтынбәкне алар янына чыгарасы килмәде, елый ук башлады.

– Үтерәләр алар сине!

Алтынбәк кызның сүзен тыңламады, атына атланып, тегеләр белән сугышырга тотынды. Кырып бетерде биш йөз орышчыны.

– Хакимебез бул, батыр шаһзадә, кызыл тунлы Хәдичә чибәрне куенына керт, – дип тез чүкте җиңелүчеләр.

– Мин тәхет варисы солтан, – диде Алтынбәк, – монда бүгеннән ирекле әмирлек игълан итәм.

Яшь әмир иң беренче эш итеп кирмәнгә керү юлында биек таш капка төзетте. Аннан соң чират җәмигъ мәчетенә житте. Мәчеттә туган энесе Галимбәк имамлык итте.

Казансу ярында яңа шәһәр калкып чыкты. Шәһәрне елга исеме белән Казан дип йөртә башладылар...

Мамай бәкне күңел күзе сөт анасы сөйләгән риваятьләр кысасында гына йомылып калмады. Буй житмәгән жиргә уй житә ди, хыял канатларында ул үзе дә Казан дигән ак калага очып барып кунды.

Казан дөрестән дә капкасы биек таш кала икән. Кирмәнен генә күр, ак кул могжизасы ич! Жил дә үтеп кермәслек итеп төзелгән. Корылмалар нык, ыспай. Уентыкларда, капка ышыкларында энәдән-җептән киенгән кораллы сакчылар арлы-бирле йөренә. Шунда ук диварлар тезелешкән. Имәне дә, ташы да бергә уралган.

Чат саен манара. Күк белән җир шул манараларда тоташа.

Болар керфек каккан арада гына чалынып киткән күренешләр. Игътибарны беренче чиратта шушы купшы вә төзек каланың гөр килеп торган тормышы җәлеп итә. Әнә, шыңгырдап зур капка ачылды. Шунда ук ишек алдыннан атлы сак күзәтүендә төяүле олаулар килеп чыкты: бер, ике, өч... Җәмгысе унике олау. Никадәр мәшәкать, дөягә генә асасы лабаса, дип уйлап куйды Мамай.

Каланың түбәнге өлешендә, елганың сулъяк ярындагы манзара аның бу тәнкыйди фикерен су кебек юып алды.

Менә нинди була икән ул чын кала!

Никадәр алачык, никадәр остаханә – искитмәле. Бистә һөнәрчеләр кулында. Чүлмәкчеләр, коючылар, тимерчеләр, коралчылар, балта осталары, дирбиячеләр – һәммәсе шөгыльдә.

Елга үзе дә шау-шулы тормыш белән яши икән. Жилкәнле көймәләрдән кызыл мал бушаталар. Күренеп тора, әмирлектә сәүдәнең урыны сәке башында.

Балыкчылар җәтмәләрен җыя, табыш мул булырга охшый, авызлары ерык.

Ә бусы нәрсә? Бүрәнә кәрваны! Агым уңаена агызып алып китәләр булса кирәк. Башлары йомры казанлыларның. Далада чыра да исәптә. Монда бүрәнә ярга сыймый.

Манзара кылып йөри торгач, Мамай Казансуга коючы инеш тамагына килеп туктады. Инеш буалы. Буага ниндидер корылма утыртылган. Аңа ике-өч колаклы куласа көйләнгән. Су шул бинаһая зур тәгәрмәчне әйләндерепме әйләндерә.

– Ни-нәрсә бу? – дип белеште Мамай колак-борыннарына кадәр ак тузанга баткан адәмнән.

Ул бу сәер яугирны шаярта дип уйлый иде, күрәсең, үзенең дә күзенә шук дулкын кунды.

– Тегермән, әфәндем.

– Нәрсә ясыйсың соң?

– Он.

– Нәрсә соң ул он?

– Коры боламык.

– Әйдә, күрсәт әле.

Мамай йөри-йөри үзе дә тегермәнче рәвешенә керде: мөшкәдән аккан кайнар онны төрлечә кыландырды, учларында да буташтырды, кабып-иснәп тә карады. Бик канәгать калды.

– Мин сине үзем белән Урдага алып китәм, тегермән корырсың, – диде яңа танышына.

– Анда иген үстерәсезме соң? – дип белеште тегесе.

– Юк.

– Иген юк икән, тегермән дә юк.

– Алайса, рәхмәт йөзеннән менә бу алтын тәнкәне учыңа йом, бездә ул зур байлык.

Тегермәнченең күзләре уйнаклады.

– Ай-вай, әфәндем, «акча» аһ белән чаһ сүзләреннән ясалган бит ул, – диде онлы керфекләрен челт-челт тибрәткәләп, – бездә чокырны «чаһ» дип йөртә укымышлы адәмнәр. Бу исә акча кабергә кертә дигәнне аңлата, фаразан...

– Баш тартасыңмыни?

– Юк, юк, әфәндем, әс-пес, артың кыс, булмаганны тегe, бу хәзинәдән баш тартсаң, Алла каргар. Исем-атыңны да әйтсәң, әфәндем, гомер бакыена кемгә дога кылганымны белеп үләр идем ичмасам.

– Бар, Хәсән әмиргә әйт, Казанга Олуг Олысның түләге[25] Мамай бәк килгән, диген.

Тегермәнченең табаннары гына ялтырап калды.

Ул арада ахшам житте. Каравыл алышынды, шәһәр капкаларына йозак эленде.

Күп тә үтми, төн пәрдәсен ертып, тау башында учаклар кабынды, шәһәр балкыш кочагына керде. Шушы нурлы балкыш яктысында әмир Мамай алдына килеп тезләнде.

– И, кояш чыгышыннан кояш баешына кадәрге Идел-Иртеш җирләренең алыштыргысыз мәликәнә боерыкчысы, җиңелү ачысын белмәс бөек җиһангир, хөрмәтле Мамай гурген[26]. Сиңа үз биләмәләреннән берсе – турылыклы вә фазыйләтле Казан Болгары иленнән, дәхи дә үз исемемнән эчкерсез ихтирамымны белдерәм...

Хәсән мәдхиясе барышында елмаюлы күзләренең чите белән генә олуг кунакның йөзен сыйпап узды: беләсе килә, сәламләве хакимнең йөрәгенә ятамы, шытым бирәме, риза-бәхилме?

– Син, әмир, ике йөзле пычак – дип туктатты аны Мамай, – мулла янында мулла, юрга янында юрга.

Хәсәннең муен алмасы кузгалып куйды, тәкерегe кече теләнә сыланды. Ошбу сүзнең кузгалуы һич тә рәхим-шәфкатькә өмет уятмый иде.

– Мин хатамны төзәттем!

[25] Түләк – патша.
[26] Гурген – хан кияве. Әлеге шәрәфле исемгә Чыңгызхан токымы кәләшләре белән никахлашкан кияүләр лаек булган.

— Төзәтергә мәҗбүр булдың, — диде Мамай, — чөнки мин кенәз Суздальскийны сиңа каршы яу чаптырдым.

— Акылга утыртуыңа рәхмәт, хаким, башка бу хәл кабатланмас. Ант эчәм.

Хәл дигәне Хәсән әмирнең Урдага хыянәт итеп, Сарай ягына чыгуы иде. Һәм ул моны аңлы рәвештә эшләде. Урда белән Сарайны маңгайга-маңгай бәрелештереп, Казан Болгарын алардан читләштерү һәм ахыр чиктә мөстәкыйль дәүләт буларак игълан итү иде. Тик хәйләсе барып чыкмады.

— Казан илен үз күзем белән күрмәсәм, мин сине баскан җирендә асып куярга боерган булыр идем, — диде Мамай, — бәхетең бар икән.

— Бәхетем булмаса, Болгар тәхете тәтер идеме?

Әмирнең авызыннан бу җөмлә тиктормас кош баласыдай үзеннән-үзе очып чыкты. Борчылуы урынлы иде, ник дисәң, Булат Тимерне үтереп иреште ул әлеге дәрәҗәгә. Ул чакта Урда моңа әллә ни зур игътибар бирмәде. Чөнки Булат Тимер дә Болгарны Алтын Урдадан аерып алмакчы иде.

Әңгәмә кайсы юнәлештән китәр — бер Алла үзе генә белә.

Мамай көтмәгәндә әлеге куркыныч теманы сикертеп узды.

— Күрәм, утрак көнкүрешнең җаен тапкансыз, тормышыгыз хәлле, — диде ул ачыла төшеп, — әле акча сугарга да өйрәнгәндерсез, ә?

Аның коңгырт күзләре ауга чыккан арысланныкы кебек чекерәеп, даирәне капшап узды. Юк, бу ачу түгел, читләтеп төрттерү генә иде. Хәсәннең үз исеменнән акча сугуы сер саналмый. Казан Болгары эчендә йөрүче бу тәнкәләр тулаем мәмләкәткә бернинди куркыныч та тудырмый. Киресенчә, файда гына итә. Акча бит ул сәүдә дигән сүз. Ә Казан чит дәүләтләр белән алыш-биреш коруга бик маһир. Бу яктан да абруе зурдан. Урдага әмирлектән шактый табыш керә.

Шулай да вассалларны үсендерергә ярамый, аларны тышауда тоту хәерлерәк.

— Җә, күрсәтегез тәнкәләрегезне! — диде Мамай, сарайга кергәч.

Казначы, орчыктай төз гәүдәле, сирәк сакаллы карачы, җилән итәкләрен җилфердәтеп җәт кенә тәбәшәк өстәлгә бизәкле тартма китереп куйды.

— Ошбу тәнкәләрне без үзебезнең остаханәдә сугабыз, рәхим итеп кара, Түләкә.

Казначы билен бөгеп, катып калды, ә кунакның куллары тәнкәләргә сузылды. Иң әүвәл учында Хәсән әмир акчасын әйләндергәләде. Күр, нинди тәкъдимнамә уелган: «Хәсән бәк хөрмәтле Солтан, Бөек Әмир, Җинүче, Боеручының ярдәмчесе».

— Боеручы бик киң төшенчә, әмир, койрык болгарга урын күп.

— Минем Боеручыларым Син нәкыйбел әшраф Мамай гурген һәм дә тәхеткә рәсми фатиха биргән Мөхәммәд Бүләк хан, — диде Хәсән тантаналы төстә, — мин фәкать Аның вә Синең генә вассалың.

— Янә ялгыштың, — дип көлемсерәде Мамай, — Алтын Урданың намус аклыгы, әдәп-әхлак үрнәге, гыйлемлек өлгесе мәшһүр Үзбәк ханның оныкчасы, хөрмәтле Җанибәк ханның кызы, мөхтәрәм Бирдебәк ханның туганы, минем хәләл җефетем Толымбикә галиҗәнаплары бердәнбер Мәликә-солтан. Толымбикә ханбикәнең исеме Җучи Олысының үз исеменнән тәүге мөстәкыйль акча койган Мәңгетимер хан тәнкәсе кебек үк мәңгеләштерелгән.

— Казначы, бүгеннән Алтын Урданың алсу кояшы мөхтәрәм Толымбикә ханбикә галиҗәнаплары исеменнән көмеш тәнкә суктыра башлыйсың, — дип, Хәсән чираттагы биремен янгыратты.

Карачының сакал төкләре күсе койрыгыдай йомарланып, ияк уемына ятты. Әмир күрәләтә үтәлмәстәй фәрман бирә ләбаса. Бүгеннән, имеш, мона ким дигәндә ярты ел вакыт кирәк. Җавапны исә ана тотарга туры киләчәк. Җөмләдән, әмир башы түгел, аныкы очачак. Хәер, каршы сүз әйтсәң дә шундый ук язмыш көтә. Дәшми калуын мең өлеш артык, җае чыгар әле.

Казначының бәхетенә күрә, Мамай Казанда Толымбикә ханбикә исеменнән акча сугу мөнәсәбәтендә төпченеп тормады, әмма хатынын олылауларына күнеле булды, хәтта тел очына шигырь дә кунды.

Белмимен, нидер сочем, каршында и күз нуры,
Әйләрем гыйшкың лә былбылдай фәган сәхәр шаһы.

Урда хуҗасының матур сүз тезмәсенә тартылуы күпләргә мәгълүм. Аның сәбәпләре турында гайбәтләр дә йөри. Толымбикәнең никахка ризалыгын алгач, Мамай артык һаваланып китеп, көйсез кияүгә әверелгән, имеш. Кәләшен үзенчә биетергә, бер дә юкка йөгертергә омтыла башлаган бу. Бер шулай кыз янына кияүли килгәч, атын әрәтәгә бәйләткән дә йомышчы гасәбәгә:

— Атыма печән сал, — дип боерган.

— Салдык, — дип җаваплаган тегесе.

Кияү моның белән генә канәгатьләнмичә, Толымбикәгә мөрәҗәгать иткән.

— Барчы, атым печән ашый микән, карап керче, — дигән.

Тагын бераз утыргач:

— Атым уң яктан ашап туйгандыр, барчы, гасәбәгә әйт, әрәтәнең сул ягына күчереп бәйләсен, — дигән.

Ошбу үтенеч тә үтәлгән. Кияү егете генә һаман тынычлана алмый, имеш.

— Барчы, кәләшем, атым көйсезләнмиме? Башыннан йөгәнен салмаганмы, карап керче, — дигән.

Толымбикә йомышчы адәмен чакыртып алган да кияве алдында:

— Барчы, көйсезләнгән кияүнең йөгәнен алып кереп, кулына тоттырчы, — дигән, — юлына ак җәймә.

Әлеге сүзләр Мамайның башына кан булып сауган. Ифрат китеп[27], киртә сикергәнен бик тиз аңлап ала һәм кәләшенең аяк астына егыла.

— Ханәкә, битем белән җир себерергә дә риза, зинһар, мине кире какма, — дип ялбара кикреге шиңгән кияү кәмәше.

— Мин хан кызы, бите белән җир себергән егеткә никахлашу зур түбәнчелек булыр иде, — ди кыз өстән генә карап, шартларны мин тәгаенлим, таләпләрне дә мин куям. Күрәм, онытып җибәргәнсең син аларны.

— Юк, юк, ханәкә, онытмадым, — дип элеп ала мырза, — башка никахка кермәскә, кул күтәрмәскә, сиңа мәҗүсиләрчә табынырга...

— Шуларга яңасы өстәлә!

— Бик рәхәтләнеп, солтаным, үтәргә әзер!

— Миңа атап шигырь-мәдхия чыгарасың. Вакытың бер атна. Хәзергә хуш!

Дөреслеккә туры киләме бу, юкмы, Алла белсен. Тик Толымбикәнең җыр-моңны, шигъри сүзне яратуы берәүгә дә сер түгел. Бу чирен ул иренә дә йоктырды. Алар катында китап ин кадерле хәзинә санала. Вакыт табып, шигъри табышмаклар әйтешәләр.

[27] Ифрат китеп — чама югалту.

Бу гыйшык бер бәладер, кем башыгы килмәйдер,
Бикадер йөргән адәм гыйшык кадерен белмәйдер.
Бигашыйк халаеклар гашыйкларны сүзләйдер,
Гашыйк кадерене белгәннәр яхшылыкка күзләйдер.

— «Шаһнамә», — дип авызын ерды Мамай, — «Шаһнамә»!

— Рәхмәт, сөендердең, — дип яз кояшыдай балкыды Толымбикә. — Сиңа Сарай шагыйре Котби белән танышырга да вакыт җиткән икән ич.

— Чакырып китерик соң.

— Юк, мамучым, Шагыйрь Пәйгамбәр дәрәҗәсендәге зат. Аңа баш ию безгә фарыз.

Шагыйрь үз өендә баштан-аяк коралга уралган угланны күргәч, гаҗәп калып, аптырып китте. Гадәттә аның тирәсендә хәлфә-шәкерт, галим-голәмә ише зыялылар мәш килә. Араларында каләм тибрәтүчеләр дә шактый. Бер-берсенә иҗтаһад җимешләрен укыйлар, әңгәмә коралар, бәхәсләшәләр, котлашалар, мактанышалар...

— Ни йомыш, углан, бу игътибарның төбендә ни-нәрсә ята? — дип белеште, — тыңларга әзермен.

Мамайның башына килгән тәүге уй: «Кара, тавышы нинди моңлы, гүя җыру суза» — дигән уй булды.

Кырма сакал-мыегына әле чал кунмаган, йөзе ак, күзләре дала кешеләренекенә охшамаган, зур. Урта Идел кешесе икәне менә мин дип тора. Яшел төстәге киң җиңле бизәкле хөлләсе дә, чит-читләре укалы күк камзулы да, башындагы чалма рәвешендә уралган ак бүреге дә әле өр-яңа.

Бүлмәсе нәкъ шөгыленә тәңгәл рәвештә җиһазланган. Кәнәфиенең янъягында затлы ике бүкән. Уң ягындасында — китаплар, сулдагысында язу әсбаплары: каләм-каурый, кара савыты, кәгазь...

Мамай боларны бер күз сирпеп карауда күңеленә сурәтләп куйды. Инде хуҗаның соравына җавап бирергә кирәк иде.

— Безне, бигрәк тә хәләл җефетем Толымбикә ханәкәне синең яңа газәлләрең кызыксындыра — диде дә кыюсыз гына тукталып калды. Чөнки әңгәмә газәлләр турында түгел, аерым әсәр турында булырга тиеш ләбаса.

Сүз бушлыгын Котби тутырды.

— Турысын әйтим, углан, мин ханәкәнең бу киртәне атлап чыгуына өмет итми идем, — дип, шагыйрь кулындагы китабын кулыннан төшерде. — Хәлбуки, гыйлем иясе хатын-кызның «Хөсрәү вә Ширин» мәҗмугасына тартылуы гайре табигый хәл түгелдер. Дәхи дә кыйсса башыннан алып, ахырына кадәр туташларыбызга олы ихтирам белән сугарылган күвәи[28]* шигърия. Аннары соң, кыйсса барыбызга да аңлаешлы татар телендә язылган беренче әсәр. Бу татар теленең байлыгын, мөкәммәллеген дәлилләүче үтә дә олуг мисал.

Әле менә гарәп сәяхәтчесе Ибне Баттутаның юлъязмаларын укып утыра идем. Безләрне бик мактаган, һәм хаклы мактаган. «Татарларның, — дип ассызыклый, — хатын-кызга олуг хөрмәт күрсәтүенә шаклар каттым. Ир-ат белән чагыштыргысыз зур хөрмәт үзләренә».

— Нинди киртә турында сүз бара соң алайса? — дип сорады Мамай. Ул әңгәмәдәшенә иҗләнеп өлгергән иде инде.

Котбинең саргылт-кара күзләренә катгый җитдилек кунды. Бераз уйланып торды да әйтте:

[28]* Күвә – куәт, көч.

– Мин бу касыйдәмне[29] Тәнибәк хан галиҗәнапларына багышлап чыгарган идем. Тел төбемне анлагандырсың, шәт.

Анладым, анламаган кая, дип уйлады Мамай, – без бу киртәнең капма-каршы ягында торабыз икән ич.

Аның Тәнибәк ханны күргәне дә булмады. Тик барыбер дошманга саный.

Мәгълүм, Үзбәк хан исән вакытында ук олы улы Тәнибәк шаһзадәне тәхет варисы дип игълан итә. Вафатыннан соң исә әлеге варисның атасына каршы юнәлтелгән кырын эшләре ачыла. Ханның кече улы Җанибәк атасының үчен кайтара, агасының муенына бау сала.

Мамай Җанибәк ханга бирелеп, чын күнеленнән хезмәт итте. Хаким дә аны яратты. Кызы Толымбикә гүзәлне хатынлыкка фатихалап, гомерлек бәхеткә төендерде.

Толымбикә өчен исә шигъри сүз тылсымы кайчандыр булган тәхет низагларыннан күпкә өстен иде, күрәсең. Җиһанны каләм теле бизи. Ханнар киләләр дә, китәләр дә. Ә каләм теле – мәңгелек, буыннан-буынга сузылучы мирас.

– Ханәкә «Хөсрәү вә Ширин»ны каләмкәшкә[30] биреп күчертергә тели иде, – диде Мамай, – бу тәкъдимгә ничек карыйсың?

Котби балаларныкыдай кечкенә ак куллары белән кыска сакалын сыпыргалагандай итенде дә, көттерми генә җавабын да житкерде.

– Мөхтәрәм ханәкәнең минем әсәр белән кызыксынуына бик шатмын, аңа ихтирам сәламемне җиткер. Тәкъдименә дә унай карыйм. Тик бер шарт белән.

– Шартың нидән гыйбарәт, шагыйрь?

– Каләмкәшне үзем сайлыйм, шулай ышанычлырак булыр. Шуннан соң чыгым-түләү мәсьәләләрен килешерсез.

– Син теләгәнчә эшләрбез. Янә дә бер үтенеч.

– Рәхит ит.

– Толымбикә ханәкәгә атап бирәр газәл чыгарсаң иде.

– Үткәндәге фаҗигале хәлләрдән соң мин багышлама әсәрләр язудан ваз кичтем, – диде шагыйрь, – өлкәнәеп тә киләм, тиздән пәйгамбәребез яше дә сугар, Аллаһу боерса.

Мамай шагыйрьнең таушалмаган ыспай йөзенә карап хәйран калды. Ул аны үзе белән бер чор кешесе дип кабул иткән иде.

– Якташым, Камышлы бәндәсе Сәйф шагыйрьгә мөрәҗәгать итеп карагыз, – дип дәвам итте Котби, – ул кыска шигырьләр остасы, фәлсәфәгә дә, мәдхиягә дә теше үтә.

Бәдр[31] – дәүләт галәмә, – котлы йөзең,
Кем, белек бәхре[32] – үзең, җәүһәр-сүзең.

Кызганыч, тәкъдим тормышка ашмый калды, Сәйф Сараи Мисырга күченеп китте. Аның урынына Котби шигъриятенең асыл үрнәкләре Мамайлар катында «бисмилла» белән бер ояга керде.

Гыйшык берлә тәрәк ошбу галәм! –
Әгәр гыйшык булмаса, булмас иде адәм.

---

[29] Касыйдә – поэма.
[30] Каләмкәш – күчереп язучы.
[31] Бәдр – яңа туган ай.
[32] Белек бәхре – белем диңгезе

***

Кая карама, агачлар, агачлар... Очлары күккә ашкан, үзләре шырпыдай төз. Дала киңлегенә күнгән кеше өчен, әйтерең бармы, сәер манзара.

— Урман һавасы мең сырхаудан дәва, — диде Хәсән әмир, — сулаган саен сулыйсы гына килеп тора.

Мамай хәл-халәтен йөзенә чыгармады. Чөнки бу сәфәр аның теләге буенча оештырылды. Әңгәмә вакытында вак ырулар хакында сүз чыккач, алар белән якыннанрак танышу ниятен житкергән иде.

Хәзерендә Хәсәннең дусты чирмеш морзасы Чутай утарына барышлары. Иртүк кузгалганнар иде. Әле һаман ат өстеннән төшкәннәре юк. Бик кыздырып та булмый, төнлә янгыр явып үткән икән, аяк асты тоташ күлдәвеккә әверелгән, чәп тә чәп.

— Мондый хозурлыкта кәеф үзеннән-үзе күтәрелә, — дип, әмир һаман үзенекен тукыды, — килеп тә житәбез, әнәтрәк.

Чыннан да, урман сирәгәеп китте, рәт-рәт тезелешкән саргылт-кызыл чыршы кәүсәләре арасыннан яктылык чаткылары шәйләнде. Бишегенә төшеп баручы кояш та, ниһаять, соңлабрак булса да нурларын сибеп сәламлисе итте.

Аларны көтеп торалар иде инде. Халык күп. Барысы да аксыл керфекле, чепи күзле, ерык авызлы. Берсен-берсе уздырышып кычкырышалар, кулларын болгыйлар.

Шунда ук, җәй булуга карамастан, өстенә бөрмәле сары тун кигән уртачарак буйлы, какча йөзле кеше калкып чыкты да, башын борып, нидер әйтте. Халык бер тында җиргә ауды.

— Хуш киләсес, хөрмәтле кунаклар, бесләрне олылавыгыс өчен ихластан рәхмәт, күрегес, барыбысның да башы җиргә орулы, — дип, Чутай морза үзе дә тезенә чүкте.

— Чирмешләр татар теллемени? — дип сорады Мамай.

— Татар дәүләте кешеләре бит алар, — диде әмир, — телне белмәсең, ничек аралашасың ди?

Җыелган халык чират торып, Мамайның аягын үбәргә керешге. Соңгы кеше читкә тайпылганда аның каршында Чутай морза үзе басып тора иде. Янында егет белән кыз да бар.

Егетне баһадир дип әйтмәс иде. Гәүдәсе таманча гына, ә менә куллары тезенә кадәр төшеп тора. Көч-гайрәте шушы бүрәнәдәй юан шөкәтсез кулларында иде булса кирәк, уйнаклатып-уйнаклатып ала. Хәер, Мамайның карашы аның өстеннән шуып кына үтте. Бар игътибарын кыз үзенә йомып алды. Мондый җилвәгәр[33]* кызны беренче тапкыр күрүе иде. Бер уйласаң, дала җиләнедәй тоташтан аксыл чибәркәйләр дала якларында туарга тиеш кебек. Юк, дала сылулары карасу төстә, кырныкылар аксыл әнә. Чәче аксыл, кашлары аксыл, керфекләре аксыл, йөзе-бите аксыл...

Шул аксыллык түрендә чәтрәннәп зәп-зәңгәр күзләр балкый. Жаны да актыр, мөгаен, йөзне жанның көзгесе диләр ич.

— Улым Садир морса белән кәләше Әлинә бикә, — дип тәкъдим итте Чутай яшьләрне, — бүген туйлары башлана.

Әлинәнең кулында куна тактасы. Анда алсу төстәге ниндидер җанлы түмгәк дер-дер селкенгәли. Монысы тагын үзенә бер сәер күренеш.

Морза сәламләү тамашасын өзмичә-куймыйча җеп урынына суза.

— Мөхтәрәм, хаким, ир-егетнең ике юлдашы бар: берсе — батырлык,

[33] Җилвәгәр – нурлы.

икенчесе — тәвәккәллек, ди чирмешләр, — дип ул әлеге алсу түмгәктән бер калжа кисеп алды да, пычак очына элде, — бу яшь аюның тере йөрәге батырлыгына яна батырлык өстәр, кабып йот.

Калжадан соң, улы кулыннан агачтан чокып ясалган тустыганны алып Мамайга тоттырды.

— Бусы чирмешләрнең милли эчемлеге — көмешкә, ул сина тәвәккәллек өстәр, суламыйча гына авысына агыс.

Мамай чак тончыкмады, көмешкә дигәннәре чын мәгънәсендә сыек ут икән. Ә бераздан тәне буйлап кайнар дулкын таралды.

Инде Садир телгә килде.

— И, бөек угланнар угланы Мамай бәк! Бүген тәүге сөфаф төнен минем кәләшем белән бер түшәктә үткәрсәң иде. Бес сиңа гомер бакый рәхмәтле булырбыс. Улың туса да, кысың туса да кояшка табынгандай табынырбыс. Сүс бирәм, синнән соң кырык көн үтмичә хатыным катына аяк та басмам.

— Урман чирмешләренең иң олы ихтирам билгесе, — дип ачыклык кертте Хәсән әмир, — үпкәләтмә, йолалары шундый.

Мамайның күзе Әлинәне эзләп тапты. Кыз да аңа текәлгән иде. Оялу, кыенсынуның әсәре дә юк, фәкать кызыксыну гына. Гүя тәүге зөфаф төнеңне синең кебек иң мәртәбәле кунак кочагында үткәрү үзе зур бәхет, ыру өчен дә зур дан, дип әйтергә тели иде.

Мамай югалып калды. Дәүләти мәнфәгатьләр хакына итали җарияләр белән күрешүләрне исәпкә алмаганда, нәфесенең хәләле Толымбикә ханәкәдән кала, бер кыз-хатынга да кузгалганы булмады. Гадәттә хан ыруына мөнәсәбәтле гаилә әгъзаларының йорт-җирләре, чатыр-биләмәләре аеры-аеры. Бу, беренче чиратта, күпхатынлылык тудырган вәзгыять. Ир җәмәгатьләренә чиратлап йөри. Мамайныкы исә — бердән-бер. Шуңа күрә бергә яшиләр. Һәм ул, кая гына китсә дә, Толымбикәсе янына сагынып-ашкынып кайта. Алар яратышып туя алмый, наз эчендә эреп агалар.

Ходай Толымбикәгә гомерлек гыйффәт насыйп иткән иде. Ир һәр якынлыкта кызлык элпәсен ерта...

Бу җәһәттән Мамай хурга да кала язган иде.

Алар зөфаф төнен үтә дә бер ярсулы вә үҗәтлек белән зилзиләләр туздырып үткәрделәр. Кияү егете үз-үзеннән бик канәгать калды.

Икенче төндә исә... Аһ, ни бу, Толымбикә һаман кыз икән ич. Булдыра алмаган. Мәсхәрә!

— Мысыгым, мин, мин... алаша, — дип хатынының аяк астына ауды.

— И, Мамучым, шатлан, сине менә шундый бәхет көтә, һәр кичне кыз катына керәчәксең.

Әлеге могҗиза Үзбәк ханның өлкән хатыны Тайдула ханбикәдән, Толымбикәнең тәрбиячесе, яраткан картыеннан килә. Ханның калган җәмәгатьләре күпкә яшь булса да, Үзбәк күп вакытын Тайдула чатырында үткәргән.

Хикмәт шунда, Тайдуланың алка рәвешле түгәрәк аналыгы чәчәк тажы шикелле йомылу сәләтенә ия иде. Ә бу ир-атка гыйффәт булып тоела.

Әлеге гадәттән тыш сирәк күренешне үзенең юлъязмасында гарәп сәяхәтчесе Ибне Баттута теркәп калдырган.

Әлинә наз-сөешү ягыннан Толымбикә белән тиңләшә алмый иде. Әмма җир җиләге тәмлерәкме, кура җиләгеме, дигән сорау урынсыз булган кебек, әлеге очракта да чагыштыру нигезсез иде.

Әнә, ятактан читтәрәк зур балчык савытта чертли-чертли чыра бәйләме яна. Ул әле дөртләп кабынып китә, әле пыскып кала...

Бу үзе бер әкияти манзара. Ә янында актан-ак, пакьтән-пакь тәнле яшь кәләш...

Чын гасре сәгадәт![34]

Иртән ул Әлинәне ире Садир кулына тапшырды.

– Хәләл җефетең хур кызларына биргесез, күз караң кебек сакла, – диде, кимсетүеңне ишетсәм, рәхим-шәфкать көтмә.

Мамай кәләшкә энҗеле вә зөбәрҗәтле медальоннардан җыелган алтын чылбырлы тезмә бүләк итте. Әлинә бик ошатты.

Чирмешләрнең дә бүләге мулдан иде.

– И, бөек хаким, бес урман кешеләре, бүләкләребес дә урман хәсинәсеннән, – диде Садир морза, – менә бу иң сатлы тиреләрдән тегелгән бүрек һәм камсулны беснең исемнән яраткан җәмәгатең, хөрмәтлеләрдән-хөрмәтле Толымбикә ханбикәгә тапшырсаң, урман халкын чиктән тыш бәхетле итәр идең.

– Рәхмәт, бу бүләгеңне шатланып кабул итәм, – диде Мамай, – калганнарын җыелган кешеләргә таратыгыз.

Чирмешләрдән риза-бәхил булды бәкләрбәге. Хәсән әмиргә дә ачуүпкәсе бетте.

– Әмирлекне бүгенге көндә ни-нәрсә борчый? – дип сорады.

– Урыс ушкуйниклары, елга юлбасарлары, – диде Хәсән, – Болгар җиренә иң зур бәла-казаны шулар китерә. Идел-Чулман буендагы калалардан халык кача башлады. Казанның Иделдән читтә бина ителүенә дә шул куркыныч сәбәпче.

– Ярдәм итәрмен, – диде Мамай, – мин монда Гарәпшаһ угланны җибәрермен, ул бик тиз бугазларына басар.

## Көлберәмә, көн ана

*Сөт урынына кан койдың,*
*Канымны түгеп ни кылдың?*
«Идегәй» дастаны

Кояш үз кайнарлыгына чыдаша алмыйча аксыл төскә кергән иде, учак өстендәге казаннан ташыган сөт күбекләре кебек читләреннән ут төерләре ишелеп-ишелеп төшә.

Даирә менә өченче көн инде ау мәшәкате белән яши. Мөхәммәд Бүләк ханның кыр үрдәкләренә ау рөхсәте биргән ярлыкка имза салган көнне һәр елны шулай кош-корт биләмәләрендә зурлап билгеләп үтәләр. Бәйрәмнең үзенә генә хас йоласы бар: иярләр өзәнсез, садаклар буш, кош кына чөяләр. Анысы да бердәнбер – Бүз тойгын, ак карчыга. Шоңкарлар да, лачын-әтәлгеләр дә ял итә. Кан бары сугым вакытында гына чыга.

Иртәнге ау тәмам. Кошларны тугрыларга куандырдылар, давылбаз, далбай ише нәрсәләр дә үз урынын тапты. Арып-талып кайткан аучылар дәстәрханны урап алды. Аш-су ачык һавада әзерләнә, чатырларга таянып тору өчен генә кереп йөреш.

Аякчылар тыз-быз касә өләшә. Җиргә күмелгән сары бал чатагын да казып алдылар. Читтәрәк уенчылар кубызларын көйли башлады, субра ерау әнә су белән тамагын чайкый.

Мөхәммәд ханның да кулын чайкаттылар. Хәзерлек тәмам.

Хан җиңелчә генә башын кагып куйды. Бу аның мәҗлескә фатиха бирүе.

[34] Гасре сәгадәт – бәхет дәвере.

Уртага чичән атылып чыкты. Сүзен шигырь юллары белән башлап җибәрде.

Иргә дәүләт бетәрдә
Карга салса да каз булыр.

– Шөкер, дәүләтебез кыя ташыдай нык, яуларыбыз җиңүле, тормышыбыз мулдан. Әлеге җәһәттән без, Алтын Урда халкы, хөрмәтле солтаныбыз Мөхәммәд Буләк ханга вә дә яшәешебезнең ту-байрагы мөхтәрәм бәкләрбәге Мамай мырза...

Чичәннең сүзе өзелде, табын алдыннан кояш яктысын да күләгәдә калдырып, ут дулкыны сызылып үтте дә, нindидер чатнама әче тавыш колакларның ушын алды.

Башлар үзеннән-үзе күккә чөелде. Ә күктә кояш өстеннән карга оясы кадәрле генә бер кара болыт үтеп бара иде.

Икенче мизгелдә даирә чалкан төшкән бәкләрбәген күреп, һушсыз калды. Бер-берсенә карашып алдылар. Мамайдан кала барысы да аякта иде.

– Яшен, – диде Диван-би, – аяз көнне яшен!

Аннан соң җәт кенә ханны чатырына алып кереп китте.

– Ходай дәүләтебезне синең кулга тапшырды, – диде йөренә-йөренә, – бу бик яхшы фал.

Мөхәммәд Буләк тә сулышына керде.

– Халыкка әмеремне җиткер, – диде хуҗаларча нык вә ышанычлы тавыш белән, – ауны өзәргә боерык бирәм. Үзем хәзер үк Урдага кайтып китәм, җитәкчелекне, идарә рәвешен тамырыннан үзгәртү эшләре белән мәшгуль булачакмын.

– Шәт, бәкләрбәге вазифасы мина тәтер, – диде Диван-би, – дәүләттә сиңа эчәк-бавырлары белән бирелгән башка мырза юк.

– Карарбыз, – диде хан эре генә, – җыен, сине дә үзем белән алам.

Бу вакытта Мамай янында угланнар кайнаша иде.

– Җиргә күмеп карарга кирәк, – диде арадан берсе, – җаны кайтыр, бәлки?

Баш очындагы углан иелеп, колагын бәкләрбәгенең күкрәгенә терәде дә сулышын кысып, тынып калды. Баш бармагын тырпайтып, янындагыларны да кисәтте.

– Тс-с!

– Сулышы сүнмәгән, урын әзерләгез!

Чокырга сузып салганда ук Мамайның күз керфекләре җилпенеп куйды. Озак та үтми, күзен дә ачты.

– Мине икенче тапкыр җирлисез түгелме соң инде, бусында ни булды? – дип белеште.

– Яшен!

– Аяз көнне нинди яшен ди ул?

– Бәла анасы буаз, мырза.

Бу әйтем чын дөреслеккә туры килә иде. Кабыргалары ялганганга әле ай да тулмады ич. Әлеге дә баягы, каһәрле очраклылык. Анысы да аяз көнне булды. Көтмәгәндә, такыр юлда. Бәлане берәү дә көтеп алмый анысы, һәрвакыт капылт кына ишелеп төшә.

Мамайның Азактан, диңгез сәүдәсенә кагылышлы эшлекле сәфәрдән кайтып килеше иде. Толымбикә бөтен Урданы кузгатып, ирен каршыларга чыкты. Өслеге зәңгәр тукыма белән уратып алынган дүрт тәгәрмәчле, зур көймәле арба ерактан ук ялтырып күренеп тора иде. Көймәнең ачык

ишекләреннән күркәм буй-сыны да шәйләнә. Янында дүрт хаҗибәсе. Көлешә-көлешә гәпләшәләр.

Эскорт елгадай сузылган. Ханәкәнең хадимәләре төялгән арбалар артыннан сакчылар, киемчеләр, ат караучылар, кушчылар, йомышчылар атлый. Күчмә казанда ит пешә, учакка тизәк өстәргә генә өлгер.

Далада элек-электән хан даирәсендәге күчмә җыенның дәрәҗәсе гамәли чатырның зурлыгы белән билгеләнгән. Чатырың иркен икән – син абруйлы. Үзбәк хан, мисал өчен, йөз-йөз илле кешелек чатыр йөрткән. Толымбикә, билгеле, бабасы белән ярыша алмый, әмма тәгәрмәчләргә утыртылган бизәкле ак чатырын әнә ун көр дөя тартып бара.

Мамай җәмәгатен билгеләнгән урында көтеп тора иде инде. Толымбикә илле-алтмыш адым ара калдырып арбасыннан төште. Аны шундук туташлар уратып алдылар да озын күлмәгенең итәк очын чеметеп тоттылар. Һәм ханәкә суна үрдәктәй талпынгалый-талпынгалый иренә таба атлады.

– Бәк, исән-имин кайтуың уңаеннан җәмәгатең кулыннан шушы кымызны эчеп куй, мин сине һәрвакыттагыча сагынып көтеп алдым, – диде җиргә тезләнгән хәлдә, – тәнеңә сихәт иңсен.

Мамай, олы хөрмәт йөзеннән, кымызын эчеп бетермәде, саркытын хатынына тәкъдим итте.

Кымыз мулракка китте, күрәсең, бераздан кече хаҗәтенә тәкате бетеп, чатырына юнәлде...

– Аһ!..

Тавышка йөгереп килсәләр, бәк ташландык коры кое төбендә ыңгырашып ята. Кура каплап киткән кое урынын абайламаган, күрәсең.

Әйтерең бармы, имгәк аяк астында.

Хәзер менә яшен җиле. Кем каныкты, нигә каныкты – аңламассың.

***

Юзекәй мосафир Мамайның күләгәсенә әверелде. Тотам да калмый. Утырса – утыра, ятса – ята, барса – бара. Атка гына атланмый. Атны таягы алыштыра. Бәк кая китсә дә, кыштырдап килеп җитә.

Мамай бу эзәрлекләүләргә теше-тырнагы белән каршы, әлбәттә. Ачуланды да, янады да – тик ябышкак суфидан барыбер арына алмады. Чөнки Юзекәй зирәгрәк тә, хәйләкәррәк тә. Ул иң элек инде чынлап торып Толымбикәне үз ягына аударды. Сырхавын куганнан бирле алар дустанә мөнәсәбәттә. Мамай үзе дә мосафирны хатынын терелткән өчен якын күрә, сәерлекләренә түзә иде.

– Күкләр бәкне инде өченче тапкыр кисәтте, солтаным, чираттагысының бакый белән тәмамлануы мөмкин, көчләрне берләштерик, – диде суфи Толымбикәгә.

Ханәкә сынап карап торды да:

– Турысын гына әйт әле, синең нинди хаҗәтең бар соң бу хәлләрдә, мосафир? – дип сорады.

– Хөрмәтле вә мәрхәмәтле ханәкәм, – диде Юзекәй мамыктай йомшаклык белән, – янә кабатларга мәҗбүрмен, Ходай хәләлең Мамай колына дөньялыкта бик зур халыкчан вазифалар башкаруны фарыз кылган. Гамәлдә шул мәнфәгатьләр белән яши дә ул. Тик ялына ябыша алмаган койрыгына ябышып ерак бара алмас ди. Бәк хәзерендә, үпкә салма, нәкъ менә мәкальдәге халәттә. Алтын Урда дилбегәсе кулыннан ычкына бара. Бу Күкләрдә дә ризасызлык тудыра булыр, ник дисәң, хәбәр арты хәбәр: каһарманыбыз әле аттан мәтәлә, әле коры коега юлыга... әле яшен ега.

– Син, мосафир, сәбәбен нидә күрәсең?

— Динсез кеше, солтаным, зобанига әверелә.

Татлыбикәнең кашлары күз кабагында сынып калды.

— Ни сөйлисең син, мосафир, бабам Үзбәк хан заманыннан бирле Урда мөселман ягында лабаса!

— Кытайлар әйтмешли, бал дип күпме генә кабатласаң да авыз балланмый, солтаным.

Әңгәмә ике арадагы килешү белән төгәлләнде. Толымбикә суфины тагын да эзлеклерәк, тагын да кыюрак булырга чакырды, үзе дә булышырга сүз бирде.

Юзекәй, ниһаять, Мамайны ачыктан-ачык сөйләшүгә котыртып кертә алды.

— Син динле кешеме? — дип, кабыргасы белән куелган сорау кузгатып җибәрде аны.

— Биш вакыт намазга басарга өлгерә алмыйм, анысы хак, әмма дә ләкин шәригать кануннары буенча яшәргә тырышам, — диде Мамай.

— Шәригать диннең башлангыч адымы гына, бәк, — дип, Юзекәй бәхәс тезгененә ябышты, — иң мөһиме, Күк аңына ирешү.

— Минем уемча, һәр адәм баласы фани дөньяга үз Алласы белән аяк баса...

— Ләкин һәркем дә аны үз кальбендә тота алмый, — дип ялгап китте Юзекәй, — Аллаһы белән бербөтен булып кушылу бик азларга гына тәти. Моның өчен Исламның шәригатьтән тыш тарикать, мәгърифәт, хакыйкать... дигән баскычларын да үтәргә кирәк, барысы тугыз баскыч...

Мамай башын чөеп, күккә текәлде. Көн дә күрергә күнеккән гадәти күк. Һәрвакыттагыча, күз иң элек кояшка барып эләгә. Офык читендәме ул, өйлә баганасындамы, куянга атланган чагымы — тәүге игътибар шушы нур көлтәсенә юнәлә. Күк кояш биләмәсе. Ә Күк аңы? Димәк, Күк Тәңрегә тиң. Димәк, Күк кояштан өстен. Күк дөньяны үз дигәненчә кора. Коруын кора, әмма гаделме соң ул кануннар?

— Мин Аллаһыга бик елышып идем, мосафир, — диде Мамай, күзен күктән төшереп, — карашлар ябышып бетмәү кулдан тота.

— Ягъни...

— Аллаһы дигәндә, адәм гаделлекне күзаллый. Бактың исә, тормышыбыз тоташ гаделсезлек эчендә изалана икән ләбаса. Аллаһы нигәдер моңа юл куя. Мин булып мин гаделсезлеккә каршы киртә куя алмыйм. Алай гынамы, вөҗданлылык, оятлылык кешегә комачау гына. Әгәр бу калып-чикләүләр булмаса, яшәү күпкә гадиләшер иде.

— Мырза, беләсеңме, бу нәрсә?

— Әйт соң, нәрсә?

— Ак эт баласын кара эткә ягу.

Мамай сүзсез генә җилкәләрен сикертеп куйды.

— Әле син телгә алган әхлакый кануннарның бозылуында Аллаһының бер катнашы да юк, — дип шәрехләвен дәвам итте мосафир, — хәлбуки, Аллаһы мөкәммәллекнең югары үрнәге, Аллаһы гомумән кимчелексез Бөек зат. Аллаһы үзе җир тормышы биргән Адәм галәйһиссәламгә, вә дә аның балаларына зур ышаныч күрсәтеп, фани дөньяга үзләрен баш иткән. Һәм кеше ничек тели, шулай яши. Син әйткән гаделсезлек бәндәләрнең үз җимеше. Аллаһы моның шулай буласын алдан белгән, шуңа күрә азып китмәсеннәр дип Коръән индергән. Коръән дә ирекле. Телисең икән, аныңча яшә, телисең икән, үзеңчә яшә. Әмма хикмәт шунда, Аллаһы безне җиргә сынау өчен генә җибәргән. Һәрберебез кыяматтә гамәлләребезгә хисап тотачакбыз. Әлеге җәһәттән, пәйгамбәрләр, әүлияләр дин кардәшләренә булышырга бурычлы. Син дә, мырза, шулар кавеменнән. Бел, һәр гамәлеңнең, дәүләти эшләрме,

яу чабумы, сәүдә яки икътисадмы — байрагы Дин булганда гына максатына ирешәчәксең.

— Килешмим, мосафир, уңышның алшарты — көч. Көчне дин бирми, көчне көч бирә.

Мамайның тарткалашуы, сүз көрәштерүләре, шик-шомланулары нигезсез түгел, әлбәттә. Күнеленнән ул үзен Югары Көч дип саный иде. Шуңа күрә кемнең дә булса өстеннән торуын, уй-гамәлләрен чит затларның үзләре иләге аша үткәрүен, бәя бирүен, тыкшынуын кабул итми.

— Сөбхәнәллаһ, мырза, пәйгамбәребезнең хак варисы, яраткан кияве Гали имам баскычына инү сиңа бу яктан да яңа офыклар ачачак.

— ?!

Бәхәс ачык калды, шулай да эзсез югалмады. Моңа бер очрак (янә очрак!) булышты. Ни сәбәпледер, бу очраклар юл белән бәйле була. Бер караганда, гаҗәпләнергә дә туры килми, ник дисәң, бәкләрбәгенең күп вакыты ияр өстендә үтә.

Әле дә тезгеннәр бушатулы иде. Атларның ярсыган чагы. Борын тишекләре гөбе авызыдай киерүле, ирен читләрендә ак күбек. Шаһсуарларның[35] да кәефе шәп. Күнелгә үзеннән-үзе җыр куна.

Табаны ялпак тарлан бүз,
Төн катуга көн сиңа...

Мамайның җыр дип ачылган авызыннан сүгенү сүзе ычкынды:

— И, атаң дөя ә...

Каршысына капылт кына бер сын калкып чыккан иде. Чуен миченнән генә алынгандай ун-унбер яшьләрдәге кара корым малай.

Сак үләксәгә ябырылган козгын өеpедәй малайны сырып алды.

— Тентедек, хәнҗәре юк, — дип хисап бирде сакбаш.

— Мамай әкә, мин гомеремне Аллаһу Тәгаләгә багышлаган мөҗавир зат, — дип, малай һичнинди кыенсынусыз сүзгә кушылды, — гамәлем гали һиммәт.

— Иярдән егылып төшкән булсам, күрсәтер идем мин сиңа гали һиммәтне, йолкыш.

Сак малайны юл читенә бәрмәк иткән иде дә, тоттырмады, ут борчасыдай ялт та йолт.

Мамай елмаеп куйды.

Малай өчен бу бик уңай килде.

— Әкә, Ходай хакына, үтенечемне тыңласаң иде, мин сине айдан артык сагалап йөрим бит инде.

— Теленне үлчәп ач, малай актыгы, бәкләрбәге, әкә түгел, — дип күзенең акларын чыгарды сакбаш.

— Аллаһу каршында барыбыз да тигез, без Аллаһуның коллары.

— Алайса, ни өчен мине айдан артык сагалап йөрдең соң? — дип иреннәрен кыйшайтты Мамай, — син дә кол, мин дә кол.

Чыдарсың бу шомбайның теленә, җавабы да әзер.

— Фанида без тигез түгел, әкә, син фаразан, бәкләрбәге, дакьянус хәзинәсе[36] иясе, биниһая зур дәүләтне үз кулында тотасың, — диде сүзләрен аксакалдай бастырып кына, — кыямәт турында да уйларга вакыт, шушы җөмләдән мин сиңа ярдәм кулын сузарга булдым...

Сакбашның түземлеге төкәнде булса кирәк, малайны күтәреп алды да, таш кисәгедәй юл читенә томырды.

[35] Шаһсуар – атчабар.
[36] Дакьянус хәзинәсе – хисапсыз мал.

– Алла юкны бар итә, җуләр барны юк итә ди, бәк, вакыт уздырып тынлама шушы тиле-милене, исәр икәне маңгаена язылган ич.

Малай мөкәйли-мөкәйли юлга чыкты. Авыз читенә саркыган канын җиңе белән сөртеп куйды да көйләп Коръән укырга кереште.

– Рәхимле, шәфкатьле Аллаһ исеме белән башлыйм гамәлемне. Ий, тәрбиячебез Аллаһ! Безне туры юлга күндер. Туры юл – Коръән вә Сөннәт юлыдыр...

Далага нииндидер үзгә аһәнле моң инде. Үсмер хафизның ныгып җитмәгән калтыраулы тавышы вакыт-вакыт өзелеп-өзелеп куя, кайсыдыр ноктада бөтенләй эленеп кала да, бушлык хасил була, инде бетте, киселде дип уйларга өлгермисең, янә ялганып китә. Бу моң иң оста субра ерау җыруларыннан да тәэссирлерәк вә тәэссоратлырак иде.

Коръән аһәне орыш кырында җан кыюдан ләззәт табучы әлеге каты бәгырьле яугирларның да күңелен эретте. Малай тамагы карлыгудан туктап калгач та беравык исләренә кайта алмыйча басып тора бирделәр.

– Син кем, ыруың нинди, нилектән чирләшкә бүредәй далада ялгызың йөрисең? – дип сорады Мамай.

– Мин белексезләр ыруыннан, әкә, кара халыктан. Бәхетсезлегем дә шуның аркасында. Атаем Исәнтәй атлы, миңа исә мулла Мөйтән исеме кушкан. Бердәнбер көнне атаем, гөнаһ шомлыгына, сорамыйча баганабызга күрше атын бәйләгән. Безнең Маңгышлак илендәге кагыйдә буенча, ул моның өчен ат хуҗасына үз чаптарына өстәп, тагын тугыз юртак бирергә тиеш. Мөмкинлеге юк икән, ир баласы белән түли. Шул рәвешле мин яңа гаиләгә керергә мәҗбүр ителдем. Андагы күргәннәремне сөйләп бетерерлек түгел. Һәм мин качып киттем.

Ә гөнаһлы гамәле өчен һәркем җавап тотарга бурычлы. Атаемның, әнә, башын чабып өзделәр. Бу хак җәза. Шушы җәза мине мөҗавирлыкка китерде.

– Ә минем ни хаҗәтем булды?

– Син, әкә, мөҗавирлыкны үстерергә булыша алыр идең.

– Ничек итеп?

– Маҗар каласындагы мәшһүр гарәп сәяхәтчесе Ибне Баттута догага оеган тәкъвә зат Мөхәммәд әл-Батаихи шәех тәкиясе[37] кырынташ[38] хәленә кереп бара. Вакытында бу изге урында берьюлы йөзгә якын татар, гарәп, төрки, фарсы диндарлары Аллаһуга дога ирештергән. Ошбу тәкияне торгызу динебез мәнфәгатендә лаеклы гамәлең булыр иде.

– Чатырымда аңлашырбыз, Мөйтәнне арбага утыртыгыз, – диде Мамай.

***

Кырым ягында көз елның үзенә бер ягымлы, мәрхәмәтле фасылы. Комда күкәй куырырлык эссе көннәр инде артта. Табигать матурлык, муллык, саф вә назлы хозурлык эчендә коена. Яңгырлары шифалы, һавасы татлы, кояшы дәвалы. Шуңа күрә күңелләр дә күтәренке. Тәкиягә дә кешеләр агыла. Суфилар, мөридләрдән тыш, тирә-юньдә яшәүче мөселманнар да иман яңарта.

Мөйтән шәех яшел чапан чабуларын җилфердәтеп, галәттәгечә, ашыгыч адымнар белән мөнбәр катына килеп басты. Гәүдәгә һаман шул какча гәүдә, әмма ул хәзер су камышыдай зифа рәвешкә кергән иде инде. Йөзгә-биткә дә үзгәргән, хәтта борын төбендә, ияк кырыйларында кыюсыз гына төкләр

[37] Тәкия – зекер әйтү өчен җыелып утыра торган урын.
[38] Кырынташ – хәрабә

борын төртә башлаган. Шушы бала йонынnан аз гына узмыш күсә сакалмыегы аңа аерым бер олпатлылык, мәһабәтлелек өстәп тора иде.

— Дин кардәшләрем, пәйгамбәребез Мөхәммәд галәйһиссәлам: «Аллаһының 99 исемен өйрәнеп, аларны даими кабатлаганнарның урыны Җәннәттә булыр», «Тимер жиргә ышкылып, күгәрегеннән чистарган кебек, без дә Аллаһының гүзәл исемнәрен кабатлап сафланабыз, пакьләнәбез», — диде. Көндәгечә, зекер билхәеребезне башлыйбыз. Минем арттан Исеме Әгъзам догасын кычкырып бертавыштан кабатлагыз.

— Бисмилләһиррахмәниррахим. Йәә Җәмиилү йәә Аллаһ. Йәә Кариибү йәә Аллаһ. Йәә Мүҗибү йәә Аллаһ...

Үтә күренмәле ахактай чиста күз һавасы йөзләгән риясыз диндар авызыннан чыккан дога авазын бүлгәләүсез еракларга-еракларга тарата. Тирә-як илаһи көмән белән тулыша.

Гавәм акшам намазына кадәр зекер әйтте. Тәгам арасында ихата янына бер атчабар килеп туктады.

— Әссәламугаләйкүм, шаех, мин бәкләрбәге Мамай мырза кушчысы, ул тәкиягә бер көтү куй насыйп итте, яланда калдырыйкмы,ябуга кертикме? — дип мөрәҗәгать ите.

— Бәккә Аллаһуның рәхмәте төшсен, сугым малларыбыз бар иде әле, яланда йөри торсыннар, — диде шаех, — ә без, мөхтәрәм өммәттәшләрем, дин кардәшебез Мамай Кыят бине Боданчар хәзрәтләренә рәхмәтле догаларыбызны ирештерик.

— Бәк хәзерендә тәкиядә күренми башлады, — диде кемдер, — сәбәбе нидә, аңлатып китсәң иде.

— Мамай хәзрәтләре узган ел ярым эчендә хак мөселман дәрәҗәсенә иреште, шәригать ягына борылды. Тәкиягә сирәкләвенә килгәндә исә, күрәсең, дәүләт эшләре тота булыр. Мин аны үзем дә бик юксынам...

***

Офык читенә төшкән кичке кояш башта аларның күләгәләрен очраштырды. Бу берсенең дә игътибарын җәлеп итмәде: уйга чумган иделәр. Гәүдәләре орынгач кына бер-берсенә караштылар.

— Әссәламугаләйкүм, суфи, — дип сәлам бирде яшь мосафир, — Ходай юлларыңны уң итсен.

— Вәгаләйкүмәссәлам, дин кардәшем, Аллаһы үзенә дә бәрәкәтле сәфәрләр насыйп итсен.

— Эчкерсез теләкләренә рәхмәт, суфи, ләкин дә туры юл дигәнебез һәрвакыт тәгаенләнгән жиренә китерми шул. Риваятьтәгечә. Көннәрдән бер көнне өч дус егет сәфәргә чыгып китә. Ниятләре изге — калага барып гыйлем эстәү. Бер көн бара болар, ике көн, өч... Ә юл озын, талчыгалар. Һава да артык узындырмый, әле эсселектән табаннары яна, әле өермә күзләрен ачырмый. Атна дигәндә, болар юллар чатына килеп теләләләр: турысын сайласаң, вакытны отасың, уравычын сайласаң — ышанычыңны арттырасың.

— Туры юлдан китәбез, — диде егетләрнең икесе бертавыштан.

— Миңа бабам бервакытта да олы юлдан чыкмаска кушты, мин бабамның васыятен тотам, — ди өченчесе.

Ул калага исән-имин барып житә, дуслары исә сазга бата.

— Бу ни-нәрсәгә ишарә, яшь дустым, тел төбендә яшерен мәгънә тоемлана.

— Хак, бабакай, ишарә бар, ләкин яшерен түгел.

— Фаразан...

— Аллаһы Тәгалә каршында без барыбыз да, шул җөмләдән пәйгамбәрләр дә, бертигез. Аллаһы гына Бөек Зат. Сөбхәналлаһи вә биһәмдихи, ягъни

дә кимчелексез вә тиндәшсез Мактау иясе. Без аның коллары. Мөселман өммәтендәге адәмнең бердәнбер юлы – Аллаһуга табыну. Аннан тайпылу – зур гөнаһ.

– Син, мосафир, Мөйтән шәех, шулаймы?

– Әйе, Юзекәй суфи, мин Мөйтән шәех булам. Синең шикелле динебезне югарыга-түбәнгә бүлгәләмим. Иман ул җиһан кебек үк, җә бар, җә юк.

Юзекәй гәүдәсен таягына терәп, корыган агачтай катып калды. Мөйтән күккә текәлде. Күктә козгыннар кайнаша иде, кайдадыр үләксә бар, күрәсең. Карт мосафирның да күзе кара кошларда булган икән.

– Шәех, игътибар ит әле, козгыннарның һәрбере җирдәге үләксәне күреп-сизеп тора. Ләкин ябырылмый, югыйсә бик тә тыгынасы килә. Нилектән бу?

Юзекәй берара Мөйтәнгә күз тегеп багып торды да, дәвам итте:

– Беренче булып тәгамгә Баш кош кунарга тиеш. Өерне дә ул тота. Мөгаен, канга батканчы чукышып, таралышып бетәрләр иде. Алтын Урда дигән бөек дәүләтнең дә Баш кошы бар. Ул – Мамай бәк. Хәзер дәүләтебез бик тә авыр чор кичерә. Аллаһы Тәгалә мәшһүр Бату хан мирасын бербөтен итеп саклап калуны Мамай мырзага фарыз кылган. Аның тоташ имтихан-сынаулардан вә каршылыклардан гыйбарәт яшәеше, тормышы моңа шаһит. Әлеге илаһи вазифа син әйткән кол кулыннан килми. Баш кеше һәртөрле чикләүләрдән дә азат булырга тиеш, дине дә башкаларныкыннан үзгә. Мин соңгы дистә елда бөтен көчемне шәкертемнең күңеленә, асылына шушы олы тәгълиматны сеңдерүгә сарыф иттем. Бу да миңа Аллаһы тарафыннан фарыз кылынган изге гамәл.

Бурычым үтәлде. Хәзерендә мин фани дөнья белән исәп-хисапны өзәргә җыенам. Ходай хәере белән алсын. Мамай Имам фатихасы белән син яшәү көче биргән тәкиядә урын табылырдыр бит?

– Минем аннан китем барышым, суфи, тәкия сиңа күчә, – диде Мөйтән, – мин сине бик хөрмәт итәм, әмма тәгълиматыңны кабул итә алмыйм. Шул сәбәп белән Мамай мырза белән дә юлларыбыз аерыла. Хуш, Ходай җәфасыз әҗәл бирсен.

Күләгәләр берьюлы кузгалды. Әле алар шактый ара янәшә бардылар, аннан ике күләгә ике якка аерылды.

***

Дмитрий хәләле бөек княгиня Евдокия белән Коломнога килгән иде. Алар шулай икәүләп кенә нindидер уңай сәбәп чыгарып, Мәскәүне калдырып киткәлиләр иде.

Өрестәм илче олуг кенәзне шунда эзләп тапты.

– Мин монда бөек княгиня карамагында, йомышын йомышларга Кремльгә килсен, – дип, Дмитрий аны кабул итүдән баш тартты.

Евдокиянең зөбәрҗәттән коелган матур йөзе нурланып китте, нәфис иреннәренә сәгадәтле елмаю дулкыны иңде.

– Кенәз, җәмәгатеңне артык узындырма, – дип, бармак янагандай итенде.

Бу бәхетле никах турында халык арасында берсеннән-берсе күркәмрәк сүзләр йөри: «Алар икесе ике тәндә бербөтен рухи җан булып яшиләр», «Кенәз белән княгиня пакьтән-пакь тапсыз вөҗдан көзгесенә ак йөз белән карап, алтын каурыйлы күгәрчен һәм дә татлы телле кервәшә кебек гомер кичерәләр».

Карап торуга да бер-берсенә охшашканнар иде ир белән хатын. Йөзләре инде түгәрәкләнеп килә, буй-сыннары да тулыша бара. Әмма бу тулылык үзләренә бик килешеп тора иде.

Ике арадагы әлеге самимилекнең дәүләт эшләренә йогынтысы юк дәрәҗәсендә иде. Дмитрий икеләнүчән, еш кына, теге яки бу эшкә тотынганчы, даирә ни әйтер дип шикләнеп кала. Моның төпле сәбәбе дә бар. Аны уникe яшендә митрополит Алексей атакай тәхеткә утыртты. Һәм ул һәр гамәлен баш рухани кушканча башкарырга күнекте. Алексейдан соң тагын да абруйлырак, тагын да йогынтылырак Сергей Радонежский кулына күчте. Хәзер аның күрсәтмәләре күрсәтмә. Шуңа күрә үзлегеннән карар кабул итүләр аңа авыр бирелә.

Әле дә илчене кире борып дөрес эшләдемме, дигән уй эчен бимазалый иде. Бу юлы Евдокия ярдәмгә килде.

– Кенәз, минем кошларымны ашатыр вакыт җитте, рөхсәт итсәң, беразга гына югалып торыр идем, – диде дә, чыгарга җыенгач кына хатын-кызларга хас астыртын хәйләкәрлек белән: «Шушы арада, бәлкем, Урда илчесен чакырып сөйләшерсең, Мәскәүдә болай да эшең муеннан», – дип өстәде.

– Рәхмәт, княгиня, бик урынлы тәкъдим, – диде Дмитрий җиңел сулап, – Мамай бәк илчесенә игътибар зарур.

Өрестәм ишектән мичкә тәгәрәткәндәй тәгәрәп кенә килеп керде. Оста телмәр буларак даны чыккан илче иде ул. Әле дә төп мәсьәләгә күчкәнче бер мәзәк сөйләп алды.

Хан вәзиренә татлы нәрсә пешерергә кушкан. Тегесе аш өенә киткән дә тат[39] салып, тел пешереп китергән. Хан ошаткан. Инде иң ачы нәрсә әзерлә, дигән. Вәзир бу юлы да тозлап-борычлап пешерелгән тел алып килгән.

Хан гаҗәпләнеп сораган:

– Тагын тел пешергәнсең ич, моны ничек аңларга?

– Ханым-солтаным, – дигән вәзир, – мин дөреслеккә хилафлык китерә алмыйм: дөньяда иң татлы нәрсә дә – тел, иң ачы нәрсә дә – тел.

Тел илченең төп коралы, олуг кенәз. Мин үзем, фаразан, көнозын такылдап та күкәй сала алмаган тавык мисалында. Нишлисең, һәркемнең үз вазифасы. Мин бит, олуг кенәз, Сарайда син шөгыльләнгән мәктәпкә йөрдем, ыруым түбән булу аркасында Мансур бәк белән кенәз Дмитрий тиңәлегенә үтеп керә алмадым. Шуңа күрә мине хәтерләмисеңдер. Күреп торасың, углан булып булмады, хәрби эшкә күңелем ятмады. Аның урынына, Ходай телне өч-дүрт кешелек биргән. Дәүләткә угланнар гына түгел, илчеләр дә бик кирәк.

– Хан ярлык җибәргәндер, шәт, – дип, Дмитрий тел бистәсе илчене вазифасы кысаларына кайтармак итте.

Өрестәм бот чапты.

– Күр инде бу лыгырдыкны, бурычымны онытып торам икән ләбаса, сине күргәч, башым әйләнеп китте.

Дмитрий сагаеп калды. Чөнки илче бервакытта да буш сүз сөйләмәс, әйләндерер-тулгандырыр, анысы хак, әмма һәр җөмләсенең төбендә нинди дә булса мәгънә ятар.

Шулай булып чыкты да. Мөхәммәд Булак ханның ярлыгына көтелмәгән яман яналык оялаган иде. Илченең шуны йомшартыбрак җиткерү өчен җирлек әзерләве булган икән.

Хан салым тәртибенең үзгәрүен игълан иткән. Салым күләме Җанибәк заманындагы дәрәҗәгә җиткерелә, ягъни Урдага һәр йөз тәңкәлек керемнең уникe өлешен түләргә тиешләр. Хәлбуки, Чыңгызхан аны ун өлеш дип билгеләгән. Җанибәк заманындагы үзгәреш тә озак яшәмәгән.

[39] Тат – тары.

– Бу хәлне бәкләрбәге Мамай мырза беләме, вакытында ул безгә күп ташламалар ясаган иде. Чиркәүләрнең яртысын гомумән салымнан азат иткән иде.

– Алтын Урдада һәр дәүләти гамәл бәкләрбәге фатихасы белән эшләнә, – диде илче вакарьле житдилек белән. Килеш-килбәтендәге әүвәлге уенчаклыкның эзе дә калмаган иде. – Ярлыкны ахырына кадәр укып чык, кенәз.

Дмитрий хәйраннан вәйранга калды – бу пычаксыз сую лабаса! Хан өч еллык салымны алдан түләүне таләп итә иде.

– Борчылма, кенәз, кергән кеше чыгу юлын да таба ул, – диде илче. – Мәскәү күзгә күренеп ныгый, Вож орышында, әнә, безнең мактанчыкларны канга батырып тукмадыгыз ич. Елгада өч тәүлек буе татар мәете аккан диләр. Булдырдыгыз.

– Мин хөрмәтле Мөхәммәд Бүләк ханның рәсми ярлыгына җавабымны атна-ун көннән әзерләрмен, – диде Дмитрий, илченең төртмәсен игътибарсыз калдырды.

Ярлык урыс җиренең астын өскә әйләндерде. Югыйсә вәзгыять Мәскәүгә йөз белән борылган кебек иде. Боярлар шурасы да шул нәтиҗәгә килгән иде. Ниһаять, Рәсәйнең үз-үзенә хуҗа булып яшәү сәгате сукты, дип тәбрикләшкәннәр дә иде.

Әлеге ышаныч, әле илче телгә алган Вож орышындагы җиңү һәм Бөек Литваның олуг кенәзе Альгирдасның кинәттән вафаты мөнәсәбәте илә туган иде.

Литвалыларның хәзер Рәсәйгә тешләре үтмәс, үз хәлләре хәл, тәхет бүлешү белән мәшгульләр. Алтын Урданың Сарай өлешендә дә ызгыш. Әле үләт котыра икән.

Һәм менә сиңа мә.

Дмитрий Мәскәүгә дә сугылып тормады. Сергей атакай янына ашыкты. Троицки монастыре архимандриды Сергей игумен олуг кенәзнең иң зур терәге иде. Олуг кенәз генә түгел, бөтен Рәсәйнең, православиенең терәге иде Радонежский.

Дмитрий атакай катына бик дулкынланган хәлдә килеп керде. Шунда ук гозерен җиткерергә ашыкты.

– Сын мой, Ходай йортында иң әлек гыйбадәт кылалар, – дип, атакай олуг кенәзне җинелчә генә битәрләп алды, – һәм дә гыйбадәткә баскач, кемгәдер дәгъвәң бар икән, аны кичер, дәхи Күк Атаң да синең гонаһларыңны ярлыкар.

– Атакай, җаным юлбарыс-киек арасында, мин дөрләп янучы ялкын эчендә, мине урап алган кешеләрнең тешләре – сөңге, телләре – үткен кылыч...

Игумен Дмитрийны каршысына утыртты да сорады:

– Нинди ашыгыч шөгыльләрең чыкты, алдан хәбәр дә җибәрмичә килүеңнең сәбәбе нидә?

Олуг кенәз хәлне аңлатып бирде.

Бөтен җиһазы аяклары бүрәнәдәй юан ике-өч урындык һәм дә шундый ук ныклы аякларга утыртылган япмасыз өстәлдән гыйбарәт биек түшәмле шыксыз хөҗрә эче тынып калды. Бу калын стеналы бинага бернинди чит тавыш та үтеп керми иде. Дмитрий үзенең йөрәк тибешенә кадәр аермачык ишетеп торды.

– Ходаем! Фатиханны бир, саклап алып кал. Ходаем! Миңа ярдәмгә ашык! – дип пышылдады атакайның иреннәре.

– Сулышыбыз ачыла гына дип торганда тагын ризасызлыклар тудыра инде бу салым мәсьәләсе, – диде олуг кенәз ачынып, – берләшүләр янә чигенә.

– Сын мой, шуны бел, кенәзләр ирекле баштан Мәскәү кочагына атылмаячак, һәрберсенең үзбаш буласы килә, – дип атакай куе сакалмыегы арасыннан тавышын чыгарды. – Рәсәй бөтен вә көчле булырмы – бу православие кулында, бары тик чиркәү генә Рәсәй халкын бер учка җыя ала. Ходай кушып, ул сәгать тә сугар. Әлегәчә динебез белән дә читләр, Константинополь әһелләре житәкчелек итте ич. Шөкер, митрополитны хәзер үз арабыздан сайлап кую хокукына ирештек. Бу бик зур җиңү. Син үзең дә кыю вә тәвәккәл адымнар ясадың. Рәхмәт.

Бу атакайның үз-үзенә рәхмәт әйтүе иде. Чөнки әлеге «кыю вә тәвәккәл» адымнар аның җитәкчелегендә ясалды. Шактый күп көч сарыф итәргә туры килде ул вакытта.

Алексей атакайның вафатыннан соң митрополит вазифасына ул Чуд монастыре архимандриды Митяйне тәкъдим итте. Константинополь исә грек милләтле Пимен атакайны үз күрде. Тик Пимен Мәскәүгә килеп җитә алмады, юлданиндидер билгесез адәмнәр (олуг кенәз кешеләре, әлбәттә!) һөҗүм итеп, саккосын[40] талап алдылар, үзен куып җибәрделәр.

Константинополь бу юлы Литва һәм Киев митрополиты Киприан шәхесендә тукталды. Тик ул да алдагы дәгъваче язмышына дучар булды. Пимен атакайдан аермалы буларак, Киприан да бурычлы калмады. Олуг кенәз Дмитрий Московскийга анафема игълан итеп, диннән сөрде.

Еллар, гасырлар үтәр, диннән сөрелгән кенәз Дмитрий Рәсәй чиркәве тарафыннан «Изге» дигән илаһи зат дәрәҗәсенә лаек табылыр.

– Синең ул басурман Мамаенның чын нияте безнең өчен карангы, – диде Радонежский олуг кенәзне борчыган мәсьәләгә күчеп, – шулай да аек акыл белән фикер йөрткәндә, әгәр исәбе этлектә булса, илчеләр җибәреп тормас иде, тотар да эшләр иде. Өч еллык салымны берьюлы талап итүе сине энә очында тоту өчен уйлап табылган нәрсәдер, мөгаен. Һәрхәлдә, шуңарак охшап тора. Түли алмавыңны белә ич ул.

– Урданың яу чабарга җыенуы турында да бернинди мәгълүмат юк, шикшөбһәгә төшәрлек гамәл кылганнары да сизелми, – дип игуменның фикерен куәтләде Дмитрий, – тик ни өчен илче Вож орышын телгә алды икән? Безнең җиңүгә соклануын белдерде, үзләренекен булдыксызга чыгарды.

– Аларда: «Тау Мөхәммәдкә килмәсә, Мөхәммәд үзе тауга килә», – дигән әйтем бар, – диде атакай сөзеп кенә, – беләсенме, Мамай янына без башлап үзебез барырга тиеш.

Дмитрийның кашлары күз төбенә җыерылып төште.

– Ни рәвешле, атакай?

– Күп уйлаган буш калган ди, орышка әзерлән, кенәз, ышанычлы воеводаларыңны җый, гаскәр тупла, сине өйрәтергә кирәкми, уңышка, гадәттә, тәүге һөҗүмче ирешә. Татарлар белән яратышу чоры узды. Мин бүгеннән җиңү хакын хаклап, гыйбадәткә басам. Ходай догаларымны ишетер, шәт.

С богом!

*Ахыры киләсе санда*

[40] Сакко – митрополит билгесе.



Рифә
Рахман

# Ә САГЫШЫМ — МОҢЛЫ ҖЫР ИКӘН

## Җир кояшы

**Таңда гына яңгыр явып үткән иде,**
**Кыш тузанын агызган ул асфальтлардан.**
**Киемемне чишеп барам — җилгә ачык**
**Күңел әзер барыгызны кочакларга.**

**Күңел әзер барыгызны яратырга,**
**Йөзем көләч — җир кояшы булганмыни?!**
**Яз шул тиклем сагындырган икән мине —**
**Өйдән чыкмый — салкыннардан туңганмыни?!**

**Өйдә яшәп, язып кына яткан идем,**
**Шуннан кайчак бер тынычлык тапкан идем.**
**Яңгыр шакып дәште мине урамнарга,**
**Юкса таңда йокларга дип яткан идем.**

**Ул яңгырга мең мәртәбә рәхмәт инде:**
**Киткән явып, җирне юып, сафлык чәчеп.**
**Яз бу тиклем сагындырган икән мине,**
**Яшик өч ай, бергә-бергә чөкердәшеп!**

## Хәтерсезгә дәгъва

**Онытгың син бик күп нәрсәләрне.**
**Анысына китми һич исем.**
**Картайдым мин, танышларны атап**
**Чыгарлык та хәтер юк, дисең.**

**Хәтереңнең исән кисәгендә**
**Минем исем, төсем бар микән?**
**Без тик дуслар булып яшибезме,**
**Әллә элеккечә — яр микән?**

---

Рифә РАХМАН – *шагыйрә, прозаик; «Төнге кояш», «Сиңа!», «Айлы күлдәвекләр» һ.б. китаплар авторы. Казанда яши.*

Тәмам онытылып бетмимдер күк,
Бергә–бергә гомер иткәчтен.
Мин йокыга синең белән китәм,
Син башканы парың иткәнсең.

Мин йортымда синең белән яшим,
Оныталмыйм шуңа сине дә.
Хәтерләрем тәмам бетте, дисең,
Оныттыңмы хәтта мине дә?

Оныттыңмы яшьтәш дусларыңны,
Кызыңны да инде буй җиткән?..
Минем хәтер һаман элеккечә:
Ул башканы кертми ишектән.

Ул бары тик синең белән яши,
Сине уйлый, якты көн туса.
Туктармын күк яшәвемнән бары,
Хәтеремнән исмең җуелса.

## Казанда — ташу

Балконымнан карап торам хозурланып:
Урамнарны чибәр кызлар күмеп киткән.
Килә алар гөрләвектәй аккан сыман
Тротуардан. Казанымда ташу җиткән!

Карга тулган иңкүлеккә, агачларда
Оялары бихисаптыр, ни галәмәт!
Балконымнан җимнәр сибәм мин аларга,
Бүлешәләр ризыгымны җирәбәләп.

Агачларны яшел бөре күмеп киткән,
Сибелгәнме ботакларга алар күктән?
Бу яз элек килгән язлар кебек кенә
Түгел икән, түгел икән, түгел икән...

## Кояш баеганда

Икәү генә калыр идең дә бит,
Бүлмәбездә кояш баеганда.
Йә җил уза, йә ай кереп килә,
Һич җайлар юк иркен тын алырга.

Инде алар безне онтып торса,
Йә калдырса берчак тынгылыкта.
Очып йөри бүлмә буйлап шигырь,
Рәхәтләнеп кичке хозурлыкка!

Тотып алып укыйм һавалардан,
Кунамы ул синең йөрәккә дә?
Ризамы син шаян шигырьләргә,
Телләренә килеп, ни әйтсә дә?

Тавышыма битарафлык салып,
Ризамы син минем укуыма,

Ризамы син, ихлас ризамы син
Мәхәббәтле сүздән куркуыма?

Тотып укыйм һавалардан шигырь,
Берсен тотсам, туа икенчесе.
Эрер алар таңгы һаваларда...
Аларның бит барсы — бу кичнеке.

Калырбыз без икәү, син китмәсәң,
Ялгыз калуларны бик теләсәң.
Синең дә ул теләкләрең узар,
Үз-үзеңне сабыр иттерәлсәң.

Эрер теләк таңгы һаваларда.
Түгел шул без баш төзәтер яшьтә:
Кояш чыккан чакта чып-чын аек,
Кояш баткан чакта исерсәк тә.

## Ике исәп

Хәзергә, дип кенә киткән идең,
Хәзер дигәннәрең ел икән.
Яратуың сагыш кебек, дидең,
Ә сагышым — моңлы җыр икән.

Агып кына тора күңелемнән,
Еллар кебек — юктыр исәбе.
Хәзер, дигәннәрең гомер булса,
Ике исәп — бердер хисабы.

## Ашыгасың

Ашыгасың. Тоткарламыйм сине.
Тоткарларлык сәбәп бар-барын.
Сөю елгаларым ташыды да,
Ашап килә күңлем ярларын.

Ныгыт аны гамәлләрең белән,
Вакытлар тап янә килгәндә.
Күңел кырындагы карлар эрде,
Син кояш күк һәр көн көлгәндә.

Акты беркөн сөю елгалары,
Күңел ярларына сыймыйча.
Ашыгасың. Аны әйтергә дә
Торган чагым әле кыймыйча.

Үпкәләтер кебек бөтенләй үк
Эшләреңне синең калдырсам.
Ә мин риза синең хакка хәтта
Туры юлларымнан яздырсаң.

Ашыгасың. Тоткарласын сине
Тирләп чыккан ишек тоткасы.
Чыгармас ул сине, сөртенерсең —
Аркылыга яткан тупсасы.

## Үбәр дә яр...

**Язгы болыт тәрәзәгә килгән,**
**Эләргә дип синле сагышны.**
**Мин орыштым аны, бармак янап,**
**Болай эшләү булыр ялгышы.**

**Мин бәхетле көлеп торсам гына,**
**Миңа рәхәт аның уйлавы –**
**Яратып тик. Һич тә кирәк түгел**
**Язның минем белән уйнавы.**

**Моңландырган булып, үртәләгән**
**Һәм саргайткан булып сагыштан.**
**Китсен болыт, язның ямьсез көнен**
**Башка якка илтсен берочтан.**

**Чыксын кояш, җанга нур тамызып,**
**Сөюеңнән хәбәр шикелле.**
**Сөеним мин язга, кайгыртмасын**
**Хәтта биткә сипкән сипкеле.**

**Үбәр дә яр, очар китәр кебек**
**Кояш биткә яккан тутыя.**
**Йөзем тимгел–тимгел, сипкел–сипкел...**
**Болыт, юыйм диеп, су коя.**

**Элмәкче ул минем тәрәзәгә**
**Сиңа бәйле мең–мең борчуны.**
**Орыш әле син дә хуҗаларча,**
**Яклаучым бул бераз, тый шуны!**

---

## Авторлар игътибарына

Редакциягә кулъязма җибәргәндә түбәндәге документлар булу мәҗбүри:

1. Паспорт күчерелмәсе (титул, прописка бите).
2. Дәүләт пенсия страховкасының страховка таныклыгы күчерелмәсе.
3. ИНН күчерелмәсе.
4. Вертикаль портрет рәвешендәге яхшы сыйфатлы фоторәсемегез.
5. Телефоныгыз (шәһәр кодын да күрсәтеп).



Вәрис
Гали

## ГОМЕР ЧЕЛЛӘСЕ

БӘЯННАН ӨЗЕК

I

Кояш бәгырьләрне өтәрдәй булып кыздыра. Җәй челләсе житте. Бар авыл халкы ерганак читләреннән үләне калынрак жир сайлап печән чаба. Үткеннәре — тиз генә төяп алып кайтып китәрлек техникалылары — агрофирманың күпьеллык печәненә дә кереп чыга. Берәүләр исә мона кайгырмый: капка төбенә үк әржәсе белән китереп бирәчәкләр. Аларын да мәшәкать баскан: бала-чагасы белән жиләк жыеп сата. Авылда бу вакытта берәү дә йокламый.

Назыйфка да хатыны Фирдәүсә иртән эшкә киткәндә:

— Быел Фәрит печән бирәме соң? Әллә элекке кебек үзебезгә чалгы күтәреп чыгарга туры киләме? — дип артыннан кычкырып калды.

Әллә шайтанның колагын юганча гына туры килде бу сүзләр: әбәт вакыты житүгә үк кайтып керде ул. Йөзе сүрән иде. Башлаган басуларының үләнен жыеп бетерә дә алмаганнар, комбайнының барабан валы шартлап сынып чыккан. Инженерлары кирәкле әйберне эзләп Мамадышка чыгып чапкан да, андагы кибетләрнең берсендә дә юк икән. Компьютер аша эзләп караганнар, Чаллыда да булмаган. Заказ биргәннәр, заводтан жибәргәннәрен кимендә өч көн көтәргә кирәк булачак икән.

— Бәк әйбәт! — диде Фирдәүсә, арба ватылса — утын дип яшәмәсә дә, иренең комбайны көйсезләнүенә бу юлы бик шат иде. — Күрше Нәфисәләр атна буе Уразбахты басуында жиләк жыеп саталар инде. Көн саен дөнья акча эшлиләр. Мотоциклынны утын лапасыннан актарып ал! Без дә төшеп китәбез хәзер!

Хатыны Назыйфка ике уйларга урын калдырмады. Бер нәрсә башына керсә, чөйләп тә чыгарырмын димә, үз туксаны туксан анын. Тукрандай тукый да тора. Әллә укытучы халкының бөтенесе хәзер шундый микән? Хатыны белән бергә эшләүче Нәфисә дә иренең миен каезларга ярата.

Тиз генә юынып, чәйләп алганнан соң, ир совет заманнарыннан калган «Иж-Планета» мотоциклын лапастан өстерәп чыгарды. Аккумуляторын урнаштыргач, бер тибүдә кабынды тагын үзе. Бишеген дә тагып куйды.

Вәрис ГАЛИ (1959) — *журналист, һәвәскәр язучы; әсәрләре республика һәм район газета-журналларында даими басылып килә. Мамадышта яши.*

Хатыны бишәр литрлы пластмасс чиләкләр әзерләп куйган иде инде. Төшеп киттеләр Уразбахты ягына. Ара унбиш чакрымнан артык булса да, хәзерге асфальт юллардан элдерүе озак түгел.

Хатын-кызга әйтергә генә ансат. Уразбахты-Омар басуларында җир җиләге ел саен ишелеп унса да, кеше йөрмәгән, таптап бетермәгән урыннарны табарга кирәк бит әле! Анда беренче тапкыр гына төшүләре түгел. Очсыз-кырыйсыз җирләр... Вәт яшәгән икән бу яктагы халык байлыкта! Ул җиләк диген, печәнлекләр, утын әзерләү өчен агачларны кисеп азапланасы да түгел, үзләре үк корып, авып яталар. Тик авыллары гына калмаган. Әнчүтин, Шарманка, Дубровка, Федоровка, Калатаева, Подгорица, Залесная, Яңа Алабуга, Михайловское... Тагын әллә ничә булган алар. Һәркайсында гомер кайнаган, балалар үскән. Чыр-чу килеп, урам тутырып уйнап йөргәннәр. Яшьләр бер-берләренә гашыйк булганнар, вәгъдәләр бирешкәннәр. Бүген өй пужымнары урыннарында нигез ташлары гына таралып ята. Илнең «перспективасыз авыллар» дигән сәясәте таркаткан, Советлар Союзы күләмендәге төзелешләр дип игълан ителгән Түбән Кама, Чаллы йоткан барысын да. Оньк-онькчыклары инде әби-бабайларының туган, яшәгән җирләрен дә белми торгандыр. Җиләк вакыты житүгә шул җирләргә халык агыла. Әллә кайлардан килеп житәләр. Үзләре җыярга иренгәннәр юл кырыена тезелешкән сатучылардан алып китә. Җиләк вакыты бер генә була. Шул вакытта өмләрәкләр күбрәк акча эшләп калырга тырыша хәзер. Бала-чагасы да, әби-бабайлары да юл буенда җиләк сата. Ул җиләкне җыю гына түгел, сата белергә дә кирәк бит. Былтыр Фирдәүсә күршедәге Нәфисәгә ияреп ике көн төшкән иде. Аларга юл хакын түләгәннән соң да кызлары Алсуны мәктәпкә әзерләрлек акчасы калды. Быел да җәйге ялын алуга ук үзенә урын таба алмый йөри башлады. Назыйфның комбайны ватылуы бик юнь килде. Әйдә, ватык техниканы саклап утыра алмый инде. Кирәкле запчасть табылганчы, үз көен караса да була. Рәтле-башлы хезмәт хакы күрмәгән килеш тә эшләп йөргәненә бик рәхмәт. Хәзер хөкүмәткә эшләми кеше, кесәсен калынайта.

Кайсы тирәгә тукталырга соң аларга? Урта Кирмәнгә житкәннәр иде инде.

— Урыс Кирмәне аша Дубровка тирәләренә барып карыйк мәллә? — дип, бишектә тибрәлеп төшүче хатынына эндәште ул.

— Анда ук барып йөрмәсәк тә була бүген. Кирмән тавында да җиләк бетмәгәндер әле. Кеше синең кебек әллә кайларга йөри ул. Якындагысын күптән бала-чага ашап бетергәндер дип уйлый, — дип кырт кисте Фирдәүсә.

«Ярар, авызыңны ачма иден. Алай булса, Изгеләр чишмәсе өстенә — элекке Кирмәнчек шәһәрчеге булган җиргә генә алып менәм мин сине!» — диде ул эченнән генә.

Анда Изгеләр чишмәсе яныннан инеш аша чыгу авыр булмады. Кирмәнкә елгасы тирән түгел икән. Тау сыртына менеп туктадылар. Фирдәүсә мотоциклның бишегеннән төште дә, оеган билен яза-яза җирдәге җиләкләрне караштырып китте. Утыз бишен тутырса да, зифа буйлы хатыны. Озын чәче дулкынланып җилкәсенә салынып төшкән. Аны муен турыннан гына будырып куйган. Акылы да үзе белән. Намусына тел-теш тидергәне юк әле. Бер сыйныфта укып, Имән Елганың ике урамында яшәсәләр дә, бергә уйнап үстеләр алар. Назыйф — тынычрак холыклы булса, Фирдәүсә яшьтәшләре арасында атаман кебек иде. Сүзен тыңламаган малайларга да эләккәләде бугай аның саллы йодрыгыннан. Гәүдәгә атасына охшап уртача буйлы, киң җилкәле, каты куллы булды ул.

Малайлар-кызлар җавап та бирә алмыйлар иде: ике абыйсы да көрәшчеләр, нык бәдәнлеләр. Ана карап, юкка-барга кешегә бәйләнеп йөрмәделәр. Бик сирәкләргә бирелә шул табигать тарафыннан берьюлы көч һәм акыл. Әнә шуңа күрә, гомер-гомергә тирә-юньдә данлыклы булды аларның нәселе. Ә Назыйфныкылар бер яктан да башкалардан аерылып тормадылар. Буйга да — урта кул, көчкә дә типсәм тимер өзәм дип мактана алмыйлар. Алар — чын эш атлары.

— Монда йөрүчеләр дә булмаган бугай әле, — дип нәтиҗә ясады Фирдәүсә, чиләкләренә әйләнеп килгәч.

Хатыны канәгать иде. Һай шуның сабый баладай сөенеп куюлары! Гомере буе йөрәгенә сары май булып ятты ул гадәте. Кечкенә чагыннан ук үзенә тарткан ягы шул булды кебек. Хәер, хәтере ялгышмаса, мәктәптә укый башлаган вакытларыннан ук Фирдәүсәне гел мактап торучы кеше әнисе булды. Ул — Имән Елгада фельдшер, Фирдәүсәнең анасы китапханәче. Фельдшерлык-акушерлык пункты да, китапханә дә бер үк бинага урнашкан. Ишекләре генә ике башында. Булачак кодагыйлар гомер-гомергә бик тату яшәделәр.

Җиләк җыюга бирелеп, дөньяны да онытасың. Икешәр чиләк тутыргач, сәгатькә караган иде, биш тулып килә. Янә берәр чиләк җыярга булдылар. Вакыт тагын сизелми дә узып киткән. Хәзер инде боларны сатарга да кирәк. Сүзсез генә бер-берсенә карашып алдылар. Тау башыннан тирә-юнь уч төбендәгедәй күренеп тора: олысы-кечесе умарта күче кебек. Олы юлдан Изгеләр чишмәсенә борылган җирдә кеше күренми. Шул тирәләрдә генә туктальрга булды Назыйф. Алардан утыз метрда гына биш-алты чиләк белән Уразбахты хатыны тора. Чиләкләрен тезеп куйдылар. Берәрсе туктагланчы дип ир теге хатыннан күпмегә сатканын белешеп килде. Миңлегөл исемле икән. Кулында — Коръән.

— Чиләгенә биш йөзне сорыйм, дүрт йөзгә җибәрәм, — ди. Изге китаптан сүрәләр укып утырганда тизрәк алып китәләр икән.

Бер заман Уразбахты хатыны янына тормозларын сызгыртып зәңгәр «джип» килеп туктады. Нишләр икән дип алар да шул якка төбәлделәр. Бик озаклап сөйләште машина хуҗасының ыспай гына киенгән, бизәнгән-ясанган, чәчен өеп лакка катырып куйган хатыны. Килештеләр бугай. Җиләкләр чиләктән чиләккә бушатыла башлады. Бөтенесен дә алып бетерде түгелме соң? Әйе шул! Бер генә җиләге дә калмады. «Джип» китеп баргач, хатын да буш чиләкләрен күтәреп, Уразбахты борылышына таба юнәлде.

— Әллә аның урынына күчикме? — диде Фирдәүсәсе.

Тиз генә чиләкләрне шунда күчереп куйдылар.

Шул вакыт алар янына искерәк кенә, ак төстәге «жигули» машинасы килеп туктады. Югары очның мәзәк кушып сөйләшергә яратучы Шәһәр Рәфәгате бу машинаны «җигүле ат» дип йөртә.

— Күпмедән сатасыз? — дип сорады чандыр гәүдәле, житен чәчле, гади генә киенгән, утыз яшьләр чамасындагы хуҗасы.

— Биш йөз, — диде Фирдәүсә.

Теге ир бераз гына уйланып торды да:

— Дүрт йөздән бирсәгез, алты чиләгегезне дә алып китәм, — диде. Юл буе бәяләрне белешеп килгән ахрысы.

Назыйф белән Фирдәүсә бер-берсенә карашып куйдылар.

— Нишлик? — дип сораса да, хатынының ризалыгы тавышына ук чыккан иде.

— Бирәбез, — диде Назыйф.

— Балалар күп минем. Аларга конфет алганчы варенье кайнату

арзангарак төшә. Көнгә берәр кило конфет кына житми бит, — дип аңлатты ир.

Аларга нәрсә, берьюлы алты чиләк җиләкләрен сатып җибәрү шатлыгы бөтен барлыкларын биләгән иде инде. Тиешле акчаны санап алдылар да, янадан баягы җиләклеккә менеп киттеләр. Кояш баеганчы шактый вакыт бар әле, тагын бераз җыя алалар. Сарыклар көтүдән кайтмый калыр, сыер савылмас дип борчыла торган түгел. Өйдә Назыйфның әнисе Нурҗидә белән кызлары Алсу бар.

Тиз генә тагын өч чиләк тутырып алдылар. Алар да дүртәр йөздән китте. Ярты көндә икесенә өч мең алты йөз сум акча эшләделәр. Көн саен болай кереп барса, шәп буласы икән!

Имән Елгага кайтып житкәндә төнге унбер тула иде инде. Әле ярый көн озын. Ун тулганда гына күз бәйләнә. Әнисе аларның кайтканын борчылып көтеп торган. Юллары уңганга ул да бик куанды.

— Төштән соң машина-трактор паркында Назыйф абый күренмәде, — дип, инженер егет Рамил сугылган булган.

Телефоннан аңа чылтыратып алды.

— Күчәр кайтып житкәнче ял итеп алам. Эшләрем бар, — дип аңлатты.

— Хатын белән җиләккә йөрибез, — дип әйтә алмый бит инде.

— Иртәнге нәрәдтә директорга әйтеп карармын, нәрсә дияр бит, — диде Рамил.

— Комбайн эшләмәгән килеш паркта вакыт уздыра алмыйм инде мин мондый вакытта, — дип катырак сөйләшүне кирәк санады Назыйф.

Хәзер авылда күмәк хуҗалыкта эшләргә бик атлыгып тормыйлар. Тракторчы-комбайнчыларның күбесе пенсиягә чыгып бетте. Шәһәр җиренә күченеп китүчеләр дә күп булды. Механизаторларга кытлык хәзер. Яшьләр авылда калырга ашыкмый. Ата-анасы кредитка бата-бата университетларда түләп укыта да, диплом алгач тегеләре, Казан, Чаллы, Алабуга тирәсендә акчалырак жиргә урнашып кала. Байтагы кибеттә сата. Аларны кире трактор белән дә өстерәп алып кайтып булмый. Житәкчеләр калган терлекче-механизаторлар белән саграк сөйләшергә тырыша. Былтыр сыер савучы Нурания директор Фәрит сүккәнгә киреләнеп эш ташлагач, авылдан фермага кеше таба алмадылар. Краснай тирәсеннән бер ялгыз хатын табып алып килергә, аңа өй сатып алырга мәжбүр булдылар. Үзенә дә ошап китте бугай Имән Елга. Һаман эшләп йөри әле. Аларның урамнарындагы тракторчы Хәмит йортка да кереп караган иде, ике ай торды да, янадан анасы янына кайтып китте, нәрсәләредер ялганып бетмәде.

## 2

Икенче көнне алар көтү kyyra — иртәнге дүрттә үк кузгалдылар. Бу юлы Кирмән елгасы аша салынган күперне узып, яшь наратлар арасындагы күләгәгә мотоциклларын калдырдылар да, тау астына ашыктылар. Төн кызу торганлыктанмы, чык бөтенләй төшмәгән иде. Куе үлән арасында юешләнеп бетәрбез, дип куркасы да түгел. Бу тирәләргә дә кеше кулы тияргә өлгермәгән икән. Уйдыклар күп. Рәхәтләнеп җыя башладылар. Бер-ике урында каен җиләкләре дә очрады. Фирдәүсә аларны майонез савытына аерым җыеп алды. Аның әнә шундый бер савыты биш йөз сум тора икән. Каен җиләкләре вак була шул, озак җыела. Дамба кырыендагы шул биш-алты сутый чамасы жирдән бишәр чиләк җир җиләге җыеп алдылар. Фирдәүсә олы пакетлар да алган булган икән. Бишәр литрлы чиләкләрне шуларга утырта башлады. Һәркайсының төбенә икешәр чиләк янәшә урнаша.

— Йөртергә дә жинелрәк болай, — дип аңлатты хатыны. Дөрестән дә, ике кулга бирәр пакет тотсаң, дүртәр чиләк була.

— Кичә Урта Кирмән кызлары урман ягыннан шундый пакетлар күтәреп төшеп киләләр иде, — дип аңлатты хатыны.

Ә ул игътибар да итмәгән. Хатын-кыз күзәтүчәнрәк була, үзенә кирәген бик тиз эләктереп ала.

Бу юлы да жиләкләрен сату өчен кичәге жирләренә туктадылар. Минлегөл дә, башкалар да күренми иде әле. Уразбахты халкы жиләкләрен сатарга төш житкәндә генә чыга башлый икән. Ун минутлап тордылар микән, яннарына бер чит ил машинасы килеп туктады. Руль артында да, янәшәсендә дә кәттә генә хатын-кызлар. Болар — жиләксез китмәячәк, бәясен сорарга гына түгел, сатып алырга дип тукталучылар.

— Әле яна гына жыеп чыктык. Менә күрәсезме, нинди эреләр. Изгеләр чишмәсе яныннан ук жыйдык. Бик шифалы жиләкләр, — дип мактый башлады Фирдәүсә.

Хатынына Назыйф та кушылды.

— Ашап карагыз әле. Быелгы жиләкләр бик баллы. Шикәр комы да күп кирәк түгел, — дип, булдыра алганча тезде ул.

Аннан сәүдәгәр чыкмастыр. Ә Фирдәүсәнең теле телгә йокмый. Хатыннарның әле алдына, әле артына чыга. Алты чиләк жир жиләге алып киттеләр. Алар чиләкләрнең кайсын алырга микән, дип аптырап карап йөргәндә, тагын бер машина туктап, каен жиләге сатып алды.

— Сез жир жиләкләрен дә майонез савытларына тутырып куегыз. Андыйларны юлда ашап барырга күп алалар. Чиләкләп сатканга караганда күбрәк акча керә, — дип аңлатты шоферы.

Аңа чын күңелдән рәхмәт әйтеп калды Назыйф. Икенче вакыт ике-өч савыт тутырып алып чыкмыйча булмас.

Көн челләсе житеп килә иде. Һава тынчу. Су эчәсе килә. Өйләреннән алып төшкән литр ярымлы пластик шешәдәге чәй эчелеп беткән. Сусаудан тел аңкауга ябыша. Кече телгә нindидер кутыр утырган кебек. Назыйф суга кул сузымындагы Изгеләр чишмәсенә барып килергә булды.

— Догаларыңны укып, теләкләреңне әйтеп ал, — дип калды хатыны.

Ул әйләнеп килгән арада, бәлки, калган чиләкләрен дә сатып жибәрә алыр. Алабугадан башлап Усали турына кадәр юл буе жиләкчеләр белән тулган диләр бит. Сатып алучылар туктаса — бәхет инде. Алар да сайлана хәзер. Арзангарак эләктерергә тырышалар. Ул жиләкләрне бит кайткач утырып чистартасы бар әле.

Изгеләр чишмәсенең һәр улагында суның тәме төрлечә. «Күз чишмәсе» дигәне бөтенләй читтә тора. Һәркайсының аерым авыруга шифасы бар диләр. Юлаучылар бик күп сугыла анда. Олы савытларга тутырып та алып китәләр. Назыйф та шешәсенә суны чишмәләрнең төрлесеннән жыеп чыкты. Битләрен-кулларын юды. Ятлаган догаларын укып алды. Чишмәләр салкынында, агачлар күләгәсендә рәхәт тә бит, хатыны юл кырыенда басып торганда, монда артык юанып та булмый. Кайтыр юлга атлады.

Артында нindидер хәрәкәт тоеп борылып караган иде, имәнеп китте. Тау өстеннән ап-ак киемле, түгәрәк сакаллы картлар буш һавага салмак кына басып төшеп киләләр. Нәрсә соң бу?! Кояш кызуыннан төшләнә башладымы әллә?! Башына кызу капкандыр дисәң, көн челләсе житеп кенә килә әле. Каккан казыктай урыныннан кымшана да алмый. Аяклары жиргә береккән кебек. Картлар, әйтерсең, күзгә күренмәс баскычтан атлыйлар. Хәрәкәтләрендә — нәзакатьлелек, горурлык, аксакаллар мәгърурлыгы. Төшеп киттеләр дә, бер-бер артлы тимер

басмадан чишмәләргә уздылар. Кулларын, битләрен, сакалларын суга чылаттылар. Чып-чын тере кешеләр кебек үзләре. Янәшәдәге, түбәсенә ярым ай куйган чатырга узып, дога кылдылар, тәкъбир әйттеләр. Үзара берни сөйләшмичә, салмак адымнары белән кире борылып чыктылар да төшкән юллары буйлап кире тау өстенә менеп киттеләр. Алар агачлар арасына кереп күздән югалгач кына хушына килгәндәй булды ир. Бөтен гәүдәсе — шабыр тир, йөрәге дөп-дөп кага. Аның тибеше колакларына кадәр ишетелә. Күргәннәрен акыл белән кабул итә торган түгел. Кешегә сөйләсәң, кеше ышанмаслык хәл. Җитез адымнар белән тизрәк олы юлга таба атлады.

Уразбахты җиләкчеләре чыгып та җиткәннәр икән. Бүген күбрәк тә бугай. Юлның ике ягына да тезелгәннәр.

— Озак йөрдең, — дип, орышып алды Фирдәүсә.

Бер чиләген генә сата алган икән.

— Әллә икебез ике якка басабызмы? Уразбахтылар шулай сата, — диде хатыны.

Ул нәрсәгә дә риза. Җиләкләрне тизрәк сатып җибәреп, яңадан җыярга кирәк. Кичә бик тиз озатканнар иде дә, гел җайлы гына килеп тормый шул. Сатучылары да чутсыз бит. Күп кеше үзе җыя торгандыр.

Чишмә янында күргәннәрен сөйлим микән дип торды да, тәвәккәлләп:

— Анда таудан ак киемле картлар төште, — диде.

Фирдәүсә иренә күзен тутырып карап куйды. Әмма бер сүз дә әйтергә өлгермәде, яннарына озын гына фургонлы «КамАЗ» туктады. Шоферы да машинасы кебек олы гәүдәле.

— Нәрсә сата соң монда бөтен кеше? — дип сорады ул алардан русчалатып.

— Жир жиләге, — диде Назыйф.

— Бу жиләк шулай дип аталамыни?

Ирнең җир җиләген беренче күрүе иде, ахры. Үзе дә:

— Хабаровскидан мин. Бездә нарат җиләкләре үсә. Мондыйларын беренче күрәм әле, — дип аңлатуны кирәк санады.

Бер-икесен авызына кабып караган иде. Ошатып:

— Тәмле икән! — дип куйды.

Шуны гына көткәндәй, Фирдәүсәнең тагын теле-телгә йокмый башлады. Жир жиләген мактапмы мактый!

— Алыгыз бер чиләген! Юлда ашап барырсыз. Чиләге белән бирәм. Биш йөзгә, — дип, кулына ук тоттырды.

Ир:

— Ну чая да инде хатының, — дип кычкырып көлеп җибәрде дә, кесәсеннән биш йөзлек акча чыгарып бирде. — Кайтышлый өйгә күбрәк алмыйча булмас, — дип нәтиҗә ясады.

Ә аларның ике генә чиләкләре калды. Ярты сәгатьләп тордылар бугай, яннарына бер кеше дә туктамый. Әллә җиләкләре аз булганга узып китәләр?! Алардан арырак җиде-сигез чиләк белән утыручылардан алып киткәлиләр. Назыйфның эче поша башлады.

— Әллә тагын барып җыеп килик мәллә? — диде ул.

— Әйдә, — диде Фирдәүсә. Ул да юл кырыенда утырып арыган иде инде.

Яңадан күпернең теге ягында дамба астына төшеп, тау бите буйлап Рус Кирмәне ягына таба барып карарга булдылар.

Кирмән елгасы кырыендагы тигез җирләргә урманчылар нарат утыртып бетергән. Сөзәгрәк тау битләре дә калмаган. Ә елга ярларын яшь таллар баскан. Әле ун-унбиш ел элек кенә бу тирәләргә Урта Кирмән, Арташ,

Имән Елга балалары кармак күтәреп балык тотарга төшәләр иде. Хәзер елга буена якын килерлек тә түгел. Ара-тирә кондыз сукмаклары күренә. Алар ярдагы юанрак агачларны кимереп аударганнар. Урманчылар ерганак читен сукалап утырткан наратлар үсеп киткәч, табигать күзгә күренеп үзгәрә хәзер. Чишмәләр саны арта, инеш сулары күбәя. Әллә көн-төн суыртылган нефть урынына су тутырганга, җир куены аларны кабул итмичә, кире чыгара микән? Әлмәт якларында чишмәләр бозылып бетте диләр. Мамадышны да илле елдан шул көтәме? Басуларда җир маен суыручы таганнар саны елдан-ел арта бара. Аларның авыл халкына гына файдасы юк. Суырткан җир маен озын-озын машиналар белән көннекен көнгә алып китеп баралар. Кыш көне агрофирма гаражларын җылытырга бер-ике мичкә дә сорап ала алмыйлар.

Тау битендә җиләк күп. Әмма ваграк. Үзләре белән алган ризыкларын капкалап алдылар да, башка урын эзләп йөрмичә, чиләкләрен шуннан гына тутырырга булдылар.

Бу юлы да караңгы төшкәч кенә өйләренә кайтып керделәр. Каен җиләген дә кушып, сигез мең сум акча эшләделәр бүген. Мондый акча шабашникларга гына тама торгандыр. Аларга да гел түгелдер.

Бүген тагын инженер егет сугылып чыккан.

— Печән чабарга китте,—дигән әнисе.

Ул пешергән ашны тиз-тиз генә ашадылар да, урыннарына аудылар.

Назыйфның төшенә тагын Изгеләр чишмәсендәге картлар керде.

3

Өченче көн дә шулай узды. Тагын дөнья җиләк саттылар. Бу юлы агрофирма директоры Фәрит сугылган. Әнисе ана да:

— Печән чабалар, — дигәч, бер сүз дә әйтмәгән.

Назыйфның: «Запчасть алып кайткач кына эшкә чыгам», — дигән сүзен житкергәч:

— Берүк эш ташлый күрмәсен инде! Аның урынына тиз генә алмаш табып булмый хәзер. Сез олы кеше, Нуржидә апа, яхшылап әйтә күрегез, — дип, бераз тынычланып китеп барган.

Дүртенче көнне җиләкләре авыррак сатылды. Тагын иртүк төшеп ун чиләк җыеп килгәннәр иде, ике сәгать торып берсе генә китте. Башкаларга да бик туктамыйлар. Болай булса, бүген җыйган чиләкләрен өйгә алып кайтырга туры килмәгәе.

— «Сайкичу» базарына барып карыйк мәллә? Анда машиналар күп туктый. Сатуы җинелрәк булыр иде, — диде Фирдәүсә.

Ул да көн челләсендә кояш кызуында таптанып торып талчыккан иде бугай.

Назыйф үзе дә анда барырга кызыга. Кайчандыр ул базарны Шүрәле чишмәсенә су эчәргә туктаган юлаучыларга кыстыбый, сөт сатып Түбән Яке хатыннары башлап җибәргән иде. Аларга Түбән Сон белән башка авыллар килеп кушылды. Тәмам заманчага әйләнеп бетте хәзер. Киоскларга охшатып, сату урыннары ясап куйдылар. Хатыннарны машина артыннан чабудан тыйдылар. Тора-бара, кафесы булган заправка станциясе ачылды. Казандагы Сөембикә манарасына охшаган мәчет салынды. Күбесенең үз сату урыннары бар бүген анда. Клубта эшләүчеләре дә, укытучылары да, сыер савучылары да чиратлашып йөриләр. Халыкны туйдыра да, тормышларын җайларга, бала-чагасын укытырга, башлы-күзле итәргә акчасын да бирә базар. Җәй житкәч җиләк, гөмбә, мәтрүшкә сатучы хатыннар һаман чиләкләрен күтәреп туктаган һәр машина, автобус каршына йөгереп бара. Алардан төшүчеләрнең бер алдына-бер артына чыга, тәмле телләрен кызганмый.

Назыйф мотоциклын киосклар артындагы аулак урынга туктатты. Хатыны ике чиләкне күтәреп китте. Монда да җиләкчеләр дөнья икән. Карап торсаң, бер тамаша. Җиләкләрен тәкъдим итмичә бер генә кешене дә калдырмыйлар. Хатыны:

— Монда өч йөз илле сумнан да биреп җибәрәләр икән. Җиләк күп бит, — дип әйләнеп килде.

Бу аның : «Нәрсә эшләргә икән?» — дип соравы иде.

— Алсалар, бир инде, — диде.

Кая барасың! Чиләк күтәреп йөрүчеләр умарта күче кебек.

Фирдәүсә китеп барды. Йөри торгач, бер автобустан төшкән хатын алырга риза булды бугай. Чиләге белән тоттырды.

— Җиләген өч йөз иллегә, чиләген илле сумга саттым. Яңасын утыз биш сумга авыл кибетеннән алырбыз әле, — дип, акчасын аңа китереп бирде.

— Майонез савытын бик тиз алалар икән, — дип, берне тутырып алып китте. Дөрестән дә, кешеләр янына барып житүгә сатып та җибәрде һәм аңа кул изәде. Назыйф тиз генә тагын берне тутырып илтеп бирде. Чоланнары почмагында берничә ел җыелып торучы буш савытлар да калмаячак болай булса. Мотоцикл бишеге артына байтак салып алып төшкән иде. Ул да ике савытны тутырып алгарак чыгып басты. Ун минут торды микән, ике яшь кенә кыз алып киттеләр. Акрынлап чиләкләре бушады. Бер сәгать эчендә җиләкләре сатылып бетте. Кеше күп булса да, көнчелек, бер-береңә комачаулау юк икән. Кем генә сатмый монда җиләкне?! Түбәтәйле бабайлар да, мәктәптә генә укучы кызлар да, яшь киленнәр дә, әбиләр дә... Кем телгә остарак, шулар тизрәк сатып бетерә бугай. Кайберләре култык асларына зәңгәр мәтрүшкәләр дә кыстырган. Аларны учламлап бәйләгәннәр. Шәһәр халкы кочаклап сатып ала. Алар йөри торган тау битләрендә дә шактый күренәләр иде. Җыярга кирәк икән. Җиләк бераз гына арзангарак китсә дә, шулай тиз сатылып бетүенә сөенделәр. Барыбер файда. Өйдә ятып кына акча керми!

Назыймның агрофирмадан хезмәт хакын рәтләп алганы да юк. Йә ашлык-печән, йә бозау белән түлиләр. Әле ярый әнисенең пенсиясе белән хатынының хезмәт хакы бар. Авыл мәктәбендә химия укыта ул. Укытучыларга хәзер акчаларын тоткарламыйлар. Бераз сөт тә саткалыйлар. Ә акча кирәк. Өй түбәләренең шиферлары мүкләнеп бетте. Кеше коймасын-капкасын хәзер тимердән, буялган калайдан ясата, аларныкы һаман унбиш ел элек вафат булган әтисе такталардан, имән бүрәнәләрдән ясап куйган килеш тора. Аның да гомер чәлләсе узып бара — утыз биш яшен тутырды былтыр. Йортны, каралты-кураны янарту хәзер аның җилкәсендә. Ләкин акчаны гына җиткереп бетереп булмый. Болай күмәк хуҗалыкка гына карап ятса, гомер мантып китә алмаячаклар. Яннан акча керту юлларын да таба башларга кирәк. Алсу да уникенче яше белән китте. Аны укытасылары, башлы-күзле итәселәре бар. Бөтенесе хәзер, иске булса да, машина ала. Аларга да зыян итмәс иде ул. Үзеннән соң оныкларына җимерек өй калдырмаска иде бит.

Фирдәүсә пәрәмәчләр сатып алган иде. Аларны капкалап, кайнар чәй белән бастырып куйдылар.

Шунда Назыйфның күзе аларга кызыксынып карап торучы, үзеннән беразга гына өлкәнрәк, тәбәнәк буйлы, юанрак бер иргә төште. Берәр таныш кешеме әллә соң? Хәтер чоңгылларында казынып караган иде, берәүне дә хәтерләтми кебек. Ә ир һаман олы гына «джибы» янында елмаеп аларга карап тора.

— Назыйф бит син, шулаймы? — дип сорады ир алар янына килеп.

Фирдәүсә дә, ул да ят кешенең ана исеме белән эндәшүеннән аптырап калдылар.

— Әйе... — диде ул һаман исенә төшерергә теләп.

— Танымадың бугай. Мине дөрестән дә бик үзгәргән диләр. Федя... Фәргать булам мин. Ягоршиннан...

Йә, Хода! Әтисенең Уралда яшәгән абыйсы малае бит! Фәргать!!!

Кочаклашып күрештеләр.

— Екатеринбурдан Казанга барыш иде. Сине күрдем дә, таныш кебек тоелдың. Мотоциклына карагач, шунда ук таныдым! Хашим абыйда гына иде шушындый кулдан ясалган мотоцикл бишеге... — дип аңлатты Фәргать.

Менә бу очрашу ичмасам! Егерме ел күрешкәннәре юк иде инде. Алар әтисе белән соңгы тапкыр кунакка кайтканда Назыйф мәктәптә генә укый иде әле. Хәзер икесенең дә әтиләре юк инде...

Озаклап бер-берсенең хәлен сораштылар. Фәргать сәүдәгәрлеккә керешеп киткән икән. Казанга баруы.

— Кайтышлый Имән Елгага сугылып чыгасы килгән иде. Болай булгач, иртәгә кермичә калмыйм. Нуржидә җиңгәчәйне дә сагындым. Бик күрәсе килә, — дип китеп барды ул.

Аны күргәч, икесенең дә күңелләре тагын да күтәрелеп китте. Рус Кирмәне тавыннан тагын алты чиләк җиләк җыеп килделәр. Ул көнне дә алар өйләренә кайтып җиткәндә төнге уникенче киткән иде инде. Анда аларны яңалыклар шактый көтә иде. Иртүк бакча башларына бер йөк рулонлы печән китергәннәр. Ул рулоннарны күтәреп сала торган тракторны да хуҗалык рәисе Фәрит печән белән бергә җибәргән. Яңгыр эчләренә үтмәсен дип әнисе белән кызы печәннең өстен полиэтилен белән каплап, колгалар белән бастырып та куйганнар. Кичке якта инженер егет:

— Назыйф абый иртәгә чәчүдә эшләгән акчасын алырга төшсен, — дип әйтеп чыккан.

Язгы чәчүдә эшләгәне өчен утыз мең сум акча аласы бар иде әле аның. Район сабан туенда ун мең сум премия алгач, бөтенләй күрмәм инде аларны дип, «әппәр» иткән иде инде. Кисәктән бәхет ишелеп төште, димәк. Ала каргадан алачагың булсын дип юкка гына әйтмәгәннәрдер. Иртүк төшеп житәчәк!

Икесенең дә жеп өзәрлек тә хәлләре калмаган иде, урынга авуга күзләре дә йомылды.

Механизаторлар жәй көннәрендә дә, кыш та иртәнге алтыда машина-трактор паркына җыелышып беткән була. Нәрәд алалар да, кайсы кайда таралыша.

— Югалттык без сине, — диделәр.

Аның комбайнына кирәкле запчасть һаман юк икән әле. Чапкан жирләрен печәнгә җыеп бетергәннәр. Хәмитнең тракторының моторы шакылдаган.

— Синең осталык бар иде, җыеп карамыйсыңмы? — диде Рамил.

Башка вакытта күнәр иде. Бүген аларга кунак кайтырга тиеш. Хатыны да артыннан:

— Озак йөрмә! Фәргать абыйның кайтуына тавык суясы, мунча ягасы бар. Ишеттеңме?! — дип кычкырып калды.

— Бүген әтинең Ягоршиндагы абыйсының малае кайта. Каршы алырга, кунак итәргә кирәк. Ачуланма инде, — диде ул.

Хәмитнең борыны салынды. Үтерсәләр дә трактор моторын үзе генә сүтеп җыя ала торган кеше түгел шул ул. Янында өйрәтеп торсаң, эшли

белә. Үзенең андый нечкә эшләргә тотынганы гомерендә булмады. Ничек укыгандыр да, кемнәр трактор йөртергә таныклык биреп чыгарганнардыр. Кечкенәдән үк олыларга ияреп, алар кушканны гына эшләп йөргән кеше бит ул. Инженер Рамил:

«Төнге уникегә кадәр жир сөр» — дисә, унике тулганчы кайтып китми. Коеп яңгыр яуса да, жирне бозып бетерсә дә, эшләвендә була. Колхоз беткәч, Хәмит кебек шәһәр жиренә чыгып китеп анда үзләренә урын таба алмаячакларын аңлаганнар һәм койрыклары авылга ябышканнар гына калды сала жирендә хәзер. Назыйф та, чыгып китсә, күптән йортлы-жирле була иде инде. Әнисе ризалыгын бирмәде.

— Әтиегез гүрендә рәнжеп ятар! — диде.

Олы кешегә каршы барып булмый. Әтисе Хашим кечкенә чагыннан ук:

— Син авылда калачак бала. Пужымыбыз бетмәсен! — дип үстерде шул аны.

— Алайса, иртәгә эшкә төш инде, — дип калды Рамил.

Бухгалтериядә аның хезмәт хакын әзерләп куйганнар иде инде. Исемлеккә имзасын салды да, акчасын алып кайтып китте. Болай булса, жиләк саткан акчаларын да кушып, өйләренең түбәсен буялган калай белән ябарга житә.

Фирдәүсәсе хезмәт хакын тулысынча алып кайтасына ышанмаган булган икән. Кулына утыз мең сумнан артык акча тоттыргач, аның да күнеле әллә нишләп куйды. Акча хакимлек иткән заман килде шул. Бәяләрнең ел саен үсүенә өлгереп булмый. Үзләреннән арткан сөтләрен тапшырып баралар да, акчасы гына бик сөендерми! Ә базардан, кибеттән берәр нәрсә ала башласаң, бәяләре кесәне тешли.

Назыйм Фәргатькә өйләрендәге телефон номерларын яздырган иде. Өйлә турында:

— Эшләрем бетте. Ярты сәгатьтән кайтырга чыгам, — дип чылтыратты.

Өч сәгатьтән Имән Елгада булачак, димәк. Кунакны каршы алуга әзерлек иртүк башланган иде инде. Алсу белән әбисе кибеткә төшеп төрле тәмтомнар алып менделәр. Өй жыештырылды, ишек алды тагын бер тапкыр себереп чыгылды. Мунча ягылды. Әнисе бер көзге бәрәннәрен көтүгә жибәрмичә калдырган булган икән. Назыйф шуны суеп эшкәртте. Ике арткы ботының итен шашлыкка — кәбапка турап куйды. Яшь ит тиз өлгерәчәк. Узган гасырның житмешенче елларында әрмәннәр-әзәрбайжаннар таштан гараж салырга килә башлаган вакытлардан бирле татар авылларында да иң олы сый хәзер ул.

Назыйф эшләрен бетереп килә иде, ишек алдына Хәмитнең анасы Нурсабах атылып керде. Исәнләшү дә юк:

— Син ник минем малайга булышмадың?! — дип туп-туры аның каршына килеп басты ул.

Ишек алдында тыныч кына чемченеп йөргән кызыл тавык, аның бөердән чыккан тавышын ишеткәч, чатыр чабып лапаска кереп китте.

Назыйф башта сүзнең нәрсә турында барганын да аңламыйча торды. Иртәнге якта инженер егет әйткәннәр исеннән чыккан иде инде. Көне буе Хәмитнең тракторы ватылуы турында гына уйлап йөрмәс бит. Беткәнмени монда уйлар нәрсәләре дә! Исенә төшкәч, йомшак кына көлеп куйды.

— Мин ремонтчы түгел. Төзәтсеннәр! — диде ул Нурсабахның Яке урамындагы иң усал, телчән хатын икәнен белсә дә, өркемичә.

Кемнән-кемнән, ә тыныч холыклы Назыйфтан мондый «шырпы»лар

көтмәгән хатын, тәртәсе ярга терәлгәндәй, бер мизгелгә аптырап калды.

— Мин дә төзәтсеннәр дим шул! — дип, ана сәерсенеп карап алды да, ничек тиз килеп кергән булса, шулай ук чыгып та югалды. Өйалды баскычын юып йөргән хатыны Фирдәүсә берни анламыйча калган икән.

— Нәрсәгә кергән иде ул? — дип сорады ул Нурсабах чыгып киткәч.

— Хәмитнең тракторы ватылган, — диде Назыйф, башка бер сүз дә өстәмәде.

— Кемдә нәрсә кайгысы... — диде хатыны.

4

Фәргать кайтып житкәндә барысы да әзер иде инде. Ерактан кайтучы кунаклар татар авылларында сирәк хәзер. Элек кенә ул сабан туйларын күрергә йорт саен диярлек икешәр-өчәр гаилә кайтып житә иде. Фәргатьләрнең дә соңгы тапкыр кайтуларына егерме елдан артык вакыт узган. Өйләрен онытмаган икән әле. Туп-туры капка төпләренә килеп туктады. Бу юлы да кочаклашып күрештеләр. Юл унаенда ул да күчтәнәчкә ике олы гына пакет тәм-том күтәреп кайткан икән. Кайтып житүгә үк өйгә барып керәсе килмәде кунакның. Үзләре уйнаган яшел чирәмле су буйларын, ындыр буасын күрәсе килде. Анда барысы да искечә, үзгәрешсез. Яшел хәтфә чирәмнәре генә калынайган бугай. Элек аларны көтү-көтү казлар, үрдәкләр йолкып бетерә иде. Бала-чагасы да шулар белән бер буада чыр-чу килеп коенды. Чир дә йоктырмадылар. Ярдан суга сикереп уйнауларын, сал ясауларын көлә-көлә искә төшерделәр. Олыгайган, тормыш баскан саен балачак шуклыклары ныграк сагындыра шул...

Табын янында да күп искә алынды алар. Фәргатьнең беренче хатыны сәүдә тармагында эшләгән. Бергәләп кибет ачканнар. Кабат буш жир алып олы гына сәүдә үзәге салганнар. Моннан ун ел элек ул жәмәгате авариягә очрап һәлак булган. Берничә елдан янадан гаилә корып жибәргән. Кибет санын да арттырганнар. Казанга беренче хатыныннан туган кызын федераль университетка укырга кертү мәшәкате белән килгән икән. Ул ана армиядән кайтуга ук өйләнгән иде бугай шул...

Ә Назыйфлар нәрсә сөйләсен?! Аларның — шул авыл тормышы инде. Хәзер агрофирма дип аталучы «Имән Елга» хужалыгында тир түгә. Кемнәрнең кесәсен калынайтканын үзләре дә белмиләр. Хәер, кесәләре калынаючы кешесе дә юктыр. Авылларының Аръяк Нәжми малае Фәрит банк кредитына сатып алган иде, өч елда тәмам бурычка батып бетте бугай. Яз житүгә янадан банкларга йөгерә башлый. «Жиде миллион сум бурычы бар», — дип Мамадыштагы «Нократ» газетасына язып чыгуларына әле күп вакыт та узмады.

— Кичә Интернеттан караган идем, сезнең «Имән Елга» агрофирмасын электрон аукционга куйганнар. Кырык өч миллион сумга саталар, — диде Фәргать.

Назыйф белән Фирдәүсә, әнисе, аптырашып, бер-берсенә караштылар. Бу турыда ишеткәннәре юк иде әле. Дөрес, быелтыр: «Авылны яһүдләр сатып ала икән», — дигән сүзләр йөрде, әмма шуннан ары узмаган иде.

— Әллә теге яһүдләр килә микән, Ходаем?! — диде әнисе.

Ерак Израильдәге бер сәүдәгәр Татарстанның Имән Елга авылында икмәк үстереп ятарга теләр микән соң?

— Хәзер жир кыйммәт йөри. Банкларга залогка да салырга була. Бәясе киләчәктә дә артып кына барачак. Жире өчен әллә кемнәр алырга мөмкин, — дип аңлатты Фәргать.

Бу темага берсенең дә башын катырасы килми иде. Назыйф кунакка мунча якканнарын, аның инде әзер булуын әйтте. Фәргать моңа бигрәк тә сөенде. Зәңгәр мәтрүшкәләр, әремнәр кушып бәйләгән иде Назыйф яңа себеркене. Озаклап чабындылар. Ләүкә кызуында утырганда да бала чакларын искә алдылар.

Кич белән шашлык кыздырганда сүз тагын «Имән Елга»ның сатылуына әйләнеп кайтты.

— Үзем сатып алыйммы соң? — диде Фәргать.

Назыйф та, Фирдәүсә дә аптырап калдылар.

Бу сүзләр салмыш кеше авызыннан чыкса, бер хәл иде. Ә абыйлары — ап-аек.

— Шуның кадәр акчаң бармыни? — дип гаҗәпләнеп сорады Назыйф.

— Кирәк икән, табарга була, — диде кунак. — Хәзерге колхозларның файдасы юк бугай. Түләгән акчаңны да бүтән күрә алмассың, — дип, үз белгәненчә аңлата башлады ул.

Болай да ике аягына аксаучы хуҗалыкларга ике мең унынчы елгы корылык бигрәк тә нык сукты. Өчәр-дүртәр йөз чакрымнан — Киров өлкәсеннән ташыган печән алтын бәясенә төште. Назыйф та ике ай буе кунып эшләп кайтты анда. Әле ярый үзләренә бушлай берәр йөк печән бирделәр, акчасын яхшы түләделәр.

Беркавым барысы да тын гына утырдылар.

— Ник алай дисең әле син! — Фирдәүсәнең аның белән килешәсе килми иде. — Нәҗми малае күпме керткәнен күрсәтеп тора мәллә! Тугыз миллион сумга сатып алып, кырык өчкә куйган ди бит әнә.

Бернәрсә дә әйтеп булмый, хатыны хаклы. Файдасы юк дигән булып, эшләп йөргән көннәре. Фермадагы сыерларның да яртысы гына калды инде. Бөтен байлыгы таралып бетмәгән, хуҗа барыбер табылачак.

— Агрофирмаларын сатып алгач, монда кайтасыңмы? — дип аптырап сорады Назыйф.

— Юк, — диде Фәргать. — Рәис итеп сине куеп китәм.

Назыйф кычкырып көлеп җибәрде.

— Булмаганны! — диде ул. — Миннән рәис чыкмаячак.

Фәргатьнең дә бирешәсе килми иде.

— Ник чыкмаска тиеш әле ул?! Кырыкка җитеп киләсең бит инде. Гомер челләсенә җитеп, кеше белән сөйләшергә генә өйрәнгәнсеңдер. Кешене эшкә куша бел син! Акчаңның тиененә кадәр кая киткәнен карап, чутлап торырга хөкүмәт бар. Сукмагыңнан чыга башласаң, бик тиз килеп җитәрләр. Аннан, хәзер бит инде үземнеке дип эшли башлыйсың! Чүптән дә акча ясыйлар хәзер, колхозны гына файдага эшләтү бик авыр булмас!

Назыйфның һаман көлемсерәп утыруын күргәч, сүзен дәвам итте:

— Ул колхозыгызның миңа бер тиенгә дә кирәге юк. Кибетләрдән күбрәк акча кертәм мин. Сезгә генә булышасым килә. Акча гына биреп китсәм, кадере булмаячак. Ә болай — үзегезгә акча эшләргә юл ачыла. Аръяк Нәҗми абый да әллә кем түгел иде. Малае күтәрелә алган. Бөтенләй кулыңнан килмәсә, таралып беткәнче яңадан сатып җибәрермен.

Яңа тәкъдим Фирдәүсәнең дә җанын билэгән иде.

— Үзем төрткәләп, өйрәткәләп торырмын! Үзем булышырмын. Безнең нәсел зур әле авылда. Сүз әйттермәбез, — диде ул.

Назыйф шикләнми, Фирдәүсә тотынса, ахырына кадәр җиткерә. Фәргатькә дә аның тәвәккәллеге ошады.

Ноутбугыннан аукционда катнашачагы, «Имән Елга»ны сатып алырга теләве турында хәбәр җибәрде ул.

Иртән юлга кузгалганда озак тормыйча кайтып житәргә вәгъдә итте. Хәзергә серне чишәргә ярамаганлыгын искәртте.

— Аукционда әллә кемнәр катнашырга мөмкин. Конкрет кемнең сатып алырга теләвен белмичә торсалар, сезгә дә, миңа да яхшырак булыр, — диде.

***

Кунакны озаткач, Назыйф паркка төшеп китте. Фирдәүсә белән киңәшкәннән соң шулай ниятләделәр. Бөтен жиләкне жыеп бетереп булмас. Фәргать әйткәнчә, иртәгесе көнне уйлап та яшәргә кирәк.

Хәмитнең трактор двигателен салдырып куйганнар иде. Терсәкле валын кырдырып алып кайтканнар. Кирәкле бөтен әйберсе дә бар. Һәммәсе дә кул астында булгач, Хәмит тә янда булышып торгач, төш турына жыеп бетерделәр.

— Юкка укымагансың син, Назыйф абый, кулың да алтын, башың да эшли, — дип мактап алды Рамил.

Унны бетергәч институтларда укып йөрмәде шул ул. Дөресрәге, үзенең укыйсы килмәде.

Төшке ялга кайтып барганда каршысына машинасы белән Фәрит очрады. Аның олы юлга чыгып баруы иде. Компьютер заманы: бөтен хәбәр секунды белән иясенә барып ирешә. Аның аукцион турында район житәкчелеге белән киңәшергә чабуы иде.

Кичке сигезләр тирәсендә Фәргать чылтыратты.

— Күңелсез хәбәр бар... — диде ул, хәл-әхвәл сорашканнан соң.

Назыйф эсселе-суыклы булып китте. Әллә кайтканда авариягә тарганмы? Хәзер машиналар күп, кеше гаебе белән дә бәла-каза килеп чыгарга мөмкин.

— Әллә... — дип сүз башлаган иде...

— Сезнең хужалыкны аукционнан алганнар, — диде абыйсы.

Йөрәгенә жылы йөгерде.

— Әллә нәрсәләр уйлап бетердем. Берәр житди нәрсә булган мәллә дип торам, — диде ул жиңел сулап.

— «Имән Елга»ны үзебезгә сатып алмакчы идем, язмагандыр инде. Ярар... Башкача булышырмын мин сезгә, — диде Фәргать.

Назыйф та, Фирдәүсә дә олы бер хужалыкны алай ансат кына сатып жибәрәчәкләренә ышанып житмәгәннәр иде, артык кайгырмадылар. Әмма икесе дә тормышларында тамырдан үзгәрешләр башланачагын тоемлаган, күңелләреннән моңа әзерләнеп беткән иде инде.



Гөлзада
Әхтәмова

# ИЗГЕЛЕКТӘ БЕЗНЕҢ БАР НИЯТ

## Шигърият

**Шигърият!**
**Серләремне сиңа ачып салам,**
**Син бит миңа һәрчак бик кирәк.**
**Син булмасаң, нәрсә эшләр иде,**
**Дулкынланып типкән бу йөрәк?**

**Кайгыларга ничек түзәр идем,**
**Синең иңнәреңә салмасам,**
**Уйлар диңгезендә бата-чума,**
**Ярларыңа ябышып калмасам.**

**Чәчәкләрне күреп соклануда,**
**Чыкларыннан чишмә ясауда —**
**Көч-куәтләр биреп торучы син,**
**Яшәтмәүче җанны кысада.**

**Мәхәббәттән яна язган көнне**
**Ярдәм кулы сузып өлгердең.**
**Кәгазьләргә тамган күз яшьләрем**
**Шигырь булып чыкты — тереләдем!**

**Туган телнең бар киңлеген тоеп,**
**Шигъри хисле йөрәк талпынды.**
**Эзләнелде сүзләр — зурлар өчен**
**Зирәк, батыр туган халкымны.**

**Җирдә хыялланып, ни әйтсәк тә —**
**Изгелектә безнең бар ният.**
**Җитәкләшеп, бер сукмактан үттек,**
**Рәхмәт сиңа, рәхмәт, шигърият!**

Гөлзада ӘХТӘМОВА — *шагыйрә; «Җәйге кар», «Йөрәгемдә яшен», «Күңел ашкынуы» һ.б. китаплар авторы. Алабуга шәһәрендә яши.*

## Көзге алдында

Көзге! Көзге! Мине бераз
Булмыймы соң яшәртеп?
Иртә-кичен торасың син
Гел дөресен күрсәтеп.

Уңга карыйм, сулга карыйм
Җыерчыклар кимеми,
Тик өстәлеп кенә тора:
Бу әбекәй — мин мени?!

Альбомдагы яшь сурәтләр
Моңсу елмаеп ала.
Йөгерә-йөгерә үтә гомер —
Эзләре йөздә кала...

## Ах, бу яз!

Һәр яз саен сулар гына,
Ярдан чыга ташкынланып.
Ә минем күңелем тыныч,
Инде бүтән ашкынмамын.

Кояш нурлары төшсә дә,
Сипкелләр ясап йөзгә,
Язларда назлар эзләмәм,
Елмаеп серле күзгә.

Янмаска, башка сөймәскә! —
Шул инде әйткән нәзер.
Кабат яратып җуярга
Йөрәгем түзмәс хәзер.

Ах, бу яз! Күңел бөресен
Яфрак итәсе кабат.
Тылсымлы көчләр пышылдый:
Ярат син аны, ярат...

Түбәдән төшә тамчылар:
Тып та, тып та, тып та тып!
Тап та югалт, тап та югалт,
Тик син туйма яратып.

Ах, бу яз! Күңел бозларын
Эретә язды инде.
Шуңа да яздыр инде...

***

Кем дисәгез —
Мин арагызда
Кеп-кечкенә бер ханым.
Зурдан кубып иҗат итмим —
Җиткән кадәр илһамым.

Тик шулай да, чын күңелдән
Әйткән бар гади сүзем.

**Самими җан тирбәлгәндә**
**Моңлана ике күзем.**

**Мин — үткәннең бер хәтере,**
**Әйләнәм дә чолганам.**
**Халкымның ерак чорыннан**
**Нидер табып чыгарам.**

**Тынгылык белмәс күңелгә**
**Бабамнар рухы дәшә.**
**Миндә бүген үткән белән**
**Киләчәкләр көрәшә.**

## Алсу мизгелләр көле

**Гомер көзе нәрсә? дисәң,**
**Алтын яфраклар иле.**
**Янып-ярсып, шаулап үткән**
**Алсу мизгелләр көле.**

**Уйланыр чак, сызланыр чак,**
**Үткәнгә кайтып-кайтып,**
**Кушып-алып, чагыштырып,**
**Нәтиҗә ясар вакыт.**

**Мыскалларга сала-сала**
**Кайгы-шатлык үлчәнә.**
**Басар кайсы як көзеңдә,**
**Басарниләр үкчәңә?**

## Көзге яңгыр

**Җирдә үткән юлларым бик күп чакырым.**
**Яңгырлардан саклый мине кулчатырым.**
**Әйтче миңа яшермичә, көзге яңгыр,**
**Язмыш көзем ниләр күрергә чакырыр?**

**Нишләрмен соң кулчатырым ачылмаса,**
**Күңелем әрнеп, сагышларым басылмаса?**
**Ишет мине, саранланма, көзге яңгыр,**
**Күктән өмет йолдызларын, зинһар, яудыр.**

**Шатлыктан гына тормады бар яшәвем.**
**Тамды-тамды минем дә күп күз яшьләрем.**
**Тыңла мине, сүндермәче, көзге яңгыр,**
**Соңгы мәхәббәт очкынын җанга калдыр.**

**Җылы түгел, салкын синең тамчыларың,**
**Юа алмас инде йөрәк ачыларын.**
**Тик шулай да ышанам мин, көзге яңгыр —**
**Алда әле бәхеткәем бераз бардыр.**

Флүс
Латыйфи

# ӨЧ ХИКӘЯ

**Җирәнкәем**

Безнең якларда мондый бер гадәт бар: игеннәр өлгереп, урак башлангач та, авылда кул арасына керердәй бөтен ир бала атка утыра. Кайсы комбайннан ашлык ташый, кайсы ындыр табагында эшли. Олырак малайлар элеваторга икмәк чыгара.

Миннән ике-өч яшькә зуррак күрше малае Әдип инде җәй буе колхозда эшли. Көндезләрен такта арбага җигелгән туры аты белән кайта ул. Тугара, арбага печән йә солы сала да атны шунда бәйләп, ашарга кереп китә. Мин шуны гына көтеп торам да. Ул кереп китүгә ат минем карамакта. Дунай кушаматлы бу туры иркәләнергә бик тә ярата. Өйрәтеп куйганнар диярсең, муенын кашыганда башын сузып күзләрен йомып тора, аннары алдына куелган чиләктән пошкыра-пошкыра су эчә, фырлый-фырлый рәхәтләнеп печән ашый.

Минем туктаусыз ат белән мәшәләнгәнемә игътибар иткәндерме, көннәрнең берендә Әдип мине чакырып алды һәм ничектер бик үз итеп эндәште:

— Ат белән эшлисең киләме?

Шаяртмый микән дип шикләнә-шикләнә генә җавап бирдем:

— Килә дә бит...

— Алайса, бик килгәч, иртәгә колхоз утарына бергә барырбыз. Анда сиңа да бирәр ат табылыр әле...

Икенче көнне таң атуга без атлар утарында идек инде. Бригадир Хәмдия апа күлмәк җиңемнән чыгып торган ябык беләкләремә, арба тәгәрмәченнән чак кына югарырак буема озаклап карап торды да авыр сулап куйды. «Эшли алыр микән бу бүлтерек?»—дигәндер инде. Аннан соң тагын бер кат миңа, аннан соң Әдипкә карап алды да «Уф!» дип кулын селтәде.

— Нишләмәк кирәк? Ындыр табагы тирәсендә булса да йөрер әле...

Аннары ат караучы Закир абыйга борылды:

— Берәр тынычрак ат җигеп бирерсең инде. Кеше житми бит...

Эш көнем шулай башланды. Закир абый, нигәдер, бик кырыс, ачулы кеше булып күренде миңа. Агач аягын такта идәнгә шак-шок басып атлавы гына да ни тора. Житмәсә, әле ул аяк бик ямьсез тавыш чыгарып шыгырдый да икән. Абзыебыз ни бригадирга, ни миңа өздереп бер сүз дә әйтмәде, агач аягын бер яктан бер якка болгап сала-сала утарга кереп китте. Ул җитәкләп чыккан атны күргәч кәеф кырылды-кырылуын. Йа Хода! Миңа дигән ат шушы микәнни?! Колыннан чак кына зуррак ич бу. Үзе тагы әллә нинди пычрак җирән төстә. Ярый, ак кашкасы матур инде матурын. Кара яллары, койрыгы тигәнәк белән уралып чәбәләнеп беткән, житмәсә, арт аягына аксый да икән әле. Нәкъ Закир абзыйның үзе кебек...

— Байталың шушы булыр, — диде атлар хуҗасы. — Акрын гына, кумыйча гына йөрсәң, тынлаучан да, күндәм дә булыр. Кара аны, әйберне күп төятмә. Аягы төзәлеп бетмәгән... — Соңгы сүзләрен ул миңа түгел, ә шушы йолкыш атка карап, аңа атап әйткән кебек тоелып китте. Бераз гына үртәлеп тә куйдым. Тапканнар байтал...

Закир абый тагын нәрсәдер мыгырданып куйды. Ни генә әйтер икән дип колакларымны торгызган идем.

— Бала-чагага биреп ат боздыралар да... — дигән сүзләрен генә ишетеп калдым.

Хәер, аның мыгырдануына игътибар итеп торыр чак идемени. Шушындый да йолкыш, таралмаган, юылмаган кечкенә ат биргәннәренә эчем пошса да, сиздермәскә тырыштым, килеп йөгәненә ябыштым.

— Ә исеме ничек аның?

— Урам Сәрвәр...

«Нәрсә аңлата соң ул?» дип сорамакчы булсам да, тыелып калдым. Закир абый биргән камыт, дуга, ыңгырчак ише әйберләр белән булаша башладым.

Бик үк сөйкемле җан иясе булмаса да, тынлаучан икән тагы. Камытны күтәреп килүгә, минем буй җитеп үк бетмәгәнне чамаладымы, башын иеп үзе үк аңа сузылды, кигертеп бетерүгә башын күтәреп селкеп алды да әкрен генә тартканга буйсынып тәртә арасына кереп басты. Әдип янында карап торып та, аңа ярдәм иткәләп тә өйрәнеп беткән идем инде, җигә башладым. Камыт бауларын тарттырып, аркалыкларын күтәреп бәйләдем дә Закир абыйга карадым. Ул бөтен бауларны тикшереп чыкты, чөелдерекне янадан тарттырып бәйләде, бер сүз дә әйтмичә генә арбага карап алды.

— Ярар, ындыр табагында апаларың ни кушса, шуны эшләрсең, — диде ул. Бу юлы да сүзләрен Урам Сәрвәргә карап әйтте. Әйтерсең лә мин ат җигүче дә, йөртүче дә түгел, биредә шушы йолкыш хуҗа.

Сәрвәрнең кыска буйлы булуы да ярап куйды. Кибәк яки ашлык төягән арада аның ялларын чистарттым. Юкса, тигәнәккә, сырганакка, тагын әллә нинди чәнечкеле үлән орлыкларына буталып беткән ул. Аларны берәмләп чүплим, тарыйм. Ат исә риза булып, башын сузып рәхәтләнеп басып тик тора. Озын кара койрыгын да чистартып чыктым. Бердән матурланып, чибәрләнеп киткән кебек булды. Куенга кыстырып ипи кыерчыгы алып килгән идем, аны урталай бүлдем дә яртысын, кулымны тешләмәсен дип курка-курка гына уч төбемә салып атка сузган идем, Сәрвәр аны тешләре белән түгел, бәрхеттәй йомшак иреннәре белән сакланып кына алды, ашыкмый гына чәйнәргә тотынды. Зәңгәрләнеп торган зур коңгырт күзләрендә әллә нишләп рәхмәт хисләре чагылып киткән кебек булды. Чәй янында шактый зур кисәк шикәр чәлдерү бәхете дә эләккән иде. Анысын да бүлешеп каптык. Кытырдатып чәйнәде аны бахбай.

Тагын бер кызык ягы бар Сәрвәрнең. Тәмле тамак булу өстенә, бер дә сукканны яратмый икән. Иләшә төшкәч, башка малайлардан күрмәкче, мин дә озын чыбыркы ишеп алган идем. Бераз мактанасы килеп микән, юырттырырга исәпләп суккан идем, бөтенләй туктады да калды. Дилбегәне дә тарткалап карыйм, аягын да атламый.

— Үпкәләде!

Күнелемне шундый уй яндырып узды. Арбадан төштем дә яңакларыннан сыйпарга, сөяргә, иркәләргә керештем. Үзем оятымнан җир тишегенә керердәй булып сөйләнәм:

— Ярар инде, Сәрвәркәем. Мин бит белми генә, ялгыш кына... Бүтән гомеремдә дә сукмам.

Ат башын аска игән, кымшанмый да. Авыр итеп тын алганы гына

ишетелә. Арбадагы чыбыркыны алдым да янына килеп аяк астына ташладым:

— Менә, күрәсенме? Бүтән сукмыйм. Чыбыркыны да юк иттем. Сәрвәр, әйдә инде, кузгал, хур итмә мине!

Әллә, чынлап та, кеше сүзен аңлый микән, малкай. Утырырга да өлгермәдем, Сәрвәр киерелеп тартты да арыш төягән арбаны җинел генә кузгатып, юыртып алып та китте. Шуннан соң бүтән кул күтәргәнем булмады. Дилбегә белән какканны да, ягымлы итеп «Йә, малкай!» дип кычкырганны да бик тиз аңлый торган ат булып чыкты ул.

Әдип шикелле хәзер мин дә төшке ашка ат белән кайтам. Аны тугарып ук бетерәм дә җылы су белән аркаларын, күкрәкләрен юам, кыргычлыйм. Ул бердән матурланып, тазарып китте кебек.

Әнкәй баштарак: «Ник маташасың инде?! Ял ит бераз, ичмасам!» — дип караса да, әткәй кул гына селтәде:

— Ярар! Чистартсын сана. Ат җене кагылгандыр...

Ни генә әйтсәң дә, эш—эш инде ул. Кич кайтканда аяк-куллар авырая, өлкәннәр әйтмешли, җеп өзәр хәл дә калмый. Башны мендәргә куюга йоклап китәм. Төшемдә дә шул Урам Сәрвәр белән җенләнәм. Менә без урманнар, таулар өстеннән каядыр очабыз, имеш. Аста зәңгәр тасма булып Ык ага, әрәмәләр, авыллар күренеп кала. Ә без һаман өскә, болытлар янына күтәреләбез. Юк, алай да түгел икән. Мин арып яшел аланда ятам. Күзләрем йомык. Янымда Сәрвәр утлап йөри. Ул да булмый, йомшак ирennәре белән минем маңгаема кагыла:

— Тор, Мансур, тор, соңга каласың. Атың көтә торгандыр инде...

Гаҗәпләнеп күзләремне ачам. Сыйпый-сыйпый әнкәй уята икән:

— Тор инде, улым. Эшкә барасың бар бит, — ди ул. — Урак беткәч бер иркенләп йокларсың әле.

Җылы мендәрдә никадәр генә ятасың килмәсен, торырга, киенергә туры килә. Иртәнге саф һавада йокы тиз ачыла тагы. Утар янына килеп җиткәндә җылы мендәрнең иртәнге тансыклыгы да, арыганлык та онытыла.

Ерактан ук сызгырып киләм мин Сәрвәр янына. Утарның капкасы янында туктап калам да, һәр иртәне гадәткә кергәнчә, куенымнан кибән баш ипи чыгарам. Сәрвәр капка бавын башы белән генә чөеп җибәрә дә ачылып җитмәгән капканы шома гәүдәсе белән аерып минем янга чыга, ипигә сузыла. Аны ашап бетергәч, тагын юкмы дигәндәй, борыны белән җилкәмә төртелә, исни, башын иңемә куеп тынып кала. Шикәр өмет итә ул. Безгә бик сирәк эләгә торган бу тәмле нигъмәтне инде икебез бүлеп кабабыз.

Урам Сәрвәр көрәйде, матурайды. Аягындагы җәрәхәте дә төзәлә башлады. Бер-беребезгә тәмам ияләшеп беттек. Аның белән аерылу ничек кенә авыр булмасын, инде беренче сентябрь килеп җиткән иде. Эшебезне ташлап, яратып өлгергән атларыбыз белән хушлашып, мәктәпкә, нишләптер сагындырып өлгергән классларга кайтырга туры килде.

...Тәнәфес вакыты иде. Мәктәп ишегалдында малайлар белән куышып уйнап йөрибез. Шул вакыт каяндыр Әдип килеп чыкты. Йөзе кырыс, иреннәре кысылган. Мине җиңемнән тартып туктатты.

— Нигә авызыңны ердың? — диде ул сәлам дә биреп тормыйча. — Җирәненне сугымлыкка дип чыгарганнар бит. Колхозда атларга ревизия булган...

Шул вакытта әллә нәрсә булды. Җир белән күк тоташып коточкыч зур тизлектә әйләнә башлады. Һәм мин шул котырынкы өермәгә кушылып күккә менеп киткәндәй булганымны гына хәтерлим. Күземне ачканда малайлар барысы да минем янга җыелган иде. Ә мин нишләптер җирдә

чалкан ятам. Баш миендә бер сурәт: Жирәнкәем белән без болытлар арасында каядыр очабыз да очабыз, имеш... Торып бастым, тавыш-тынсыз гына малайларны аралап чыктым да җан-фәрман атлар утарына таба чабып киттем. Йөрәгем атылып чыгардай булып тибә, үземнең тизрәк йөгерә, тулпардай канатланып оча алмавыма ачуым килә.

Бәрелеп-сугылып атлар утарына килеп кердем. Капка шар ачык. Буш улак кимереп маташучы дүрт-биш ат арасында Урам Сәрвәр юк! Үзәгемне үкенеч хисе яндырып узды—соңга калганмын!..

Бригадир Хәмдия апа янына ничек атылып килеп кергәнемне хәтерләмим. Керүем булды, яшь аралаш үксү белән кычкырып та җибәрдем:

— Сәрвәр кайда? Жирәнкәем минем...

Бригадир апа яныма килде дә кытыршы учлары белән битемнән аккан яшьләремне сөртеп алды, авыр көрсенеп куйды:

— Йә, тынычлан! Жегет кешегә елау килешми... Үксүемне тыя алмадым:

— Аны... аны бит суярга алып киткәннәр...

Хәмдия апа әллә ничек җиңел сулап куйгандай булды, кулын җилкәмә салып тыныч кына әйтте:

— Сәрвәрең исән... Аллага шөкер, таба алмадылар аны. Мал куучылар Бөгелмәгә ансыз гына китте...

— Исән! Жирәнкәем исән! — дип ышанмыйча үз-үземә кабатлый бирдем.

— Әйе, аранны ачып чыга торган сәер гадәте бар бит аның, мәхлукның. Бүген дә каядыр чыгып югалган. Мал куучыларның эзләп йөрергә вакытлары юк иде... Юкка гына исеме Урам Сәрвәр түгел инде аның. Йөридер берәр җирдә...

Шатлыгымнан чак кына серне ачып ташламадым, ярый әле авызымны учым белән капларга өлгердем. Беләм, аның кайда икәнен беләм ич мин.

Хушлашырга да онытып чыгып чаптым. Аякларым үзеннән-үзе өйгә таба тартты.

...Жилкапканы ачып керүгә шатлыгымнан биеп җибәрә яздым. Булдырган, булдырган, Жирәнкәем! Көтүгә чыкмый торган кәкре мөгезле карт кәҗәбез белән бергә лапас янында бу минутларда миңа иң кадерле җан иясе—Урам Сәрвәр басып тора иде. Мине күрүгә ул колакларын селкетеп алды, алдына салынган яшел печәннән башын күтәрде дә әкрен генә кешнәп җибәрде. Йөгереп барып башыннан кочаклап алганымны сизми дә калдым. Ә аткаемның зур күзләрендә нишләптер яшь бөртекләре күренә иде кебек.

## Кырагай

— Бармыйм, бармыйм мин, әни, медицинскийга... — Зәбидә, сүзләренә бөтен ышандыру көчен салырга теләгәндәй, ярым пышылдап тагын кабатлады. — Бармыйм!.. Класстан Мөнирә дә, Әминә дә чит телләр институтына бара. Алар белән сөйләштек, сүз куештык бит инде... Аларны алдыйммыни хәзер?

— Кызым, үзенә ни кирәген һаман да аңламыйсың син!

Киләчәгеңне уйлыйсыңмы? Нигә үзеңне алар белән тиңлисең? Берәр бәхәс чыкса, һәрвакыт шулай аның әнисе. Тота да шушы сүзләре белән Зәбидәнең авызын каплый да куя:

— Нигә син үзеңне алар белән тиңлисең?..

Үзен-үзе белә башлаганнан бирле шушы сүзләр эзәрлекләп килә аны. Башкалар шикелле уйларга, сөенергә, хыялланырга да хакы юкмыни соң аның? Һич югында әнисе исенә төшермәсен иде.

Зәбидә, менә-менә атылып чыгарга җыенган күз яшьләрен тыеп, иренен

тешләде. Күңеленең ташырга җыенганын сиздерәсе килми иде. Әмма һич баш иярга теләмәгән үҗәтлеге тагын калкып чыкты:

— Бармыйм, әни. Бармыйм дигәч, бармыйм!

— И бала!

Әнисе башка сүз әйтмәде. Хәер, аның да йөрәге үз урынында түгел иде бугай. Өстәл җыеп йөргән җиреннән кулларын алъяпкыч итәгенә сөртеп алды да, йомшак кулына бөтен күңел җылысын салырга теләгәндәй, иплэп кенә Зәбидәнең башыннан, чәчләреннән сыйпады.

— Шулай да тагын бер тапкыр уйлап кара әле, кызым...

Бүтән берничек тә әнисен җиңә, ышандыра алмаячагын белгәнгә күрә Зәбидә сүз көрәштереп тормады. Иелә төшеп, башын аның кулы астыннан тартып алды да йокы бүлмәсенә кереп китте. Керде дә мендәренә капланды. Баядан бирле тыелып килгән яшьләре ике ягы буйлап мендәргә тамды. «Аһ, нигә мин шундый булганмын соң?»—дип кычкырасы килсә дә, Зәбидә иренен тешләп тыелып калды. Кычкырудан, елаудан ни файда! Ничәме еллар шулай түзеп, үз-үзен кызганып та, кимсенеп тә яши бит инде ул. Онытылып китеп, башкалар шикелле көләргә, яшьлек дәрте белән сикергәләргә тотынса, йә әнисенең, йә иптәшләренең каш астыннан сынаулы карашларын тоеп ала да, каты кабырчыкка кереп югалган әкәмтөкәмдәй, тагын үз кабыгына бикләнә. Шомырт кара күзләре уйчанланып кала, йөзенә үз яшенә хас булмаган кырыслык, җитдилек чыга. Өйдә булса рәхәт әле, бүлмәңә керәсең дә бикләнәсең. Иң кыены мәктәптә. Гадәттә, иң арткы партада утыра ул. Башкалар кызып-кызып өйдә нишләгәннәрен, кайда булганнарын, кемне күргәннәрен, нинди егет белән сөйләшкәннәрен, күлмәк фасоннарын тикшергәндә, ишетмәскә теләгәндәй, йә китабына каплана, йә дәфтәрен алып ни дә булса яза башлый. Күңеле исә һаман иптәшләре янында була. Аның да шул ук күлмәкләр турында, кичәләрдә ниңәрсә булганы хакында сөйләшәсе килмимени! Килә, бик килә. Әмма тагын каһәр суккан шул сүзләр искә төшә: «Нигә син үзеңне аларга тиңлисең?»

Юк! Мәктәптә дә, класста да беркемнең ана шулай дип күтәрелеп әйткәне юк. Ул сүзләр күз карашларында!.. Алар барысын да сөйли, күрсәтә, аңлата. Укытучыларның да мөнәсәбәте башкачарак түгелмени?!. Дөрес, башкалардан аны бер ягы белән дә аерып куймыйлар кебек. Киресенчә, әле һәр эшен мактаган булалар:

— Менә Зәбидәдән үрнәк алыгыз. Язмасында ник бер хата булсын. Үзе чиста, үзе дөрес, — диләр. Әмма шуларда да үзенең аерымлыгын тоя Зәбидә. «Әгәр мин дә башкалар шикелле булсам, өчлегә дә, хәтта икелегә дә ризалашыр идем», — дип уйлап куя ул эчтән генә. Ә болай, гел бишкә генә укуның да ни кызыгы бар?! Шулай гадәтләнелгән инде. Нәрсәгә булса да тотынса, аны бөтен ягыннан да тиешенчә эшләмичә, ахырына җиткермичә туктый алмый ул. Кечкенәдән кергән бу гадәт әнә шулай унынчы класска кадәр дәвам итте. Шулай булмый, ничек булсын инде тагы. Башкалар күңел ачканда, шаярганда, уйнаганда ул дәрес карады. Классташлары концертка әзерләнде, спорт ярышларында катнашты, көч сынашты—ул дәрес карады. Беренче класстан бирле бер генә дүртле дә алмавын үзе шуннан күрде. Башкалардан аерымлыгын да, класстагы кайберәүләр әйткәнчә, үзенең «башлы»лыгын да тоймады, һәр бишленең, һәр ирешелгән уңышның нинди хезмәт, тырышлык белән килгәнен яхшы аңлый шул ул. Шуңадырмы, үзенең холкы-фигыле, фикер сөреше белән классташларыннан, яшьтәшләреннән күпкә өстен иде. Хәер, өстенлек тә түгелдер әле ул, бәлки. Бары тик Зәбидәнең башкалардан күбрәк кичерүе, шуның нәтиҗәсендә алардан акыл ягыннан өлгергәнрәк булуы гына иде бугай. Унҗиде яшьлек кешедә егерме биш-утыз яшьлек акыл була ала микән? Әгәр була алса, Зәбидә әнә шундыйдыр да инде.

Яшьлектә аңлатып бетерә алмаслык ниндидер юләрлек була, диләр. Ул кайчагында акланмаган усаллыкта да, тормыштагы теге яки бу вакыйгага кирәгеннән артык олы яки кечкенә бәя бирүдә дә чагыла. Үзенең әле генә кемгәдер рәнҗетерлек сүз әйткәнен, үпкәләтерлек караш ташлаганын да күпләр аңлап бетерми.

Зәбидәгә дә шулай тоела. Иптәш кызлары шау-гөр килеп көлешеп йөргәндә, аның кинәт төркемнән аерылып, партасына барып утыруын күрәләр дә «Кырагай» дип куялар. Кырагай, ягъни кыргый, башкаларга ияләнмәгән мал ул. Аның мәгънәсен шулай аңлый Зәбидә. Баштарак, әле бу сүзгә ияләнеп җитмәгәндә бик рәнҗи, эченнән үпкәли торган иде. Тора-бара күнекте, үзенең кырагайлыгын да шулай булырга тиешле бер нәрсә итеп саный башлады. Башкалардан ким икәнсең, димәк, син башкалар шикелле түгел.

Башкалар шикелле түгел!.. Кайчан башланды соң бу?

Анысын Зәбидә төгәл генә белми. Кечкенә чагында ак халатлы апаларның озаклап аркасын капшаганнарын, аны бер врачтан икенчесенә йөрткәннәрен генә хәтерли. Әнисе елый, әтисе дәшми. Зәбидә аларга карап тора да, елыйсы килүгә карамастан, елмаерга тырыша иде. «Нигә елыйсың, әни? Минем бит бер җирем дә авыртмый. Врач абый да авырттырмый. Елама, әни», — диярга тели иде ул. Ә әнисенең битен кульяулык белән каплавы, әтисенең исә күзләрен челт-челт йома башлавы аның да елыйсын китерә. Зәбидәгә гел елмаеп караган врач абый аларны ачулана:

— Нәрсә, сез монда балавыз сыгарга килдегезме, әллә кинәшкәме?! — ди ул. Аннары тагын ниндидер кәгазьләр язып бирә, Зәбидәнең башыннан сыйпый. — Бәлки әле, төзәтеп тә булыр. Иң мөһиме түземлелек, режим. Кичекмәстән санаторийга салырга кирәк. Дәвалау гимнастикасы да эшләрләр, гипска да салып карарлар... Анда күптөрле ысуллары бар аларның... Ярдәм итәрдер кебек.

Менә инде ничә еллар шушылай кырагай булып яшәвенә сәбәп булган «скалиоз» дигән сүзне беренче тапкыр шунда ишеткән иде Зәбидә. Әле мәктәп яшенә дә җитмәгән килеш ничәмә-ничә санаторийда, больницада дәваланырга туры килде аңа. Әмма барысы да юкка—әлегә медицина мондый авыруларны дәваларлык дәрәҗәгә ирешмәгәнме, әллә аның авыруы дәвалауга бирешми торган булып чыктымы, еллар үткән саен бу чир дә үзенекен итте: Зәбидәнең аркасы бер яктан һаман калыная барды. Махсус корсет киеп йөрү дә, массаж да, электр белән җылытып дәвалаулар да ярдәм итмәде. Табиблар катгыйлыгын киметмәде. «Әгәр чиреңнең һаман да артуын теләмәсәң, корсетны һәрвакыт киеп йөрергә кирәклеген исеңнән чыгарырга тиеш түгелсең», — диделәр алар.

Әнисенең медицина институтына керергә димләве дә әнә шуннан иде. Гәүдәне туры тотып тору өчен күн белән металлдан эшләнгән авыр корсет киеп йөрү никадәр мәшәкатьле булса да, Зәбидә түзде, аны классташларына да, иң якын дуслары булган Мөнирә белән Әминәгә дә сиздермәскә тырышты.

Калын кара чәчләрен аркасына таратып сала, берничә үлчәмгә зуррак эре бәйләмле йон кофтасын киеп куя да көзге каршына килеп баса. Әле болай, әле тегеләй борылып карый. Иңennән асылынып төшкән кофтасы, җилкәләренә таралган чәчләре аның аркасын каплый, гомере буе газапланган гариплеге кеше күзенә бик ташланмый башлый. Классташлары аның салмак хәрәкәтле булуын, уртак уен-көлкеләрдә, тәнәфестә әледән-әле кабынып китә торган әүмәкләшүләрдә катнашмавын шул кырагайлыктан күрәләр иде булса кирәк. Эчтән авыр корсет кигәнен беркем дә башына да китереп карамый. Зәбидәнең чирен белми түгел, беләләр алар. Уку елына бер-ике мәртәбә Казанга барып кайтуын да, җәйләрен санаторийда

үткәрүен дә белеп торалар. Әмма чиренең бу кадәрле үк икәнен алар анламый, әлбәттә.

Дөресен генә әйткәндә, Зәбидә әле һаман өмет белән яши. Кайчандыр аркасы төзәлер, гариплеге бетәр, гәүдәсе дә тал чыбыгыдай төз һәм зифа булыр. Бәлки, белмибез генәдер, кайдадыр аны дәвалый алырлык санаторийлар да, врачлар да бардыр. Менә көннәрнен берендә чакырып алырлар да операция тәкъдим итәрләр. «Күп интектең инде, хәзер менә корсетыңны салыр вакыт житте», — диярләр кебек иде аңа.

— И чибәр дә инде син, Зәбидә, — диде аңа көннәрнен берендә дус кызы Әминә. — Буең гына кечкенә. Кара әле, синең башны мина алып куйсак, ничек шәп булыр иде, ә? Ул калын чәч, шомырттай кара күз, озын керфек, уймак хәтле генә авыз... — Үзе, шаркылдап көлә-көлә, Зәбидәне кочаклап алды. — Мин генә йөрим менә колга чаклы буй үстереп. Ичмасам, күзләрем генә дә кешенеке төсле түгел бит. Йа Хода, кемдә яшел күз була инде? Битемә бетчә чыгып интектерә. Синең кершән ягасың да, пудра сөртәсең дә юк...

Зәбидә бер сүз дә эндәшмәде. Үзе эчтән генә: «Их, булса иде миндә синең буең, синең төзлегең», — дип уйлап куйды. Юк шул. Табигать ничек яраткан, шулай булып каласың инде ул. Бик авыр минутларда әнисенең дә әйткәне бар:

— И кызым, кызым! Шул чиреннән яртысын гына булса да үземә ала алсам иде. Икебезгә бүлгәндә ул кадәр сизелмәс иде әле...

Аның шул сүзләрен исенә төшергәч, ничектер җиңел булып калды Зәбидәгә. Әллә күз яшьләре белән бергә авыр уйлары да юылып төште, әллә әнисенең әйткәннәрен искә төшерү күңелендәге ташны эретте—бердән уйлары яктырып киткәндәй булды.

— Чынлап та, нигә мин шул чит телләр институтына ябышып ятам соң әле? Әти-әниләр, бәлки, дөресен әйтә торгандыр. Бик теләсәң, чит телне болай да, үзлегеңнән дә өйрәнеп була бит аны. Ә медицина... Үзем укысам, бу чирнең сәбәпләрен өйрәнсәм, башка ил галимнәренең хезмәтләре белән танышсам... кем белә, аны дәвалау серләрен ачып булмас микәнни?!.

Аттестат алып кайткан көн Зәбидә өчен шатлыктан бигрәк әнә шундый газаплы уйлар, кичерешләр көненә әйләнде. Моңа кадәр тыныч кына, бер көйгә генә агып барган тормышы ике тау арасындагы тарлавыкка килеп кергән елгага охшап калды, уйлары да ашкынулы агымга әверелде, күз алдыннан әллә никадәр вакыйга, истәлекләр, кайчандыр уйланып та, билгеле бер карарга килә алмыйча калган кичерешләр янарып узды.

Мәктәпне алтын медаль белән тәмамлаган кызга институтның кайсысын сайласа да була иде, әлбәттә. Аның классташлары да, укытучылар да, әти-әниләре дә Зәбидәнең теләсә нинди имтиханны тапшыра алачагын беләләр. Бу беркемдә дә шик тудырмый. Тик менә кайсы хезмәтне сайларга, кайсысы күңелгә якынрак булыр... Бу турыда беркемнең дә башына килми, күрәсең. Юкса, берәүләр әнә юрфакка, икенчеләре медицина институтына, өченчеләре тагын ниндидер башка вузга бар, дип киңәш бирмәсләр иде. Ә Зәбидә үзе чит телләр институтын якын күрде. Хәзер менә ул хыялдан да ваз кичәргә туры килә. Әмма киләчәк хакына, шул хыялның тормышка ашуын якынайту хакына баш тарту булачак бу. Зәбидә шуларны уйлады. Язмышыңны гына түгел, үзеңне дә үзең формалаштырырга тиешсең... Бәлки, яшерен хыяллар да кайчандыр тормышка ашар.

***

Авыр булмады аңа институтка керү. Химиядән беренче имтиханны бишкә тапшыруга ук, аларны, мәктәпне алтын медальгә тәмамлаучыларны, җыеп алдылар. Факультет деканы һәрберсенең кулын кысып, данлы медицина институтына кабул ителүләре белән котлады, бәхет, уңышлар теләде.

Галимнән бигрәк, ит чабучыга охшаган декан ниндидер сәер тәэсир калдырды Зәбидәдә. Машинка белән кырдырып алынган чәчле, калын иренле, зур җәлпәк борынлы бу кеше, беренче карашка, чыннан да, тупас булып тоела иде. Тик аның шешенке күз кабаклары арасыннан үз итеп каравы, ачык елмаюы бу тәэсирне бик тиз оныттыра. Зәбидәнең уйлары шушы урында бүленде. Бераз тынып торганнан соң декан, бүлмәдә утыручыларны тагын бер кат барлап чыккандай, күзен йөгертеп алды да һәр сүзен өзеп-өзеп дәвам итте:

— Башта ук әйтеп куйыйм, уку авыр булачак. Бер имтихан тапшырдым да җиңел генә кердем дип, үзегездә әллә нинди иллюзияләр тудырмагыз. Мәктәптә уку авыр булган икән, бездә уку бер ярым тапкырга, бәлки, ике тапкырга авыррак булыр. Бүгеннән үк борыныгызга киртләп куегыз: кеше язмышы, кеше тормышы өчен көрәштә җиңел нәрсә юк. Белем кирәк, тәҗрибә кирәк! Һәр кешенең язмышын үзеңнеке кебек кабул итә белү кирәк. Әле сезгә «кирәк» дигән сүзләрне күп ишетергә туры килер. Бүген шуның беренчесен әйтәбез, — диде ул мәзәк кенә итеп үзенең борын очын уа-уа, гүяки әйткән фикерләрен шунда киртләп куярга теләгәндәй.

Менә шулай яңа шәһәрдә, яңа кешеләр арасында, яңа шартларда яши башлады Зәбидә. «Кеше язмышы өчен көрәштә җиңел нәрсә юк». Деканның бу сүзләре дә хәтерендә уелып калды. Әйе, шушы максат белән кергәнсең икән, тырышырга, өйрәнергә, укырга кирәк. Зәбидәнең беркем алдында да ачарга җөрьәт итмәгән, әнисе дә үзе генә белгән яшерен теләге дә бар бит әле. Ул—үзе интеккән чирнең асылын өйрәнү, шуны дәвалау серләренә төшенү.

Аһ, кемнәргә генә ярдәм итмәс иде дә ул, кемнәрне генә үзе шикелле яшерен газаплардан коткармас иде.

Беренче көннәрдән шундый гадәт алды Зәбидә. Иртәнге якта институт, лекцияләр, семинарлар, практик дәресләр. Ә төштән соң китапханә, уку заллары.

Бәхетенә дигәндәй, әтисенең бертуган абыйсы үзәк китапханәдән ерак яшәми икән. Алар: «Беренче курста булса да бездә торып торсын. Кызыбыз Дилбәргә дә иптәш булыр», — дип, Зәбидәне торырга үзләренә алганнар иде...

Баштарак бик ачык күренгән җиңгәсе, нишләптер, соңгы вакытта кырын-кырын карап куя башлады аңа. Телефоннан сөйләшкәндә дә ниндидер таныш-белешләренә: «Аһ, кешедән туйдым. Ял кирәк, ахрысы», — дигәне еш ишетелә башлады. Бәлки, дөрес тә аңламый торгандыр, әмма Зәбидә аны һаман үзенә төрттерү дип кабул итә. Ничек кенә булмасын, кайтып бераз ял итеп ала да, сумкасын асып, тизрәк китапханәгә чыгып китү ягын карый. Анда рәхәт, ичмасам. Кырын караучы да, аның артык кеше икәнен сиздереп торучы да юк. Әле сессияләргә ерак. Заллар ярым буш. Борынгы бер асыл затның особнягы булган бу мәһабәт бина талгын тынлыгы, зиннәтле бүлмәләренең тантаналы хозурлыгы белән дә уйлануга, фикер туплауга тарта, кешене җыйнаклыкка, тупланганлыкка чакыра. Аеруча бер залны яратты Зәбидә. Тау куышы кебек итеп эшләнгән бүлмәнең диварларыннан үрмә гөлләр салынып төшкән. Бер яктагы зур аквариумда тылсымлы тынлыкка ямь өстәп алтын балыклар йөзә. Шәһәр урамнарының ыгы-зыгысы да, институт коридорларының шау-шуы да юк биредә. Зәбидә иң ерак почмактагы өстәл янына кереп утыра да китап дөньясына чума. Укыйсы әйберләр күп. Анатомиясе дә, латин теле дә — таныш түгел, өр-яңадан үзләштерәсе, киләчәк белемнәрнең нигезен тәшкил итәсе фәннәр.

Шулай утыргач, беразга залга күз төшерә, төрле кешеләрне, аларның йөзен, укыгандагы кыяфәтләрен күзәтеп утырырга ярата ул. Берәүләр шулкадәр китапка биреләләр ки, хәтта тирә-якта ни булганын аңышмас

дәрәҗәгә житәләр. Бармаклары белән чәчләрен аралыйлар, ручка башын кимерәләр. Икенчеләр исә бер-ике бит карап чыкканнан соң күзләрен каядыр текәп уйлана-уйлана, назланып кына укыйлар. Киемнәре дә төрле. Шуларга карап кемнен кем икәнен билгеләргә тели. Олы яшьтәге, салмак, дәрәҗәле абзыйлар, билгеле инде, фән кешеләре. Яшь-җилкенчәк, күбесенчә, студент, ахрысы. Алган китаплары, анарның әле берсен, әле икенчесен актаргалаулары да, нидер эзләп казынулары да шул турыда сөйли.

Дәфтәренә китаптан авыр аңлаешлы урыннарны күчереп язып утыра иде. Бераз ял итү, арыган буыннарны язып алу теләге белән каләмен куеп, күзен күтәрүгә ишектән керүче ике егеткә игътибар итте. Аларның берсе базыграк гәүдәле, чем-кара чәчле таза егет. Икенчесе исә нечкә, озын буйлы, дулкынланып торган сары чәчле. Икесе дә бер үк төрле киемнән— студентлар униформасына әйләнгән зәңгәр джинсы һәм калын свитердан. Беренче егеткә күз сирпеп кенә алган Зәбидә карашының ирексездән икенче егеттә тукталып калуын сизде. Нәрсәсе беләндер ул башкалардан аерыла иде. Тик нәрсәсе белән? Шул ук кием, шул ук буй, төс-бит. Тукта, тукта! Нәкъ шул төс-бите үзгә түгелме соң? Чыннан да, залга таба борылган егетнең кыяфәтен тагы бер кат күздән кичерүгә шул аерымлыкны чамалап та алды. Сары чәчле егетнең кашы белән мыегы сумала төсле кара икән. Чиста ак йөзе фонында алар аңлашылмый торган, әмма сөйкемле контраст тудыралар. Күзләрендә дә ниндидер җете зәңгәр нур чагыла сыман.

— Мондый кешеләр дә була микәнни? — Гаҗәп, бу төсләр әлеге егеттә диссонанс тудырмый, киресенчә, аның кыяфәтенең камиллеген күрсәтә, тагын да бизи иде.

Шушыларны уйлап алырга өлгергән Зәбидә, әллә нинди эчке бер канәгатьләнү кичереп, янадан китабына үрелде. Укыган һәр нәрсәнең башына тиз һәм ныклап кереп утыруына гаҗәпләнә-гаҗәпләнә шигырь юллары кебек яңгырый башлаган латин терминнарын өйрәнергә кереште.

Башка көннәрдә ике-өч сәгать ятлап азаплана торган күләмне шулай тиз ерып чыга алуына сөенеп, кайтырга җыенды. Залга күз төшереп алды. Баягы егетләр анда юк иде инде.

Икенче көнне китапханәгә гадәттәгедән иртәрәк килде Зәбидә. Кирәкле томнарны сорап алды, үзе ияләшеп өлгергән почмакның буш булуына сөенә-сөенә килеп утырды. Тик бүген нәрсәдер житми, авыр терминнар да алай шома гына башка керми иде. Зәбидә, арыганмындыр ахры, дип китапларын читкәрәк этәрде, бераз ял итү максаты белән залны күзәтергә кереште. Берәм-берәм барлык өстәлләр буйлап күз йөртеп чыкты, игътибарны җәлеп итәрдәй нәрсә тапмады һәм кинәт сөенү катыш гаҗәпләнү белән үзенең кичәге сары чәчле егетне эзләвен абайлап алды. Арыганы онытылды, сәер бер җиңеллек кичерүен сизде. Алда ниндидер бәйрәм булыр, күңеллелек килер сыман иде.

Озак көтәргә туры килмәде. Бераздан, чыннан да, залда янадан теге егетләр күренде.

Ишектән керүгә кара чәчлесе иптәшенә дәште:

— Рәшит, мин китаплар алам. Син урын карый тор!

Шулай дип әйтте бугай ул. Ерак арадан аларның һәр сүзен ишетүенә гаҗәпләнде Зәбидә.

Рәшит!.. Кара нинди матур исем икән бит! Мәктәптә дә бар иде Рәшит исемле малайлар. Ул чагында бу сүзнең ничек матур яңгыравы башка да кереп карамаган. Чыннан да, ни дигән сүз икән ул Рәшит? Рәшит, Рәшидә, рәшә, рәшәткә... Юк, кеше исеме рәшәткәдән булмый инде ул.

Егетләр Зәбидәдән ерак түгел генә өстәл янына утырдылар. Рәшит киң ак маңгаена төшеп торган чәчләрен сыпырып алды, калын дәфтәрен өстәлгә салып яза башлады. Башын күтәреп, залга күз йөгертеп алганда, аның үзенә

карап-карап алуын тойды Зәбидә. Моны ул күзе белән күрмәде, әллә нинди жиденче тойгысы белән сизде кебек. Эчендә нидер куырылып килгәндәй булды, анын күз карашы белән очрашудан куркып, башын да күтәрмичә китабына ябышты. Башта колаклары, аннары бите дә кызара башлады. «Шулай да нәрсәне анлата икән бу Рәшит дигән сүз?»

Әллә анын берәр магик көче бармы? Шул исемне әйтүгә ана ниндидер әйтеп бетерә алмаслык жинеллек килгән, дөньясы кинәеп киткән кебек тоела башлый. Әбисе укыган бер борынгы китаптан Рәшит хәлиф турындагы риваять кылт итеп хәтеренә килде. Рәшит—туры юлдан баручы, зирәк кеше дигән сүз түгелме сон? Шулайдыр... һәм менә шушындый егет булгандыр да әле ул.

Үзе каршында утыручы, джинсы һәм кызгылт фонга ак кар бөртекләре шикелле эре сурәт төшерелгән свитер кигән егетне әкият шаһзадәсе итеп күз алдына китереп, Зәбидә көлеп жибәрүдән чак кына тыелып калды. Аннан үз-үзен битәрләп, житдиләнергә тырышып, китабына текәлде.

Әнә шуннан башланды да бугай инде. Китапханәдә Рәшитне күрмәгән көннәрдә ул үзенә нидер житмәгәнне тоя, ишек ачылган саен өмет белән ялт итеп башын күтәрә. Болытлы көндә кояшны зарыгып көткәндәгедәй түземлек, сабырлык белән көтә ул. Менә-менә ишек ачылыр да ул килеп керер, барысы да үз урынына утырыр. Укыганнар да жинелрәк анлашыла башлар, залда да яктылык артып китәр сыман.

Күрше өсталләрнен берсендә утыручы шушы тыйнак егетне күрү көндәлек ихтыяжга әйләнде. Нишләптер, хәзер күбрәк ялгызы гына килә Рәшит. Ул да Зәбидә утырган почмактан ерак түгел бер өстәлне үз итте булса кирәк, һаман саен шунда утырырга тырыша.

Шуларны уйлап өлгермәде, ишектән Рәшит күренде. Анын килүен эчке бер өмет белән көтеп утырган Зәбидә, бөтен барлыгы белән елмаюын сизми дә калды, һәм нәкъ шул мизгелдә аларнын күзләре очрашты. Егетнен дә йөзе яктырып китте, кара мыек астыннан тигез ак тешләре күренде, күзләрендә шатлыклы очкыннар балкыган кебек булды. Моны ук көтмәгән иде Зәбидә. Күзен яшен тизлеге белән китабына күчерде, йөрәгенен атылып чыгардай булып тибә башлавын тойды. Иреннәре ирексездән үз гомерендә монарчы беркемгә дә мондый хиссият белән әйтелмәгән, тәүге тапкыр яна мәгънә, яна дөнья ачкан сүзләрне пышылдады: «Йа Хода, яратам түгелме сон мин аны?!»

Шуннан сон башын күтәрергә кыймады Зәбидә. Түземсезлек белән Рәшитнен тизрәк китүен көтә башлады. Үзе генә калып, айкала башлаган хисләрен анларга, ни өчен кеше кулына эләккән нәни кошчык шикелле шулай калтырана башлавынын сәбәбен төшенергә тели иде ул.

Бүтән көннәрдә бер-ике сәгать утырганнан сон кузгала торган егет бүген, нишләптер, китәргә жыенмый да иде бугай. Зәбидә ана берничә тапкыр күз сирпеп алырга батырчылык итте. Әмма тегесе гүяки китап дөньясына чумган иде...

Дәфтәрләрен ябып, инде чыгып китим дип омтылган Зәбидә, кинәт аякларында хәлсезлек тоеп, янадан урынына утырды.

— Чыгып барганда аркамны күреп калса?!

Бу уйдан анын тәне эсселе-суыклы булып китте. Көне буе илаһи бер яктылык белән балкыган күнелен шомлы кара болытлар каплап алды.

Нишләргә? Нишләргә? Нишләргә...

Ничарадан бичара булып утырудан башка чара калмады.

Бәхете бар икән әле. Шулай хәлсезлек белән көрәшеп күпме утыргандыр, хәтерләми. Ул арада Рәшит нәрсәдер эзләп китабын актарырга керешге. Күрәсен, үзенә кирәкле мөһим нәрсәне тапмады, торып абонемент ягына чыгып китте. Шуны гына көтеп утырган Зәбидә бәрелә-сугыла ишеккә ташланды. Тиз генә пальтосын алды да, үзен кемдер эзәрлекләп килгәндәй,

урамга ашыкты. Озак йөрде ул көнне Зәбидә. Институтка кереп утырырга да, өйгә кайтып китәргә дә була иде. Әмма ул үзен кая куярга белмичә якын-тирә бакчаларны урап үтте, аннан соң Бауман урамына төште. Йә кешеләр арасында югаласы, йә тыныч кына ялгыз каласы килә иде. Күз алдында үзен Рәшит белән чагыштырып карады: зифа буйлы чибәр бу егеткә тиңме соң ул?

Кинәт, аяз көнне яшен ялтырагандай, фикер ачыклыгы китереп, күңелен тынычландырган уй килде. «Кем сиңа аны тиң дигән соң әле? Авыз ерып каршы алгач, нигә елмаймасын, ди ул. Әллә сөйләшеп карадыңмы? И җүләр, и җүләр», — дип битәрләде ул үзен.

Тынычланып калгандай булды. Шайтаннан җәяүләп качкандай чыгып чабуы үзенә дә көлке булып тоелды. Шулай да бу юануга, Рәшит күзендә балкыган чаткының гади балку гына булмаганлыгына күңел түрендәге хисләр ышанырга теләми иде.

Шул көннән китапханәгә йөрүен туктатты Зәбидә.

Берничә атна үтте. Дәрестән соң уйланып, бераз һава сулыйм әле дип кенә шәһәрдә йөрмәкче булган иде. Үзенең шул әкияти йорт янына килеп чыгуын сизми дә калды... Һәм тәвәккәлләде. Аяклары мәгарә залына тартса да, башка уку залына кереп утырды. Күңегелмәгән залда Рәшит турында да уйланылмас, аны очратып та булмас! Хәер, очратмас өчен керде дә бит инде ул бу залга.

Әллә нинди көн булды ул. Күңеленең тынычлана башлавына сөенә-сөенә китапларын, дәфтәрләрен чыгарды. Гадәттәгечә, иркенләп дәрес карап алырга иде исәбе.

Идәннән түшәмгә кадәр күтәрелгән саллы имән ишек шыгырдап ачылганга башын күтәргән иде, аннан кемнедер эзләгәндәй башын сузган Рәшитне күреп өнсез калды. Ул да күрде аны. Ишек шар ачылды, очарга җыенгандай җиңел хәрәкәт белән, Рәшит аңа таба килә иде.

Шул вакытта әллә нәрсә булды. Үткән көннәрдәге барлык газаплы уйлар, үзенең чиреннән гаҗиз калган минутлардагы кичерешләре янарды Зәбидәнең йөзендә. Моны ул үзе дә сизмәде. Әмма читтән караган кеше аны газап та, ачу да, нәфрәт тә дип аңлый алыр иде.

Рәшит белән дә шулай булды, күрәсең. Әйтерсең лә очып барган кошның канатларын кистеләр: ул бердән адымнарын әкренәйтте, йөзендәге елмаю сүнде, беренче очраган өстәл янына утырды. Әмма укырга дип килмәгән иде ул. Азмы-күпме анда утырганнан соң, акрын гына атлап, залдан чыгып китте. Адымнарында баягы җиңеллек тә, сыгылмалы талпыну да юк иде инде.

Зәбидә, кичерешләрен кешеләргә сиздерергә теләми иде. Кинәт кенә ул бөтен буыннарын биләп сулкылдый башлаган чиксез арыганлык тойды, түзә алмыйча башын китабына салды. Рәшит белән күз карашлары беренче тапкыр очрашкандагы татлы да, газаплы да уйлары күңелен теткәли башлады.

— Юк, юк! Мин аны бүтән күрергә тиеш түгел!..

***

Институтта көннәр бер көйгә акты да акты. Декан, аның фамилиясе Әхмәтов булып чыкты, беренче очрашу вакытында дөрес әйткән икән— институтта уку авыр, бик авыр һәм катлаулы иде. Укытучылар таләпчән, һәр дәреснең конспекты, лекциясе язылуын мәктәптәгедән дә болай тикшереп торалар. Зәбидә тырышмады түгел, тырышты, әлбәттә. Әмма мәктәптә гел бишлеге генә укырга күнеккән кыз бередә һаман да бер эзгә төшеп китә алмый йөдәде. Аудиториядән чыгып киләләр иде. Деканат секретаре Нурия Мәхмүтовна Зәбидәне туктатты.

— Хафизова, сезне декан чакырган иде, — диде.

— Нигә икән, Нурия апа?

Студентларга бер җылы сүз әйтсәм авторитетым төшәр дип курыккандай кыланучы бу ханым рәтле җавап бирә алмады.

Рәшитне очратып күңеле урыныннан кузгалган, аны күрмәс өчен үзен тыеп, газаплы уй, гаҗизлек эчендә яшәгән Зәбидә соңгы вакытта, чыннан да, укуында бераз артка кала башлаган иде. Сөйләшү бик күңелле булмастыр, ахры, дип уйлап куйды ул. Ләкин керми чараң юк. Әхмәтов ике чакырганны яратмый.

— Әйдә, утыр, Зәбидә, — дип елмаеп каршы алды аны Сөләйман Гарифович. — Йә, күнегеп буламы инде? Уку бик авыр түгелме?

— Була-а, — дип җавап кайтарды, аңа ни әйтергә белмәгән кыз.

Әхмәтов өстәлдән яшел тышлы калын бер журналны алды да Зәбидәнең янына ук килеп утырды. Тавышы әле һаман да рәсми түгел иде. Тагын ни әйтер икән, дип күңелсезләнеп көткән кызга аның шушылай җылы сөйләшүе бигрәк тә үзәк өзгеч булып тоелды.

— Сеңелем, менә бу журналда бик кызыклы бер мәкалә басылган. Ортопедия институты профессоры Дәүләтьяровның өметле эшләре турында элек тә белә идек белүен. Ә бусы медицинада ачыш буларак та, аерым алганда, синең өчен дә бик кызыклыдыр, дип уйлыйм. Танышып чык әле.

Аптырап калды Зәбидә. Сорау катыш гаҗәпләнү белән Әхмәтовка карап утыруын белде. Ә тегесе аның җавапсыз утыруын ризалык билгесе дип аңлады бугай, үз фикерен тагын бер кат расларга теләгәндәй дәвам итте:

— Әйе, укуың яхшы гына бара. Анысы өчен борчылма. Берничә айга артка калсаң да, ярдәм итәрбез. Уйлап кара! Бәлки, тәвәккәлләрсең...

Декан яныннан шул журнал белән чыкты Зәбидә. Чыкты да тиз-тиз актарырга кереште. Сүзнең үзе инде ничә еллар өмет белән көткән эш турында баруын хәзер генә төшенеп алды ул. Бер кат күз йөгертеп чыгу белән генә канәгатьләнмәде, мәкаләнең һәр сүзен үлчәп, уйлап, миенә сеңдереп калдырырга теләп, бөртекләп укый башлады. Танылган галим Илизаровның шәкерте, Казан профессоры Дәүләтьяров скалиоз авыруларын дәвалауның принципиаль яңа ысулларын тәкъдим итә иде. Инде дәваланган дистәләп кешенең савыгу процессының ничек баруы турында да бәйнә-бәйнә язылган иде мәкаләдә. Зәбидәнең алдында күк капусы ачылгандай булды. Ниһаять! Мин дә кешеләрнең күзенә туры карый алырмын микәнни? Мин дә башкалар шикелле була алырмын микәнни? Аның күз алдыннан төз гәүдәле чибәр курсташ кызлары тезелеп узгандай булды. Алар арасында үзен дә күз алдына китерде. Бу сурәт тә эреп юкка чыкты. Аның урынына китапханәдә соңгы тапкыр күргәндә хәтердә уелып калган, канаты сынган кош кебек китеп баручы, аптыраулы карашын аңа текәгән Рәшит пәйда булды.

Йа Илаһым, чыннан да бу дөрес хәбәр микәнни? Зәбидәнең бала чагындагы шикелле йөгереп китәсе, очраган бер кешене кочасы, шатлыгын уртаклашасы килде. Сөенеч яшьләре ага башлаганын үзе дә сизми иде ул. Профессор Әхмәтов янына яңадан керәсе, аңа кат-кат рәхмәт укыйсы иде бит. Ләкин еллар буе күнегеп киленгән басынкылык, күңелендәгеН тышка чыгармаска тырышу аның холкына сеңгән иде инде. Эченнән бәхет кошы тоткандай куанса, очынса да кыяфәтендә артык чагылмады алар. Чыннан да, бәхет кошы иде аның өчен бу яңалык.

***

Ортопедия институтының клиник больницасы...

Зәбидәнең урыны тәрәзә янына туры килде. Монда яктырак та, уңайлырак та. Палатада тагын өч кыз бар. Барысы да Зәбидә шикелле

терелүгә өмет баглап, яшерен ышаныч белән килгәннәр. Болай караганда, бернигә дә зарланмыйлар алар. Үзара тыныч кына сөйләшәләр, укыйлар, чәй эчәләр, тиешле вакытта анализга, төрле тикшерүләргә барып киләләр. Ә инде бүлмәгә профессор Дәүләтьяров килеп керсә, һәрберсе әйтеп бетергесез бер тугрылык, инану белән ана карый. Әйтерсең лә аларның бөтен язмышы, тормышы, бүгенгесе һәм киләчәге, яшьлек гүзәллеге, өмет-идеаллары—барысы да аның кулында. Хәер, шулайдыр да, һич югында Зәбидә өчен нәкъ шулай. Ул аның коткаручысы, ак халатлы фәрештәсе. Балачактан килгән барлык газаплар шушында бетәр, үзенне башкалардан ким итеп тоюдан килгән ачы күз яшьләренең соңгысы шушында тамып калыр сыман.

Йоклый алмый хәзер Зәбидә. Түземсезлек белән берничә көнгә сузылган тикшеренүнен, анализларның нәтиҗәләрен көтә. Операция ясауның мөмкинлеге шуларга бәйле. Ничек чыдап ятмак кирәк! Күзен йома да хыял дингезенә чума. Больницадан чыккан көнне үк үзәк китапханәгә баруын, иркен адымнар белән рәтләр арасыннан очынып үтүен, матур бер рәсем шикелле, күз алдына кат-кат китерә, ләззәтләнеп, сокланып уйлый боларны. Менә ул мәгарәгә килеп керә. Ә анда... Рәшит! Зәбидә аның янынннан үтешли туктап калачак та, «Гафу итегез, сәгать ничә икән?»—дип сораячак. Юк! Юк! Алай ярамый. Киресенчә, ул аның яныннан игътибар бирмичә генә үтеп китәчәк. Нәкъ элеккечә үз урынына барып утырачак та сиздерми генә күзәтәчәк. Нишләр икән? Элеккечә якты күзләре белән Зәбидәнең карашын эзләр микән?

Тагын әллә ниләр уйлап бетерде Зәбидә. Балаларым Рәшиткә охшар микән? Охшасын иде. Әтисенә охшаган балаларны бәхетле була, диләр. Шушындый тузга язмаган уйлар башына килүенә үзе дә аптырап куйды. Бүген бәхетле иде ул. Ә бәхетле кешегә ни уйласа да килешә. Бәхете булгач, тормышка ашмас хыял буламыни?!

Уйга бирелеп, янына профессор Дәүләтьяровның килеп утыруын да сизми калган икән.

— Зәбидә, үзенне ничек хис итәсең? Анализлар әзер. Иртәгә операция ясарга мөмкин.

Үзенең озын, сизгер бармаклы каты кулына Зәбидәнең беләген алды, пульсын санады. Бераз уйланып торгач кына, авыр сулап тагын өстәп әйтте:

— Риза булганчы, тагын бер кат уйла, сеңлем! Бик катлаулы, авыр операция... Куркытырга теләп әйтүем түгел, уңышлы чыгачагына шигем юк. Тик бер «ләкин» бар...

Зәбидәнең эче жу итеп китте. Әллә берәр анализы ярап бетмәде микән? Юк, юк... ул күпме көтәргә дә риза. Тик ясасыннар гына. Сабырлык белән профессорның ни әйтүен көтте.

— Сез бит кыз кеше... булачак әни кеше. Ләкин дигәнем шул, бу операциядән соң сезгә әни булырга ярамаячак. Аңлыйсыңмы, сеңлем, андый авырлыкны күтәрә алмаячаксың, бәби күтәрү җинел түгел... Уйларга вакыт бар. Уйла! Барысын да үзенә хәл итәргә.

«Ә» дә, «җә» дә дип әйтә алмады Зәбидә. Аның бу минуттагы халәтен аңлаган профессор ишек янына җиткәч, карашы белән Зәбидәне хуплаган кебек, керфекләрен төшереп алды.

..Төне йокысыз үтте Зәбидәнең. Билгеле бер фикергә килә алмыйча җәфаланды. Барысы да, барысы да яңадан тагын бер тапкыр күз алдыннан үтте.

***

Икенче көнне обходка кергән профессор, Зәбидәнең урыны буш булуын күреп, бер сүз дә әйтмәде. Бары тик авыр көрсенеп кенә куйды.

## Җыясы ризыгың

Төмән автовокзалында китә алмыйча инде икенче көн ятабыз. Атна буе коеп яуган янгыр авыллар арасын гына түгел, хәтта районнарны өлкә үзәге белән тоташтыручы юлларны да үтә алмаслык баткакка әйләндергән. Әлүмин чиләк төсле динамиктан бер-бер артлы теге яки бу автобусның маршрутка чыкмаячагын игълан итеп кенә торалар. Әмма автовокзалда халык кимеми. Берәүләр кулын селтәп китә тора, аларны икенчеләре алыштыра.

Безнең эчтә исә бүреләр улый. Алай-болай автобус килсә дип, бик еракка, читкә китеп тә йөри алмыйбыз. Автовокзал буфетына сугылгалыйбыз-сугылгалавын. Ә анда кофе, пешкән йомырка, бәясен күргә үк чәчләрең үрә торырлык кыздырган тавык, шикәргә катырган коржик ише нәрсәләрдән гайре әйбер юк. Студент кесәсе күтәрерлекмени! Кофе дип аталган болганчык суы гына да егерме тиен тора бит аның.

— Тизрәк авылга барып житәргә кирәк. Анда барып эләгә алсак, мантыр идек бер, — дип юандыра безне бу якларда йөргәләгән группа житәкчебез, аспирант Госман Жаббаров.

Ә хәзергә күрше кибеттәге килька консервасы белән канәгатьләнергә туры килә. Группадашыбыз Нурия әйтмешли: «Иртәнгә томат соусындагы килька, төшке ашка килькалы томат, кичкә томатлы килька». Кыскасы, һаман бер балык башы. Тышына берничә вак балык сурәте төшерелгән бу юка металл банкаларны күргә үк эчебез борып авырта башлый. Нишләмәк кирәк, студентның башы белем белән шыплап тутырылган булса да, кесәсе такыррак шул.

Шулай күпме яткан булыр идек, билгесез... Житәкчебез Жаббаров беркөнне каяндыр, без барасы якларга юл тотучы нефтьчеләр машинасын белешеп кайтты.

— Әйберләрегезне жыя торыгыз, таралып йөрмәгез. Озакламый машина киләчәк, — диде.

Кәсебенә керешсән була икән. Бер-ике сәгать үттеме-юкмы, автовокзал янына тәгәрмәчләренә кыш көнендәгечә чылбыр чорнаган «Урал» вездеходы килеп туктады.

Төялеп, Төмәннән йөз илле чакрымнардагы урман-күлләр арасына сыенып утырган Каскара авылына чыгып киттек. Себер якларына жыр, әкият, бәет эзләп экспедициягә чыккан студентларнын, ягъни безнең сәяхәтебез әнә шулай башланды. Без дигәнем—биш студент—Харис, Миннурый, Фидания, Нурия һәм мин.

Без килеп житкәндә жәйге кояш агач башларында тәгәри башлаган иде инде. Салулый-салулый, сикәлтә саен телләребезне тешләргә мәжбүр иткән машинаның гүелдәве дә, ниһаять, күнеллерәк ишетелә башлады. Алдыбызда озын күл буенда таралып утырган зур, төзек авыл пәйда булды. Йөзләребез бердән яктырып китте, эчкә жылы йөгерде. «Машинадан сикереп төшәрбез дә тымызык күлгә чумарбыз. Юлдагы талчыгу да, ару да юып алгандай юкка чыгар, эче эчкә ябышкан ашказаннарыбызга жылы ризык керер». Шуларны уйлап һәркайсыбыз ләззәтле минутлар кичерде бугай. Хәтта юл буе Харисның beлəгенә чатырдап ябышып килгән Фидания дә торып, кузовны кабинадан аерып торган биек тактага килеп ябышты.

Теләгебезгә ирештек ул көнне. Күлдә дә коендык, мунчасына да кердек, туйганчы жылы аш ашап, иртәгесе көнгә планнар корып, йокларга яттык.

...Авыл жирендә таң тиз ата. Без торганда йорт хужабыз Шәмсетдин бабай белән аның корткасы Хәдичә әбинең эшләп алжып, инде икенче

тапкыр чәй янына утырулары икән. Без дә авыл малайлары түгелмени?! Сикереп тордык та күлгә йөгердек. Чистарынып, сафланып кайтканда өстәлдә бәйрәм сые әзер иде инде. Менә сиңа Хәдичә әби! Ниләр генә юк бизәкле ашъяулык өстендә. Кыяр, яшел суган кебек нәрсәләрне әйтеп тә тормыйм, аның янында каймакка салынган, Себерчә әйткәндә, тукмак җиләк, парын бөркеп утыручы ит, ярмаланып торган бәрәңге һәм башкалар, һәм башкалар... Оятыма көч килсә дә әйтим, филология бүлегендә укып йөреп тә, әле исемнәрен белмәгән ризыклар, тәм-томнар бар икән! Тамакка бик үк хирыс булмаган кызларыбыз да, патшабикәләр шикелле ялындырып тормады, өстәлдәге сыйлар берәм-берәм эреп юкка чыга барды.

Хәдичә әби белән Шәмсетдин бабай канәгать. Бигрәк тә бабай. Ул сирәк сакалын сыпыра-сыпыра вәкарь белән генә һаман сыйлый.

— Яле, оланнар, ит белән картупына да җитешең. Көне буе йөрисегез бар. Эсседә ашалмый ул...

Хәдичә әби күп сөйләшми. Шундый ерактан килгән кунакларга сыенның ошавы күңеленә бик хуш килде бугай аның. Ә безгә нәрсә?.. Студент корсагы резин туп кебек бит ул. Тулай торактагы кефир малайлары дип башыңа да китермәссең... Аспирант Җаббаров кына бик беллекле кеше шикелле үзалдына елмаеп нәзберекләнеп утырган була.

Тәмам хушланып, әби белән бабайга рәхмәт укый-укый өстәл яныннан кузгалдык. Инде эшкә тотынсак та ярый. Парлашып бүлештек тә, җирәбә салып, авылның кайсы урамы кемгә туры килүен билгеләдек. Миңа Нурия белән күл буендагы түбән оч урамы эләкте.

Тук тамакка бераз авырая төшсәк тә, кәгазь-каләмнәребезне алып, түбән очның иң аргы башына ук чыгып киттек. Шуннан килә-килә әбәткә чакырып калган Хәдичә әби янына төшке ашка кайтып житү иде исәбебез.

...Авыл кырыендагы беренче йортның капкасын шакыдык. Әллә көтеп үк торганнар инде, безне йорт хуҗабыз шикелле үк сирәк сакаллы, бәйрәм көннәрендәгечә, башына кара түбәтәй, әле генә үтүкләнгән ак күлмәк өстеннән камзул да киеп җибәргән бер карт каршы алды. Тирән җыерчыклар белән чуарланган көрәктәй ике кулын биреп күрешкәч, күптән көткән кунакларыдай күреп безне ак өйгә чакырды.

— Бергә-бергә шунда чәй янында гәпләшеп утырырбыз. Карчыгым да күптән көтә инде сезне...

— Юк, юк, бабай!.. Без чәйләп утыра алмыйбыз. Әле яңа гына өстәл яныннан кузгалдык, — диде куркып калган Нурия. Дөресен генә әйткәндә, икебезнең дә бер генә кабар ниятебез дә юк иде. Бөтен теләгебез тизрәк халык иҗаты хәзинәләрен җыя башлау, әле бер генә хәреф тә төшмәгән дәфтәрләребезгә монарчы адәм колагы ишетмәгән борынгы җырлар, кинаяле такмаклар, тылсымлы әкиятләр, дастаннар теркәү. Икебез дә тизрәк әнә шул сафландыргыч чишмәгә кушылырга хыялланабыз. Авылдагы һәр өйдә таныш булмаган моңнар, риваятьләр, һәр бабай, һәр әби хәтерендә алтынга тиң шундый хәзинә бөртекләре саклана дыр сыман тоела.

— Бабай, без чәй эчеп тормыйча гына сөйләшик инде. Казаннан ук җырлар, әкиятләр язып алырга килдек бит, — дип дәвам итте Нурия үрсәләнеп.

Ачык йөзле бабаебыз кинәт кырт кисте дә куйды.

— Сөйләй алмаем сиңа, йөрәгем. Хәтерем дә тишек инде. Хәтерләмәем. Әнә кәмпиремнән сорап карагң...

Бабайдан картрак күренсә дә, житез хәрәкәтле карчык инде баскыч төбенә чыгып баскан икән. Ул сүзгә кушылды.

— Сиңа әйтәм, нигә өйгә чакырмыйсың? Самавырым суынаты.

— Әби, ичмасам, сез белмисезме соң? Безгә... ни, җырлар кирәк иде бит.

— Хаҗәтен белгем киләте. Нигә соң ул?

— Без шуларны җыеп йөрергә дип килгән идек.

— Ярар, балалар, уйлашырбыз. Башта сыйдан авыз итик тә.

Ах, шул сый дигәннәрен. Ансыз гына булмыймыни инде?!

Икебез беравыздан җавап бирдек.

— Юк, әби! Рәхмәт! Чәй эчеп тормыйбыз инде, — дидек без икебез беравыздан.

Әбинең йөзенә үпкәләү галәмәте чыкты.

— Нинди сүз ди ул. Карт башың белән көпә-көндез җырлап утыру. Сез инде үпкәләмәгез, белмибез без. — Аннары, картына карап, тагын өстәде. — Аяк-уенга[1]* да үнәребез юк.

Безгә хушлашып чыгып китүдән башка чара калмады.

Күңелебез шактый ук төшәргә, баш өстебездәге алсу хыялларыбыз тарала башларга өлгергән иде инде. Тагын ни булыр икән дип, кыяр-кыймас киттек өй борынча. Яшьләр күбесе эштә, күрәсең. Гадәттә карт-карчык каршы ала. Керәбез, сәлам бирәбез. Ачык йөз, тәмле сүз белән каршы алалар, хәл-әхвәл сорашалар һәм... өстәл янына чакыралар. Җыр, әкият, мәзәк турында ишетергә дә теләмиләр. Бу турыда сүз чыккач: «Әй, кара син аны! Хәзер шуны җыеп йөриләр икән», — дип тел шартлаталар, бот чабалар, гаҗәпләнәләр. Ә үзләре ник бер нәрсә сөйләсеннәр. Бар сүзләре шул:

— Үнәрем юк шул, балам.

— Белмәем...

— Хәтерем тишек иләк кебек.

Чираттагы өйдән чыгып Нурия белән бер-беребезгә карашып торгач, аптырап кулларымны җәеп җибәрдем.

— Каскара авылы картлары җыр белми икән, ә?!

— Шулай икән шул. Гомереңдә уйламассың, — дип сүзләремне куәтләде Нурия. — Безнең авыл картлары алтын икән.

Шулай карашып тордык та, өйдән-өйгә йөрмәс булып, авыл кырыендагы Пыктын Карагае дигән күл янына төшеп киттек.

Себер кояшы көньякныкыннан ким кыздырмый икән. Рәхәтләндек бер, ичмасам. Ничә көн кояш күрмәгән тәннәребез, кызарып, ачыта башлаганчы кызындык, су коендык. Көн кичкә авышкач кына: «Госман Җаббаровка ни әйтербез икән?» дигән уйга төшеп, кайтырга чыктык. Бик тә ашыйсы килә иде. Иртәнге сый-хөрмәтләр искә төшеп, авыздан сулар ага хәтта.

...Капка төбендә Шәмсетдин бабай каршы алды. Койма янындагы калын бүрәнәдә, черем иткәндәй, оеп утыра иде. Безне күргәч, үзе яныннан урын күрсәтте.

— Йә, оланнар, кайларда булдыгыз, ниләр күрдегез? Ничек сыйладылар?.. — дип тизеп китте ул ашыкмас тавыш белән.

— Булмады ла, бабай... Берни язып ала алмадык.

Шәмсетдин карт ышанмыйча, бер күзен кыса төшеп, безгә карап торды.

— Ничек? Аит Сәйдулласы да берни сөйләмәдеме?

Аның соравына сорау белән җавап биргәнебезне сизми дә калдык.

— Кем соң ул?

— Соң, беренче булып шуларга кергәнсездер ләбаса. Түбән очның иң кырыйдагы йорты. Авылда беренче ерауцы, аяк-уен остасы иде бит ул яшь чагында.

[1] Аяк-уен—бию (Себер диалекты).

— Шуларга кердек, — дип сузды Нурия. — Берни дә сөйләмәде бит.

— Чынлап та аларның өенә кердегезме? — дип төпченүен дәвам итте бабай.

— Ю-у-к! Өйләренә үк кермәдек, — диде Нурия. — Ишегалдында гына сөйләштек.

— Чакырмадымыни?

— Чакырды... Үзе дә, карчыгы да... Чәй эчәргә дип чакырдылар.

Шәмсетдин бабай, нидер уйлагандай, колак артын кашып куйды да картларча кеткелдәп көлеп җибәрде:

— И балалар, балалар! Үзегезне аштан өстен куйгансыз бит. Бергәләп ризык җыймагач, сыен авыз итмәгәч, ишегалдында сезгә кем җыр җырласын да, кем әкият сөйләсен ди инде.

Хатабызны шунда гына аңладык.

— Хәзер нишлик соң инде, бабай?

Җавап көтеп, икебез дә аңа текәлдек.

— Нишлик-нишлик, — дип үртәгәндәй кабатлады Шәмсетдин бабай. — Иртәгә барасыз да, янадан керәсез. Аш ашка, урыны башка.

***

Бераздан Харис белән Фидания дә кайтып керде. Аяк атлауларыннан ук сизеп торам, безнең шикелле үк берни дә кыра алмаганнар. Бары тик Госман Җаббаров белән Миңнурый гына, дәфтәрләрен уалыр дип курыккандай, кадерләп тотып, янібыздан үтеп киттеләр.

Ярар, иртәгегә таңны аттырсак, без дә ак сакаллы карт булырбыз, дип йокларга яттык. Ә иртән, Хәдичә әбине үпкәләтмәс өчен, берәр чынаяк кына чәй эчеп, кире Сәйдулла бабайларга юл тоттык.

— Хәерегез белән киләсез, — дип елмаеп каршы алды ул. — Җыясы ризыгын булса, тешеңне сындырып керер, ди.

Нурия белән икебезнең дә колакларыбыз торды. Кара син бабайны, бүген беренче сүзеннән үк мәкальләр сибә түгелме?..

Шатланып авызымны ерырга өлгермәдем, касыгыма Нуриянең йодрыгы килеп төртелде.

— Кичә мин сөйләшкән идем. Инде бүген сөйләшүне син алып барырсың, — дип пышылдады ул теш аралаш.

Ризалыгымны белдереп, бабайга сиздерми генә аңа күз кысыйм дип борыла башлаган идем, кыз җиңемнән тартты.

— Минем белән түгел, бабай белән сөйләш!..

Картыбыз ашыкмый, салмак кына атлап килеп күреште, кулларыбызны сыйпап торды. Хәер... бу юлы да кичәге шикелле башлады:

— Ягез инде, без картлар янына килгәнсез икән, өйгә үтик. Әбиегезнең самавыры суынып өлгермәгәндер әле.

Карышып тору кая! Чакырмаслар инде дип, куркыбрак та килгән идек әле. Әдәп өчен икенче тапкыр әйткәнне дә көтеп тормастан, ашыга-ашыга аякларыбызны салып эчкә үттек.

Әллә Себер картлары самавырсыз яши алмый инде. Чынлап та, түрдәге өстәлдә башына чәйнек менеп кунаклаган самавыр җырлап утыра. Аның янында эреле-ваклы чынаяк-касәләр, өсте чигүле сөлге белән капланган савыт-саба иде.

— Йә, утырыйк, балалар. Бүген дә шул җыр эзләп йөрүме?

— Әйе шул, бабай, — дип, инициативаны үз кулыма алдым. — Халык җырлары... алар бит безнең халыкның «мәңге күгәрмәс вә тутыкмас җәүһәрләре»...

Шул вакыттагы сөенүемне күрсәгез!.. Университетта алай-болай гына

укытмыйлар икән. Габдулла Тукайның мәшһүр сүзләрен ничек оста китереп «сыладым».

Бабай ризалыгын белдереп, ике куллап юка сакалын сыпырып алды. Кһым, кһым дип, тамагын кырып куйгач, чаршау артында кыштырдаган карчыгына эндәште.

— Сиңа әйтәм, чык инде монда. Менә бит кичәге кунакларыбыз килгән.

Озак көттерми карчыгы да күренде. Тышына чык типкән балчык чүлмәкне киндер сөлге белән сөртә-сөртә кичәге сөйләшү булмаган да кебек киң итеп елмайды:

— Менә баздан шомырт суы алган идем әле. Сөйләшкәндә тамак кибүчән, -— дип сөйләнә-сөйләнә өстәл янындагы эскәмиягә килеп утырды.

Авызыбыз бер пешкән бит. Бүген инде без кыстатып тормадык. Студентлар әйтмешли, өстәлдәге сыйны урдык кына. Әмма чама ягын да онытмадык. Әле тагын башка кешеләргә дә керәсе булыр бит.... Бары тик шуннан соң гына язарга әзерләнеп, дәфтәрләребезне чыгардык.

— Йә, ни эшкә инде ул безнең җырлар? — Бабай тагын соравын кабатлады.

— Ни эшкә дип, белә торгансыздыр инде... Аларны җыеп, китап чыгаралар, тарихны өйрәнәләр....

— Әйе, бабай, әле халыкта җыеп алынмаган меңнәрчә җыр, әкият, мәкаль, бәет булырга мөмкин. Киләчәк буыннар өчен югалырга тиеш түгел, хәзинә алар, — дип сүзгә кушылды Нурия. Сөйләсә, сөйли белә дә инде!

— Ә-ә... анысы кызык икән... Ерлар күп инде ул. Үзегез ниндиләрне беләсез соң? Сез яшьләр инде. Нәпример, уен ерларын, — шулай диде дә бабай, көлемсерәп, күзен миңа текәде.

Кирәк чагында ник берсе искә төшсен икән. Үземнең туган авылдагы (хәер, авыл түгел инде ул, район үзәге) ял кичәләрен искә төшереп карыйм, күз алдына университет дискотекалары килә. Җыр җырламыйбыз икән ләбаса. Күбрәк тыңлыйбыз гына микәнни соң? Өмет белән Нуриягә карыйм. Ул исә китмәгән кыяфәт белән дәфтәренә нидер язып утыра. Әллә мин җырлаганны язмакчы ук инде.

Тавышым юк минем. Хәтта әни дә: «И бала, бигрәк инде тавык җырлаган кебек кенә җырлыйсың», — дип җәлләп куя торган иде. Ну монда сынатырга ярамый. Бабайның телен ачасы бар ич әле. Шул вакыт кылт итеп хәтеремә бер җыр килде. Күкрәгемне тутырып тын алдым да (кычкырмасам җырлый алмыйм мин) түшәмдәге такта ярыкларына карап, тамак төбе белән бар көчемә кычкырып җырлап та җибәрдем:

Комбинезон алган, диләр,
Шинелен салган, диләр.
Шинелен салса да, солдат
Гадәте калган, диләр.

Башка куплетларын бик белеп тә житкерми идем. Җырлый башлагач, үзе чыга икән. Бер генә кавым да туктап тормыйча дәвам иттем:

Шинелен салган, диләр дә,
Шинелен салган, диләр.
Әллә каян күренеп тора,
Солдатта булган, диләр.

Булдырдым бит әй, дип Нуриягә караган идем, авызын кулы белән каплаган. Әллә елый, әллә көлә. Хәер, аның бәясе әллә ни кирәк түгел миңа. Иң мөһиме—картлар. Алар ни әйтер!..

Бабай бик канәгать калган, күрәсең. Күзләрендә шаян очкыннар балкый. Әбигә карап күз кысып та ала әле.

— Маладис егет икәнсең, — диде ул. — Монысын радиодан безнең дә ишеткән бар. Тагын берәрне жырлап күрсәтсәң иде.

Инде чирканчык алынган, күп уйлап тормый, икенчесен дә әйттерә башладым:

Утыр әле яннарыма,
Ял булсын жаннарыма.
Син утырсаң яннарыма,
Ял була жаннарыма.

Казандагы танылган бер жырчы шикеллерәк иттереп жилкәләремне дә сикертеп алам, аякларым белән идәнгә дә тибеп куям.

Тагын да жырлыйм диеп тәмам азартка кереп барганда Нуриянең пырхылдап көлүе бүлде. Битенә дәфтәрен каплаган, иңсәләре дерелдәп-дерелдәп куя.

И рәнжедем ана шул вакытта. Әллә үзен концертта дип белә микән, чытлыкланып утырырга. Үтергеч караш ташлап, шуны әйтергә авызымны ачмакчы идем, әби кулыма тустаган китереп тоттырды.

— Тамагың кипкәндер, улым, эчеп йибәрең әле... — Шомырт исе аңкып торган ширбәтне йотып куйгач, ачуым басыла төште тагы. Әле һаман пырхылдаган Нуриягә:

— Соң, алай булгач, үзең жырла, — дип кенә әйтә алдым. Жырга минем кебек кенә түгел инде ул. Анысын яхшы беләм. Тик ана жырларга туры килмәде. Сәйдулла бабай егерме яшьлек егетләр шикелле итеп кәләпүшен кыңгыр салып куйды, камзулын жилбәгәй жибәреп Нурия каршына килеп басты да, үзе әйтмешли, «ерлап» та ебәрде:

Карагай ла башы кәвеш-кәвеш,
Сызылып ла килә бер тавыш.

Бармаккаен камыш, йөзең кояш,
Акылларын камил, үзең яшь.

Ашыкмый гына, көйнең, моңның тәмен белеп сузып, һәр сүзенең мәгънәсен йөрәге аша үткәреп жырланган бу жыр икебезне дә телсез калдыргандай булды. Нуриягә генә кара!

Әйтерсең лә үзенә атап жырлыйлар. Битләре үк алланып китте. Көязләнеп, бабайга елмаеп утыра. Мин жырлаганда борылып та карамаган иде.

Әсәрләнеп, дәфтәргә теркәп барырга да оныта язганбыз. Тиз генә каләм-дәфтәргә ябыштык. Хәер, инде бабай безнең турыда үзе үк онытткан иде, күрәсең. Әллә Казан хәтле Казаннан килгән студентларның һәр сүзен кәгазьгә теркәп утырулары күңеленә хуш килде, әллә егет чакларына кире әйләнеп кайтты, бабабыз карчыгы янына барып, инде ана атап жырлый башлады:

Кимә итек, ки читек,
Аякка жиңел итеп.
Аргы урамдин ярлар сөйдем,
Бирге урамга үч итеп.

Аңа калтырап чыккан тавышы белән, әмма ниндидер борынгы көйнең бормаларын үзенчә бик рәвешенә китереп, әбиебез дә кушылды:

Агыйделкәйләрнең аръягында
Ат аунаган кара җирләр бар.
Чакырсам барман, кулын салмаң,
Күңелкәем калган ярым бар.

Бабай да җавапсыз калмады. Салмак хәрәкәтләр белән идән уртасында түгәрәк ясап җырлый башлады:

...Үзем дә лә генәй сөйгән ярны
Күз күрмәгән якка озаттым.

Әби башына чөйгән яулыгының бер чите белән йөзенең яртысын каплады, оялчан кызлар шикелле иттереп, сузып кына җавап бирде:

Зәл килә сәлки, Садрый сәлки,
Камзуллары яшел гарнатур.
Сән сорамайсың, мин әйтмәем,
Сәлам дигән сиңа бер матур.

Бер-ике тапкыр самавыр янарттык без ул көнне. Әби белән бабайның хәтерләре бер дә тишек түгел икән. Сүз иярә сүз чыгып дигәндәй, аларның бер такмаклары икенчесен хәтерләтте, бер бәеттән икенчесенә күчтеләр, авылда төрле елларда булган вакыйгаларны, аларга карата кемдер чыгарган такмак-бәетләрне бәйнә-бәйнә сөйләп бирделәр. Кеше халәтенә җырның ничек тәэсир иткәнен үз күзләребез белән күрдек без. Сәйдулла бабай белән карчыгы бердән яшәреп киткәндәй булдылар. Әйтерсең лә җилкәләренә заман, чорлар авырлыгы белән басып торучы сигез дистәгә якын ел чалымы да, битләрендәге җыерчыклары да юкка чыкты. Аларның гәүдәләре тураеп китте, күзләреннән яшьлек нуры бөркелгәндәй булды. Себернең адәм генә түгел, киек җанвар адашырлык кара урманнары арасына кереп поскан татар авылларының чал үткәнен безнең алда янарттылар, җырлары белән безне дә шул чорга алып кереп киттеләр алар. Иртән килгән җиребездән без төш вакыты җиткәнне дә, кояшның кичлеккә авышканын да сизмәгәнбез. Яза-яза кулларыбыз арыды, дәфтәрләребез тулды. Инде Сәйдулла бабай сүзне үзе очлады:

— Менә шулай, оланнар. Килгәнегезгә рәхмәт. Яшь чакларыбызны искә төшердегез әле, — диде ул. Аннан соң, карчыгы белән карашып алгач, ягымлы көлемсерәп өстәп куйды. — Кичә кергәндә бик эре нәрсәләр икән дип хәтер кала язган иде. Бүген сөендердегез тагы... Инде сезнең җырларны да тыңларга насыйп итсен.

*1986*

# РУШАД АБЫЙ ЧЫН КӨРӘШЧЕ ҺӘМ ӘЙБӘТ КЕШЕ ИДЕ

Язмыш Рушад Хисаметдиновны җәлилчеләрнең батырлыгын илгә җиткерсен өчен исән калдыргандыр, күрәсең. Ләкин сөйләгәнен ишеткәннәрме соң? Аны янадан төрмәгә утырталар. Инде совет төрмәсенә. Анда да ул тикшерүчеләргә Муса Җәлил һәм аның көрәштәшләре алып барган фидакяр көрәш турында кат-кат сөйли. Нәтиҗәдә аны... атарга хөкем итәләр. Ничек мөмкин булган соң бу? Өч ел элек үк СССР Язучылар берлеге җитәкчесе Александр Фадеевка солдатларның Моабит төрмәсе ишек алдында Муса Җәлил үзенең сәяси гаепләнүен һәм, күрәсең, тиздән атачакларын язган китап бите тапканлыкларын хәбәр итәләр. Фадеев бу хакта инде 1946 елның февралендә үк Татарстан Язучылар берлегенә җиткерә. Пленнан кайткан Нигъмәт Терегулов шул Татарстан Язучылар берлегенә Мусаның шигырь блокнотын да тапшыра. Боларны Рушад Хисаметдинов сөйләгәннәр белән бергә куеп карау гына кирәк бит инде юкса. Хисаметдиновны ату һәм Җәлилне сатлык җанга чыгару тагын да гадирәк эш булган инде, күрәсең.

Андре Тиммерманс Бельгиядә Константин Симоновка «Моабит дәфтәре»н 1956 елны тапшыра. Ә бирмәгән булса? Йә бу күренекле язучыга түгел, бүтән берәүгә биргән булса?

Җәлилнең батырлыгын, ниһаять, таныйлар, ләкин бары аныкын гына. Үлем җәзасы бетерелү турында Указ чыгып, янә могҗиза белән генә исән калган Рушад абый мондый олы, колачлы батырлыкны Җәлил үзе генә эшли алмаганлыгын, аның тугры, батыр көрәштәшләре булганлыгы, бу көрәшнең ничек барганлыгы турында туктаусыз сөйли килде. Ләкин моны һаман танымадылар. Белоруссия, Украина, Франциянең партизан отрядларында фашистлар белән сугышкан легионерлар сугыш бетеп ярты гасыр үткәч тә реабилитацияләнми әле. Рушад абый әрнеп болай дип язган иде: «Берия һәм Абакумовларның варислары һаман да качып яталар һәм гаделлеккә юл куймаска тырышалар кебек тоела миңа».

Мин Татарстан Китап нәшриятында мөхәррир булып эшләгәндә, 1983 елда миңа Исхак Зәбировның «Җәлил һәм җәлилчеләр» дигән китабын редакцияләргә туры килде. Анда Рушад Хисаметдинов турында да гадел, җылы сүзләр күп. Бер тапкыр мине нәшрият директоры янына дәштеләр. КГБ кешесе Хисаметдиновны без җәлилче дип санамыйбыз дип әйтер өчен махсус килгән икән. «Как?!» — көтелмәгән бу сүзләргә аптыраудан минем авыздан әнә шундый сүз чыкты. «Бу — Хисаметдиновның апасының кызы», — диде директор. — Кирәк икән, аны редакцияләүдән алырбыз». Мондый очрашуга әзер булмаган иптәш: «Юк-юк, калсын, Хисаметдинов турында күп кермәсен бары. Кыскартыгыз», — диде. Шушы хәлдән соң мин Дәүләт иминлеге комитетына бардым, анда генерал белән очраштым. «Хисаметдиновка мондый мөнәсәбәт ни белән бәйле?» — дип сорадым. Әмма ул, тикмәгә борчылуымны, Хисаметдиновка бернинди дәгъвалары да юклыгын әйтеп, мине тынычландыра башлады.

Ул чордагы күпләр кебек, Рушад абый да Хрущев амнистиясенә эләкте. Ләкин җәлилчеләр белән бөтен күңелен биреп шөгыльләнгән Гази Кашшаф, моның белән генә тынычлана күрмә, реабилитация кирәк сиңа, диде. Абыйны, туйган инде, маташмыйм, диюгә дә карамыйча, шуңа керешергә мәҗбүр итте. Рәхмәт инде аңа.

Рушад абый үзен саклап, кадерләп, сәламәтлеген кайгыртып яшәмәде. Ул солдат, көрәшче иде. Җәлил һәм аның көрәштәшләренең батырлыгын ул бер кеше алдында

да, ун кеше алдында да, тулы зал алдында да ачып, күрсәтеп бирергә омтылды. Ул сөйләгәнне бик яратып тыңлыйлар иде. Шул ук вакытта ул бик гади, аралашырга ярата торган, шаян һәм ягымлы кеше дә иде. Хатын-кызларның исләре-акыллары китә торган иде...

Бу хатирәләрне асылда абый үзе язды, ләкин аңа мин Бакый Урманченың хатыны Флора ханым магнитофонга яздырганнарны да өстәдем. Бакый абый белән гел аралаша, төннәр буе сөйләшеп чыга торганнар иде алар.

Фуад абый Кыргызстанда, Ош шәһәрендә яшәде. Ләкин Казанга гел килгәләп торды. Без дә бара торган идек. Әниебез Кәшифә аның бертуган апасы иде бит.

Бер генә үкенеч калды. Пенсиягә чыккач, аның турында зур документаль әсәр язам дип килешкән идек. Пенсиягә чыгып та дүрт ел үткән иде юкса, өлгерә алмадым шул менә... 1992 елны дөнья куйды бу гаҗәеп шәхес...

**Азалия БАДЮГИНА**

Рушад
Хисаметдинов

# ҖӘЛИЛЧЕ БУЛУЫМ БЕЛӘН ГОРУРЛАНАМ

Мин 1911 елның 27 октябрендә Верный шәһәрендә (элек Алма-Аты шулай дип йөртелгән) укытучы гаиләсендә дөньяга килгәнмен. 1884 елда туган әтием Билал Шәриф улы Хисаметдинов чыгышы белән элекке Казан губернасының



Мамадыш өязе Югары Искебаш (Казаклар) авылыннан булган. Ачлыктан качып, әтиемнәр гаиләсе XIX гасыр ахырында Оренбур губернасының Грознен станицасына күченгән.

Әти «Хөсәения» (Оренбур), «Исхакыя» (Троицк) мәдрәсәләрендә белем ала, Троицкида ук реальный училище тәмамлый. 1905 елда миллионер купец Исхак Габделвәли чакыруы белән Верныйга барып, укытучы булып эшли башлый. 1907 елда әти борынгы Казан ханнары нәселеннән чыккан Мәрьям Газиз кызы Гозәеровага өйләнә. 1916 елда әтием Беренче бөтендөнья сугышында катнаша. Сугыштан исән-сау кайтып, Верныйда 1917 елгы революцион вакыйгаларда катнаша.

Гаиләбездә туган унбер баланың өчесе сабый чакта ук дөнья куйган. Калган сигезебез (дүрт кыз, дүрт малай) оешып килә торган чорга лаеклы рәвештә яшәп, дөнья кичердек.

Әти-әниебез безне кечкенәдән үк эшкә өйрәтеп үстерде. Эштән яисә укудан йөз чөерү, алдашу кебек гамәлләргә гаиләдә каты бәя бирелә иде. Әтиебез турында аерып әйтәсем килә. Ул безнең өчен һәрвакыт намуслылык, гаделлек, тугрылык үрнәге булып торды. Безгә күп төрле милләт кешеләре арасында — руслар, казакълар, уйгырлар, үзбәкләр һ.б. арасында яшәргә туры килде. Әти тирәбездәге һәммә кешегә хөрмәт белән, тигез карый, күбесенең телен белә, гарәп, фарсы телләрендә иркен аңлаша иде. Үзе төрле телләрдә укып, ул бездә дә китапка карата мәхәббәт уята белде. Укытучы буларак җирле халык арасында аның абруе зур иде. Мәгарифнең Семиречье губерна мөдире буларак әти күп

эшләде, рус мәктәпләре дә һәм башка милли мәктәпләр дә ачты. Тәрбиясез калган урам балалары өчен приютлар оештырды. Казакъ мәктәпләре өчен алфавит төзү эшендә актив катнашты.

Татарның һәм башка милләтләрнең алдынгы укытучылары белән бергә кулга алынып, әти 1937 елда атып үтерелүгә хөкем ителде. Аның нахакка атылган булуын без 1954 елда гына белә алдык.

Минем үземә дә гомеремдә фашист зинданнарында һәм Сталин ГУЛАГларында күп михнәтләр кичерергә туры килде. Әтиемнең кинәшләрен истә тотып, үзем белән бергә бәхетсезлеккә тарыган иптәшләремә, нинди генә милләттән булсалар да, хөрмәт белән карыйм. «Улым, — дия иде ул, — милләтенә карамастан, рәнжетелгән, кыерсытылган кешене кимсетмә, аны якларга, аңа ярдәм итәргә тырыш. Шулай булганда гына үзең дә хөрмәткә лаеклы булырсың», — дия торган иде. Тормыш аның хаклы булуын раслады. Әти-әнием тарафыннан күңелемә салып калдырылган игелеклелек, тәрбиялелек сыйфатлары миңа иң авыр җәзаларны, кыйналуларны, ачлык-ялангачлыкларны җиңәргә, үтә чыккан караклар һәм башкисәрләр, наркоманнар һәм һәртөрле кабахәтләр арасында да кешелек дәрәҗәмне төшермәскә ярдәм итте. Хәзер миңа бик еш яшьләр белән очрашырга туры килә, шунда инде мин аларга да әтиемнең игелекле васыятьләрен тапшырырга-җиткерергә тырышам.

Яшьләр белән очрашуымның максаты — дусларыма-көрәштәшләремә биргән вәгъдәмне-антымны тормышка ашыру: герой шагыйрь Муса Җәлилнең һәм аның белән бергә гитлерчылар тарафыннан җәзалап үтерелгән иптәшләренең фашистлар оясында аларга каршы көрәшүе хакында сөйләү.

Шулай да, хезмәт эшчәнлегемнең башына әйләнеп кайтыйк әле. 1931 елда Аулеатин зооветтехникумын тәмамлагач, мине өлкән врач сыйфатында Семипалат өлкәсенең Кок-пектин ит әзерләү совхозына җибәрделәр. 1932 елда үзем теләп чик сакчылары гаскәренә хезмәт итәргә киттем. Башта Ерак Көнчыгыштагы 58нче Гродеков кавалерия погранотрядына эләктем. Маневр группасы составында атаман Семенов бандаларын, Кытай хунхузларын һәм контрабандистларны юк итүдә катнаштым. Аннары, 1937 елда, Казакъстанга, Совет-Кытай чигенә, элек 30нчы Бахтин, аннары Кызыл байраклы 49нчы Джаркен кавалерия погранотрядына күчерделәр. 1940 елда авыру сәбәпле демобилизацияләндем һәм Бөек Ватан сугышы башланганчы Алма-Аты өлкәсенең Илий районында баш ветврач булып эшләдем.

Сугыш башлану белән мин тагын Кызыл Армиядә. 79нчы аерым кавалерия дивизиясенең 233нче кавалерия полкы составында Көньяк-Көнбатыш фронтында барган сугышларда катнаштым. Немец-фашистларның бронетанк дивизиясенә каршы тигезсез каты сугышта безнең полк бөтенләе белән тар-мар ителде. Исән калганнарыбыз бергәләшеп полкыбызның байрагын чолганыштан алып чыктык. Аннары Кызыл байраклы 30нчы Кубан-Дон казакларының кавалерия дивизиясе составында Краматорск (Красноармейская станциясе) тирәсендәге тигезсез сугышларда катнаштык.

Мин ничек фашистлар кулына эләктем соң?

1942 елның июлендә, Төньяк Донецк чикләрендә чолганышта калып, авырлык белән сугыша-сугыша частебез Дон елгасына таба чигенә иде. Гитлерчылар юлларындагы һәр җан иясен юк итә барды. Аларның алгы частьләре, безне кысрыклый-кысрыклый, тылыбыздагы частьләребездән йөзләп чакрымда гына булган Вешенская станицасына якынлаштылар, тар-мар ителгән дивизиябезнең калдыкларын Төньяк Донецкига таба кысрыкладылар. Авыр сугышлардан хәлсезләнгән сугышчылар — кайсысы чишенеп, кайберләре кием-салымнары белән үк — суга сикерә башлады. Мин дә коралым-җиһазым белән шундук суга ташланмакчы булган идем дә, башта атым буйсынмыйча маташты. Суга сикерүгә

шундук төпкә китә башладык. Атымның бик нык тырышуы аркасында гына йөзеп баручы кешеләр, атлар арасына өскә калыктык. Түбәннән генә очкан дошман бомбардировщиклары безне рәттән кырып баралар иде. Суга тончыгучы кешеләрнең кычкырышуын, атларның хырылдашуын хәзер дә ишетәм кебек. Елга тутырып су түгел, кан агадыр сыман иде. Фашист карчыгаларының берсе эре калибрлы пулеметын миңа таба юнәлтеп ут сиптерде. Мин атымның ялына ябышып сеңдем. Куркыныч сызгырып, пулялар очты. Шинель итәкләрем, йөгән, тезгеннәр тишкәләнеп бетте. Бәхеткә күрә атым белән без исән калдык һәм ничек кирәк алай ярга чыктык. Шул арада мин бомба чокырында сазда батып баручы берәүнең ярдәм сорап кычкырганын ишеттем. Тиз генә аңа йөгәнне ыргыттым да, аткаем әлеге батучыны тартып чыгарды. Ичмасам, бер генә кешене булса да үлемнән коткарып калдык.

Армиябез күз алдында таркала барды: кем ничек булдыра, шулай үзебезнекеләргә таба юл ала. Барлык авылара юлларны һәм шоссе юлларны инде немес частьләре биләп алган иде. Тугыз кешедән торган төркемебез төнлә генә алга таба хәрәкәт итте, көндезләрен урманлырак җирләрдә, куаклыклар арасында, чокыр-чакырларда посып яттык. Үтеп киткән чакларында безнең качкан-поскан урыннарыбызны немесләр утка тота. Ярылгыч пуляның бер ярчыгы минем уң аягыма килеп тиде. Ярчыгын алуын алдым, әмма каны бик каты ага иде. Үземдә индивидуаль пакет булу коткарды. Ачка интегәбез: үлән чәйнибез, җиләк-җимеш ише нәрсә эзлибез. Бер мәлне үзебезнекеләрдән калган тозлы балык мичкәсенә килеп юлыктык. Атна буе шул балыкка алданып, сусыз кибегеп, үләр хәлгә җиттек. Бер көнне иртән каядыр якында гына чишмә челтерегән тавыш ишетелгән кебек тоелды.

Сөзәк җирдән аска таба төшә башлауга көтмәгәндә немесләрнең танк патруленә килеп чыктык. Немесләрнең берсе, чалбарымдагы кызыл кайманы күрепме, «Комиссар!» дип кычкырып җибәрде дә штык белән кадап үтермәкче булып приклад белән бәреп екты. Безнең белән бергә Кацоев дигән бер таулы егет бар иде, ул: «Найн, нихт комиссар! Эр ветеринар. Арц!» — дип кычкырырга өлгерде. Немес, итеге белән касыгыма тибеп: «Ауфштеен!» — дип команда бирде. Бу юлга үлемнән исән калдым.

Безне конвой белән алып киттеләр, һәм без озакламый үзебезнең хәлдән тайган хәрби әсирләребезгә килеп кушылдык. Колоннаны этләр белән автоматлы немесләр әйләндереп алган. Атлый алмаганнарны шундук атып үтерәләр. Хәлсезләнгән кешеләр бер-берсенә ярдәм итешергә тырышалар. Кыска-кыска гына тукталышлар ясаталар. Янки дигән вакытлы гына лагерьга безне кич кенә китереп җиткерделәр. Чәнечкеле тимер чыбык белән әйләндереп алынган лагерь территориясендә без төрлебез төрле якка таралыштык.

Полкташларымны эзләп йөргәндә мин аяклары аннан-моннан гына салам белән каплаштырылган берәү янына килеп чыктым. Сакал-мыегы житкән йөзе янында шырпы кабы хәтле генә Коръән ята. Мин мөселманча «Әссәламегаләйкем!» дип исәнләштем. «Су» диде ул татарчалап әкрен генә. Кулы белән киеменә яшерелгән калай банкасын күрсәтте. Банканы алып, мин кухняга таба киттем. Нәкъ шул чакта берәү кухняга мичкә белән су китерә иде. Мин аннан калай банкама әз генә су салуын үтендем. Су саласы урында ул кулындагы авыр чүмече белән башымны сугып ярды. Шул чакта кухнядан ак халат кигән пешекче килеп чыкты. «Ни булды сиңа, туган?» — дип сорады ул миннән. «Үләргә яткан кеше сораганга суга килгән идем, ә монда башымны сугып ярдылар», — дидем. Пешекче су китерүчене сүкте дә, су салырга кушты. Калтырана-калтырана алып барып, суны үләргә ятучының авызына тидердем. Ул бер генә йотты да соңгы сулышын алды. Мин аның күзен йомдырып, Коръәннән үзем белгән сүрәләрне укыдым. Банкада калган суны йотлыга-

йотлыга үзем эчеп бетердем. Кухня ягыннан сызгырган тавышка борылып карасам, анда пешекче мина кул болгый икән. «Суны илтеп эчерерсең микән дип карап тордым», — диде ул. Әле генә дөнья белән хушлашкан кеше аның якташы, Казаннан булган икән. «Урыны җәннәттә булсын, әйбәт кеше иде, — диде рус кешесе булган пешекче. — Булдыра алганча булыштым инде мин ана. Бер этаптан идек без.» Пешекче мина, эндәшмәскә кушып, бераз гына ботка бирде, аннары булдыра алган хәтле булышырга да вәгъдә итте.

Ул Коръән ничә тапкырлар минем гомеремне саклап калды.

Икенче көнне безгә кием-салымыбызны салып сафка басарга куштылар. «Коммунистларга һәм еврейләргә алга чыгарга!» дигән команда яңгырады. Бераз көткәннән соң немецләр кешеләрне, еврей һәм мөселман кыяфәтенә карап, үзләре аерып чыгара башладылар. Мин шулар арасында булдым. Кыяфәтем татар түгел бит минем: зәңгәр күзле, сары чәчле. Мине бит еврейгә чутладылар, аталар бит хәзер! — дигән уй йөрәгемне кисте. Нишләргә?! Үрсәләнеп эсэсчыга эндәштем: «Гер офицер! Мин еврей түгел бит, мөселман бит мин!» — дидем. Башын чак кенә бора төшеп, русчалатып: «Чем докажешь?» — диде бу. «Догалар беләм мин, менә, Коръәнем дә бар». «Йә, укып күрсәт!» Мин бала чактан ук ятланган сүрәләрне тезә башладым. Немес мина кире сафка басарга кушты.

Соңрак, Варшава, Берлин, Лион төрмәләрендә дә Коръән мине ничәмә-ничә тапкыр коткарды. Еш кына надзирательләр камераларга басып кереп, дорфа-тупас рәвештә тенти башлыйлар. Кесәмнән иман китабы килеп чыккач, гаҗәпләнеп: «Вас ист дас?» дип сорап куялар. Мин тыныч кына, бу талисманым минем «религиозиш бух Коран», — дип җавап бирәм. «Ду религиозиш ман?» — дигән сорауларына уңай җавап биргәч, кайберләре ашарга биргәндә йә берәр бәрәңге, йә берәр кашык апара да артыграк өстиләр иде.

Төрмәләрдә тәртип бозучыларны каты җәзага тарталар иде. Коръәнем мине еш кына андый җәзалардан да коткарды.

1943 ел ахырында мин Берлиндагы Тегель төрмәсендә Архангельски ягыннан чыккан Михаил Иванович Иконников белән таныштым. Ул Власов армиясендә яшәп килгән яшерен оешмада тора иде, оешманың максаты — Власов армиясен таркату. Кулга алынганга хәтле Муса Җәлил дә Бушманов, Рыбальченколар аркылы шушы яшерен оешма белән бәйләнештә була.

Тегельдә Михаил Иванович башка җәлилчеләр белән дә элемтәдә иде. Ул рус халкының иң гүзәл вәкилләреннән берсе, чын гуманист һәм интернационалист, зур эрудицияле кеше иде. Аның янында үземне рәхәт һәм иркен хис итәсең, чөнки ул хәленнән килгәнчә ярдәм итә, күнелне күтәрә. Сугыш беткәннән соң да очраштык без аның белән. Язмышы фаҗигале булды — Сталин режимы чорында күп кимсетелүләр, рәнҗетелүләр кичерергә туры килде. Истәлекләренең берсендә ул болай дип яза: «43нче елның ахырында мин бер төркем татар подпольщикларын очраттым. Болар — Курмашев дигән укытучы, Хәсәнов, Батталов, Солтанбәков һәм Хисаметдиновлар. Рушад Хисаметдиновны якыннанрак белә идем, аның белән капитан А.Р.Русанов та таныш иде. Рәшәткә аркылы сөйләшкәннәрен күргәләдем. Төрмә коридорларында да очрашкалаган булды. Сын-сыйфатлы, басынкы, елмаючан, нур чәчеп тора торган зәңгәр күзле Рушад яхшы тәэсир калдыра иде. Чик сакчыларына хас зур сабырлык, тотнаклылык сизелә иде анарда. Конспирация саклап, ул яшерен оешма эшләре хакында сөйләми иде. Соңрак, Рушадны алып киткәч, мин Гайнан Курмашев белән еш очраша идем. Курмашев Рушад турында, якын дусты һәм көрәштәше дип, бик җылы фикердә иде. «Офицер-пограничник ул, аны шагыйребез Муса хөрмәт итә һәм кадерен белә иде, — дип сөйләде Гайнан. — Без аны хәвеф-хәтәрдән сакларга омтылдык. Лагерьга эләгеп, кача алса, бәлки безнең өчен үч алыр». (М.Иконниковның житмеш яшенә Хисаметдиновка бүләк иткән хатирәләр альбомыннан).

Лион төрмәсеннән этап белән күчергәндә француз макилары янына качып китеп, миңа чыннан да, корал тотып, һәлак булган дусларым өчен үч алырга туры килде.

Инде 1942 елга әйләнеп кайтыйк. Янки лагереннан безне Демблин крепостенә күчерделәр. Башта лагерь кухнясында ярдәмче эшче булып йөргән Гайнан Курмаш белән таныштым.

Бермәлне ул бездән якында гына басып торган бер кешене күрсәтте. «Бу — танылган шагыйрь Муса Жәлил» — дип пышылдады. Мин таныштыруын үтендем. Һәм без Мусага таба юнәлдек. Гайнан үзе шагыйрь белән сугышка чаклы ук таныш булган. Күрештек. Кулымны кысып, Муса: Мин — Гомәров, диде. Моңа гаҗәпләнмәдем, чөнки фашистларның коммунистлар белән ничек эш иткәнен белә идем. Мусаның кыяфәте кызганыч иде: коры сөяккә калган гәүдәсендә иске солдат шинеле капчык кебек салынып тора, йөзе шешенгән, күз кабаклары салынып төшкән. Әмма аның карашыннан көчле холыклы кеше булуы, әле күңелендә игелеклелек, кешегә ышану сыйфатлары сүнмәгәнлеге сизелеп тора. Аның һәр сүзе әңгәмәдәше күңелендә теләктәшлек таба. Ул миннән кайсы яктан булуымны, әсирлеккә ничек эләгүемне, безнең гаскәрләрнең хәзер кай тирәдә булуын һ.б. сорашты. Гомеремдә миңа күп төрле кешеләр белән очрашырга туры килде, әмма алар арасында мондый да мөлаем, ягымлы, бу хәтле дә белемле, саф, матур татар әдәби телен бу кадәр дә камил белүче очраганы юк иде. Шул вакыттан башлап аның белән очрашмый калган көнем булмады. Җәлил яныннан кеше гел өзелеп тормый, төрле милләттән булган әсирләр аны тыңларга, аның белән киңәшергә дип киләләр. Ул укыган шигырьләр кешенең яшәүгә өметен уята, җиңүебезгә ышанычын көчәйтә иде.

1942 елны Мусаны Берлин янындагы кайсыдыр лагерьга җибәрделәр. Кызыл Армиянең беренче уңышлары, фашистларның фронтларда җанлы көчләрен күпләп югалтулары аларны хәрби әсирләрне юк итәргә дигән планнарын үзгәртергә мәҗбүр итте. Һәм алар хәрби әсирләрдән төрле милли формированиеләр оештыра башладылар. Кешеләрне үз илләренә каршы корал күтәрергә котырту өчен советларга каршы пропаганда көчәйтелде. Сатлыкҗан ак эмигрантлар җитәкчелегендә милли «дәүләт» булдыру күздә тотыла. Милли кыяфәтләре буенча сайлап алгач, хәрби әсирләрне, үз туганнарына каршы сугыштырыр өчен, әйбәтләп туендыра, ныклап коралландыра башладылар.

Әсирләрне идеологик яктан эшкәртү эшенә алар арасында абруе булган кешеләрне күндерергә кирәк иде. Муса Җәлил һәм аның иң якын иптәшләре — Әхмәт Симаев, Абдулла Алиш һәм башкалар — гитлерчыларның бу мәкерле ниятенә үз планнарын каршы куймакчы булалар. Алар менә шул «Идел-Урал» дигән марионет «дәүләт» эчендә (аның составына Идел һәм Урал буендагы автономияле республикалар территорияләре керергә тиеш була) — бик киң тармаклы һәм бик нык конспирацияләнгән оешма төземәкчеләр. Максатлары — инде оешкан дүрт батальонны таркатып, аларның Ватанга каршы күтәрелү мөмкинлеген юкка чыгарырга. Һәм бу план уңышлы рәвештә тормышка ашырыла! Әсирлеккә төшкән башка кайбер күренекле гаскәр башлыклары (мәсәлән, генерал-лейтенант Карбышев) үлемне өстен күрәләр.

Фашистлар алдында ышаныч казанып, подпольщиклар бик кирәкле пропаганда чарасын — «Идел-Урал» газетасын баса торган типографияне кулга төшерәләр, яшерен рәвештә листовкалар басар өчен ротаторлардан һәм язу машинкаларыннан файдаланалар. Легионерларны, коралларын фашистларның үз өстенә юнәлттерер өчен, восстаниегә әзерлиләр.

Листовкалар Идел буе халыклары өчен төрле телләрдә басыла һәм аларга «Звезда» дип тә, «Патриот», «Четвертый комитет» дип тә кул куела.

Муса Җәлил дошман тылындагы башка яшерен оешмалар белән дә (мәсәлән, власовчылар армиясе эчендәге РОА оешмасы белән) элемтә урнаштыра. Болар да ошбу армияне таркату белән шөгыльләнде. Араларында Бушманов, Рыбальченко, М.Иконников аеруча актив булды. Михаил Иванович Иконниковның татар халкы алдындагы казанышын аерым әйтеп үтәргә кирәк. Җәлилчеләр белән төрмәдә якыннан аралашуы аркасында Җәлилнен өченче шигырь дәфтәре Иконников кулына килеп кергән була һәм ул дәфтәрне СССРга алып кайта. Дәфтәрне КГБнын фильтрлау лагеренда Иконниковтан алып, кире кайтармыйлар, һәм ул шунда юкка чыга.

1943 елның башында мине һәм күп кенә башка татарларны һәм башкортларны Ротвайль дигән лагерьдан этап белән Идел-Урал легионы оештырыла торган җиргә — Едлино станциясенә күчерделәр. Монда мине авыру атларны карарга дип эшче командага билгеләделәр.


*Уңнан өченче – М.Иконников, дүртенче – Р.Хисаметдинов.*

Бер мәлне каяндыр колагыма татар көе ишетелгәндәй булды. Күнелемә якын моң килгән якка таба юнәлдем. Баракларның берсендә нимес униформасы кигән берничә татар әсирен күреп алдым. Без таныштык. Егетләр артистлар булып чыкты. Кәрим Ходжаев — скрипкә, Нәҗип Гәрәев — аккордеон, Гариф Мәликов гитара уйный һәм җырлый да икән; Зариф Солтанов бубенчы, Шәехнур Хәмиев ике рәтле гармун уйный, Сабитов — биюче, аны кызлар ролен уйнарга да файдаланалар икән. Ибраһимов дигәннәре — гитарачы, Җәүдәт Шамбазов дигәне рәссам булып чыкты. Хәзер инде бөтен буш вакытымны шушы музыкантлар янында үткәрә башладым, үзем дә бала чактан ук мандолина уйнарга ярата идем.

Бер көнне безнең музыкантлар янына нимесләрнең һәм марионет «президент» Шәфи Алмасның ышанычын казанган Гариф Солтанов дигән кеше килде. Ул бездән, музыка кораллары кирәкмиме, башка ни дә булса кирәкмиме дип сорашты. Без бертавыштан профессиональ артистларыбыз, музыкантларыбыз юк, дидек. Солтанов әйтүенчә, Муса Гомәров Демблин крепостендә мондый кешеләр бар дигән икән. «Берәрегез белмиме шуларны?» — дип сорады Солтанов. Җәлилнең кем хакында әйткәнен чамалап, мин ул артистларны беләм, дидем. «Алай булгач, иртәгә үк шуларны алырга барырбыз», — диде Солтанов.

Икенче көнне Галимов белән мине Солтанов белән конвойчылар Демблинга алып бардылар. Кирәкле кешеләрне табар өчен мине лагерьга керттеләр. Мин шундук кухняга юнәлдем — дустым Гайнан Курмашев шунда булырга тиеш иде. Аның белән киңәшеп, без барлык танышларыбызны — ышанычлы һәм илебезгә тугрылыклы кешеләрне үзебез белән алырга булдык. Гайнан Мусаның Демблин крепосте турында юкка гына әйтмәгәнлеген аңлап алды: музыкаль капеллага ул тугрылыклы иптәшләрне җыярга өметләнгән. Соңыннан без фикеребезнең дөреслеккә чыгуына инандык. Үзебез белән без унөч кеше ала алдык. Болар: Абдулла Баттал (мәшһүр татар шагыйре Салих Батталның бертуганы), без аны шагыйрь

дип таныттык, ул яттан бик күп шигырьләр белә иде; Гайнанның якын дусты — Зиннәт Хәсәнов; җырлый белмәсә дә, без аны хор солисты буларак тәкъдим иттек. Мин үзем дә Зиннәткә тыйнаклыгы, туры сүзле, тәвәккәл булганы өчен зур хөрмәт белән карый идем. «Юкка мине үзегез белән аласыз, берәр фашистны гарипләндереп ташлармын да, шуның өчен үзегезгә җавап бирергә туры килер», — диде ул. Мин: «Вакыты җиткәч, фашистларга бурычлы булып калмабыз», — дип тынычландырдым үзен; Гарәф Фәхретдиновны Казан филармониясе солисты дип тәкъдим иттек, гәрчә ул бервакытта да Казанда булмаган һәм консерваториядә дә укымаган (күп тапкырлар качарга омтылып, тотылган чакларында ул надзирательләр тарафыннан рәхимсез рәвештә кыйналган; Дим Алиш дигән тәхәллүс йөрткән). Аның борынгы татар җырларын гаҗәп дәрәҗәдә моңлы тавыш белән җырлавын татар, башкорт әсирләре бик яраталар иде. Муса аңа карата аталарча мөнәсәбәттә булып, татар җырларын өйрәтергә омтыла иде. Тора-бара Гарәф музыкаль капеллада төп солистлардан берсе булып, бик оста биюче дә, Муса Җәлил һәм Гайнан Курмаш язган пьесаларда төп рольләрне башкаручы да булып китте. Ул подпольщикларның яшерен киңәшмәләре вакытында ишек төбендә сакта тора торган иде. Фуат Сәйфелмөлековны, җырлый белмәсә дә, хор артисты иттек. Бу безнең сәяси яктан яхшы чыныгу алган иптәшебез иде. Соңрак, яшерен оешмага пропагандистның кирәге чыккач, без Мусага бу эшкә Фуат белән Гали Корбановны (Мичуринны) алырга киңәш итмәкче булдык. Бу турыда белгәч, Фуат миңа болай диде: нимес формасыннан йөргәнне туган илдә белсәләр — асачаклар, ә инде пропагандист та булганны белсәләр — ...» Ахыр чиктә без аны үгетләп ризалаттык: дошман тылында көрәшеп йөргәнебезнең дөресен Ватаныбызда кайчан да булса беләчәкләр һәм тиешенчә бәяләячәкләр, дидек. Озак үгетләргә туры килмәде, мин аны шундук Мусага тәкъдим иттем. Легионерлар өчен лекцияләрне ничек итеп яхшырак оештырырга икәне турында киңәшелде, Мусадан күрсәтмәләр алынды. Тыңлаучылар аны ярты сүзеннән үк аңлый торган булдылар, совет гаскәрләренең якынлашуы турында мәгълүматлар белән кызыксыналар — болар төрле уен сүзләр, кинаяләр аша гына белдерелә иде. Гали Корбановны сатирик, юморист, артист дип күрсәттек. Белгечлеге буенча юрист булып, ул сугышка кадәр чик сакчылары гаскәрендә хезмәт иткән, сәяси яктан чыныккан ышанычлы, тугрылыклы иптәш иде. Ул да пропагандист булып китте, өстенә төшкән бурычны Муса Җәлил җитәкчелегендә оста башкара иде. Абдулла Батталның якын дусты Фәрит Солтанбәков, мандолиначы-музыкант булып, Гайнан Курмаш төркеменә кушылды.

Милләте буенча еврей, бик матур тенор тавышлы Борис Поповка без исем-фамилиясен татарчага үзгәртергә киңәш иттек, һәм ул Бари Кәримов булып китте. Аны татар җырлары җырларга өйрәттеләр, һәм ул аларны зур осталык белән башкара иде. Ышанычлы, тыйнак башкорт егете Салават Юлаев курайчы иде. Башкаларның фамилияләрен хәзер хәтерләмим дә инде.

Едлинога килгәннәрнең барысын да эшче рота составындагы музыкаль капеллага керттеләр. Мин инде ат абзарында атларны карау эшемне дәвам иттердем. Легионерларны нимес формасына киендереп, совет гаскәрләренә һәм француз партизаннарына каршы фронтка җибәрер өчен шәпләп ашатып-эчертергә тотындылар.

Шул көннәрдә мин качарга дигән нияткә килдем, мунча караучы поляк белән килештек: ул миңа поляк партизаннарына чыгу юлын өйрәтергә вәгъдә итте. Ялгызың гына качу бик унайлы түгел, мин үземә иптәш табарга булдым. Иң ышанычлы иптәшләрдән берсе булган Гайнанны сайладым. Аны үземнең планым белән таныштырдым. «Башта ныгып алыйк әле, Рушад абый, аннары күз күрер», — диде Гайнан.

Ул арада Муса Җәлил Миттелштильгә, Шәфи Алмасның «Идел-Урал» дигән

марионет хөкүмәте резиденциясенә күчерелгән иде. Элекке купец Шәфи Алмас — Оренбурдан чыккан ак эмигрант. Уртача буйлы, какча гәүдәле бу кеше холкы белән дуамал, тиз кызып китүчән иде.

Лагерьда Муса гел Шәфи Алмас белән йөри иде, күрәсең, немецләр ана әллә ни ышаныч белдермиләрдер. Башта мина Муса фашистлар яклыдыр сыман тоелган иде. Качарга ниятләвебез турында Гайнан Мусага сөйләде. «Мондый ачык лагерьдан һәркем кача ала, — дип, Муса бу фикерне куәтләмәде. — Партизаннар ягына бөтен легионны алып чыгарга кирәк», — диде ул. Муса безгә капелланы житәкләргә: мина — житәкчесе, Гайнанга режиссер, сәнгать житәкчесе булырга тәкъдим итте. Шуннан сон минем Мусага карата булган бөтен шикләрем бетте.

Озакламый безнең музыка командасын Берлинга экскурсиягә алып киттеләр. Монын да оештыручысы Жәлил булып чыкты. Башта безне бөтен дөньянын иң бай хайваннар коллекциясе жыелган мәшһүр Берлин зоопаркына илттеләр. Ерткычлар монда әсирләргә караганда яхшырак шартларда яшиләр иде. Паркны караганда без Гайнан белән зур гына маймыл вольеры янында туктадык. Безнең арттан Муса Жәлил килеп туктады. «Маймылларны каравыгызны дәвам иттерегез, — диде ул әкрен генә, — үзегез мине тынлагыз. — Мин сезгә ышанам, фашистларга каршы бергә көрәшик, легионны таркатыйк», — диде ул. Үзе, сиздермичә генә, тирә-юнен күзәтә-күзәтә безнекеләрнең һөҗүме хакында сөйли. «Монда, дошманнын тылында, безгә көрәшне көчәйтергә, монын өчен яшерен оешманын аерым төркемнәрен оештырырга кирәк.» Сонгы сулышыбызга кадәр көрәшербез, дип, оешманын барлык заданиеләрен үтәрбез, дип, Гайнан белән без Мусага ант иттек. Шунда ул безне яшерен оешма әгъзалары дип игълан итте, һәм шундук яхшы конспирацияләнгән төркемнәрне ничек оештырырга икәнен өйрәтте. Төркемнәр өч-дүрт кенә кешедән торырга тиеш, төркемдәге кеше житәкчедән башка беркемне дә белмәсен, хыянәтче була калса, ул житәкчедән башка берәүне дә сата алмаска тиеш. Хәрби әсирләр арасында листовкаларны ничек таратырга икәнен дә анлатты. Листовкаларны кулдан кулга гына, иң ышанычлы иптәшләргә, якташларга гына бирергә кирәк. Муса безгә ике пачка листовка бирде, без аны ышанычлы урыннарга яшердек. Экскурсиядән сон Еллинога әйләнеп кайттык.

Капеллада эш жанланып китте. Гомуми эшебезгә турылыклы булган иптәшләребез чыгышларга әзерләнә башлады. Жырлардан, биюләрдән кала Жәлил белән Курмашев язган инсценировкаларны, пьесаларны куйдык. Концертлар кую хәйләсе белән без Польшанын, Германиянен легионерлар булган шәһәрләренә чыгабыз. Концерт программаларын, репертуарларны эшләгән Муса Жәлил кайчакларда үзе дә безнең белән чыга. Без легионнарнын частьләрендә, эшче батальоннарында, фабрика-заводларда да чыгышлар ясыйбыз. Безнең бу чыгып йөрүләребезне Муса башка яшерен оешмалар белән элемтә урнаштыру өчен һәм көрәшкә өнди торган листовкалар тарату өчен дә файдалана иде.

Капелланын репертуары Салих Сәйдәшевнең, Заһид Хәбибуллиннын Муса Жәлил сүзләренә жырлана торган күп кенә жырларыннан, шагыйрьләрнен халык көйләренә жырлана торган жырларыннан, бик күп халык жырлары һәм популяр совет жырларыннан гыйбарәт иде. Хәзер дә исемдә әле — бу жырлар һәм шигырьләр күнелебездә жинүгә һәм озакламый илебезгә кайтуга булган ышанычны көчәйтәләр иде.

Жәлилчеләр тарафыннан сайлап алынган көрәш тактикасы тулысы белән үзен аклады. Көрәшкә өнди торган листовкалар, туган якнын гүзәллеген тасвирлый торган жырлар, пропагандистлар эше — барысы бергә үз гамәлен кылды. Легиондагы дүрт батальоннын берсе дә үзебезнең гаскәрләргә һәм партизаннарыбызга каршы

корал күтәрмәде. Автоматлар, танклар һәм артиллерия белән коралланган беренче (825нче) батальон немесләр тарафыннан оккупацияләнгән Белоруссия җирендәге партизаннарга барып кушылды. Бу хәрәкәтне Мөхәммәдов дигән кешебез җитәкләде. Немес фашистларының җәза частьлары белән авыр сугыш алып баручы украин партизаннарына каршы җибәрелгән батальон да партизаннар ягына чыкты. Партизаннарга Золотаренко командалык итте. Ышанычсыз дип саналган дүртенче батальонны немесләр Франциягә, Ле-Пюи шәһәренә озаттылар. Легионерлар, капитан Сегель командалыгындагы партизаннар дивизионы белән элемтәгә кереп, французлар ягына чыктылар (штаб башлыгы — подполковник Жевольд-Запальский). Бу гамәлдә Г.Фәхретдинов, А.Утәшев, Г.Мәликов, Г.Садыйков, Ш.Хәмиев һәм башкалар актив роль уйный. Кызганычка каршы, кайберләренең фамилияләре инде онытылган. Шулай да күбесенең исем-фамилиясен А.Утәшев, Г.Фәхретдинов, М.Хөсәеновләр хәтерлидер әле. Сугыш кырларында геройларча башларын салган, Сталин лагерьларында җәзалап үтерелгән, ачлыктан-ялангачлыктан юкка чыгарылган кешеләрнең исемнәрен ачыклап, Идел буе халыклары тарихында аларга тиешле урыннарын бирергә иде. Бу мәсьәләдә минем җәлилче-эзтабарлар Рафаэль Мостафинга һәм Исхак Зәбировка өметем зур. Алар бит әсирлектә калып та дошман тылында көрәш алып барган кешеләрне җентекләп эзләп, патриотларның исемнәрен дөньяга кайтаралар.

Әсирлектә булган һәр кешене Берия-Абакумов өере озак срокка Себер, Ерак Көнчыгыш һәм Ерак Төньяк лагерьларына озатты.

Ахры, әкренләп гаделлек кайтарыла башлады бугай: союздаш республикаларда хөкем ителгән әсирләрнең эшләрен янадан карау башланды. Безнең автономияле республикада гына бу процесс күзәтелми. Р.Мостафинга һәм башка җәлилчеләргә «Идел-Урал» легионының дүрт батальоныннан бер генәсе дә, аерым бер мөртәтләрне исәпләмәгәндә, Ватаныбызга каршы сугышмаганлыгы тәгаен мәгълүм. Татарлар, башкортлар да, марилар, чуашлар да, удмуртлар, мордвалар да тугрылыклы уллары белән горурлана ала. Хәлбуки Татарстанның тикшерү органнары яшерен оешмаларның ролен һәртөрле юллар белән түбәнәйтеп күрсәтергә тырышалар. Белоруссия, Украина һәм Франция җирләрендә хәрәкәт иткән партизан отрядларында сугышкан кешеләр, документлары, бүләкләре, шаһитларының таныклаулары булуга да карамастан, хәзер дә акланмаган. Хәтта фашистлар иң югары җәза чарасын кулланып, башлары гильотинада чабылган кешеләр дә акланмаган. Мин҅а хәзер дә Берия һәм Абакумовлар калдыклары каядыр посып ятып, гаделлекнең тантана итүенә карышалар кебек тоела.

Уллары Гражданнар сугышында һәм Бөек Ватан сугышы фронтларында куркусыз рәвештә сугышкан татар милләтеннән булуым белән горурланам.

Бер мәлне Муса миннән, «Капеллачылар арасында рәсем ясый белүчеләр бармы?» — дип сорады. «Гримерыбыз Җәүдәт Шамбазов рәсем ясый, — дидем: — Гармунчы Шәехнур Хәмиев тә ару гына ясый». «Әйт әле шуларга: кое буена көянтә-чиләк белән суга килгән татар кызын ясасыннар, өстендә милли кием булсын. Кызый ямансулап Көнбатышка таба карап тора. Рәсемнең астына «Мин көтәм сине!» дип язып куйсыннар», — диде Муса. Мусаның сөйләгәнен мин әлләни әһәмият бирмичә генә тыңладым. Әмма дә рәсем ясалып, легионерлар була торган күренекле урынга элеп куелгач, кешеләрнең рәсемгә ничек итеп караганын күреп шаккаттым. Рәсем янына кеше җыелды. Кайберәүләр сиздермичә генә күз яшен сөртә. Рәсемнең астына «Мин көтәм сине!» дип язылган. Шунда гына Муса ясаткан рәсемнең хикмәтен аңладым — ул сәнгатьнең бөек көченнән файдаланмакчы булган! Үземнең дә шул чакта өебез күз алдыма килде, туган яклар, әни, сеңелләрем, сөеклем... Күңелемдә безне шулардан аерган фашистларга карата нәфрәт өр-яңадан кайнап чыкты.

Августның 8нче, 9нчы числоларында яшерен киңәшмә булды, анда Г.Курмашев, Ф.Сәйфелмөлеков, Г.Корбанов һәм мин катнаштык. Киңәшмәне Муса Җәлил үзе үткәрде. Барак ишегендә сакта Г.Фәхретдинов торды. Польша партизаннары белән элемтә урнаштырылуы турында хәбәр итте Муса. Легионда восстаниегә әзерләнеп, бөтен личный составны коралы-ние һәм атлы артиллериясе белән бергә Польша партизаннарына илтеп кушар вакыт житте. Барысы да конкрет задание алды: кемдер тимер чыбыкны кисеп, элемтәне өзәргә; кемдер немец сакчыларын үтереп, корал һәм азык-төлек складларын, атлары-ние белән артиллерияне кулга төшерергә тиеш. Восстание 1943 елның 14 августына билгеләнде. Киңәшмә икенче көнне дә дәвам итте, бер сәгатьләп кенә барды, легионерлар да, музыкантлар да бaрактан тыш эшләр белән мәшгуль чакта гына. Нәкъ менә шушы көннәрдә А.Баттал белән З.Хәсәнов «Идел-Урал» газитләре белән бергә Берлиннан листовкалар да алып кайттылар. Аларны музкапелла барагында матраслар, мендәрләр эченә яшерделәр.

10 августта Муса Җәлил кинәт кенә лагерьдан юкка чыкты. 11 августта безнең барыбызга да — артистларга да, музыкантларга да — солдатен хайльгә (ашханәгә) керергә боердылар. Безнең баракны җентекләп тентегән булулары һәм соңгы кайтарылган листовкаларны тапкан булулары ачыкланды. Барыбызны бер бүлмәгә кертеп тутырдылар да, бик дорфа кычкырып берәм-берәм чакыра башладылар. Һәрберебезне озаклап тентеделәр. Беренче итеп Гайнанны, аннары мине, А.Батталовны, З.Хәсәновны, Әмировны, тагын берничә кешене чакырдылар, һәрберебезне аерым бүлмәгә япканлыктан, барысының да фамилиясен ишетеп бетермәдем. Урын-җирендә листовка табылганнарның барысы да кулга алынды. Бер кат сорау алгач (һәрберебездән аерым-аерым), безне Варшава төрмәсенә алып киттеләр. Барлыгы кырыктан артык кеше кулга алынган иде. Шушы төрмә тоткыннарының әйтүенә караганда, 10 августта монда Муса Җәлил китерелгән. Барысының күз алдында төрмә капкасы төбендә аны аяклары белән типкәли-типкәли ерткычларча кыйнаганнар. Аннары Берлинга, Моабит төрмәсенә алып киткәннәр.

Варшава төрмәсендә без сорау алуларны, каты җәзаларны, кыйнала-кыйнала очная ставкаларны үтеп, камераларга аерым-аерым утыртылдык. Мин һичнинди гаепләүләрне танымадым, һаман бер сүзне тәкърарладым: бернинди листовка күргәнем юк, гаебем шунда: мин лагерьдан качарга җыендым. Мин гади рядовой солдат, сибиряк, ветеринар, дидем, фронтка да ветеринар буларак җибәрелдем, әсирлеккә дә яраланган, контузияләнгән хәлдә төштем, дидем. Тикшерү эшен табигате белән интеллигентка охшаган Ханс дигән обер-лейтенант алып бара иде. Мин аны табигать законнары буенча тозакка эләккән ерткыч җанвар да үз оясы булган җиргә китәргә омтыла дигән фикергә күндерергә тырыштым. Мин дә качу турында хыялландым. Шуның өчен мине хөкем итәргә, атарга мөмкин. Гомеремдә мин гадел яшәдем һәм үлгәндә дә гадел үлем белән үләсем килә. Листовкалар турында берни белмим, бернинди сәяси оешма турында ишеткәнем дә булмады, дидем. Карт чекист-чик сакчысы буларак, сорау алулар вакытында үзенне ничек тотарга икәнен белә идем. Сорау алулар вакытында әлеге тикшерүченең миңа карата мөнәсәбәте үзгәргәннән-үзгәрә барды. Мин, үземне артистларча беркатлы, гаепсез кеше итеп күрсәтергә тырышып, һаман бер сүзне кабатладым. Кулга алынган иптәшләрем мине фаш итмәделәр, тентү вакытында урын-җиремнән листовкалар чыкмады, чөнки мин аларны бaрактан читтә яшергән идем.

Кулга алынган легионерларның күбесен Варшава төрмәсеннән каядыр җибәрделәр. Концлагерьга олактырганнар дигән сүз чыкты.

1943 елның сентябрь ахырында безне — Г.Курмашевны, А.Баттал, З.Хәсәнов, Ф.Солтанбәковны һәм мине төрмә вагонына утыртып, Берлинга алып киттеләр.

Юлда мин Абдулла янәшәсендә туры килдем. Конвоирларның үзара сөйләшеп утыруларыннан файдаланып, мин әкрен генә: «Кем сатты икән безне?» дип сорадым. Баттал хыянәтче турында шигырь язуын әйтте һәм пышылдап кына шигырьне миңа сөйләде. Анда мондый юллар бар иде: «...Их, Җамалетдин! Син перчаткәнне канга батырдың. Ал ул кулларыңны — син кәтәнәгә, безнең күкрәгебезгә буең җитәрлек түгел![1]» Сугыштан соң, Татарстан язучылары һәм журналистлары белән 1958 елны беренче тапкыр очрашканда сөйләгән идем бу турыда. Шунда Абдулланың абыйсы Салих Баттал минем сүземне бүлде. Ул үзенең бу шигырьне 1929 елда СССРның иң зәһәр дошманы Чемберленга каршы язган булуы турында әйтте һәм «Хәзер минем өчен Хисаметдиновның чыннан да минем энем белән бергә булуы ачыкланды», — диде ул.

Шулай итеп, безне Берлинга — башта Моабитка, ләкин анда урын булмау сәбәпледер инде, Вайдельштрассе, 39дагы мәгълүм Тегель төрмәсенә урнаштырдылар. Төрле камераларда һәм төрле этажларда булдык. Ашау начар, көн саен бер үк нәрсә — өч-дүрт бәрәңге дә азык-төлек калдыгыннан пешерелгән апара бирәләр, кайвакыт парланган шпинат белән ниндидер үләннәрдән пешерелгән ботка ашыйбыз. Прогулкага эчкәрге ишек алдына алып чыгалар, сирәк-мирәк сорау алырга алып баралар.

Ул чакта Берлинны союзникларның авыр бомбардировщиклары көн саен бомбага тотты. Бомбежкалар вакытында надзирательләр шүрләп бомбоубежищеларга качалар, ә без, әсирләр, алар югыннан файдаланып, башка камералардагы тоткыннар белән сөйләшә башлыйбыз. Төрмәдә гадәттән тыш гауга күтәрелә — кешеләр төрле телләрдә — инглизчә дә, немесчә, русча, татарча да һәм башка бик күп телләрдә кычкырыша башлыйлар. Һәркем үз иптәше, үз якташы белән хәбәрләшергә тырыша. Көннәрдән бер көнне мин аермачык үзебезнең «Синенький скромный платочек» дигән җырны җырлаганнарын ишеттем. Аста, беренче катта кемдер русча җырлый иде. Куплетын җырлап бетергәч, ул туктады. Мин җырны дәвам иттердем. Мин туктагач, астан «Кем җырлый?» дип кычкырдылар. «Мин бу, Алма-Атыдан Рушад Хисаметдинов», — дип кычкырдым да, тегеннән үзен әйтүен сорадым. Бу — Александр Русанов дигән кеше булып чыкты. Шул көннән башлап без бомбежкалар вакытында сөйләшә торган булып киттек. Мин аның Дәүләт иминлеге капитаны икәнен, Украина партизаннар хәрәкәте штабы башлыгы генерал-полковник Строкачның шәхси адъютанты икәнен һәм дә үлемгә хөкем ителгән булуын белдем. Аның гаиләсе-хатыны, кызы, хатынының анасы — хәзерге вакытта Черемисиново станциясендә яши икән. Партизаннарның карательләр белән барган сугышы вакытында ул әсир төшкән. Якты чырай күрсәткән атлы булып, гестапоның аннан партизаннар хәрәкәте турында яшерен мәгълүматлар алырга тырышуын да белдем.

Бервакыт минем камерага надзор буенча прокурор керде һәм, кирәксенгән нәрсәң юкмы, дип сорады. Мин русча гәзит булса яхшы булыр иде, дидем. Блокнотына нидер язды да чыгып китте. Берничә көннән миңа гәзит бирделәр. Исемен хәтерләмим инде, «Русское слово»мы, «Новое слово»мы. Гәзитнең беренче битенә зур итеп Русановның портреты урнаштырылган һәм эре хәрефләр белән: «Госбезопасность капитаны Александр Дмитриевич Русанов биргән мәгълүматлар» дип язылган. Гәзитнең битен тутырып безнең дәүләтебез өстенә, җитәкчеләре, Политбюросы өстенә кара ялган язылган. Әлбәттә, болар барысы да махсус уйлап чыгарылган нәрсәләр иде.

Чираттагы һава тревогасы вакытында үзебезнең позывнойлар ярдәмендә мин Русанов белән элемтәгә кердем. «Нәрсә, Рушад, нинди яналыклар бар?» — диде ул. «Минем алдымда русча гәзит, шунда синең фоторәсемең», дидем. «Нәрсә

[1] Бу юллар мәкаләгә русчадан тәрҗемәдә кергән. Ред.

язалар?» «Син үзебезнең хөкүмәтне гаеплисең, Политбюроны һәм башкаларны, алар өстенә пычрак атасың». «Син шуна ышанасыңмы?» — дип кычкырды ул. Һәм мин шунда, уйлап та тормыйча: «Белмим», — дип кычкырдым. Һәм шул «белмим»ем өчен җәза алдым — минем белән сөйләшергә теләмичә, Русанов айдан артык позывнойларыма җавап бирмәде. Уйланылмаган җавабым өчен миңа бик тә оят булды һәм дошман кулланган чараларны аңламый торган нинди чик сакчысы инде син, дип, үземне битәрләдем. Үзе кебек тоткыннан шикле җавап ишетү аңа ничек авыр булганын күз алдыма китерәм. Мин элемтәбезне урнаштырырга, аннан гафу үтенергә омтылдым. Һәм, менә бәхет! — «Капитан Грант балалары» фильмындагы җыр исемә төште: чираттагы очрашырга маташу вакытында «Капитан, капитан, улыбнитесь!..» дип җырлап җибәрдем. Һәм шундук аның: «Нәрсә, Рушад, ямансумыни?» дигәнен ишетеп алдым. Мин гафу үтендем. Ул элеккечә, дусларча сөйләште, безнекеләрнең көнбатышка хәрәкәтендә күп яңалыклар булуын әйтте, безнең татарларның барысының да бергә, бер камерада утыруларын, димәк, араларында провокатор бар дигән сүз икәнен, ничек тә аларны кисәтергә кирәклеген әйтте. Аннары Тегель төрмәсендә Германия компартиясенең генераль секретаре Эрнст Тельман утырганын һәм тагын бик күп нәрсәләрне әйтте.

Русановның язмышы болай булды. Озак вакытлар маташып та телен ачтыра алмагач, аңа карата иң авыр, адәм чыдый алмаслык иң шәфкатьсез җәзаларны куллана башлыйлар. Дөньядан китәргә карар кылып, Русанов веналарын кисә. Надзирательләр, моны күреп, перевязка ясыйлар. Әмма төнлә Русанов повязкаларын алып ыргыта. Аны Заксенхаузенга күчергәннәр иде, бу хәл шунда булган. Ләкин дөнья белән хушлашканчы Русанов төрмә ишегалдындагы чүп өеменә кечкенә тимер тартмасын күмеп калдыра. Тартма эченә кечкенә блокнот салынган була. Сугыштан соң күп еллар үткәч, блокнот безнең солдатлар кулына, аннары язучы Юрий Корольков кулына килеп керә. Ошта яшәп ятканда миңа аннан хат алырга туры килде. «20 ел үткәннән соң булса да, бер төрмәдә бергә утырган дустың турында хәбәр алу бик күңелле инде, — дип язган иде ул. — А.Д.Русанов блокнотында сезнең фамилиягезне һәм адресыгызны, хатыныгыз «Тоня»ның исемен, сеңлегез Дэлинын да исемен язган. Бергә Тегель дигән төрмәдә утыруыгызны язган. «Җәзалауларга чыдый алмадым, үләм, ләкин Ватаныма турылыклы калып үләм», — дип язган Русанов.

Тегельдә безнең Берлиннан китерелгән җәлилчеләр утыра иде. Бер көнне прогулкада йөргәндә миңа Җәлилнең үз кулы белән язылган «Төн. Төрмә» дигән шигыре очрады. Тоткыннар прокулкада йөргәндә бер-берсенә төрле-төрле язулар бирешәләр иде. Без чит телдә булганын ары җибәрә, русчаларын һәм татарчаларын — ала торган идек. Бу шигырьне мин онытмаслык итеп ятладым.

1944 ел башында Курмашевны, Батталны, Хәсәновны, Солтанбәковны һәм мине «Черный ворон»га төяп, тимер койма белән әйләндереп алынган бер бинага илттеләр. Берәм-берәм чакырып сорау алдылар да, кире Тегельгә кайтардылар. Язмышыбызга тәэсир итәрдәй, судка-мазарга охшаган берни дә булмады.

Озакламый, 1944 елның феврале иде бугай, мине төрмә капкасы төбенә алып чыктылар. Анда Солтанбәковны һәм тагын бер татарны күрдем, монысы Моабит тоткыны иде. Шәрипов иде бугай фамилиясе. Безне бергә тимер юл вагонына утырттылар да Франциягә озаттылар. Юлда, Германия җирендә чакта, Фәритне төшереп калдырдылар. Аннары аны нишләткәннәрдер, анысын белмим.

Безне Ле-Пюи дигән француз шәһәренә илттеләр, капеллабызның кулга алынмый калган өлеше шунда иде. Гарәф Фәхретдинов, Гариф Мәликов, Шәехнур Хәмиев һәм яшерен оешмадагы башка иптәшләр мине шатланып

каршы алдылар. Мин аякта басып тора алмас дәрәҗәдә хәлсезләнгән идем. Алар мине эшче команда больницасына урнаштырдылар. Көн саен диярлек ашарыма китереп тордылар, зинданда какшаган сәламәтлегемне һәм көчемне кайтарырга тырыштылар. Хәлем әзрәк рәтләнә башлагач та мин Гариф Мәликов аша француз партизаннары белән, дөресрәге, аларның командиры капитан Сегель һәм 18нче маки субдивизиясе штаб башлыгы подполковник Жевольд (Запальский) белән элемтә урнаштырдым. Элемтә Мишель дигән парикмахер аркылы урнаштырылды. Мин партизаннар штабыннан задание алдым. Французлар легиондагы нимес солдатларының һәм офицерларының саны, корал, боеприпас турында, легионерларның кәефе турында мәгълүмат сорадылар. Мәликов минем янга больницага килеп барысы турында да хәбәр итә торды. Дусларыбыз Хәмиев, Фәхретдинов, Корбанов аша без бу мәгълүматларны җыеп, партизаннар вәкиле аркылы макилар штабына тапшырабыз.

Легионерларның партизаннар ягына чыгуы да шул юл белән башкарылды. Корал һәм боеприпаслар белән төркемләп качу гамәле дә партизаннар штабы белән килешенгән иде. Мәсәлән, Әмир Утәшев белән Гарәф Фәхретдинов житәкчелегендәге зур төркем партизаннар ягына шул рәвешле чыкты. Бу иптәшләр отрядларга кереп, шундук нимес-фашист оккупантларына каршы сугыш операцияләрендә катнаша башладылар. Әмир Утәшев партизаннар арасында бик тиз зур абруй һәм ышаныч казанды, орденнар һәм кыйммәтле бүләкләр белән бүләкләнде. Гарәф Фәхретдинов, пулеметчы буларак дошманның бик күп солдатларын һәм офицерларын юк итте. Аңа шеф-сержант дигән звание бирелде. Ул да югары француз ордены белән бүләкләнде. Партизаннар хәрәкәт иткән районнардагы шәһәрләрдә һәм авылларда Дим Алишның (Г.Фәхретдиновның) башы өчен йөз мең марка вәгъдә иткән белдерүләр эленгән иде. Франциядә, Голландиядә һәм башка илләрдә сугышкан татар, башкорт егетләренең барысының да исемнәрен хәтерләмим инде. Аларның исемнәрен Утәшев, Фәхретдинов һәм башка иптәшләр аша ачыкларга мөмкин.

Минем дә иптәшләрем белән бергә китәсем килгән иде, ләкин алар, әле ныгып житмәгәнсең дип, ияртмәделәр. Беренче мөмкинлек булу белән килеп алмакчы иделәр. Хәлбуки эш алай барып чыкмады шул. Качып китүчеләр белән элемтәдә булуда шикләнеп, мине больницада ук кулга алдылар да Ле-Пюи шәһәр төрмәсенә яптылар. Аннары башка тоткыннар белән бергә мине мәшһүр Мон-Люк төрмәсенә күчерделәр. Төрмә кеше белән дыңгычлап тутырылган иде: бер кешелек кечкенә генә камераларга фашистлар 8-9ар кешене шыплап тутыралар иде. Безне, 60лап тоткынны, подвалдагы кечкенә генә бүлмә кебек нәрсәгә керттеләр. Монда юеш, һава житми, тынчу, суык сөяккә кадәр үтә. Фашистлар монда сорау алмыйлар.

Август ахырында безне, сиксән тоткынны, төрмә ишегалдына алып чыгып, парлап богаулдылар да сафка тезеп станциягә алып киттеләр. Товар вагонына төяп Германиягә, үлем лагерена озаттылар.

Макон һәм Шалон шәһәрләре арасындагы Тюрнус станциясендә тимер юл полотносын деголльчылар бомбага тотып җимергән булган. Безнең эшелон кинәт туктап калды. Конвой белән француз партизаннары арасында атыш башланып китте. Соңыннан ачыкланды: партизаннар үзләренең патриотларын коткармакчы булганнар икән. Конвой полотно буендагы кюветка төшеп ата башлады. Мин Татарстаннан Зиннур Гатин белән богауланган идем. Чик сакчысы буларак, мин кул богауларын ничек ачарга икәнен белә идем. Һәм вагонда чакта ук үземнең богауны ычкындырдым. Атыштан файдаланып, башка тоткыннар кебек үк без дә, вагоннан чыгып, төрле якка йөгерә башладык. Минем белән бергә туры килгән олы яшьтәге француз карты белән без виноград бакчасы аша үтә башладык һәм ашламалар тутырылган чокырга төшеп яшерендек. Озакламый атышулар туктады, партизаннар чигенде. Яхшы коралланган нимес

конвоирлары күбрәк иде. Атышлар туктады, кешеләрне аулый башлаулары ишетелде. «Хальт!» дип кычкырганнан соң аткан тавышлар, кычкырышкан, ыңгырашкан тавышлар ишетелде. Каядыр якында гына, башыбыз өстендә генә дөпелдәгән аяк тавышлары ишетелә. Чокыр буена икәү килеп туктаганын чамалыйм. «Рус!» дип акырган тавыш ишетелде. Карт француз бирелергә әзер, ахры. Минем котым очты һәм муенына басып мин аны җиргә сеңдердем. Немецләр ут ачты. Ярый әле без яткан яктан аталар. Каршы яктан атсалар, бу чокыр безгә кабер булачак иде. (Мина янадан — инде ничәнче тапкыр — бәхет елмайды! Әнкәй: «Унбер баланы гомерле иттем. Рушадым гына бәхет йөзлеге белән туды. Шушы улым бик бәхетле булыр!» — диярго ярата иде. Минем шул «йөзлекне» әнкәй бәләкәй тартмага салып саклый иде).

Юлны рәтләделәр. Паровоз озын итеп кычкыртты да, эшелон кузгалып китте. Нинди бәхет — без иректә! Күңел шатлана, йөрәк чыгардай булып сикерә. Француз карты кочагын җәеп мина ташланды. Караңгылана башлады. Иплап кенә чокырдан чыгабыз. Виноград бакчасын үткәч, бер француз агае очрап, безгә өеннән су чыгарып бирде һәм партизаннар янына барыр юлны өйрәтте.

Куаклар арасыннан каршыбызга: «Атас!» дип кычкырып, бер кеше килеп чыкты. Кулында — җиңел инглиз автоматы. Кулларыбызны күтәрдек. Юлдашым телгә килде. Мине «рус, камрад» дип атаганын ишетәм. Партизан, тынычланып, автоматын муенына элде дә, барыр юлны күрсәтте. Без тауга таба менә башладык. Кичкенә генә бер өйне күргәнче бардык. Анда партизаннар туктаган булып чыкты. Күрәсең, әле шул немецләр белән атышканнары, ахры. Араларында хатын-кызлар да бар. Барысы да коралды. Безгә галәмәт зур кружкаларга — ике литрлап бардыр, мөгаен — тутырып җиңел шәраб салдылар. Су эчкән сыман зур йотымлап эчәм. Тәмле дә соң аларның шәраблары. Бу эшнең сирәк осталары шул инде алар. Картым да калышмый миннән. Җиңелчә генә баш әйләнеп китте, күз кабаклары авырайды. Яткан җирдән мина кешеләрнең башлары аста, аяклары өстә сыман тоела. Хатын-кызларның юбкалары парашют сыман. Ник ачылмый микән ул? — дип гаҗәпләнәм мин. Беркадәр вакыттан соң безне йөк машинасына утырттылар. Бер часовой өстә, тагын берсе — кабинада. Мәһабәт Крузель таулары буйлап барабыз. Ул андагы матурлык! Серпантиндай булып юл өскә таба үрмәли. Машина көчкә генә, беренче тизлектә генә өскә таба күтәрелә. Әрҗәдәге часовой җырлый башлады. (Ул итальян булып чыкты). Тавышы матур. Шул рәвешле берничә сәгать үтүгә борынгы бер шату (замок) янына килеп туктыйбыз. Мөгаен, бу крепость монда урта гасыр рыцарьлары заманыннан бирле үк торадыр — турыдан-туры кыяга кырып ясалган бит. Капка төбендә — часовой. Безне де Голль гаскәрләренең бригада штабына китергәннәр икән. Без машинадан төшкәч, картка җикеренә башладылар, иненнән эләктереп алып, дорфа рәвештә этеп җибәрделәр. Минем хәлләр дә яхшыдан түгел. Нинди кешеләр соң болар, партизаннармы, әллә фашистлармы? Бина эченә алып керделәр. Картны бер ишектән, мине икенче ишектән төрткәләп кертеп җибәрделәр. Сорау алу башланды. Полякча сөйләшүче тәрҗемәче дә табылды: «Яшермәгез, сез бит немец шпионы, сезне бит безгә махсус җибәргәннәр!» — ди болар. «Ничек инде махсус? — дип аптырыйм мин. — Сез немецләрнең Германиягә менәрләгән французны куып китергәнен белмисезмени? Юлларны бомбага сезнең самолетлар тотмадымени?!» Минем белән озак сөйләшеп маташмадылар, тимер ишеккә таба төрткәли-төрткәли алып бардылар да подвалга кертеп җибәрделәр. Юеш, тездән саз. Саздан эчкәрегә таба атлыйм. Караңгыга күз ияләнгәч, күрәм: гел немецләр генә, хатын-кызлар да күренә. Стена буена бастым. Баш бик тиз әйныды. Шул рәвешле берме, икеме сәгать басып тордым, йокымсырап та алгандай булдым. Яктылык сирпелә башлады. Игътибар беләнрәк карансам, чыннан да немецләр, гаскәри формадан. Мин үземне-үзем битәрли башладым:

«Кайда синең кыюлыгың, син бит чик сакчысы! Үлгәндә дә лаеклы итеп үләргә кирәк!» — дидем. Ишеккә килеп, йодрык белән төя, аякларым белән типкәли башладым. Ишекнең теге ягыннан «Кес кесе сё?» — дип сорадылар. «Чыгарыгыз мине! — дип акырдым мин, — мине монда тотарга хакыгыз юк сезнең! Рус офицеры, совет офицеры мин! Барыгыз, әйтегез, югыйсә мин хәзер...» Мине штабка илттеләр. Мин рольгә кердем дигәндәй, инде каным кызды! Тупсаны атлап керүгә йодрыгым белән өстәлгә суктым: мин рус офицеры, совет офицеры. Мин сездән сәяси сыену хокукы таләп итәм! Этап вакытында качканымны сез бик яхшы беләсез! Сез мине ничек немецләр белән бергә подвалда тота аласыз?!» «Сез офицер бит, мсье, шуна күрә тикшерергә кирәк икәнен беләсез», — диләр. «Кирәк булгач, тикшерегез! Мин каршы түгел, тик немецләр белән утыртмагыз. Мин аларның Берлинында туйганчы утырдым инде!»

Француз офицерының йокысы туеп житкән, күрәсең, елмаеп карап тора. «Алайса, ярар, подвал ошамаса, без сезне чарлакта тотарбыз», — ди бу. Бер кисәк колбаса белән шәраб салынган фляга тоттырдылар (гадәт шундый инде аларда — су урынына шәраб эчертәләр). Тамак ялгап алгач, мине ат абзары өстендәге чарлакка озаттылар. Менә, ичмасам, монда шәп: хуш исле печән, салам! Каядыр төшеп югалган сыман, мин шундук йокыга талдым һәм кыймылдамыйча да кичкә хәтле йоклаганмын. Төшемдә мин туган якларга да очып кайтып килгәнмендер сыман тоелды.

Кичен уянып китсәм — чарлак тулы кеше. Тавыш, гауга, сөйләшәләр! Безнең егетләр дә шунда — Закиров, Ризванов! Рус егетләре дә — Никитченко, Марченко! Мин аларның барысын да беләм, алар да шул эшелоннан, французларга гына соңрак килеп ирешкәннәр. Туганнар кебек кочаклашып күрештек. «Подвалга төшермәделәрме әле сезне? — дип сорыйм. — Алайса, күрәселәрегез алда әле! Ожмах булыр анда сезгә!» — дим.

Безнекеләр — татарлар, башкорт, рус, украиннар һәм бер грузин — Орошвили — барысы егерме бер кеше. Бер атна чамасы тикшерделәр безне. Аннары бригада комиссары мсье Дьюм, минем якка таба карап: «Арагызда офицер бар бугай?» — диде. «Бар, бар, ул командир булсын!» — диештеләр иптәшләр. Тикшерү барган арада мин азык-төлек бүлү белән шөгыльләндем — ипи, шикәр, — биргәннең бөтенесен дә бүлдем. Барысы да миңа ышаныч белән карыйлар, яшем белән дә мин башкалардан өлкәнрәк бит.

Шулай итеп, мсье Дьюм мине «рус группасы»ның командиры итеп билгеләде. Башта безне хуҗалык эшләрендә файдаландылар, аннары сугыш хәрәкәтләрендә катнашырга рөхсәт иттеләр. «Арагыздан берәрегез качарга маташса, калганнарыгыз барыгыз да атып үтереләчәк», — дип кисәттеләр безне. Һәм болар буш сүз генә түгел иде: подвалда утырган башка кешеләргә карата шул сүз тормышка ашырылды.

Сугышларда без үзебезне тәҗрибәле сугышчылар итеп күрсәттек. Бер мәлне Париждан немецләр француз сәнгате шедеврларын Германиягә алып китәргә җыена икән дигән хәбәр килде. Моңа юл куймаска кирәк иде. Француз группасы белән бергә безнең взвод төп автомагистральне контрольгә алды. Операциягә киткән чакта мин үзебезнекеләргә сапер көрәкләрен алырга куштым. «Шундый йөкне өстерәп йөрисегез киләме?» — дип, французлар гаҗәпләнде. «Кирәге чыгуы бар», — дидем мин. Таулы урыннарда немецләрнең минометтан ату гадәтен белә идем. Урынга килеп житкәч, куаклыкта шахмат тәртибендә чокырлар казыдык. Жир йомшак булып чыкты. Командир безгә колонна башындагы машинага ут төртергә кушты. Сугышчыларның һәрберсенә аерым задание бирелде. Пулеметчы Марченко, мәсәлән, беренче машина куаклыкка килеп житү белән кисәтүсез ут ачарга тиеш иде. «Бензин багына төбәргә тырыш, машинага ут кабарлык булсын», — дидем мин. Тиздән тезелешкән йөк машиналары күренде. Машиналар

бик күп булганлыктан, колоннаның ахырын күрерлек түгел иде. Брезент белән капланган алдагы машина безгә таба якынаю белән, Марченко ата башлады. Машина кара сөрем эчендә калды һәм шартлады. Колонна туктады. Ыгы-зыгы, йөгерешү, кычкырышу башланды. Машиналарда сәнгать шедеврлары түгел, эсэс дивизиясе солдатлары булып чыкты. Франциядән көнчыгышка китеп барышлары икән. Анда безнекеләр немецләрнең арт сабагын нык укыта, күрәсең. Алар юкка гына Совет Армиясенә каршы үзләренең иң ышанычлы дигән, сайлап алынган гаскәрләрен җибәрмиләр шул.

Окоп казып мәшәкатьләнергә теләмәгән французлар авып-авып төшә, исән калганнары чигенә башладылар һәм тиздән күздән дә югалдылар. Без атуыбызны дәвам иттердек. Немецләр бөтен утларын безгә юнәлттеләр. Миналар очты. «Утны туктатырга!» — дип команда бирдем. Без атмый башлагач, немецләр ашыгыч рәвештә машиналарына төялделәр дә үз юлларына китеп бардылар. Безнекеләрдән берәү дә һәлак булмады, бар да исән-сау! Үтерелгән французларны бер җиргә ташып куйдык, чыбык-чабыктан носилкалар ясап, яралыларны лагерьга алып кайтырга җыенган идек, шул арада качып киткән французлар кире килделәр дә кычкырып-кычкырып үлгәннәр хакында елый башладылар. Бераздан казармаларга әйләнеп кайттык. Ял итеп алгач, мсье Дьюм мине үз янына чакырды. Каршысына килеп баскач, тиешле форманы үтәп: «Рус группасы командиры капитан Рушад Хисаметдинов сезнең боерык буенча килде!» дип рапорт бирдем. (Егетләрне дә: «Бернинди башбаштаклык булмаска тиеш. Тәртип — армиядәгечә!» — дип, кисәтеп куйдым. Француз партизаннары арасында тәртип юк, шәраб эчәләр дә теләсә нишләп йөриләр.) «Группагызда үлүчеләр яисә яраланучылар бармы?» — дип сорады командир. «Юк». «Моны ничек аңларга: французлардан һәлак булучылар бар, ә сезнекеләр исән-сау?» «Немецләр белән беренче генә сугышуыбыз түгел, — дидем мин. — 1941 елда ук инде коточкыч бәрелешләрдә катнашырга туры килде. Таулы җирләрдә немецләр гадәттә миномет кулланалар. Алардан окопларда гына котылып калырга була. Без окоп казыганда сезнекеләр көлеп тордылар».

Берничә көннән французлар безне бүләккә тәкъдим итмәкче булдылар. «Нәрсә телисез: орденмы, кыйммәтле бүләкме? — дип сорадылар. Үзебезнең егетләр белән киңәштем: «Әлбәттә, бүләк, аларның орденнары нәрсәгә безгә!» — диделәр егетләр. Шунда миңа алтын сәгать бирделәр. Мин аны өйгә алып кайтып җиткердем. Ул чын алтын түгел, алтынланган гына булып чыкты. Башкаларга да сәгатьләр, портсигарлар тапшырдылар.

Французлар белән бергә сугыш операцияләрендә катнашып, без немецләрне Эльзас һәм Лотарингиягә хәтле кудык, аннары инде Германия башлана. Фронт линиясе шунда күчте. Генерал де Голль, партизан ополчениесен бетереп, француз регуляр армиясен оештыра башлады. Командирыбыз мсье Дьюм безгә болай диде: «Моннан соң макизарлар булмый инде, сезгә, армиядә хезмәт итәр өчен, француз гражданлыгы алырга туры килер, — диде. — Уйлашыгыз да иртәгә җавап бирегез». Бу тәкъдим турында без бергәләп киңәштек. «Сезнең күпләрегезне мин белмим, — дидем мин. — Сугышта сез үзегезне батырларча тоттыгыз. Ватан алдында нинди гаебегез булуы миңа мәгълүм түгел. Үзегез уйлагыз да, гражданлык кабул итмәкче булсагыз, белегез: Ватаныгызны мәңгегә югалтачаксыз». «Ә командирыбыз ни уйлый?» дип сорадылар егетләр. «Өйдә минем әнкәй, улым бар, мин гаиләмә кайтам. Ватан каршысында әлләни зур гаебем бар дип уйламыйм, атылып үлә генә алмадым инде. Германиядә төрмәләрдә утырдым, яшерен оешма өчен күп нәрсә эшләдем. Мин мондагы гражданлыкны алмыйм, өйгә кайтам», — дидем. Шуннан соң барсы да бердәм рәвештә өйгә кайтырга булды. Ростовцев фамилияле бер кеше генә монда калырга теләде.

Икенче көнне мин карарыбызны мсье Дьюмга җиткердем.

СССР консулы Богомоловның Парижга килүен ишеттек. Консулдан һәм хәрби комиссиядән җавап көткән арада мине элекке партизан штабының коменданты итеп билгеләделәр. «Складта калган бөтен нәрсә — азык-төлек, кием-салым, — сезнең карамакта», — диде мсье Дьюм, киткәндә.

Шулай итеп, без үзебез генә калдык. «Французженкаларны яратасыз, — дим егетләремә, — карагыз аны, югалып йөрмәгез, вакытында кайта торган булыгыз».

Без нибары егерме бер кеше. Унике татар — Гайсин, Ходжаев һ.б. (Исемлегебез хәзер дә исән әле минем). Соңрак партизаннар хәрәкәтендә катнашкан өчен безгә акча бирделәр. Үзебезнең хәлебез турында мин Парижга хат язып җибәрдем. Тиздән: «Лион шәһәрендәге Пардью казармасына килергә», — дигән җавап алдык. Шәхси коралларыбызны алып, шунда киттек.

45нче совет җыелу пунктына бер департаменттан гына да мең кеше җыелган. Барысы да безнекеләр — егерме милләт кешесе. Бар да Франциядә сугышкан, бу илне азат итүгә күп осталык һәм күп көч салган. Сафка баскан кешеләргә генерал-майор Вихорев команда бирде: «Командный состав, 15 адым алга! Рядовойлар, урыныгызда!» Безгә совет хөкүмәтенең мөрәҗәгатен укыдылар: «...Ватан-анабыз кулына корал алып каршы чыкканнарны ди кичерә», диелә анда. Мөрәҗәгатьтә мондый сүзләр әйтелмәсә, ватанга кайтырга җөрьәт итүче күп булыр иде микән?

Мина да чират җитте. «Кайда хезмәт иттең?» дип сорыйлар. «1932 елдан башлап сугыш башланганчыга хәтле ил чиге гаскәрләрендә — 58нче Градов отрядында, оператив дивизионның маневр группасында.» «Маневр группасында командир кем иде?» «Майор Минкевич. Аннары мине Духовская заставасына күчерделәр, Минкевич урынына карарак кына чибәр, кечерәк буйлы, өч шпаллы бер полковник килде. Анысының фамилиясен белмим». Сорау алучы елмаеп куйды. «Сез калыгыз, — диде ул миңа. (Шул чакта яңа килгән полковникның үзе булып чыкты ул! Әйтәм бит: язмыш гел елмая миңа, юкка бәхет йөзлеге белән туганмынмени!) — Мин сезне партизаннар батальоны комиссары, командирның политпросвет эше буенча ярдәмчесе итеп билгелим».

Озакламый мин бу батальонның командиры идем инде. Муса Җәлилнең 80 еллыгына багышланган альбомда ул чорга караган фотолар бар. 1944-1945 елларда мин элек хәрби начальниклар булган иптәшләр белән бергә үземнең кул астындагыларны Кызыл Армия уставы буенча укыту белән шөгыльләндем. Французженкалар белән мавыгып китеп, кешеләребез Франциядә кала күрмәсеннәр дип тә кайгыртасы булды. 1945 елның ахырында батальон тулы составында безнең совет зонасына килде. Батальонны тараттылар — яшьләрне кадрлы армиянең төрле частьләренә алдылар, безне, офицерлар составын исә Мәскәү янындагы Невель станциясенә — фильтрлау пунктына җибәрделәр. «СМЕРШ» контрразведкасы безне җентекләп тикшерде. Бер айдан мин 18нче артиллерия частеннән демобилизацияләндем. Алма-Атыга кагылып, әнкәй белән, туганнар белән күрешкәч, Ош шәһәренә, гаиләм янына кайттым. Мин юкта хатыным бөтен балаларын сугышта югалтып бетергән карт әткәсе Борһан Гыймадетдинович янына күченгән булып чыкты.

Бу урында хатыным Тайфә хакында берничә җылы сүз әйтү артык булмас. Бала чакта ук ул әнисе Газизәдән ятим кала. Газизә Татарстанның Кызыл Юл районындагы Яна Чишмә авылында туган. Тайфәгә үги әнисе дә, туган-тумачалары да укырга ирек бирмәскә тырышалар. Һәм ул япь-яшь килеш Петропавелга китеп, шунда медицина техникумын тәмамлый. Медицина учреждениеләрендә тырышып эшләгәне өчен аны Алма-Аты медицина институтына җибәрәләр, һәм ул аны 1939 елда тәмамлап чыга. Мин аның белән

1935 елда, чик сакчысы чакта таныштым һәм без 1937 елда өйләнештек. 1939 елда ул миңа улыбыз Равилне алып кайтты. Тоткынлыкта улымны сагынган чакта мин ничектер Муса Җәлилдән һәм Гайнан Курмаштан улыма багышлап шигырь язуларын сорыйсы иттем. «Дусларым бар да шагыйрьләр, Алма-Атыда минем улым калды, шуның турында язмассызмы икән?», — дидем. «Туктале, тукта, — диде Муса, — фронтка каян киттең әле син? Йә, сөйләп бир әле!» Шуннан мин Казакъстанның гүзәл табигатен сурәтли башладым — иркен көтүлекләрен, алма бакчаларын. «Кичләрен улыбыз белән бергә өчәүләп шул бакчаларда йөрдек, инде дә бәхетле идек! Менә шуларны төштә генә булса да күрсәң икән!» Мине тынлый-тынлый Муса нидер яза. Мин сөйләп тә бетермәдем, ул инде язган шигырен миңа тоттырды: «Мә, «Урман кызы» көенә җырларсың», — ди.

*Җыерчыклар төшеп, чал керсә дә,*
*Мактанырлык минем юлым бар –*
*Биек күксел тауның итәгендә*
*Яшь арыслан дай улым бар.*
*Бөтен дөньяларны шаулатырлык*
*Галим булыр, бәлки, ул бала.*
*Гасырларның исен китәрерлек*
*Шагыйрь булыр, бәлки, ул бала.*
*Бик күп еллар узды мин киткәнгә,*
*Бик күп сулар акты тугайда.*
*Улым, Равил, сагынамын сине,*
*Их, күрәсе килә шулай да!*
*Алсу таңда, биек күксел тауда,*
*Гөлбакчаның җәйге кичендә*
*Өчәүләшеп йөргән чакларыбыз*
*Кайчак керә ярсып төшемә.*

Соңгы строфасын Гайнан язды.

Ошта мин ит комбинатына баш инспектор һәм баш ветврач булып эшкә урнаштым.

Әмма каһәрләнгән 1949 ел җитте, Берияләр, Абакумовлар вакыты. Әсирлектә булган офицерларны рәттән кулга ала башладылар. Мине 58нче маддәнең 16нчы пункты буенча хөкем иттеләр (хәрби хыянәт). Муса Җәлил белән бергә дошманга үз тылында каршы торган өчен бит бу! (Хәер, бу вакытта Мусаның үзен дә хыянәтче итеп йөртәләр иде.) Фашист зинданнарында җәзаланган өчен, Франция партизаннары белән бергә бу илне фашистлар коллыгыннан азат итүдә катнашкан өчен мине 5 елга түгел, 25 елга хөкем иттеләр. Башта атарга дип хөкем иткәннәр иде, «үлем җәзасын» гамәлдән чыгарганнан соң, аны каторгага алыштырдылар. Югыйсә һәр сүзем документ белән расланган. Айлар буена без, җәлилчеләр, олы, мөһим эш белән шөгыльләндек! Юккамени фашистлар иптәшләремнең башларын гильотинада чаптылар. Сорау алган вакытларда мин боларның барысы турында бәйнә-бәйнә сөйләдем. Соңыннан аңлашылганча, миңа срокны нәкъ менә шуның өчен биргәннәр икән!

Мин хөкем ителгәннән соң хатыным врач-рентгенолог булып эшләвен дәвам итте. Бермәлне аның янына КГБ хезмәткәре килеп, халык дошманы дип, миннән баш тартырга тәкъдим иткән. «Мин аннан бервакытта да баш тартмаячакмын, ул хыянәтче түгел, мин аның бөтен нәселен беләм», — дигән хатыным. Теге аңа дипломыңнан колак кагарсың дип тә янаган. «Миңа дипломны сез бирмәдегез, сез ала да алмыйсыз», — дигән хатыным.

Ул чаклардан соң күп вакытлар үтте, тормышта күп нәрсәләр үзгәрде:

Берия, Абакумов һәм башкалар фаш ителде, тиран Сталин үлде. Нахакка хөкем ителүчеләр акланды, гаделлек, ниһаять, тантана итте.

Бер мәлне без Тайфә белән урамда әлеге КГБ капитанын очраттык. Штатский киемнән, елмаеп күреште. «Бу шул синнән баш тартырга кушкан кеше», — дип пышылдады да хатыным, адымын тизләтеп китеп барды. Тегенең белән сөйләшәсе килмәде аның. Мин исә туктап сәламен алдым. Иренә тугрылыклы булганы, ныклыгы өчен Тайфәгә рәхмәт әйтергә җыенганын әйтте бу һәм минем алда, «халык дошманы» алдында, акланырга тотынды. Мин сиңа ачу тотмыйм, чөнки син боерыкны сукырларча үтәүче генә, дидем. Өстәвенә, мин инде СССР Югары Судының Хәрби Коллегиясе тарафыннан акланган кеше, һәм минем күнел яраларын янадан ярсытып торуның да кирәге юк, дидем.

Гомумән дә КГБ мине бервакытта да тынычлыкта калдырмады. Хәтеремдә әле, 1945 елда без хатыным белән Алма-Атыга, авыру әнием янына барган идек, берничә көннән, прогулкадан кайтып килсәк, ни күзебез белән күрик, капка төбендә КГБ кешеләре тора. Алып киттеләр мине. Аерым бүлмәгә кертеп утырттылар да сорау алырга тотындылар. Допрос тәнәфессез өч тәүлек буена дәвам итте. Һаман шул бер сорау: ничек әсир төштем, әсирлектә нәрсә эшләдем һәм башкалар. Башым шаулый, йокы килә... Болай итеп сорау алу чараларының бездә тыелган булуын белә идем, ләкин минем карышуларым игътибарга алынмады... Өч тәүлектән соң гына җибәрделәр.

1949 елда, трибунал хөкем иткәндә, миңа хәтта адвокат ярдәме дә рөхсәт ителмәде. Судта булган хәрби прокурор мине хәтта оятсыз сүзләр дә әйтеп мыскыллады! Соңгы сүземдә мин, гаебем юк, дидем, Ватан өчен хәлемнән килгән бөтен нәрсәне дә эшләдем, дидем.

Ерак лагерьларга җибәрер алдыннан балаларым һәм хатыным белән күрешергә рөхсәт иттеләр. Мине күргәч, алар кычкырып еларга тотындылар. Балаларны, дәваларга җибәрәләр мине, тиздән кайтырмын дип тынычландырырга тырыштым. Хатыныма исә 5 елга хөкем иттеләр дип әйттем, следовательдән дә якыннарыма шулай дип әйтүен үтендем, чөнки хатынымның йөрәге сау түгел иде.

Ош төрмәсеннән мине, кулларыма богау салынган хәлдә, 25 чакрымдагы Карасу станциясенә җәяү алып киттеләр. Анда тоткыннарны ташый торган вагоннарга утырттылар. Шахталар районына барып җиткәч, Сөлек Ата дигән станциядә төшерделәр. Шахтада эшләү шартлары коточкыч авыр иде. Анда мин нык кына авырый башладым һәм забойга төшүдән баш тарттым. ГУЛАГ положениесе буенча тоткыннарны эштә белгечлеге буенча файдаланырга тиешләр иде. Лагерь башлыгы мине тәүлегенә 200 грамм ипи һәм бер кружка су белән карцерга утыртты. Карцерда тагын бер кеше утыра иде, укытучы иде бугай. Ул ярсынып камерада йөренә, ачлык игълан иткән. Мин аңа ачыкмаска кинәш иттем, чөнки монда аңа берәү дә игътибар итмәячәк, сузылып ят та сәламәтлегеңне сакла, дидем. Тиздән безне Кемерово өлкәсенә урман кисәргә китүче этапка куштылар. Кемеровода безне — йөздән артык кешене, бер колоннага тезделәр дә кара яңгыр астында тездән саз ердырып, эшлисе урынга алып киттеләр. Кешеләр ачлыктан һәм хәлсезлектән аяктан егылалар. Колоннадан читкә бер генә адым атлаган кеше дә атып үтереләчәк, дип кисәттеләр конвоирлар.

«Глубинка» дигән концлагерьга ике тәүлек буена бардык. Төнне юл буенда, сазда үткәрдек. Ниһаять, барып җиттек. Безне баракларга тараттылар. Саносмотрдан, төрле-төрле лагерь процедураларыннан һәм тикшерүләрдән соң сак белән әйләндереп алган урман кисәсе урынга җибәрделәр. Бригадир кайда куя, шунда эшлисең: берәүләр агачны кисеп ега, берәүләр ботакларыннан арындыра, берәүләр кабыгын кыра, берәүләре әзер агачны юлга чыгара. Миңа

төрле эштә булырга туры килде. Бик авыр шартларда — каты суыкларда азыксыз диярлек эшләдек. Мин еш кына чирләдем. Монда мин рус, украин, татар, үзбәк, кыргыз иптәшләр белән таныштым. Барысы белән дә дус булдым — кешеләрнең күнелләрен күтәрергә тырыштым, мин бит инде бер кат мондый хәлне кичергән кеше. Өйдән посылка-мазар килә калса, иптәшләрем белән бүлештем. Шул лагерьда чакта туганнардан һәм Тайфәдән дүрт посылка алдым. Минем кайгымны үзләренең кайгысы итеп кабул иткән туганнарым алдында мин мәңгегә бурычлы. Посылкада килгән азык-төлекне башлыклар белән дә бүлешергә туры килә иде.

Урман эшендә үземнең якташым — кыргыз укытучысы Таубалды Камчибәков белән дуслаштым. Бу кеше бик тә эрудицияле тарихчы-интернационалист иде. Аның белән безгә бар кеше дә тигез, барысы белән дә туганнарча аралашабыз. Өйгә без бер үк вакытта диярлек әйләнеп кайттык: мин — Ерак Төньяктан, ә ул Себердән. Амнистия өчен Хрущевка рәхмәт инде. Без бик гарьләндек: немец хөкүмәте халыкара конвенция нигезендә үзенең әсирләрен иленә кайтарды, японнар да шул гамәлне кылды, ә безгә исә ГУЛАГ лагерьларында чиктән тыш авыр газапларны кичерергә туры килде...

Еш кына бер хәл исемә төшә. Камчибәков белән без киртә әзерли идек. Шул чакта сугыш вакытында фашистларга кешеләрне асарга-кисәргә булышып йөргән бандеровчы әздән генә мине үтерми калды. Без әзерләгән киртәләрне чанасына төягән дә, алып китәргә җыенган. Мин шуны күреп үзебезнекен алып калырга омтылдым. Чанасыннан төшеп ул мине тукмарга тотынды. Гәүдәгә ул миннән олырак та, көчлерәк тә, эчләремә, бавырларыма типкәли-типкәли рәхимсез рәвештә кыйнады. Инде анымны җуям дигәндә генә, бу хәлне күреп, Камчибеков кулындагы балтасы белән мина ярдәмгә ташланды. Балтадан коты алынган әлеге явыз җан качып китте. Шулай итеп, без бер көнлек паегыбызны, 400 грамм ипиебезне коткарып калдык. Шушы паекны алыр өчен безгә бер куб метр киртә әзерләргә кирәк иде бит.

Ватаныбызга кайткач, без гаиләләребез белән дуслашып яши башладык. Кыргызларда шундый борынгы гадәт яшәп килә: һәр гаилә үзенә якын туган булырдай дуслар (аяш-ата, аяш-ана) сайлый.. Менә без инде Тайфә белән кырык еллап Таубалды белән Саулә балаларының шундый аяш-ата, аяш-анасы булып яшибез.

1953 елның ахырында мине «Глубинка» лагеренннан этап белән Ерак Төньякка күчерделәр. Бу юл аеруча авыр булды. Кемерово станциясеннән бөтен Себер аша без Татар бугазы буендагы Ванино порты дигән перевалочный пунктка хәтле бардык. Монда безне зур йөк пароходының трюмына урнаштырдылар. Дыңгычлап кеше тутырылган, суларлык һава да булмаган шушы тынчу трюмда бик каты чайкалып, җәфалана-җәфалана атналар буена йөздек. Кешеләр дизентериядән үлде. Мәетләрне туп-туры диңгезгә ыргыталар иде. Безнең юлыбыз Сахалин ярлары буеннан, башта Охот диңгезе, аннары Беринг диңгезе буйлап, Камчатка, Магадан һәм Чукотка яныннан үтте.

Монда мин үзем кебек үк $58^{6}$ маддәсе (Ватанга хыянәт) буенча хөкем ителгән бер табиб белән дуслаштым. Аны сирәк-мирәк кенә даруга дип палубага чакыралар. Үкенечкә каршы, дустым озакламый дөнья куйды. Аның медикаментлар салынган санитар сумкасы миндә калды. Шул сумканы начальствога тапшыру нияте белән мин часовойга мөрәҗәгать иттем. Мине корабль фельдшерына чакырдылар. Беренче тапкыр палубага күтәрелдем. Диңгез формасы кигән фельдшер каршылады мине. Медицина сумкасының мина ничек килеп эләккәнен сораштырды. Дустым булган мәрхүмгә булышканымны әйттем, үземнең табип-эпизоотолог икәнемне, медикаментларны бераз чамалый алганымны сөйләдем. Фельдшер миннән

авыруларга ярдәм күрсәтүне дәвам итүемне үтенде. Мин булдыра алган хәтле тоткыннарга ярдәм итә башладым.

Чукотка ярымутравын Певек порты буеннан үттек. Аннары Төньяк Боз океаны аркылы, Көнчыгыш Себер дингезе, Лаптевлар дингезе буйлап Яна елгасы тамагына килеп җиттек. Анда баржаларга төяп елга буйлап югарыга таба алып киттеләр дә, бер кешесез яр буена илтеп бушаттылар. Барлык корабльләрдән җыелган 500ләп кеше идек, саф алдында булачак «Депутатский» дигән лагерьның башлыгы майор сөйләде. Тырышып эшләгән кешеләргә бер көн өч көнгә исәпләнәчәк, дип белдерде ул. Шулай иткәч, янәсе, 25 елны 8-9 елда тутырырга була. Аның ачыктан-ачык, кешечә сөйләве кешеләрне үзенә тартты. Бәлки, чик сакчылары фуражкасы кигәнгәдер, ул минем дә күнелемә ошап куйды. Ул кычкырып, украин акценты белән, арагызда табиблар юкмы, дип сорады. Эндәшүче булмады. Ул соравын кабатлады. Шунда трюмда бергә килгән иптәшләр: «Нишләп дәшмисен? Юлда чакта син дәваладың бит безне!» — диделәр. Сөйләшкәнебезне ишетеп, майор безнең янга килде дә, миннән, кем буласың, дип сорады. Мин, «Табиб-эпизоотолог, ветеринар», — дидем. Сөенеченнән ул: «Да яка разница! Будешь у меня хвершалом!» — дип кычкырып җибәрде. Шундук миңа медпункт ачарга фәрман бирде, егерме урынлы палатка кору өчен берничә кеше алырга, тимер мич куярга кушты. Палатканы ничек җылытырга икәнен аңлатты. Кыш көне палатка тыгыз кар кирпечләре белән, җәен кипкән мүктән киселгән кәс белән әйләндереп-тәреп алына икән.

Озакламый палатка әзер иде. Лагерьга вольнонаемный табиб килгәндә анда 25 кешелек стационар әзер иде инде. Мондагы ашау-эчү яклары — чыдарлык. Лагерьдан ерак түгел генә кассетелит (кургаш рудасы) чыгару урыны оештырылды. Лагерь айдан-айга зурая барды — этап-этап зэклар китерелде. «Депутатский» караклар лагере булып исәпләнә иде. Монда каракларның төрледән-төрлесе бар: «шестеркалары» белән бергә «закондагы караклар»дан башлап вак-төяк бурлар, кесә караклары, «медвежатниклар» һәм хезмәт халкы исәбенә көн күрүче башка һәртөрле әрәмтамаклар. Сәяси маддәләр буенча хөкем ителүчеләр ($58^{10}$, $58^{1А}$, $58^{16}$ һ.б. маддәләр) төп эш көче булып исәпләнә иде. Руда чыгаруның бөтен авырлыгы шулар җилкәсенә төшә. Сәяси тоткыннар чын хезмәтияләре иде. Лагерьда аларны «мужиклар» дип атап йөрттеләр. Караклар, «сукалар» һ.б. шуның кебек адәм актыклары шулар исәбенә яшәде монда. Алар сәясиләрнең әйберләрен урлый, посылкаларын талап ала, каршылык күрсәтүчеләрне үтерә иделәр.

Хезмәт күрсәтүче персонал указлы караклардан җыела. Сәяси тоткыннарны монда кую катгый рәвештә тыела. Миңа да фельдшер булып эшләргә безнең лагерьны тикшерергә килгән ЯнЛагның санитария бүлеге башлыгының яхшы мөнәсәбәте аркасында гына рөхсәт ителде. Амбулаториябездә бөтен нәрсә чип-чиста, медикаментлар тиешле тәртиптә куелган, мин кардан әзерләгән, дистилляцияләнгән суның сыйфаты әйбәт — шушы суда ясалган даруларның сыйфаты бозылмый. Кыскасы, стерильлек бик шәп саклана. Тикшереп бетергәч, начальник (ул хатын-кыз иде) минем койка торган почмакка күз салды, Тайфәнең игез кызларым белән төшкән фотосын күреп, кычкырып җибәрде: «Тайфә ич бу! Кемегез ул сезнең?» Мин әйтеп бирдем. Ул миңа игътибар белән карап алды. Тайфәнең ирен белүе, һәм аның матур, гаярь булуын әйтте. Менә шул матур чик сакчысы мин идем инде, язмыш мине шулай танымаслык хәлгә китерде, дидем. Ул минем турыда лагерь башлыгы белән сөйләшергә вәгъдә итте. Мин дә кайчандыр чик сакчысы булгангамы, начальник миңа болай да әйбәт карый иде. Чик сакчылары да, дингезчеләр кебек, үзләренекеләргә авыр хәлләрдә ярдәм итәргә тырышалар бит.

Указ буенча хөкем ителгән Борис Харитоновның исемлек тикшергәндә чын

исеме Бари Хәбибуллин булуы ачыкланды. Руслар компаниясенә кермәкче булгач, тегеләр моны: «Син, сука, үз исем-фамилиянне саткансың, безне дә сатарсың», — дип, бик каты тукмап, иди к своим татарам», — дип, куган. Мөселманмын дип чеченнарга сыенмакчы булган. Тегеләр, мөселманча исәнләшә дә белмәгәч, нинди мөселман син?» — дип, куып җибәргәннәр. Санитар булып эшли торган Бари абзыйга тап булган бу. Егетнең зарын тыңлагач, карт: «Кайсы якныкы соң син?» — дип татарча сораган. Егет татарча бер сүз дә белми икән. Бари абзый дорфа кеше, нинди татар инде син, теленне белмәгәч, дип, ул да сүгеп җибәргән. Егет үкереп елый башлаган. Боларның сүзен ишетеп торган бүтән санитар латыш Ремицанс: «Сиңа безнең доктор Рушад Билалович ярдәм итәр, яхшы кеше ул», — дип, егетне минем янга кертеп җибәргән. Үксеп-үрсәләнеп елаучы егет ана телен өйрәтмәгәннәре өчен ата-анасын сүгә, «Кайтыйм гына, үтерәм мин аларны!» дип яный. Мин аны, кочаклап алып, таблеткалар каптырып юата башладым. Тынычландыргач, Бари абзыйны дәшеп, егетне татарчага өйрәтергә куштым.

Лагерьда кешеләр ачлыктан түгел, күбесенчә милләтара «разборкалардан», төркем-төркем булып чеченнар белән яисә «сука» дигәннәре (болары да караклар, ләкин башка караклар алдында ниндидер гаеп эшләгәннәре) белән сугышудан үләләр иде. Бер очрак аеруча нык хәтердә калган: каракларның чеченнар белән сугышуы иде. Сугыш-талаш килеп чыкканда охранниклар, сугышучылар янына барырга куркып, вышкалардан гына, башлар өстеннән генә атарга тырышалар. Санитарлар белән без ярдәм итеп бетерергә дә өлгерә алмыйбыз. Бу юлы кемдер кемнедер үтерәме, кемдер кемнедер куамы, кешеләр төрлесе төрле якка чабыша. Кинәт бәдрәфтән йөрәк әрнеткеч ачы тавыш ишетелде. Йөгереп барсам, икәүләп өченче берәүне башы белән сыек тәрәткә тыгып батырмакчы булалар. Шунда ярдәмгә ташландым. Бандитлар корбаннарын ташлап миңа ябыштылар. Миңа ярдәмгә санитарлар йөгереп килде, бергәләп бәдрәфкә батырылган кешене тартып алдык, амбулаториягә алып кереп, юындырып, чистарындырып топчанга яткырдык.

Лагерь башлыгы һәм солдатларның бөтен составы белән конвой командирының хәлиткеч катнашуы аркасында гына әлеге сугышны туктатып булды. Чеченнар белән ингушларны лагерьдан күчерделәр. Зонадан аерып, алар өчен вакытлыча барак төзеделәр. Санитарлар белән бергә безгә анда да булырга, ярдәм итәргә туры килә иде. Аларның башлыклары — Юрка кушаматлы ингушның башын тишкәннәр, 11-12 сантиметрлы җәрәхәт ясалган. Мин аны әйбәтләп чистарттым, җөй дә, повязка да салдым һәм Юрканың башы төзәлеп җиткәнче барагына барып йөрдем. Тиздән аларны «Депутатский»дан 20 чакрымдагы бүтән зонага күчерделәр.

Бу хәлләрдән соң берәр ел үткәч, теге лагерьның фельдшерын азат иттеләр. Аның урынына мине куйдылар. Анда баргач, чеченнар барагында мине караңгы чырай белән каршыладылар. Үзләренең җыелышларында алар, бандит Юрка таләбе белән, мине, янәсе, мөселман диненә хыянәт иткән өчен, руслар зонасында калган өчен дип үтерергә карар иткәннәр икән. Чеченнар арасында элекке хәрби әсир, өлкән лейтенант, танкист Әхмәт Идрисов дигән бер дустым бар иде. Ул катнаш баракта яши иде. Кереп мине койкасына утыртты да: «Шушында утыр, кузгалма!» — диде. Эш шунда ки, чеченнар гадәте буенча аларга өйләренә кергән кунакны үтерергә ярамый икән. Бер якта басып торган ике чеченга күрсәтеп, Әхмәт: «Күрәсеңме әнә теге... Шулар чечен җыенының карарын тормышка ашырып, сине үтерергә тиеш инде», — диде. Үзе калган чеченнар белән сөйләшергә дип китеп барды.

Бу зонага күчерелүем турында ишетеп, яныма танышларым — Кечкенә кушаматлы башкорт һәм Кудряш дигән татар килеп керделәр. Алар минем белән

сөенешеп исәнләштеләр һәм сәламәтлегем турында сораштыра башладылар. «Әлегә исән, — дидем мин, — әмма бу койкадан кузгалуга әнә шул икәү чеченнар җыены карары буенча мине суячаклар», — дидем. Күз ачып йомарга да өлгермәдем, минем дуслар палачларымны буып үтерделәр дә наралар астына тыгып куйдылар. «Хәзер ничек тә үзен котыл инде», — диделәр дә чыгып та киттеләр. Әхмәтнең койкасыннан тордым да юлга юнәлдем. Юлым чеченнар барагы яныннан үтә иде. Чеченнар мине күреп алдылар да, сагаеп калдылар. Хәлем мөшкел иде. Йөгерә башласам, барыбер куып тотачаклар да, эшемне бетерәчәкләр дип уйладым... Их, ни булса да булыр! Мин бит куркаклардан түгел, үзем баракларына керим әле, дидем.



*Сулдан икенче – актриса Р.Җиһаншина. Каршыда – җәлилчеләр Ф.Солтанбәков һәм Р.Хисаметдинов.*

Өстәл буйларында, нарларда утызлап кеше утыра. Күбесен беләм. Кайберләре Ош шәһәреннән, Ош өлкәсеннән, кайберләре белән бер этапта булдык, урман кисүдә, шахтада эшләдек, бергә диңгез транспорты трюмында газап чиктек. Мөселманча сәлам бирдем, җавап кайтармадылар. Киеренкелек көчәя бара. Өстемдә дошмани карашларны тоям. Чәбәләнеп, умырып өстемдәге киемемне салып ыргыттым. Селтәнеп күкрәгемнән күлмәгемне йолкып аттым. Күкрәгемне ачып җибәрдем: «Мин егет кеше! — дип кычкырып җибәрдем. — Үләсе булса, үлемне егетләрчә, чын ир-егет кулыннан тиешенчә кабул итәрмен! Әмма минем беләсем килә, ни өчен сез мине үтерергә булдыгыз?» «Дин сатучы син! — дип кычкырды Юрка. — Руслар белән сугышканнан соң син шулар белән калдың, мөселманнар белән түгел. Менә шул хыянәтең өчен без сине үтерергә булдык». «Башлап син мөселман законын боздың, — дидем мин. — Мин синең гомереңне саклап калдым, — дидем, — башыңның ничек имгәтелеп беткәнен оныттыңмени? Үзеңнең коткаручыңа кул күтәрергә тиеш түгел син! Ә синең белән, Мөхәммәт, — дидем мин Юрка белән янәшә утырган кешегә, — Ош шәһәреннән үк ни газаплар чигеп килдек без монда, ипи-тозны бүлеп ашадык, үлгән иптәшләребезгә бергә Коръәннән сүрәләр укыдык. Минем үзебезнең гореф-гадәтләребезгә, динебезгә беркайчан да хыянәт иткәнем юк. Хакыйкать хакына үләргә мин әзер! Үтерегез! Газаплардан коткарыгыз, ичмасам!» Шуннан соң башкалардан өлкәнрәк булган Мөхәммәт Юркага чеченча нидер әйтте. Аңа башкалар да кушылды. Алар Юрканы гафу үтенергә мәҗбүр иттеләр... Үлем мине тагын әйләнеп үтте.

Чеченнәрда озак эшләмәдем мин. Яна фельдшер килгәч мине «Депутатский»га кайтардылар. Лагерьда күренә башлагач та мине вор-пахан чакырып алды да, нишләп чеченнәргә киттең, анда сине ничек каршы алдылар, дип сорау ала башлады. Мин медик, мин тоткын, үзем-үзем хуҗа түгел, кая җибәрәләр, шунда барырга тиеш, дидем. Чеченнәргә килгәндә исә, берәүне дә үртәмәс өчен, ак халатлы кешене акылы булган кеше үтерми, үтерсә, фашист кына үтерә, дидем. Ул минем сүзем белән килеште, һәм шундук нинди дер үтенеч белән

мөрәҗәгать итте. Минем белән дустанә мөнәсәбәтне бозунын ана файдасы юк икәнен аңлый идем, һәм ана үпкә тотмадым. Бөтен караклар да наркоманнар да чифиристлар, наркотик матдәләргә кушар өчен аларга мин әзерли торган дистиллирланган су кирәк...

Муса Җәлил үрнәгендә мин лагерьда музыкаль капелла оештырып җибәрдем, ул тоткыннар алдында чыгышлар ясый торган булды. Бу эшне без мәдәни-тәрбия чарасы бүлеге белән бергә башкардык. Лагерь башлыгы Рудых миңа ышана иде. Анын белән без чик сакчылары турында сөйләшеп утырган чакларда еш кына икебез өчен дә таныш булган кешеләргә дә барып чыга торган идек. Бу лагерьның җитәкчеләрен мин башка лагерьлардагы белән чагыштырганда кешеләргә карата дорфалыкта, кешене кимсетүдә һәм рәнҗетүдә гаепли алмыйм.



*Р.Хисаметдинов Азалия Бадюгина белән.*

1956 ел ахырында мин лагерь начальствосы тарафыннан бирелгән яхшы характеристика белән амнистия буенча азат ителдем. Ул документлар минем шәхси архивымда саклана.

Менә инде мин яңадан өйдә. Ош шәһәрендә. Авыл хуҗалыгы идарәсе мине Ош районындагы Фрунзе исемендәге колхозга баш зоотехник һәм рәис урынбасары итеп куйды. Соңрак мине шул ук районлагы Ленин исемендәге эре миллионер колхозга шул ук дәрәҗәдәге хезмәткә күчерделәр. Елның күбрәк өлешен Алтайның биек тауларындагы көтүлекләрдә үткәрә торган терлекләр белән эшләдем. Сәламәтлегем кинәт начарланды — баш әйләнү, борыннан кан китү, Бөек Ватан сугышы фронтларында алынган контузияләр, әсирлектә, ГУЛАГ лагерьларында кичерелгән михнәтләр барысы да үзен нык сиздерде.

1958 елдан 1976 елга хәтле мин геологларда атлар базасы башлыгы булып эшләдем. Шуннан көтеп алынган ялга киттем.

Пенсиягә чыккач та мин мәктәпләрдәге, югары уку йортларындагы яшьләр арасында хәрби-патриотик тәрбия эше белән шөгыльләнүемне дәвам иттердем, «Белем» җәмгыятендә әгъза булып торам. Минем һәрвакыттагы темам: «Бөек Ватан сугышы вакытында дошман тылында яшерен оешмаларда алып барылган көрәш». Дошман тылында патриот шагыйрь Муса Җәлил оештырган яшерен оешмабызның эше турында мин армый-талмый сөйләдем. Кайсыбыз исән калсак та, яшерен оешмабызның эше хакында дөреслекне халкыбызга җиткерергә дип ант иттек бит без бер-беребезгә. Халкыбызны яраткан һәм соңгы сулышларына хәтле җиңүебезгә ышанычын җуймаган җәлилчеләр сафында булуым белән горурланам!

*1990*

**Саимә ИБРАҺИМОВА** *тәрҗемәсе*

Айдар
Хәлим

# БЕЗ АНЫ КӨТӘ ИДЕК...

## I

Мина бу язманы язуы ифрат та рәхәт. Ләззәтле халәттә эрим. Чөнки язасы кешем — сүзендә үзенә тиң гамәл иясе. Милләтебезгә ифрат та мөһим һәм саваплы гамәлләр кыйлган зат. Әйе, яңлышмыйм: бу урында «кылган» түгел — «кыйлган».



Тәнкыйтьче. Мөхәррир-нашир. Шагыйрь.Аны җәмгыятебез шушы сыйфатларда таныган. Язучылар берлегенә дә шушы сыйфатларда кабул иткәннәр. Шагыйрь дә, дидек. Әмма башкалар кебек түгел. Үз юлы белән: «Шигырь арты шигырь укыйсың: барысы да дөрес, барысы да мәгълүм... Һич аңлашылмый: нинди максат белән әле Кояш системасы өчен кайгыртучы «фәйләсуф» булып күренергә тырышабыз? Газета хәбәрләрен нигә дип рифмалаштырабыз? Модасы шулмы, заман гаме белән янган булып күренәсебез киләме? Авторның чын йөзе, тормыш позициясе урынын тышкы кыяфәт — поза ала бара. Бер табылган алымнар, темалар, образларны ахыргача сыгу хәтта иҗатлары белән танылып өлгергән шагыйрьләрнең дә кызыклы дөньясын кызганыч хәлгә китерә — ахыр чиктә бер даирә эченә бикли бара. Аларда шигырь — тәкә мөгезе шикелле — үз эченә бөтерелеп, башына кайтарылып үсә башлый: гамәлгә яраксыз, гарип бер нәрсәгә әйләнә...»

Ә нигә ул прозаик та түгел? Кемгәдер артык матур, артык бөдрә күренер идемени? Булса соң!.. Ә бит анарда нинди бай, сыгылмалы тел, ягымлы стиль, камил сюжет, салмак фикер агышы!.. Тынлап карагыз әле! «Әдрәпи әбинең килеш-килбәтендә иң әсәрткәне, — шомырт тамырыдай кара бармакларыннан, аларга сарышкан саргылт балдакларыннан бигрәк, әнә шулай җәйге чилләдә кәбестә кебек катлы-катлы киенеп йөрүе иде. Итәкләренә басып абынмас өченмедер, ул бик вак атлый, әмма шактый җир китәргә өлгерә. Өй борынча хәл белешеп йөри дә, авыл биргән кучтәнәч-төенчекләрен күтәреп, олы юл ягына китеп югала...

Атналар-айлар узгач, кайсыдыр хәбәр ишетеп кайта: «Имеш, Чистай юлында буранлы көнне тунып үлгән икән», — ди... Яисә: «Юк, үлмәгән, каядыр Ташкент якларына чыгып югалган», — дип сөйлиләр. Карчыклар: «Мескен, — диләр, — адашкан шул инде», — диләр, күз яшьләрен сөртәләр...»

Авторның 1981 елда язылган «Ачы әрем исе» дигән тәнкыйть мәкаләсеннән бу. Чып-чын хикәя түгелмени?

Ә нигә ул «тәнкыйтьче генә», публицист-эссеист та түгел? Ул бит татарда «эссе» дигән сирәк жанрның коеп куйган остасы. Аның, әгәр шулай әйтергә яраса, эсседән-эссе эсселарындагы үзәккә үтеп кергән публицистик чаң сугулары һәр язмасында чатыртап ала. «Тапшырылмаган хатлар» дигән тетрәткеч памфлетыннан бер генә

мисал: «Кайчандыр күкрәгенә «әллә нинди кара көчләр» басып торганга гына уяна алмаган халык өстенә янә житмеш кат вәгъдәләр юрганы ябылган. Россиядә сан ягыннан икенче булган милләт — Урал, Казакъстан, Урта Азиягә яңа дәвер мәдәниятеннән ут алып биргән милләт — чыра яктысы кебек бердәнбер нәшриятка карап калды. Дөнья базарына «кара алтын», мех чыгарган, автомобиль, очкычлар төзү, химия, хәрби комплекс гигантларын инендә күтәргән Татарстан жире бүген «эштән чыгарылган татар кызы» хәлендә...Ә шул ук вакытта, үзен милләт хадиме дип санаган агай-эне (ни аяныч!) өч хәрефкә койрык ялгамакчы булып мәш килә, «татармы без, болгармы?» дип дөнья болгата, дин китапчыклар белән спекуляция ясый...»

Ә нигә ул, кайбер башка «иптәшләр» кебек, «атказанган педагог», педагогика фәннәре кандидаты яисә докторы түгел? Ул бит лепкәсеннән аяк бармаклары очына кадәр тәрбияче-педагог!.. Бөтен гомере мәгариф-мәгърифәткә хезмәттә үткән, бар язганы татар баласына тәрбияви китаплар чыгару, укытучылык-остазлык итү белән сугарылган!? Шушы өлкәдән кычкырып торган янә дә бер мисал: « Мәктәп балаларының букчасын күтәреп караганыгыз бардыр, — бигрәк тә башлангыч сыйныфта укучыларныкын. Ни өчен таш төягән кебек авыр соң алар? Дәресләр күп булганы өчен генәме? Әллә инде уку әсбаплары калын булган өченме? Кайбер дәреслекләр икешәр, хәтта өчәр сыйныфка исәпләнгән бит. Бала ничә ел буе һаман шул бер кирпеч-китапны күтәреп йөри-йөри туеп бетә. Миңа калса, жиденче сыйныфка кадәр һәр дәреслекне ярты еллыкка бүлеп чыгару — балалар өчен бик уңайлы булыр иде. Әлеге китапларны тулы көенчә алып килү ихтыяжы кабатлау дәресләрендә генә туачак. Әмма... колхоз басуын әзмәвердәй тракторлар белән издерә генә белгәнебез кебек, супердәреслекләргә жайлашканбыз шул без. Әле бер уку әсбабын чыгару мен бәла булганда, аны икегә, өчкә, дүрткә бүлеп аерым китаплар итү — кая ди ул, авызымнан жил алсын!..»

Безнең ата-аналарыбызның бу хакта уйлап та караганнары юк бит!..

Әмма мин, үземә бирелгән сыйфат-сәләтлекләрдән чыгып, шунысын һич аңлый алмыйм: шагыйрь бер үк вакытта гамәли тәнкыйтьче һәм нашир, тәнкыйтьче бер үк вакытта гамәли шагыйрь һәм нашир, нашир үз чиратында гамәли шагыйрь һәм тәнкыйтьче була аламы? Мең еллык татар мәгариф-мәгърифәтендә үземә билгеле нашир «борадәр Кәримовлар», тагын дистәләгән «борадәрләрне» хәтеремдә капшап карасам да, анык параллель таба алмыйм. Ярый, монысы шулай булсын да ди. Кем соң, нинди соң ул шагыйрь, чәчмә әсәр остасы-прозаик, тәнкыйтьче, публицист, педагог, нашир аерым бер кеше, аерым бер шәхес мисалында, әйтик, бер генә жөмлә, бер генә гыйбарә яссылыгыннан чыгып караганда?

Әйдәгез, тәжрибә мәйданы итеп, чия бакчасын алыйк.

«Нинди матур чия бакчасы бу!..»

Языласы шигырьнең беренче юлы була ала бит, әйеме? Әгәр шушы бер юлны иркенләп, чәчмә рәвештә чәчкәләп сурәтләсә, шагыйрь прозаик булырга дәгъва итә дияр идек. Ә инде «Нинди матур чия бакчасы бар иде, аны кисteләр», дисә, шагыйрь һәм прозаик инде тәнкыйтьче булып та житешә түгелме? Әмма кисүченең исемен әйтмичә «шома тәнкыйтьче» була инде ул. Әгәр дә инде ул «Шундый матур чия бакчасы бар иде, аны явызларча Айдар Хәлим кырдырды» дип тә жибәрсә, бу «шома тәнкыйтьче» инде, жәмәгать, ут чатнатып торган, хөкем карарлары дәһшәте килгән публицистка әйләнә дә куя, шулай бит? Факты бар!.. Конкрет исем бар һәм йөзгә бәреп әйтелгән! Әгәр дә шушы бер үк кеше булган шагыйрь, прозаик, тәнкыйтьче, публицист шушы «куркыныч» жөмләне курыкмыйча бастырып та чыгарса, бу инде нашир да була дигән сүз. Күпләрнең батырлыгы житәр микән гомер буе мондый кыл өстендә эквилибристик (бу сүзне минем якын дустым, этруск телен үзлегеннән өйрәнгән Нәсим Сәхапов раславынча, «икеле бер уен» дигән төрки-татар гыйбарәсеннән итальяннарга кергән дип исәпли) уеннар уйнап яшәргә?!

Әмма минем яза торган каһарманым уйнап түгел, уйлап эшли торган чын каһарман. Ул гомере буе кешеләргә китаплар чыгарып, үзенең бердәнбер шигырь

китабын нибары 1998 елда, илле яшенә житеп барганда гына, истәлеккә дип кенә чыгарды. Йөз илле шигырьдән торган «Яшьлектән хат»та аны шагыйрь итеп танытырлык мисаллар байтак иде:

*Күрше апа әйтеп хат яздыра,*
*Бер ашыгып тезә... бер тына.*
*«Уйлап йөргән сүзем күп иде дә,*
*Хат яздырган чакта онытыла!..»*

Тормышчан гади һәм шигъри матур. Башка яшьтиләренеке һәм остазларныкыннан бер дә ким түгелме? Ким түгел! Яз гына!..

*Гүя кемдер, изге тәсбих итеп,*
*Сиңа язган хатларымны тезгән... —*
*Тезелешеп очкан кыр казлары!*
*Мин буш оя булып карыйм сезгә...*

Буш оя. Фронттан буш кайткан күз чокыры... Тетрәндергеч күренеш!

Аның, Алпар урта мәктәбенең 9нчы сыйныфында укыган баланың, «Татарстан яшьләре»ндә чыккан беренче гөләндәменә сүз башын әле 1969 елда ук Равил Фәйзуллин язган булган. Үзе дә яшь шагыйрь, аерым бер сиземләү белән ул аңа зур өметләр баглаган: «Алар (М.Вәлиев шигырьләре — А.Х.) яратып кабул итәрлек, уйландырырлык, күңелләренә хуш килеп, эстетик ләззәт китерерлек әсәрләр... Димәк, бүгенге көн кешеләрен, үз замандашларыңны дулкынландырырлык итеп язу өчен, безгә тикле яшәгән бабаларыбыз калдырган хәзинә-мирасны да, бүтән халыклар әдәбиятлары казанышларын да тирәнтен үзләштерергә кирәк...»

Әй, бирелә хәтта шигърияттән тәнкыйтькә дә юл сызылган.

Әйе, төркем-кланга теркәлеп, үзенне мактауга корылган мәкаләләр оештырып, ил алдында бил катырырга, өстәмә су сиптереп, гербицидлар белән ясалма тукландырулар үткәреп, үзенне һәм кешеләрне җәфалап та шагыйрь, кемнәрдер хәтта «халык шагыйре» дә була аладыр ул. Менә ул бит үзе дә шушы хакта яза түгелме: «Яисә шулай да була... Игътибар итә киләсең: берәү артык күзгә чалынмыйча гына шигырь язып маташа, ара-тирә басылгалый да. Язганнарының төп өлеше — балаларның кибеттән «Конструктор» тартмасын сатып алып, әзер детальләрдән уенчык җыюы шикелле үк — яна сүз түгел... Житдигә санамыйсың: андый әйберләр басылгалый инде, мондый шаярулар поэзиядән ерак тора... Житә бер вакыт, — әзер өлге-конструкцияләр белән эш итәргә остарып килүче автор инде үз юлында бернинди тоткарлык күрми кебек... Аны мактап язылган «тәнкыйть» күзгә керә. Хөрмәтле генә агайлар гажәеп жинеллек белән зур-зур сүзләр ычкындыралар, Яна исем, диләр, табыш, ачыш, диләр. Аптырап каласың: чынлап та шулаймы соң?»

Ул прозаик булудан да баш тартты. Тәнкыйте публицистик кайнарлык белән сугарылса да, ул «факт-фамилияләрне атап», җәмгыять чирләрен турыдан-туры дәвалау белән шөгыльләнгән прагматик газета-журнал публицистикасына кереп батмады. Бу аның эше дә түгел иде. Ул тумышыннан барлык бөтенлеге белән нечкә әдәп, такт, беллетризм белән сугарылган тәнкыйтьче-мәгърифәтче иде. «Без прозадан да хисләр чынлыгы, хәрәкәтләр чынлыгы эзлибез, — дип язды ул, үзен бер гаепсезгә акларга теләгәндәй. — Документаль әсәрләрнең күтәбрәк алынуы, кулдан-кулга йөртеп укылуы тикмәгә генә түгелдер. Галәм тормышы өчен шәхси җаваплылык турында чиләк төбе кагу төсендәге купшы юлларга кем мохтаж?» Минемчә, бу бераз кискенрәк әйтелгән. Мин үзем, мәсәлән, шагыйрь һәм публицист буларак, бу очракта тәнкыйтьче белән килешеп бетмим. Безгә XX гасыр азагында-XXI гасыр башында теле, сюжет-динамикасы, образлар системасы ярлыланган, купшылыгы — әфисәрләрне, буш-көпшәклеге белән салам-сенажны хәтерләтә башлаган, үз-үзебез белән сокланууга корылган «әдәби продукцияне» мендәрдән тузан каккандай кага торган «чиләк төбе» трубадурлары да кирәк иде.

Әдәби тәнкыйть алдында янару бурычы торса да, проблемаларның «исем-

адресларын әйтеп» янарту бурычына жигелүче «неистовый Белинскийлар» табылмады. Ул елларда М.Гайнуллин, Х.Госман, Г.Кашшаф, И.Нуруллин, Н.Юзиевләргә алмашка килгән Р.Мостафин, Ф.Мусин, Т.Галиуллин, А.Әхмәдуллин, Х.Миннегулов, Ф.Миннуллин, Ф.Галимуллиннарга инде безне куандыра-куандыра яңа бик көчле яшь тәнкыйтьчеләр буыны: Р.Мөхәммәдиев, Равил Рахмани, Ләис Зөлкарнәй, Вәли Мансур-Баржылы, Наис Гамбәр, Әхмәт Сәхапов, Галимҗан Гыйльманов, Әлфәт Закирҗанов һәм безнең сүз алып барган мөхтәрәм кардәшебез Мөдәррис Вәлиев һәм башкалар килгән иде.Тәнкыйтьче — берәмлекле тауар. Алар да, бер шагыйребез әйтмешли, арысланнар кебек, гадәттә, өерләре белән йөрмәсә дә, бу юлы Аллаһ ярдәмендә өерләре белән күктән төшкәннәр иде. Аларның һәркайсында татарның Белинские булырлык кодрәт бар иде. Без әдәби йортыбызны өмә ясап җиләтергә тиеш идек. Әмма, әмма... Ренессанс булмый калды. Ләкин алар арасында Равил Рахмани, Мансур Баржылы, Әлфәт Закирҗанов, Галимҗан Гыйльманнар әдәбиятка да, әдәби тәнкыйтькә дә шактый өлеш кертә алдылар һәм кертәләр. Ә менә кертә алмау, мәйданнан югалу сәбәпләрен татарның үзеннән эзләп язган хәлдә берничә томлык маҗаралы әсәр туган булыр иде.

Әйе, югарыда телгә алынган һәр зат, «неистовый» була алмаса да, бурычын заманның җиңел булмаган шартларында үзенчә үтәргә тырышты. Аларның кайберләре, ни кызганыч, бу якты дөньядан китеп тә барды. Урыннары оҗмахта булсын. Әмма аларның һәркайсы фаҗигаи иҗатчы һәм шәхес буларак зур игътибарга, ихтирамга һәм гыйбрәтле сабак алуга лаек.Аларның тәрәзәсендә, телисенме-теләмисенме, бөтен татар халкы чагыла.

Мөдәррис Вәлиев алар арасында иң үзенчәлекле, сирәк затларның берсеДер кебек. Әдип. Әдәп белгече. Интеллектуаль фикер иясе, акыллы вәгазьләр остасы. Сәнгатькяр. Милләте каршында бурычларын үтәп, җәмәгать эшлеклесе, тәнкыйтен яңа, нечкә беллетристик алымнар белән баеткан әдәби публицист — тарихыбызда сирәк нашир, педагог-мәгърифәтче һәм Китап-Абый булып кала алды. «XX гасыр азагында татар балалар китабы» дигән мавыктыргыч хезмәт язып, ул китап фәне буенча галим исемен дә яулады. Әбрар абзый Кәримуллин исән булган булса, әй куаныр иде!..

## II

Бишектән ятим калу, күз карашының бишектән каз бәпкәләренә төшүе аны сабый чагыннан ук гадәттән тыш хиссияти, тиз яраланып, үз кичерешләрен яшерә белүчән, үзенә ышанучан, тиктормас эшчән, җыйнак-тыйнак, йомшак фигыльле һәм башка яхшы, катлаулы һәм каршылыклы сыйфатлар йомгагы итеп тәрбияли. Иҗатының башында ук диярлек ул татар әдәбиятында беренче тапкыр «тамыр тирәнлегән яфрак тоя» дигән яңа вә ачык концепция алып килә һәм үзе үк « Шуңа имән яфракларын соңлап коя» дип белдерә.

Әйе, талантлы кеше — каршылыклы, каршылыксыз кеше шәхес тә була алмый, андыйларның башкалар өчен кызыгы да, тормышка дәгъватлары да юк. Мөдәррис Вәлиев иҗатындагы (бирелә «эшчәнлегендәге» дип әйтәсе килеп куйды) шушы халәтне Нәҗар ага Нәҗми әле 1988 елда ук инде аның хакындагы мәкаләсендә, автор үзе ачкан атама белән, «тирәнлекне тою» дип атаган иде. Ләкин мондый дәрәҗәдәге тирәнлекне тою фаҗигаи чыганаклардан гамәлгә килә. Бишектән төшү — башлангыч сыйныфлардан ук матбугатта басыла башлаган сабый-автор әдәби тәҗрибәдә сирәк очраган феномен —ике исемгә — әүвәлдән курыкмыйча беренчел әдәби кушаматы «Салих Маннапов»ка, аннан гына, ниһаять, үзенең «пашпорттагы» реаль исеме Мөдәррис Вәлиев галиҗәнапләренә хезмәт итә башлады. Моның өчен күпме көч-тәвәккәллек кирәк!.. «Бала чакка кайту кешенең гомерен озайта» дип белдерә ул үзенең бер мәкаләсендә, имештер, әнисенең сүзләрен кулланып. Бу ачыш, хак, әнисенекедер, әмма ул әнисе биргән гомер башыннан, әнисе аскан бишектән киләдер. Мин моның шулай икәнен үземнән беләм. Инде житмешемне узсам да, һаман балачагымнан аерыла алмыйм. Нәрсә язсам да, «монысының сикесе астыннан балачак баш калкытырмы», дип каләмемә куркып тотынам, аларның һәркайсы, кызганычка каршы, мин гомердә укымаган, ишетеп кенә белгән Диккенс

ижаты кебек, олылар турында язган балачакка барып бәйләнеп, «өч аяклы ат» булып чыга. Менә ни өчен тәнкыйтьче Мөдәррис Вәлиев мәнге сагындырачак «үр менгән» әдипләребез Әмирхан Еники, Гомәр Бәширов, Аяз Гыйләжев, Мөхәммәт Мәһдиев, Нурихан Фәттахлар иҗатын «балачакка йөгереп кергән» сукмаклар белән чагыштыра. Әйе, хак, балачагы белән бәйләнеше никадәр көчле булса, әдәбият та шулкадәр көчле, саф һәм садә була.

Каршылыклар йомгагы, дидек. Бу ихластан да шулай. Чын иҗади шәхес — үзе үк каршылык һәм ул аларны, әгәр булмасалар, үзе ясый. Башта укучылар гына түгел, язучылар да аның исемнәре арасында буталып беттеләр. (Нәкъ минем кебек!) Аяз Гыйләжев ана Язучылар берлегенә биргән тәкъдимнамәсендә, әле ничә ел алдан сизенеп, «Без аны көтә идек...» дигән искиткеч нечкә, тирән мәгънәле, алдан күрүчән, кинаяле кәлимә ычкындыра. Көтүен көтә идек тә, әмма... Мөдәррис Вәлиев кебек соңгы дистә елларда бездә бөтенләй күренмәгән, ерткычлыктан ерак, тирән белемле, итагатьле, кешелекле һәм шул ук вакытта таләпчән, принципиаль тәнкыйтьче, язучы турында кайгыртучан, югары мәдәни әзерлекле, азат Татарстаныбызның горурлыгы булып өлгергән «Мәгариф» нәшриятын оештырып, анда ике дистә елдан да ким вакыт эчендә сокланырлык күпме китап чыгарып өлгергән галим-наширны без бер дә «көтеп алгандай» итеп озатмадык бит әле...

Гәрәй Рәхим аны «Сабырлыкның төбенә житкән...оялчан тәнкыйтьчебез» дип атый. Дөрестер. Әмма мондый «рәхмәтсез» авыр эштә оялчанлык илһам да, акча да китерми. Ачуны гына китерә. Биредә шарт-шорт килгән чыбыркы һәм аран кирәк. Заманында Михаил Светлов әйтмешли, илһамны диктатура чыбыркы аша кертә. Мин үзем дә шулайрак уйлыйм.Тәнкыйтьче — һөнәр-профессия, вазифа түгел, язмыш. Тәнкыйтьче, ничек кенә итагатьле булырга тырышмасын, ул күпмедер микъдарда «санитар», «крокодил», — ә крокодил тыйнак вә «оялчан» була алмый. Югыйсә аның үзен «йоталар». Татар әдәби тәнкыйтенең шул «тыйнак оялчанлыгы» аркасында юкка чыгуы, әдәбият, аеруча шигърияткнең ялгыш юлдан кереп китүе турында алда сүз булыр әле. Чын тәнкыйтьче гаделлек, матурлык һәм киләчәк хакына кемнедер утка тота, икенче берәүгә бикләнгән юлны ача. Анардан йомшак бәгырьле диктатор булу, йомшак түшәп каты утырту сорала. Шуңа да безнең шигъриятебез борчак бакчасының киез эшләпәле каравылчысы (яратып әйтәм!) Сибгат абзый Хәким бер дә юкка «мин Мөдәррис Вәлиевнең бераз усал булуының сизелеп торуын телим», — димәгәндер. Әдәбият галиме Азат Әхмәдуллин «Тәнкыйтьче алдына усал булу бурычы гына куелмый бит әле... Яшь тәнкыйтьчене усал булырга чакыру берьяклырак», — дип моңа каршы чыга. Ә менә гомере буе тәнкыйть кадере күрмәгән Нәби Дәүли ана «Рәхмәт хаклыкны яклаучыга!» — дип хатлар яза. Менә бит ничек.Биредә чынлап та каршылык өстендә каршылык. «Мәгариф» нәшриятында миллионлаган данә китап чыгарып, үз китабын чыгарырга онытткан Мөдәрриснең инде үз исемен дә онытып, «Китап абый», «Әбугалисина» дип атаулары, «Мөдәррис Харисович» урынына «Мәгариф Харисович» дип йөртүләре, инде «суверенитет поезды үтеп киткәч», үзе бер мәзәк кебек күренә. Аның тыйнаклыгы турында фикер йөртеп, Равил Фәйзуллин ул заманнарда яшь шагыйрь, тәнкыйтьче, башта «Казан утлары»нда җаваплы сәркәтип, аннан баш мөхәррир урынбасары булып ун ел эшләп, журналда нибары ике тапкыр басылуын бер феномен итеп искә ала. Нигә, Татарстан хөкүмәте Бауман урамындагы легендар Матбугат йортын япкач, барысы авызына су кабып аптыраш торганда, нәшрият директоры кебек «номенклатурщик»ның, дөньясын онытып, барлык хезмәткәрләрен эшкә жигеп, кырыкка якын автордан истәлекләр яздырып, мәдәни тарихыбызда мәнге сагынычлы «Матбугат йорты — гомер китабы» дигән проектны тормышка ашыруы үзе бер феномен түгелмени? Аның бер китапсыз, бары тик матбугатта чыккан мәкаләләре белән генә Язучылар берлегенә кабул ителүе шушы каршылыклар бердәмлегенең тере бер чагылышы түгелмени? Татарстан Язучылар берлегенең кабул итү комиссиясенең Мөдәррис Вәлиевне Берлеккә кабул итүгә багышланган утырышында чыгыш ясап, аксакалыбыз Сибгат абзый Хәким, «Аның мәкаләләре кызыклы, проблемалы, язучыларның иҗатына тирән үтеп керә белә, бәяләре

дәлилле, ышандыргыч, — ди. — Ул күбрәк шагыйрьләр, поэзия турында яза. Күрәсең, үзенең дә шагыйрь булуыннан киләдер...».

Чорыбыз тәнкыйтенең «бабасы» дип исәпләнгән Рафаэль Мостафин исә Мөдәррис Вәлиевне «соңгы елларда тәнкыйть өлкәсенә килгән яшьләрдән иң талантлысы, өметлесе» дип атый. Нил Юзиев исә аның мәкаләләре «әдәби әсәр кебек мавыгып укыла», дип өсти. Аяз Гыйләҗев яшь әдипнең югары эстетик зәвыгына басым ясап, ул «татар әдәбияты хәзинәсеннән иң көчле әсәрләрне төпле итеп сайлап ала белүең» искәртә һәм, әйткәнемчә, «Без аны көтә идек...» дип тә өстәп куя. Фәрваз Миңнуллин «...ихтирам саклап, турысын әйтеп бетермәгән чаклары булгалый, — ди, — кайвакыт артык матурлап язарга омтылышы сизелә, мин моны шулай ук бетерелергә тиешле кимчелек дип саныйм..» Тәлгат Галиуллин «...Мөдәррис утыз яшендә Союзга керә, — дип билгеләп. —Бездә тәнкыйтькә яшь чактан ук үз йөзеңне табып килү еш була торган хәл түгел...» Менә бу хактин-хак нәрсә. Гомумән, булмаган хәл дип әйтер идем мин. Һәм һич арттырмыйча шунысын да өстәр идем: әдәби тәнкыйть — эстетика, этика һәм философияне кушкан матурлык-әхлакъ фәне. Мөдәррис Вәлиев үз иҗатындагы «Ачы әрем исе», «Тәллитут», «Хәтер», «Тапшырылмаган хатлар», «Чынлап та шулаймы соң?» кебек сискәндергеч әсәрләре белән шушы әхлак фәненең мина билгеле атаклы осталары Виссарион Белинский, Николай Чернышевский, Фридрих Энгельс, Анатолий Луначарский, татардан Галимҗан Нигъмәти, Гомәр Гали, Гали Рәхим, Габдрахман Сәгъдиләрнең эстетик ачыш-эзләнүләрен искә төшерә.

### III

Мөдәррис Вәлиев яратмыйча яза алмый. Ул хәтеребезнең тирән һәм өзлексез тере булуын тели. Әдәбиятның миссиясен дә шунда күрә. Бер үк вакытта шул ук ярату ана үзе анализлап әсәрләрнең житешсез якларын яшерергә, «күрмәскә» дә ярдәм итә. Аларга башкаларга «ямьсез күренмәүдә» булыша. Тик шунысы куанычлы, ул «яратып кына» чикләнми, бер үк вакытта язмыйча кала да алмый. Куану — аның вазифасы. Кеше өчен куана белү, гомумән, Аллаһтан төшкән рәхмәт. Тәнкыйтьче өчен «почти күрелмәгән сыйфат». Кайвакыт ул мина офыклардан офыкларга очкан шоңкар булып күз алдына килә: әгәр ул өлгерә алса, тере табигатьтәге һәр үлән кыягы, һәр җанвар, үткән һәм бүгенге татар әдәбиятының һәр вәкиле, аларның һәр әсәре турында язган булыр иде. Ул ярата, тик яраткан әсәргә карата тәнкыйди фикер белдерү ана читен эшкә әверелә, ул чирли, ана авыр, гүя әйтергә ярамаган сүз — гөнаһлы эш, аны әйтсә, ул кемнедер рәнҗетер кебек. Бу шәхеснең эчке холкы, тәрбия кодексы, кешелеклелек, гуманистик караш чыганакларыннан килә. Бу хакта ул үзе дә яшерми: « Әйе шул, һәр тәнкыйтьченең эчендә тагын бер тәнкыйтьче утыра бит әле. «Личный», «лирик» тәнкыйтьче дигәндәй... Язганда, ул сине кисәткәли тора: фикереңне ипләбрәк әйт, тамырына балта чабу булмасын, төп тонны берүк басып китмәсен! Алга таба сүзләр «түгәрәкләнә», шомара, димәк, тагын бераз йомшара... Укучыга тәкъдим ителгәндә инде мәкалә кулдан тере балык кебек шуып чыга. Тәнкыйтьче үзе аптырап кала...» Бәй, безнең татар әдәби тәнкыйтенең эчке лабораториясен ачып салган бит бу!..

Тәнкыйтьчедә туган әдәбият — үзен үстергән ана турында кайгырту беркайчан да юкка чыкмый. Ул — гомерлек кизүдә. Агымдагы татар әдәбиятын гына түгел, күрше әдәбиятлар, беренче чиратта замандаш рус, украин, чуаш, якут һәм башка әдәбиятлар вәкилләренең күренекле әсәрләрен тизрәк күрергә, алар турында беренче булып аваз салырга тырышуы да менә шушы туган әдәбиятыбызны мөмкин кадәр баету, аны башкалардан ким-хур итмәскә тырышу кебек гуманистик теләкләрдән чыгып эшләнә. Безнең тәнкыйтьтә Чыңгыз Айтматовның, Валентин Распутинның, Виктор Астафьевның атаклы романнарын беренчеләрдән булып Мөдәррис Вәлиев әйләнешкә кертте дисәк тә хактыр. Менә шундый кайгырту нәтиҗәсе инде ул. Сарыүзәк далаларында анасының йөрәгенә аткан Мәнкорт — гүя биш гасыр буе Хәтердән читләттерелгән татар баласы, аның башына кигезелгән яшь дөя тиресе гүяки Явыз Иван тарафыннан кара кышта Казаннан

куып чыгарылган татарлар ыруы, жимертелгән мәчетләр, тәрегә борыны төртелгән авыллар иде. Распутинның Анна апасы белән Әмирхан Еникинең Акъәбисе, диннәренә һәм милләтләренә карамастан, гүя икесе бер тамырдан чыккан ике кыяк: аларга кояш яктысы житмәүдән, куылудан ясалган моңсагышлар эленгән. Тәнкыйтьче скальпель белән кеше хәтереннән «кайтарылган» (фәлсәфәдә «кайтарылу» — «отражение» теориясе) күренешкә сирәк операция ясый. Жир йөзендә хәтергә ясалган операциядән дә җаваплы гамәл юк. Һәм әдәби тәнкыйтьнең бурычы — кеше хәтеренең изгелеккә явызлык белән түгел, изгелек белән җавап кайтаруына ирешү, кайчандыр тупас көч белән тартып алынган мәхәббәтне бәйсезлек-суверенитет өчен сугышлар аша гына түгел, ә иман, ярату, тигезлек-туганлык аша да яулау. «Наркоз бирмичә яру» — операция ясауга тиң гамәл бу, — ди тәнкыйтьче. — Эшләнми калган игелек, тирән үкенеч тойгысы белән ваемсыз геройларын гына түгел, безнең һәммәбезне дә газап утына салалар алар. Әлеге әсәрләрдән безгә: «Кыска хәтерле булмагыз, рухи һәм әхлакый сафлык чыганакларына юлны онытмагыз!» — дигән өндәү авазы ишетелә», — дип гомумиләштерү ясый ул.

Мөдәррис Вәлиев кешелек табигатендә намусның мәңгелек хлорофиллын эзли. Ул намус һәм әхлак лабораторияләрендә хәтер имтиханнары үткәреп, Ә. Еникинең «Әйтелмәгән васыять», «Соңгы китап», Шәриф Хөсәеновның «Әни килде», Аяз Гыйләжевнең «Жомга көн кич белән», Мөхәммәт Мәһдиевнең «Без кырык беренче ел балалары», «Фронтовиклар», Нәби Дәүлинең «Яшәү белән үлем арасында»сы һәм башка дистәләгән язучыларыбызның романнары, повестьлары, хикәяләренә барлык дөнья әдәбияты биеклеге таләпләреннән чыгып анализ ясый һәм шундый куанычлы фикергә килә: татар әдәбияты башка тугандаш әдәбиятлардан ким түгел. Тәнкыйтьчене бер генә жанр да куркытмый. Ул Мостай Кәримнең «Озын-озак балачагын» да, Адлер Тимергалинның фантастик әсәрләрен дә, Әхәт Гаффар хикәяләрен дә, фронтовик язучы Хисам Камал романнарын да бертигез сөйкем белән тикшерә. Аңардан беркем дә читтә калмый. Хәтта кичә генә беренче хикәясен язган сабый да игътибар үзәгенә алына.Тик, ни кызганыч, ул безне оялта гына алмый. «Тикшерә» дигән үтә дә «гомуми» сүз уңаеннан бер ачыклау кертик. Мөдәррис Вәлиевнең тәнкыйди иҗаты белән якыннан танышкач, мин таң калдым: ул барлыгы өч йөзләп татар язучысы һәм шагыйренең әсәрләрен телгә алып, һәркайсына аерым тукталып анализлаган икән. Күпме көч, нинди колач!..

Әйе, хак, ул беркемне онытмый. Аның өчен классиклар да, башлап язучылар да «юк».Аның өчен һәр язучы — әдип. Һәм ул әдиптән бары тик образлар гына таләп итә. Әйе, кемнәргәдер язучы булып исәпләнү өчен Язучылар берлеге әгъзасы булу да җитә. Юк, җитми икән шул! Бу – җаваплылыкның саплам башы гына. Язучы булган кешенең үз әсәрләрендә нинди образлар тудыруы мөһим.

Ул шагыйрьләр һәм шигърият турында аеруча күп яза. Иң яратканы, кумирлары, әлбәттә, — Габдулла Тукай, Такташ, Туфан һәм Сибгат Хәким. Габдулла Тукайдан ул махсус аркан баскычлар буйлап, каты кагылмыйча, иплəп кенә Равил Фәйзуллинга да, Рәдиф Гаташка да, Гәрәй Рәхимгә дә, Рөстәм Мингалимгә дә, Ренат Харискә да, Рахмай Хисмәтуллинга да, әлбәттә, безләрдән яшьрәкләргә — Мөдәррис Әгъләм, Зөлфәт, Фәннур Сафин һәм башкаларга да төшеп җитә... Башкаларга булган игътибар безне дә җылыта.

Бу унайдан бер сагынычлы нәрсә хәтергә төште: 1968 елда мин Университет һәм Татарстан Язучылар берлеге юлламасы белән Түбән Камага килеп төпләнгән идем һәм Рахмай Хисмәтулла белән берлектә «Кама таңнары» дигән әдәби берләшмә оештырган идем. Шул чорда комбинатта слесарь булып эшләп йөргән Фәннур Сафинның беренче шигырьләренә сүз башы язып, Вәгыйзь Зәйнетдинов җитәкләгән «Нефтехимик»газетасында бастырып чыгарган һәм Мисхәт Хәбибуллин дигән бик талантлы яшь шагыйрь белән икесен Казанга алып килеп, телевидениедән чыгышларын оештырган идем. Хәзер инде аларның берсе дә юк. Кайда алар? Аһ, китеп барганнар! Нигә алай иртә?! Мин боларны тәнкыйтьчедән дә сорыйм. Ул мина «Чынлап та шулаймы соң?» дигән хезмәтендә, «Шигырьнең

дәрәҗәсен төшерүче сәбәпләр күп», дип җавап бирә. Әмма артык эчкә керми. Мин анардан безнең шигърият, әдәбият тәнкыйтенең дәрәҗәсен төшерә торган сәбәпләрне сорыйм. Ә ул миңа һаман «куллан шуып чыккан шамбы балыклары» турында бер нәрсәне талкый: «Без, ихтимал, ул сәбәпләрнең кайберләрен —иң өстә ятканнарын гына күрәбездер әле. Чынлап та, тулы бер китаптан, зур шигырь бәйләменнән ни өчен санаулысына, аерым юлларга гына тукталасың, игътибар итәсең, тәэсирләнәсең, истә калдырасың?..» Мәсьәлә анда түгел бит. Шигырь әнә шул бер юлда ачыла да инде ул. Шагыйрьләр дә, шигърият тә, хәтта әдәбият та шулай. Айтматовның Мәңкорты, Еникинең Әкъбисе ачылган кебек. Татарга тарлыгыннан, көнчелегеннән, өер психологиясеннән, әйтеп үткәнчә, нәкъ шул татар мәңкортлыгыннан котылырга, безгә бер-беребезне күрә, күтәрә белергә кирәк. Әнә шулай «күрә белмәү» күрә алмаучылык, «дошманлык» чиренә әйләнә дә куя. Тора-бара ачышлар күмелә, әлбәттә, алар милләтнең язмыш ташына яктылык булып ятмый, башкаларны үстерми, әдәбият бер урында таптана, үзен-үзе изә, ваклана башлый. Яңа исемнәрне күрмәгәч, яңа җисемнәрдән җил исми. Яфрак селкенми. Застой, торгынлык дигән күренеш иң яхшы халәт булып «торгынлаша».

Үткән гасырның алтмышынчы елларында әдәбиятка килгән шагыйрьләр белән шулай булмадымыни? Безне «нииндидер» яшерен көч икегә, дөресрәге, өчкә бүлде. Шигъриятебез «телгә алырга яраган», «урталыктагы» һәм «телгә алырга ярамаган» «обоймаларга» бүленде. Бу хәл Мөдәррис кардәшем Вәлиевнең «Гамәл дәфтәре» дигән искиткеч дөрес исем бирелгән китабында аеруча яхшы чагыла. Китап башыннан азагына кадәр ул елларда «телгә алырга яраган» «обойма» иярәренә багышланган. Сүз дә юк, алар – соңгы утыз-кырык елда шигъриятебезне тотып торган талантлы авторлар. Бүген инде — тере классиклар. Бу — зур куаныч. Әмма мин, табиган, китап буенча үзебезне, ул заманда «телгә алудан тыелган», яисә «телгә алмаган хәлдә яхшырак булган» исемнәрне эзләдем. Алар биредә юк иде. Яшермим, үземне күрергә теләп түгел, тарихи дөреслек, гаделлек хакына ул елларда, әле алтмышынчы елларда беренче булып милләт учагына кереп канатларын көйдергән бөркет кебек, теләсәм-теләмәсәм дә, сул күзем булса да, үз исемемне күзәткәләштерде. Юк идем. Монда «колмак җыйган кызлар» да, «Беренчеләр»нең туңган тәзүчеләре дә, «Чернобыль»нең атом нурыннан көйгән халкы да, «Палестина качаклары» да, «Өч аяклы ат»лар да, «Сагыш китаплары»да, «Хунвейбин»нар да кирәкми иде... Ә аларны да күрәсе килә, шайтан алгыры. Адәм хезмәте бит. Мактану, макталу өчен түгел, милләт тәрәккые өчен. Дан туртасы эчәсе килүдән түгел. Биредә бөдрәлек бар, әмма без генә юк идек. Әмма бөдрәләнеп кенә әдәбиятны матурлап, бөтенләп булмый. Мин бу китапта укытучыбыз, яшьлегебезнең кумиры, бөек шагыйрь Роберт Әхмәтҗанны, әдәби агымга юнәлеш биргән дусларым, искиткеч зур талант ияләре —шагыйрьләр Рәшит Әхмәтҗанов, Кадыйр Сибгатуллин, Рифгать Закиров, Зиннур Насыйбуллин, Булат Сөләйманов, Разим Вәлиуллин, Рим Идиятуллин, Фәрит Габдерәхим, Эдуард Мостафиннарны таба алмадым. Әле болар хәтергә төшкәннәре генә. Кайда аларның иҗатларына бәя? Әдәбият тарихы томнар, фолиантлар белән түгел, еш кына бер әсәр, бер шигырь белән байый. Нәтиҗә нинди? Нәтиҗәбез күз алдында, яисә каберда. Их, дидем мин үз-үземә, әгәр дә без барыбыз да бер йодрык булып тупланган, бердәм бәяләнгән, бердәм көчкә әйләнгән булсак, безнең шигъриятебез генә түгел, тоташ әдәбиятыбыз дә, үзебез дә икенчерәк булган булыр идек. Һәм мин тагын да сүзне тәнкыйтьчебезгә бирәм: «Бәлки поэзиядә... юк, поэзиядә генә түгел, прозада да, драматургиядә һәм тәнкыйтьтә дә дөньякүләм әйберләр хакында сүз куертып, аяк астындагы туфракны онытып җибәргәләү, җирдән аерылу, нииндидер бөҗрага бикләнү, йомылу —менә шундый тормышның үзендәге сәер хәлләргә иш булып чыкмыйбыз микән?»

Әйдәгез, йомылмыйк. Әйдәгез, бикләнмик. Әйдәгез, барны күрик, күрсәтә белик. Бездән соң килгән яшь буынга матур үрнәк күрсәтик. Милләт тә, хөрмәт тә, үрнәк тә исән-сау булыр.

## VI

Мөдәррис Вәлиевнең күрсәткән иң зур җегетлеге, чын каһарманлыгы — ул татар китабы, аның балалар китабы флагманы булып оешып, олуг эшләр башкарып, «Мәгариф» нәшриятының җитәкче-нашире, галим-мәгърифәтче буларак тарихка керүендә. Сез 1950—1990 елларга кадәр илгә бушлай миллиардларча тонна «кара алтын» биреп, үзенең китапларын селедка төрә торган кәгазьгә басып чыгару белән килешеп яшәгән чорларны күз алдыгызга китерегез. «Мәгариф» нәшрияты кебек татар милләте балаларына хезмәт итәчәк нәшриятны ачу-оештыру өчен күпме көч исраф итүебезне исәпкә алсагыз иде. Болар берсе дә заяга китмәде. Аллага шөкер. Нәшрият башына нәкъ шундый хәерле урында, хәерле сәгатьтә маңгаен фәрештәләр якты каурый белән сыпырган иманлы кеше — тәнкыйтьче, нашир, галим-педагог Мөдәррис Харис улы Вәлиев килде. Килде һәм үзе кебек якты биналар табып, үзе кебек якты мөхәррирләрдән торган якты коллектив оештырып, татар милләтенә татар тарихында булмаган ЯКТЫ КИТАПНЫ бүләк итте. Бу ике сүз бары тик зур хәрефләр белән язылырга хаклы. Бу елларда татар балалар китабын бастыруның фәнни системасы, милли идеологиясе барлыкка китерелде. Унар мең тираж белән бар дөнья укучысын таң калдырырлык «Хәзерге татар әдәбияты», «Балачак әдипләре», «Балачак энциклопедиясе», «Татар шигърияте» кебек серияләр, дистәләгән дәреслекләр, фразеологик, миллият, Тукай сүзлекләре өстәлгә ятты. Татар баласының күзе ачылды. Мәктәпләр мондый җәннәткә ышанмый торды. Татарстан хөкүмәтенең бу чорда татар баласына биргән куәте бәяләп бетергесез. Болар бит «Мәдәни җомга», «Шәһри Казан», «Мәгърифәт» газеталарына, «Аргамак», «Идел» журналларына канат куйган өметле заманнар иде. Шунысын гына әйтү дә җитә: чагыштырмача кыска вакыт эчендә «Мәгариф» нәшрияты милләтебезгә тирән уйланылган программа буенча 2000 исемдәге 20 миллион данә китап бүләк иткән. Бу чын каһарманлык иде. Ул Рәсәй Федерациясендә иң зур нәшриятларның берсенә әверелде. Һәм... табанның төбе көя башлады. Иң беренче булып аны татар үзе көйдерде. Нашир Мөдәррис Вәлиев өстеннән югарыга шикаятьләр агылды. Үзәккә, татарның үз кулы белән, аны яптырырга кирәк иде.

Һәм нәшриятны яптылар да.

Әйе, ул унтугызынчы гасыр азагы — егерменче гасыр башында «Болгар нумерлары»нда, Тукай йолдызлыгында туып яктырып куйган, әмма большевиклар хакимиятендә юкка чыгарылган «Мәгариф» нәшрияты иде. Мөдәррис әфәнде Вәлиевкә үзе туплаган коллектив белән бергә аны янадан гамәлгә кую бәхете тиде. Реформатор иң сабыр, тыйнак, гади, керсез юл белән революция ясады да куйды. Аны «күрми калдылар».

Әмма татар китабын болай гына бетереп-үтереп булмый. Мөдәррис Вәлиев җитәкчелегендә «Мәгариф»нең талантлы коллективы чыгарган китаплар татарга хезмәт итүен дәвам итә. Көн килер, барысы да үз урынына кайтыр.

Аяз абзый Гыйләҗев әйтмешли, без аны көтәбез.

Хисаметдин
Исмәгыйлев

# КЫРЫМ ТАТАРЛАРЫ ФАҖИГАСЕ

Тик бу шигырьдә капиталист таможнигынын егерменче елларда совет паспортын кулына алганы сурәтләнә. Ә бит шул ук кызыл тышлы паспортны Совет чиновнигы әле генә куркуыннан идәнгә төшереп җибәрде. Менә шулай, туганым. СССРда, аның калдыгы Россия дә — парадокслар иле. Без Үзбәкстанда төрле милләт кешеләре бертуган булып яшәдек. Ә менә хәзер үземнең төп Ватанымда, әти-әниләр, бабай-картәтиләрнең кендек каннары тамган җирдә мин— чит. Үз илем дип йөргән илдә мин — килмешәк, үги бала хәлендәмен. Кайсы гына «өлкән агайлар» күпләп яшәгән өлкәгә барма, без анда килмешәк хәлендәбез. Безнең белән балаларны куркыталар. Алар үзләренең нинди гөнаһ, нинди коточкыч аламалыклар эшләгәннәрен беләләр. Шунардан куркалар. Без Кырым татарларыннан түгел, ә үзләренең безгә карата нинди геноцид эшләгәннәрен исләренә төшерүдән куркып, тагын да аламарак гөнаһлар кылалар.

Шунда мин дә үҗәтләнеп:

— Нигә минем паспортны алай атып бәрәсез. Бу паспорт минем шәхси документым гына түгел, бу — Совет паспорты! — дим, бик каты гына.

Теге калтыранган куллары белән иелеп идәннән паспортны сак кына алды да:

— Без сезнең паспортны терки алмыйбыз. Сез Кырым татары бит. Безгә сезнең милләт кешеләрен теркәргә катгый тыела. Өстән күрсәтмә бар. Урысча яхшы сөйләшәсез, шуңа да мин сезне урыс милләтеннән дип торам, — ди. Тирән итеп тын алды да:

— Мин сезгә берничек тә ярдәм итә алмыйм. Бездән югарырак органнарга мөрәҗәгать итегез. Ә гомумән, монда нәрсә эшләргә уйлыйсыз? — ди бу.

— Эшкә урнашырмын. Минә дүрт баланы үстереп аякка бастырырга кирәк.

— Монда үзебезнекеләргә дә эш юк.

— Үзегезнекеләр кем дә, читләр кем? Мин дә совет гражданины бит. Хөкүмәт эш бирмәсә, бакчамда бәрәңге, помидор үстерермен, — дим.

Бу инде уйлый алырлык хәлгә килде, ахры. Һәм мина:

— Сатарга бәрәңге, помидор үстерү, бигрәк тә теплица ясап сатарга үсентеләр үстерү «нетрудовой доход»ка керә. Сезне хөкем итәргә мөмкиннәр, — дигәч, тәмам ачуым кабарды:

— Сез пропискага теркәмәсәгез дә, хәттә эш бирмәсәгез дә, без хәер сорашып, теләнеп йөрмәячәкбез. Урлашмаячакбыз да! Без андый халык түгел.

Шулай дидем дә, кулыннан үрелеп, паспортымны тартып алдым, бүлмә ишеген шапылдатып ябып чыгып киттем. Ә бит тышта житмеш алтынчы ел. Ничек итсәм иттем, район үзәгеннән ерак түгел, иң артта калган бер колхозга барып эшкә кердем. Эшкә алмыйча булдыра алмыйлар. Эшче кул җитешми. Барсы да бу колхозны ташлап качалар. Шуннан урындагы паспорт өстәленә барып, паспортым арасына йөз тәнкә акча кыстырып(шулай кинәш бирделәр), паспортистка хатынга сузам. Илле тәнкәмне кире кайтардылар. Паспортны кире кулыма алганда теге илле тәнкәне күреп калдым да:

*Ахыры. Башы узган санда.*

— Бусы да сезгә, — дигән булам.

— Юк. Безгә иллесе дә җитә. Сезнең балаларыгыз дүртәү бит. Монысы өчен дә оят. Әмма бездән өстә дә түрәләр утыра шул, — диде бу.

Апам сөйләвеннән туктап кеткелдәп көлеп алды.

— Мөгаен, Кырым татарларыннан иң беренчеләр булып кайтканбыздыр инде, туганым.

Шулай сөйләшә-сөйләшә чәй эчәбез. Диләвир абзыйга сүз кушып карыйм, әмма абзыемның сөйләшергә исәбе юк кебек. Ләкин мин үземнең эш дәверемдә нинди генә дәшмәс кешеләр очратмадым да кемнәрне генә сөйләндереп, күңелләрендәге яшерен серләрен әйләндереп тышка чыгартмадым. Әле дә шулайрак булды. Апа кирә-чыга чәй тәм-томнары ташыганда, Диләвир абзыйның колагына иелеп, тавышымны әкренәйтеп кенә сорап куйдым:

— Апа белән ничек, кайларда танышып күрештегез? Мөгаен, онытып та бетергәнсездер әле?

Абзыем сәер сораудан аптырапмы, әллә минем бер күземне кысып алып, апа чыгып киткән якка баш кагып ымлавымны күрепме, үзе дә елмаеп җибәрде дә, тавышын әкренәйтә биреп минем колакка:

— Аны онытып буламыни. Әлбәттә, хәтерлим. Кичә генә танышкан кебек без, — диде, авызын ерып.

Мин инде абзыйның бу елмаюын кулымнан ычкындырмадым:

— Ә ничек булды соң бу?

Абзыем тотлыга биребрәк һәм ничектер кыенсынып, тавышын әкренәйткән көе сөйләп алып китте.

— Мин... ул ча..кта ниф..те һәм газ рразведкасында эшли идем. Үзебезнең егетләр белән кичләтеп кенә Лидиә апаннар яшәгән авылга килеп төштек. Яшьләр клуб алдында төрле уеннар уйныйлар. Без дә киенеп-ясанып клуб алдына килдек. Уенга кушылып киттек. Менә шул уенда беренче тапкыр мин аны күрдем. Күрдем дә, күз аттым. — Абзыйның сөйләгәне апага да ишетелде булса кирәк. Төрле тәм-томнар күтәреп килгән Лидиә апа сүзгә кушылып:

— Юк, ин тәүдә мин аны үзем күреп алдым. Ул башкалардан ничектер аерылып тора иде, — диде.

Диләвир абзый:

— Әйтәм, кырыңа мин килеп баскач, миңа елыша идең. Мин күз кыскач, бөтенләй эреп киттең, — дигәч, көлешеп алабыз. — Ул чакта яшьләр «өченче артык», ягьни урысча әйтсәк — «третий лишний» дигән уен уйныйлар иде,— дип, абзый сөйләвен дәвам итә. Тик ул сүзләрне ничектер кыенлык белән әйтә. Абзыйга күптән түгел генә инсульт булган икән. Сөйләшми утыруы да шуннан икән. Мондый хәл ачыклангач, мин Диләвир абзыйга киңәшләремне бирәм. Һәм аңа күбрәк сөйләшергә кирәклеген аңлатам, сихәтле күнекмәләр ясарга өйрәтәм. Шулай итеп, Диләвир абзыйны да җайлап-көйләп әңгәмәбезгә ияртеп алып кердем.

Диләвир абзый болайрак дип хәтерли икән теге хәлләрне.

— Мин 1935нең гыйнвар аенда туганмын. Әти сугышта. Без гаиләдә дүрт бала: өч кыз һәм мин. Кара таңнан безне уятып, авыл очына җыйдылар. Өч көн буена машина көттек. Ашату дигән нәрсә юк инде. Кем нәрсә эләктерә алган, шуны ашыйлар. Күпләр коры ярма чәйниләр. Безгә бит ашарга алыгыз дигән кеше булмады. Машиналар килгәч, төяп тимер юл стансасына алып барып, вагоннарга тутырдылар. Поездда ничә көн барганыбыз хәтердә юк. Әмма Сарытау (Саратов) стансасында бик яхшы итеп ашаттылар. Ботка өстенә чокыр ясап май салып биргәннәре әле дә хәтеремдә. Тәмле, бик тә тәмле иде ул ботка. Нык ачыккан булганмындыр инде. Ничәмә еллар үтүенә карамастан тәмен әле дә тел очымда тоям.

Шулай безне Үзбәкстанның бер кышлагына алып килделәр. Һәм сакларга ике бабайны куйдылар. Ул вакытта без бала-чагага алар бабайлар кебек тоелган инде. Без сугышны күргән малай-шалайга кызык. Чөнки теге ирләрнең кулында агачтан юнып ясалган винтовкалар. Имеш, безне саклыйлар. Халыкка якын җибәрмиләр. Бездән уттан курыккан кебек куркалар. Азактан гына белдек, без килер алдыннан халыкка коточкыч нәрсәләр сөйләп киткәннәр. Имеш, безнең һәрберебезнең

танавында зур-зур алкалар. Мөселман исәпләнсәләр дә яшь балаларны тотып көчлиләр, аннан үтереп ашыйлар, имеш. Ирләре кызлары белән, аналары уллары белән йоклыйлар. Сезнен белән дә якынаерга тырышырлар, арагызга кертмәгез, янәсе. Шунын аркасында урындагы халык белән озак кына аралаша алмый яшәдек. Тик безнең өстә торган коллык балтасы ул барыбыз өчен дә бер инде. Үзбәк ни дә, урыс ни дә, татар ни. Барыбызга да тормыш авыр. Ә безгә мең тапкыр авыррак. Чөнки без — куылганнар. Һәм нинди яман исем тагып әле. Имеш, сатлык җаннар. Исәпләп карасаң, ул сугышта сатылганнар урыста күбрәк тә булгандыр әле. Генерал Власов теге якка армия кадәр армияне алып чыккан әнә. Дон, Кубань, Терек казаклары арасында булмадымы алар? Украиннарда юкмы? Сталинградта пленга эләккән Фельдмаршал Паулюсның шәхси тылмачы Украинаның бер комсомол обкомының беренче секретаре булган түгелме?

Куып китерелгәннәрне элекке ниндидер төрмә баракларына урнаштырдылар. Безгә өч метрга дүрт метр зурлыктагы бүлмә эләкте. Әниләр совхоз җирендә мамык үстерәләр. Ул елны мамык күп булды. Кыш суык һәм карлы килде. Үскән мамыкны җыеп ала алмадылар. Ә безнең кышкы киемнәр дә, итекләр дә юк. Әниләр тездән кар ерып мамык җыялар. Әнинең аягында ниндидер машина тәгәрмәче покрышкаларыннан теккән агач табанлы ботинкалар. Аны төшеп калмасын өчен аякка бау белән бәйләп куялар. Эштән кайткач, әни менә шул «ботинкаларны» үзе бавын чишеп сала алмый. Мич кырына куеп эреткәч, бауларын без балалар чишеп салдырабыз. Әни ярты төнгә чаклы җылына алмый. Эшкә бармас иде, безнең тамакны туйдырырга кирәк.

Әти безне кырык алтынчы елны гына эзләп тапты. Шуннан тормыш күпкә яхшырды.

Аннан Лидия ханым сүзгә кушыла:

— Безнең дә әти шул кырык алтынчы елны безне эзләп тапты. Шуннан төрле урыннарга язып, әнинең апаларын эзләргә тотынды. Аларны табып, безнең кырга күченергә ярдәм итте. Апалар Свердлау өлкәсендә урман кискәннәр. Кырык җиденче елны Үзбәкстанга килделәр. Бер бәләкәй генә төрмә «фатирында» ун кеше яшәдек. Ничек сыйганбыздыр инде?

Апа тагын нәрсәләрдер исенә төшереп, күңелсезләнеп китте. Шунда Диләвир абзыйның килене Зиләрә табынга янә ниндидер тәмле сыйлар алып керде. Җаен туры китереп:

— Ә сез нәрсәләр әйтерсез менә шушы әниеннәр сөйләгән хатирәләр турында, — дип, аңа да дәшәм. Зиләрә татар киленнәренә хас оялчанлык белән кызарып китте дә сораулы карашын Лидия ханымга күчерде. Каенанасы килененә генә аңлаешлы ишарә белән рөхсәт бирде шикелле. Диләвир абзый да:

— Аларның әти-әниләре дә безнең кебек депортированныйлар. Сөйлә, кызым, сөйлә, — дигәч, Зиләрә ханым:

— Без үзебез ногай татарларыннан булабыз, — дип сөйләп китте. — Картәти дә, картәни дә. Картәниләрне алып китәргә килгән солдат бик яхшы кеше булган. Кешелекле кеше. Картәнигә әйткән:

— Әби, бик алама эшләр. Сезне хәзер бик ерakларга алып китәчәкләр. Шуңа күрә тормыш көтәргә иң кирәкле һәм иң кыйммәтле әйберләрегезне генә алыгыз, — дигән. — Иң кыйммәтле әйберләрегезне генә алырга тырышыгыз, — дип кабатлап та әйткән. Шуннан картәни алка-йөзекләрен, чулпыларын һәм «Зингер» тегү машинасын төреп ала. Башка өйләргә кергән солдатлар кешеләргә кирәк-ярагын төйнәп алырга да ирек бирмәгән. Өйләреннән мылтык приклады белән төрткәләп чыгарганнар. Кайтырга рөхсәт булгач та картәниләр, картәтиләр күп михнәтләр күреп булса да шул авылларына кайта алганнар. Үз өйләренә түгел инде. Анда читләр яши хәзер. Мин үзем шушында тудым. Олылар сөйләгәннән генә беләм. Куылганнан соң тегү машинасы бик тә ярдәм иткән. Картинәм теге солдатка гомере буе рәхмәтләр укыды. (Ул Казан ягы татары булган. Һәм татарлар арасында бер-берсенә карата дошманлык хисе тудыру өчен бу эшкә бүтән як татарлары күпләп хезмәт иткән частьләрне җәлеп иткәннәр). Бик оста тегүче булып, картинәй һәммәсенә кием-салым теккән...

Диләвир абзый үз эше белән күп кенә республика-өлкәләрне аркылыга-буйга гизеп йөргән кеше. СССР дигән илдә хөкүмәт сөрелгән-депортировать ителгәннәрнен НКВД бүлегендә ун көн саен билдәләнеп[1] торуларын 1976 ( ?) елда гамәлдән чыгаргач, күп уйлап тормыйча үзенең туган якларына гаиләсе белән кайтып төшә. Әтисе »Улым, җае чыгу белән туган якка кайтып кит. Чит җир һәрвакыт чит инде», — дип әйтеп калдырган була. Тиз генә кайтып урнашырга уйласалар да, алай җиңел генә булмый шул. Ул гаиләсен кайтарып бер танышларында калдыра да, үзе тагы эшенә чыгып китә. Калганын Лидия апа сөйләгәннән беләбез.

Ә бит 1976 елны мин Уфа Авыл хуҗалыгы институтының ветеринария факультетының икенче курсына күчтем. Үзем яратып йөргән Рәмилә атлы кыз практика үтә анда. Миәкә районының Дим елгасы буендагы Яшәсен дигән авыл кырында гына урнашкан пионер лагерена китеп барам. Көн шулкадәр дә матур. Күнелем канатланып, күкнең җиденче катында оча! Менә озакламый күрешергә тиешбез. Һәм без Рәмилә белән шул елның утызынчы декабрендә язылыштык. Көндез сәгать уникеләрдә язылышкан булсак, кичен унбер тулгач, безне кияү йортына ябып, мылтыклардан аттылар. Безнең якта кияү белән кәләшне аерым өйгә япкач, мылтыктан ата торган гадәт бар. Әле дә бар ул йола. Рәмиләнең апа-җиңгиләре мине кәләш янына кертмәскә тырышып, ишеккә аркылы торалар. Мин бүләкләр өләшеп, үземнең үткерлегемне, усаллыгымны чама белән генә күрсәтеп, аркылы сузылган бауны өзеп, кәләшем янына үтәм. Менә шундый татлы хатирәләр калдырган мина житмеш алтынчы ел. Кайдадыр ерак Үзбәкстанда Кырымнан депортировать ителгән милләттәшләребез гомер кичерүе, һәр ун көн саен НКВД бүлегенә барып билдәләнүе, ул чакта ике ятып бер төшебезгә кермәде ләбаса. Ул чакларда иң нык социализм төзеп, шунда яшибез дип уйлый идек. Без, икенче курс студентлары, «Фәнни комунизм» дигән фәнне өйрәнеп, тагын да КПСС тарихын укып, Янбарисов дигән укытучыга имтихан да тапшырдык әле. Фәннәрнең дә фәне философияны өйрәндек. Ә шул вакытта туган җирләренә кайта алмый интеккән милләттәшләребез һәм башка милләтләр турында нәрсә генә белә идек соң?

Әлеге көнне дә без шушы Россия дигән илдә торырга урын эзләп, паспортларын туган җирләрендә терки алмаган милләттәшләребез һәм башка депортировать ителгән халыклар бар икәнен беләбезме? Юк! Туган якларына кайтырга интегеп, кайтсалар да анда йорт төзергә җир алалмый интеккән милләттәшләребез унар, йөзәр меңләгән. Без аларны күрмибез, белмибез. Белергә дә теләмибез. Чөнки алар шушы илнен үги балалары. Юньлерәк ата-ана үзенең үги баласына да бу кадәр каты бәгырьле булмас. Әйе, без бернәрсә дә белмибез. Белмәгәннең беләге авыртмый шул. Чөнки безнең илдә ялган геройлар белән ялган даһилар кадерле. Литвада үз илләренең бәйсезлеге өчен көрәшкән литва партизаннарын күпләп кырып йөргән ялган герой турында без күбрәк беләбез дә, теге арт ягын сикертеп, бишәр тапкыр кияүгә чыгып, бердәнбер баласын да юньләп тәрбияли алмаган артистларның тормышын күбрәк өйрәнәбез.

Менә шундый күңелсез уйлар уйлап, ачудан тешләремне кысып, уртларымны чәйнәп, палаткама кайтып аудым. Күңелемдә ниндидер бер күтәрә алмаслык төшенкелек.

***

Икенче көнне мин Куртимер Сайдалиев белән очрашырга тиеш идем. Бара алмадым. Барырга бер теләгем дә калмады. Чөнки кем белән генә очрашсам да ул кешеләрнен хатирәләрен тыңлау күңелемә бик авыр тәэсир итә. Алтмыш-житмешне узган, сиксәнгә якынайган абый-апаларның үзләренең яшьлекләрен, бала чакларын исләренә төшереп елый-елый бәян итүләрен күз алдыгызга китерегез инде. Ай авыр. Кичә ишеткәннәремне бераз үзләштереп, тынычлана төшәргә кирәк иде мина. Көнем шулай авыр кичерешләр белән үтеп китте.

Бүген иртән, ниһаять, Куртимер әфәнде белән очрашуга киттем. Сайдалиев — эшкуар. Матур гына итеп оештырган үз эшләре бар. Уллары да шуның белән

[1] Билдәләнеп (диал.) – билгеләнеп.

шөгыльләнәләр. Ул үзе инде мина әтиләренең башыннан үткән хәлләрне бәян итә.

— Әтиләр Балаклав районында яшәгәннәр. Авылдан иртән иртүк унбиш минут эчендә куып чыгарып, бер урынга җыялар. Аларны машиналарга төяп, Сурен стансасына алып киләләр. Андагы мәхшәр, андагы елашулар. Чөнки кайбер зур гаиләләрне бүлгәләп, төрле эшелоннарга утырталар. Бер өлешен Мари АССРга алып китәләр, калганнарын Ташкент өлкәсенә озаталар. Сайдалиев Әнвәрләр гаиләсен Ташкент өлкәсенең Калинин районына, коры яланга илтеп бушаталар. Халык качмасын дип солдатлар уратып саклап тора. Барча халык землянкалар казып, шунда яши башлый. Пешереп ашарга ни казан юк, ни табак-савыт житешми. Үлгәннәрнең исәп-хисабы юк. Аларны чокыр казып шунда җыялар. Чокыр тулгач, күмеп куялар. Килгән халыктан сугару каналлары казытканнар. Кырык сигезенче елны әти әнине очрата һәм алар өйләнешәләр. Авыр тормыштан Әнвәрләрнең туган балалары үлә тора. 1951 елда мин туганмын. Балалары гел үлгәч, бер бабай киңәше белән мина Куртимер дигән исем кушалар. Имеш, кешегә тимер сүзен кушып исем кушсан, кеше тимер кебек ныклы була икән. Дөрестер, күрәсең, менә мин исән бит. Мина хәзер илле тугыз яшь. Аллага шөкер.

Икәүләп көлешеп алабыз. Шуннан мин дә:

— Бездә дә шундый ышану бар һәм бездә дә Биктимер, Тимерханнар белән Тимергали, Тимербулатлар житәрлек, — дим. Шуннан Куртимер белән Кырым татарларының бүгенге хәлләре турында сөйләшәбез. Мондагы татарларның да башка милләтләр тарафыннан йотыла баруына нык борчыла ул. Милләтара никах нык таралган икән. Чөнки Кырым татарларына үз авылларын төзергә, янәшә яшәргә жир дә, ирек тә бирмиләр икән. Хәтта ике татар гаиләсенә ике өй салып, күршеләр булып яшәргә дә жир бирмиләр ди. Уртага һәрчак башка милләт кешеләрен утырталар. Анапа шәһәрендә дә, Анапа районында да хәтсез генә Кырым татарлары яшәсә дә, балалар татарча укымыйлар. Күп татар гаиләләрендә оныклар татарча бөтенләй белми икән. Үзләрен мин татар дип йөрсәләр дә. Кайчакны артистлар һәм төрле музыкаль ансамбльләр килеп, татарча концертлар куеп китәләр икән. Әмма мондый хәл бик сирәк була. Куртимер тагын да шуна басым ясады. Башка милләтләр, мәсәлән, әрмәннәр, чеченнар, көрдләр милләттәшләреннән елына күпмедер взнос җыялар. Акча шушында туган телне укыткан укытучыларга эш хакы итеп түләнә, уку әсбаплары алырга тотыла, якшәмбе мәктәпләре оештыруга. Һәм башка милли мәнфәгатьләргә кулланыла. Ә менә безнең мондагы татарда бу взнос җыюлар оештырылмаган. Анапа шәһәрендә әлегә көчле генә Кырым татарлары үзәге дә юк. Бу җәһәттән Ришат әфәнденең тырышлыгыннан башка бер эш тә эшләнми дияргә була. Яшьләрне туплау, оештыру да юк диярлек. Бу эшләр тик Украина дәүләтендә торып калган Кырым өлкәсендә генә ныклап җәелдерелгән. Алар чын-чынлап үзләренең дәүләтләрен төзү белән шөгыльләнәләр.

Куртимер әфәнде, депортировать ителгән татарлар турында әнием бик күп белә, әйдәгез, аның белән сөйләшеп карагыз, — дигәч, без икәүләп Зәйнәп апа бүлмәсенә керәбез. Кырым татарлары бездән ничек кенә ерак яшәмәсеннәр һәм сөйләмдә шактый гына аерма булуга карамастан, өй гап-гади татар өе инде. Ин түрдә бик матурлап язылган шамаиллар һәм берничә дога эленгән. Аннан инде ага-туганнарының фотосурәтләре тезелгән рамнар. Һәм һәр өйдә ин түрдә — Коръән. Тик бездәге кебек тышлары тузып, тузанга батып тормый. Һәр Коръән китабы махсус бик яхшы итеп эшләнгән тартма-кумталарда саклана. Һәр китап бик зәвыклы төрле төсләге бәрхет тукыма белән тышланган. Ягъни һәр Коръәнне бәләкәй генә кыйммәтле сандык-тартма эчендә саклыйлар.

Ул чакларны олы кешеләр күз яшьсез искә төшерә алмыйлар. Барысының да хатирәләре күз яше белән башланып китә. Әле дә шулай булды.Зәйнәп апа бераз тынычлангач, жай гына сөйләп алып китте.

— Мина ул чакны ун яшь иде. Төнлә ишекне яман каты итеп дөбердәттеләр. Ишекне ваталар дип торабыз. Ачып җибәрсәк, озын бер солдат. «Әйдәгез, әйдә, чыгыгыз. Тизрәк, тизрәк торыгыз», диләр. Без урысча аңламыйбыз. Урамга чыксак, халыкны авыл читенә куалар. Әни кешеләргә карап ашык-пошык кайбер нәрсәләрне

төенләп алган булды. Тик тиз арада нәрсә генә җыеп өлгерәсең ди. Халыкны шулай авыл кырына тупладылар. Хәзер сезне алырга машиналар килә, диделәр. Тик безне алып китәсе машиналар да, бричкалар җигелгән атлар да юк. Бер көн буе тордык. Халык ачыкты, балалар сусады. Өйләргә кайтып су, ризык алып килергә рөхсәт итмиләр. Икенче көн шулай эссе кояш астында утырабыз. Төннәрен бездә әле суык. Тәүге төнне ничек итсәк иттек, бергәләп җыелышып, кемнең нәрсәсе бар шуны ябынып кундык. Әни уфтана:

— Их, ди, нигә икән аш пешерергә берәр чуен, йә булмаса бәләкәй казанны алмаганмын, ди. Халык ачыкты. Солдатларны да ашатмый, эчертми безне саклаталар. Бала-чаганың безне саклаган солдатларда эше юк. Үзара чым-чыкыр уйнап та алалар, елап та җибәрәләр. Эссе кояш астында әлсерәгән солдатларның да игътибары әзәйде. Йокымсырап утыралар шунда. Үзем бәләкәй булсам да бик ушлы идем. Башка балаларга ияреп уйнаган булып, аз-азлап кына солдатлардан читкәрәк киттем дә, мин тиз генә йортлар арасыннан үзебезнең өйгә чаптым. Тиз арада кереп, мичтән бәләкәй казанны актарып алып чыга алдым. Кача-поса берни белмәгән балалар арасына килеп кушылдым. Шул ук уйнаган балалар белән казанны күтәреп кире әниләр янына килдем. И әниемнең шатланганын күрсәгез! Чөнки әни әз-мәз ярма алган булган икән. Сусаган халыкка кайдандыр мичкә белән су алып килделәр. Шул суга бутап әни мин алып килгән казанда ботка пешереп безне ашатты. Казан шәп булып чыкты, күршеләр дә ул казанда боламык бутадылар. Шулай итеп, халык чират торып ашарга әзерләргә тотынды. Безне өч көн үткәч кенә стансага алып барып, скотвагоннарга шыплап төяделәр. Ишле гаиләләрне идәнгә һәм астагы сәкеләргә урнаштырдылар. Яшьләр һәм аз гаиләләләр өске сәкеләргә урнаштылар. Айга якын ач, суга интегеп стансадан-стансага туктый-туктый алга барабыз. Картлар, балалар авырышып кырыла башлады. Шуннан Ташкент өлкәсенә китереп кола-ялангa бушаттылар. Барча халык озак юынмаудан бетләп, тәннәре бозыла башлады. Барып төшкәч, ниндидер бер складта безне санитар эшкәртү үткәрделәр. Каралин белән юдылар, ахры. Исе бик сасы иде. Үзебез җир казып землянкалар ясадык. Әти олы яшьтә булса да бик шәп иде. ГЭС төзелешендә ташчы булып эшләде. Почет тактасында фотосурәте беренчеләрдән булып эленеп торды. Шуңа да әтигә бүләк сыйфатында өй төзергә алты сутый җир бирделәр. Бергәләшеп балчыктан өй күтәрдек. Яшем житмәстән элек эшкә тотындым. Йөк ташучыларга подсобник-ярдәмче булып эшләдем. Булачак ирем Әнвәр дә йөк ташучы иде. Мин аларга балчык, цемент, кирпеч төяп тордым. Әнвәр үз гаиләсе белән күршедә генә яшәде. Әтиләрдән минем кулымны сорагач, каршы килмәделәр. Шулай итеп, без өйләнештек. Депортациягә кадәр дә аларның авылы безнең авылга күрше генә булган. Тик алар икенче районга кергән. Шулай бергә тормыш корып алып киттек.

Бездән еракта, диңгез буенда, таулар арасындагы бәләкәй генә авылда бер апабыз яши иде. Аларның авылын депортация ыгы-зыгысы вакытында онытып калдырганнар. Ул көнне апабыз ниндидер эше чыгып, ерак кына авылга туганнарга киткән булган. Туганнарның авылына барып керсә, авылда бер кеше юк. Урамда ач этләр белән савылмаган сыерлар гына хуҗабикәләрен чакырып үкерешәләр дә урамда яткан кирәксез кыягаз, китап-дәфтәрләрнең битләрен йолыккалап җил генә сызгыра. Апа коты очып өенә йөгерә. Авылга кайтса, авылларында да шундый ук хәл. Бер кеше дә калмаган. Шулай исәрләнер хәлгә житеп авыл буйлап китеп барганда бер авылдашына тап була. Шул егет сөйли. Авыл халкын бергә җыялар да, бер иске генә пароходны тиз-тиләмән төзәтеп, халыкны шунда тутыралар. Яр күздән югалгач, яннан тагылып килгән катер пароходның ниндидер астагы капкачын ача. Пароход барча халкы белән бата башлый. Ә катер тиз арада ярга таба качып күздән югала. Шул баткан пароходтан бер генә кеше исән кала. Чөнки бу вакытта диңгез суы бик суык була. Ә эш болай була. Теге онытылып калган авыл үзенең исән-имин яшәп ятканын белдергәч, Кырым халыкларын депортациягә җаваплы түрәләрнең котлары оча. Халыкны тиз генә Уралга, Себергә, йә булмаса шул ук Үзбәкстанга озатырлар иде, эшелоннар китеп беткән. Аннан да бигрәк Үзәк Комитетка Кырым татарлардан азат дип доклад ясалган. Таулар арасында бу онытылып калган авыл

халкын нишләтергә? Өстәгеләр белеп алсалар, баштан сыйпамаячаклар. Үзенне үк татарлар артыннан җәһәннәмгә озатырга мөмкиннәр. Ни эшләтергә? Жыеп атар иден, солдатлар да китеп беткән. Аннан атылганнарны күмсән, каберләре кала. Еллар үткәч булса да тикшерергә мөмкиннәр. Уйлый торгач, жаен табалар. Дингезгә батырырга! Һәм шулай итәләр дә. Шаһитлар да бер-ике генә солдат. Аларны фронтка үлемгә җибәрәләр. Мәетләр дә юк, жирләп мәшәкатьләнәсе дә түгел. Шулай итеп, онытылган авылдан могжиза белән ике генә кеше исән кала. Менә шундый хәлләр, улым.



*Зәйнәп апа улы Куртимер белән*

Ә без шушы якларга качып кайттык. Тегеннән киткәндә Ерак Көнчыгышка, Сахалинга китәбез дидек. Монда ташландык, таралып барган бер хужалыкка житмешенче елларда кайтып төштек. Туган илләргә якынырак булыйк дидек. Улым, менә шушы куллар белән Ташкент кырындагы 1нче, 2нче, 3нче ГЭСларны төзедем. Перестройка башлангач, үземнең туган авылыма кайтып килдем. Безнең йортта башка милләт кешеләре яши иде. Алар белән дә сөйләшергә туры килде. Өебез искергән. Аның кырында яңа өй төзегәннәр. Үзебезнең өйгә кереп карарга да рөхсәт иттеләр итүен. Балалар кереп карады. Минем көчем житмәде. Өебезгә тыштан гына карап елый-елый әти утырткан, хәзер инде шактый юанайган груша агачын кочаклап, аның белән сөйләшеп еладым.

Монда безнең йортларга көчләп куып китерелгән хужаның улы сөйләвенчә, аларның әтиләре дә үз туган якларын сагынып, әллә ничә тапкыр гаиләсен алып туган якларына качып китә. Тик туган йортын гына кайтып күрә алмый. Районнарына кайткач, кире тотып тагы монда сөрәләр. Ике тапкыр ярты юлдан боралар. Тагы качсаң, сина йә төрмә, йә Себер дип куркыткач кына язмышына буйсына ул.

Зәйнәп апа бу авыр хатирәләрдән үзен начар тоя башлагач, сөйләшүне шушында туктаттым. Аның хатирәләрен тыңлау миңа да кыен иде.

***

Куртимер, минем хәлне аңлап бетермичә, урам аша гына ерак түгел йортта яшәгән Нәзифә апаларга кереп чыгыйк ди.

— Юк, бүтән беркем белән дә очрашып сөйләшмим, шушы материалларым да житәрлек, — дим. Минем исәбем тизрәк палатама кайтып аварга һәм тынычланырга. Югыйсә бу хатирәләрне тыңлаудан фазаң күчеп исәрләнергә мөмкинсең. Шуннан язмаларымны да тәртипкә китерермен дим. Югыйсә язып өлгерә алмаганнарым буталып бетәргә мөмкин. Куртимер исә үзалдына сөйләнә бирә:

— Ә бит Нәзифә апа минем әнигә караганда да күбрәк белә. Кереп бер ярты сәгать сөйләшүдән, мөгаен, кәмемәбез, — дип, мине көчләп дигәндәй күршеләренә алып кереп китте.

Менә без өйнең капкасын ачып керәбез. Йортны (ишек алды) тутырып КамАЗ машинасы тора. Ачык гараж ишегеннән жиңел машина да күренә. Йорт түрендә яшелчә бакчасы белән жимеш бакчасы. Анда алма, хөрмә агачлары белән бергәттән аларга үрмәләгән йөзем куаклары. Йортка керүгә үк бер яшь кенә ир безне татарча сәламләп каршы ала, Куртимернең хәл-әхвәлләрен сораша. Куртимер минем белән таныштыра. Өйгә үтәбез. Өйдә пөхтәлек. Алгы бүлмәгә үтәбез. Безне йомшак кәнәфидә ниндидер кул эше белән шөгыльләнгән апа каршы ала. (әби дип әйтәсе дә килми). Шунысына игътибар иттем: апа күзлексез әллә чигү чигә, әллә төсле жеп белән нәрсәдер тегә.

Минем шулай олы яшьтәге кешеләр белән очрашып, аларның депортация турындагы хатирәләрен язып йөрүемне белгәч, апаның кәефе кырылды. Йөзләре үк каралып китте. Сөйләгәннәрен язарга әзерләнеп өстәл артына утыргач, куллары ук калтырый башлады. Кулындагы эшен бер читкә алып куйды да, сөйләп китте тагын үзе:

— Анын нәрсәсен сөйлисең инде. Бик алама һәм авыр чаклар иде. Мин үзем егерме бишенче елгымын. Акъяр шәһәрендә тудым. Шәһәр кызы мин. Шуңа да урысча яхшы беләм. Әти нинди дер хәрби заводта эшли. Мәктәпне тәмамлагач, башкача укыйсым килмәде. Шуңа да мин кыска гына курс тәмамлап, парикмахер булып эшли башладым. Әтиләр ниндидер бер ярымхәрби өйрәнүләрдә йөриләр. Шуңа да өйгә атнасына бер генә кайта. Ул көнне әти өйгә кайткан көн иде. Төнге икенче яртыда бик нык шартлаулар ишетелеп, самолетлар оча башлады. Прожекторлар төнге һаваны айкыйлар. Әти безне тынычландыра. «Курыкмагыз, бу безнең Кызыл армиянең хәрби өйрәнүләре генә», — ди. Иртән әти үзенең заводына, мин үземнең эшкә киттем. Барча халык аптырый, күршедә генә өйләр жимерелгән. Урамда кирпеч ватыклары аунап ята. Эшемдә дә бернәрсә дә белерлек түгел. Эш көнебез шулай башланды. Ниндидер имеш-мимешләрдән генә сугыш башланганын белдек. Шуннан китте инде дөньялар буталып. Магазиннарда азык-төлек кырка[2] кыйммәтләнеп, тора-бара бөтенләй юкка чыкты. Каты сугышлардан соң шәһәрне немецлар басып алды. Без әни белән анын туган авылы Тулигә кучеп кайттык, Бакчасарай районы бу. Чөнки ни дисәң дә авылда ашарга бар. Ярый әле эш коралларымны тыккан идем. Авылда кешеләрнең чәчен алам, сакал-мыекларын тәртипкә китерәм. Ни дисәң дә әзме-күпме хак бирәләр. Немец солдатлары да кергәлиләр, алар инде кофе, шоколад, кайчакны ботка, бәрәңге калдырып китәләр. Безнең бик кысан гына бүлмәдә яшәгәнне күреп бер немец солдаты ишек төбендәге чөйгә үзенең шинелен элеп куйды да, бүтән солдатлар керсә, бездә бер солдат яши дип әйтерсез, диде. Соңыннан гына белдек, авылга тагын немецлар килеп тулган, аларга яшәргә урын кирәк икән. Кайбер хуҗаларны хәтта өйләреннән куып чыгардылар. Без торган йорт хуҗасының имчәк баласы да бар. Немец бик нечкә күнелле кеше булып, ярма һәм шикәр дә калдырып киткәли. Ана кешегә яхшы ашарга кирәк дип. Менә шулай дошман булсалар да, алар арасында да юньле кешеләр бар иде. Немецларны кугач, барыбызны да Совет хөкүмәте исәпкә алып, журналга теркәп куйды. Һәм менә бер төнне оккупациядә калган барча халыкны уятып мәйданга җыйдылар. Без тәмам курыктык. Яһүдиләрне юк иткән кебек безне дә атарга алып баралар дип уйладык.

— Уң якка бер адым, сул якка бер адым читкә чыксагыз, атабыз, — дип тә бакырдылар әле.

Берни анлатмый безне эшелоннарга төяп алып киттеләр. Шунысы үкенечле булды, мәхшәр вакытында сенелем Әйшәне бездән аерып, икенче вагонга утырттылар. Әни солдатлардан елап-елап сорап караса да, безнең вагонга күчермәделәр. Шуннан вагоннарның бөтенләй ишекләрен ябып, өстебездән бикләп үк куйдылар. Тәрәзәдән дә чыгарлык түгел, анда баш бармактан да юанрак тимер рәшәткә. Балаларыннан-туганнарыннан аерылганнар бер без генә түгел икән. Шуңа да китте елаш, китте кычкырып бер-берсен чакырулар. Халык кычкырып елаша башлагач, тирә-якка ишетелмәсен дип тәүдә громкоговоритель аша теге «Валенки, валенки» җырын акырта башладылар. Шуннан инде вагоннарны тиз-тиләмән паровозларга тагып, стансадан читкә үк алып киттеләр. Менә шуннан соң ул марҗаның җырларын һич тынлый алмас булдым. Ишетәсем килми. Аннан инде юлга кузгалдык. Бер тәүлек беркая чыгармый алып бардылар. Ни кече хаҗәтне, ни олысын үтәрлек түгел. Вагондагы берничә олы яшьтәге абзый сөйләшеп, эшелон барганда, кем кайдан нинди тимер кисәге таба, шуның белән вагон идәненә тишек тишәргә тотындылар. Кемдә пәке, кемдә кадак — барысын да эшкә жиктеләр. Шуннан соң гына әзрәк хәл жинеләйде. Хатыннар үз мөешендә, ирләр үз мөешләрендә[3] хаҗәтләрен үтәделәр. Ярый әле хатыннар ягына бер кешенең чыбылдыгын кордылар. Менә шулай итеп

[2] Кырка – кинәт.
[3] Мөеш – почмак.

без фашистлар коллыгыннан котылып, хәзер инде үзебезнең совет коллыгына билдәсезлеккә[4] китеп барабыз. Әнинең шундагы Әйшә сенелемне югалтуына кайгырып елауларын белсәгез. Ана кушылып мин елыйм. Бер тәүлектән соң гына вагоннарны ачып су бирделәр. Әни әрсезләнеп эшелонны буйдан-буйга кычкырып йөреп чыкты.

— Әйшә дигән кыз монда юкмы? Әйшә кызым...! Әйшә дигән кызны күрмәдегезме?

Юк, Әйшәне беркем дә күрмәгән булып чыкты. Тик кемдер бераү, шундый-шундый күлмәкле, яулыгы шундый төсле кыз бала утырган вагонны икенче составка тактылар шикелле дип кенә әйтә алды. Югалды Әйшә...

Уналты-унсигез көннәр чамасы баргач, безне Мари АССРдагы Волжский каласына китереп бушаттылар. Элекке ниндидер зеклардан калган җимерек баракларга китереп яптылар. Карт халык юлда кырылса, хәзер мондагы авыр тормыштан күпләр авырып аяктан егылды. Әни дә авырый башлады. Мине елгадан агып килгән салдагы агачларны судан чыгарып, пилорамга озата торган урынга куйдылар. Шәһәрдә үсеп юньле физик эш эшли белмәгән кыз баладан тездән-боттан булган су эченнән бүрәнә ташытсыннар инде. Һич кенә дә эшли алмыйм бит. Норманы үтәп булмый. Норманы үти алмагач, паек та ачтан үлмәслек кенә. Авыр эштә бөтенләй бетерендем. Аның өстенә ләпәк[5], черки дигән кан эчә торган бөҗәкләр сырып алалар. Шул кан эчкечләрдән дә бигрәк бригадир хатын усал. Көн саен, сәгать саен кычкыра да кычкыра. Ул элек тә тоткын-колларны карап эшләткән икән. Аптырагач, мине кирпеч заводына эшкә җибәрделәр. Анда мин кирпеч яндыра торган мич кырында эшләп, мичләрне чи кирпеч белән тутырырга тиеш идем. Эссе мичкә кирпеч ташыганда өстемдәге пальтоның алдын яндырдым. Әнинең пальтосы бит, икебезгә бер. Эшкә барырга киемем калмады. Берәр бишмәт әмәлләгәнче эшкә бара алмадым. Шуннан мине Волжск шәһәрендәге НКВД бүлегенә чакырттылар. Сине ин зур түрә күрергә тели, диделәр. Мине алырга солдат җибәргәннәр. Мин, әнидән башка бармыйм, дим. Шуннан әнине дә ияртеп киттек. Әнине бер бүлмәдә калдырып, мине түрәнең үзенә кертеп җибәрделәр.

Күрсәгез икән ул бүлмәнең зурлыгын. Һәм аның идәненә җәелгән келәмнәрне. Алар өстеннән ишек төбеннән алып түргә чаклы кып-кызыл тагы бер тар гына келәм җәелгән. Бу начальник миннән тегесен-монысын сораштыра башлады. Немецләр ничек иде? Ничек сөйләшәләр? Ничек ашый-эчәләр? Барысын да сораша. Мөгаен, сугышта булмагандыр. Мин нәрсә сөйләргә дә белмим. Бу сорый. Дөресен сөйләргә булдым. Мин, дим, Акъяр шәһәрендә парикмахерга укыдым да, шул һөнәрем белән эшләдем, дим.

— Оккупация вакытында да эшләдеңме? Тик син алдашасың, андый шәһәр юк. Син фашист калдыгы, дөресен сөйлә! — дип тавышын күтәрә бу.

Чамалап алдым: Акъяр шәһәрен урыслар, безне басып алгач, Севастополь дип атадылар.

— Мин Севастополь шәһәрендә тудым, шунда укыдым, — дим.

Бу соравын кабатлый:

— Оккупация вакытында да эшләдеңме?

— Әйе, оккупация вакытында да эшләргә туры килде, — дим

— Немец солдатларының да чәчен алдыңмы? Алар нәрсә белән түләделәр?

— Әйе, аларның да чәчен алгаладым. Чөнки ачтан үлеп булмый бит инде. Алар йә сабын, йә кофе белән түләделәр. Кай чакны ит тушёнкасы, балык консервылары бирәләр иде, — дим.

— Димәк, син оккупантларга булышып яткансың? Немецлар белән берлектә булгансыз, Совет армиясенә каршы көрәшеп яткансыз, — дип теге кычкырырга ук тотынды. Мин куркышымнан елый ук башладым.

— Мин, — дим, — үзебезнең солдатларның да чәч-сакалларын кырдым. Оккупация вакытында күршедә яшеренеп яткан яралы ике совет солдатына Украинадан ашарга ташыдым. Кырымнан төрле-төрле кием-салым алып бара

---

[4] Билдәсез – билгесезлек.

[5] Ләпәк – вак чебен.

идек тә, шуны Украинада азыкка алыштыра идек. Ул чакта Кырымда кием-салым житәрлек, ә ашарга юк. Мин алып кайткан ризыклар белән күп кеше исән калды. Кырымдагы подпольщикларны, партизаннарны һәм аларның гаиләләрен туйдырып тордык, — дим. — Чөнки без, берничә кеше, товар поездындагы күмер вагоннарына утырып, кыш буе азык ташыдык. Немецлар да, товар вагонына утырып барганыңны күрсәләр, күп сөйләшеп тормыйлар, аталар да куялар иде, — дим.

— Ярар, нимесләргә әзме-күпме каршылык күрсәткәнегезнең бусын беләбез, калганын тикшерербез. Тик син монда да каршылык күрсәтү оешмасы төзегәнсең икән. Саботаж оештырып ятасың икән. Нигә пилорам цехында эшләмәдең? Кирпеч заводында да эшләргә теләмәгәнсең. Ни өчен? Саботажга башкаларны да котыртасың икән, фашист подстилкасы, — дип, мине мыскылларга ук тотынды. Мин елый башладым. Бу НКВД түрәсе тагы:

— Нинди Кырым татарлары яшьләре оешмасы оештырдыгыз? Кемегез бу оешмада житәкче? Бу оешмада Эдем нинди вазифа били? Һәм аның оешмадагы роле? Менә сиңа ручка, кыягаз. Яз барысын да! Йә булмаса имзаңны куй! — дип, минем алга бер язылган кыягаз белән язылмаган таза бит куйды. Мин нәрсә язарга да белмим. Кулларым калтырый. Шулай да ике кыягазга да «Мин бернәрсә дә белмим, бер оешмада да тормыйм», дип яза алдым. Бу минем жавапны укыды да:

— Ярар, иртәгә мин сезне Эдем белән күзгә-күз очраштырырмын, шуннан нәрсә диярсез? — диде дә мине алып китәргә конвойны чакырды. Мине базга төшереп бер бүлмәгә кертеп яптылар. Бүлмә эчендә ниндидер бер хатын ята. Әллә авыру, әллә исерек, белмәссең. Бер як стена юка гына. Игътибар белән тыңласаң, кемнәр нәрсә сөйләшкәнне дә чамаларга була. Кичкә жайлап кына стенага шакый башладым. Шакый торгач, берәү:

— Кем кирәк сезгә? — ди.

— Эдем дигән егетне чакырыгыз әле, — дим. Шуннан озак кына вакыт үткәч, Эдем үзе килеп стена шакыды. Шуннан мин аңа сөйләп бирдем эшнең нәрсәдә икәнен.

— Безгә бик житди жинаять эше ягарга уйлыйлар. Иртәгә сине минем белән очраштырачаклар. Шунда син мине танымыйсың, мин сине танымыйм, — дип үзебезчә әйтә алдым. Шунда теге селкенми генә яткан хатын торып утырды да:

— Нигә урысча сөйләшмисең? Син нәрсә әйттең ана? — ди.

— Әнигә әйтергә куштым. Минем өчен кайгырмаска куштым. Булдыра алса, мина ашарга жибәрсен, — дип кенә әйттем, дим.

Төнлә, уйланып ята торгач, ни өчен мине монда ябып куйганнарын чамаладым. Бер атна-ун көн элек, төшке ял вакытында, теге эссе мич алдында пальтом янгач, ачуымнан:

— Әзрәк акча тапкан көе моннан качам, — дип әйткән идем.

Шунда минем сүземне куәтләп теге Эдем дигән егет тә:

— Мин дә качарга уйлап торам. Бергә качарбыз, — дигән иде. Безнең сүзгә тагы берничә егет-кыз кушылып, алар да шул исәптә торганнарын әйттеләр. Менә кайда булган икән безнең хөкүмәткә каршы сөйләшүебез. Бу турыда НКВД органнарына кем хәбәр иткән? Ачыклый алмадым. Әмма бу хәл минем өчен сабак булды. Читләр алдында авызымны үлчәп ачарга өйрәндем.

Икенче көнне безне Эдем белән очраштырдылар. Һәм алдан сөйләшкәнчә без бер-беребезне «танымадык».

Әйтүемчә, мин чәч алучы бит. Әле дә ярый безне Кырымнан куганда эш коралларымны да алган идем. Шуның белән буш чакларымда тиенләп булса да әз-мәз акча әмәлләдем. Һәм үземнең күптәнге хыялымны тормышка ашырып, күзебез кайда карый шул якка качып киттек. Исәп ничек тә жылырак якка китү. Бер татарча белгән вагон озатучы хатын безне Казан шәһәренә алып барырга риза булды. Казанга килеп төштек. Кая барырга да, кемгә дәшәргә дә белмибез. Шулай йөри торгач, бер татар хатыны өендә кундырып чыгарды. Кем беләндер сөйләшеп, поезга утыртышып жибәрде. Икенче стансада безне контролерлар тикшереп, куып төшерделәр. Йөри торгач, тагы бер вагон озатучы безне утыртып алып барырга ризалашты. Тик безнең юлга түләргә акча житеп бетми. Акчаны биреп бетерсәк,

ашарга-эчәргә калмый. Ач нәрсә эшлисен? Ярый әле әни таш сала белә. Тотты да бу хатынга таш салды. Һәм әни тегенә ташлар нәрсә әйткәнен сөйләп бирде. Бу хатынны нәрсә борчый, нәрсәдән сакланырга кирәген дә әйтте. Теге хатынның бик тә күнеле булып, безне Свирдлауга чаклы алып барды. Свирдлаудан тагы төрле мәшәкать-михнәт, зур кыенлыклар белән Арист стансасына килеп житә алдык...

***

Апа үзенең баштан кичкәннәрен искә төшереп утырганда Кырым татарларының бик борынгы бер жырын жырлап күрсәтте. Бу жыр Акъяр, ягъни Севастопольгә багышланган. Шушы жырны ишеткәч, минем дә күземә яшь тулды. Апага яшемне күрсәтмәскә тырышып, алдымдагы дәфтәр битенә ныграк иеләм. Нәрсәдер язарга тырышып карыйм, барып чыкмый. Ирексездән кесәдән кульяулыгымны алып яшьләремне киптерәм. Һәм менә нәкъ шушы мизгелдә бер катгый ниятқә киләм. Мина Кырымга барырга кирәк! Әлбәттә, барачакмын! Барачакмын!

Апаның хатирәләрен тагы да озак, бик озак язып утырдым. Аның белән сөйләшә-сөйләшә чәйләр эчеп, ашлар ашагач, үземнең палатама кайтып аудым. Бераз ял итеп алырга уйласам да, барып чыкмады. Дәфтәремне алып, ападан ишеткәнне тәртипкә китерергә тотындым. Белештем, Украина дәүләтенә кергән Кырым ярымутравына бару өчен виза кирәкми икән. Паспортың булса, шул житкән. Кичке ашны ашагач та автовокзалга киттем. Автобус кичке сигездә кузгала. Менә кичке Сочи-Симферополь автобусына утырып кузгалып китәбез. Минем исәп юлда тәрәзәдән тирә-якны күзәтеп барырга. Тик озак карап барып булмый. Гадәттәгечә бу киңлектә караңгы кинәт кенә һәм иртә төшә. Аның өчен бик кайгырмыйм. Әле язның башы гына, шуна тирә-як шәп-шәрә. Зур-зур йөзем басулары белән ужым бодае чәчелгән басулар гына күренә. Юлның ике ягына урыс һәм казак станицалары тезелгән. Һәр юл чатында һәм авыл читендә галәмәт зур бетон һәм тимер тәреләр куелган. Һәр авылда төрле-төрле каланчалы чиркәүләр күренә. Һичкайда мәчет-мазар күрмәссең. Краснодар крае бай дисәләр дә, авыллар бик пычрак. Тазартып өлгермәгәннәрдер дияр идең, кыш эчендә ул кадәр пычракны ничек жыясың ди? Өй кыеклары да бик шәптән түгел. Беркайда да матур итеп төсле калайдан ябылган өй түбәләре күрмәдем. Бездә бит хәтта ферма кыекларын да хәзер төсле калай белән яба башладылар.

Юл газабы — гүр газабы, йокымсырап бара торгач, төнге сәгать икедә таможня (татарның «тамга» сүзеннән ясалган) тикшерүен үтеп, паромга автобус белән кереп утырабыз. Аннан ярты сәгатьләп вакыт төнге Керчь бугазын үтеп, Кырымга, Украина жиренә аяк басабыз. Нинди-дер анкеталар тутыргач, тагы Украина таможнясы тикшерүен үтәбез. Һәм янадан автобуска утырып, Ак Мәчеткә (Кырым татарлары Симферопольне Ак Мәчет диләр[6]) таба юл алабыз.

***



*Милли мәжлес бинасы*

Менә мин Кырым татарларының Милли мәжлесләре урнашкан бина каршысында басып торам. Кыюсыз гына ишекне ачып эчкә үтәм. Мине мөлаем генә елмаеп бер татар хатыны каршы ала: шундый ук күлмәк-яулык, шундый ук елмаю. Иртәрәк килгәнмен, шуңа да бераз көтеп торырга туры килде. Һәм менә Милли мәжлестә эшләгән милләттәшләрем белән гәпләшеп утырабыз.

Минем белән Милли мәжлес әгъзасы Куртимиров Жәүдәт әфәнде бик теләп сөйләшә. Мине бик күп төрле сораулар кызыксындыра. Һәм ул үзенә генә хас басынкылык белән сөйләп китте.

[6] Симферополь 1784 елны шул исемдәге татар шәһәре урынында салынган. Ред.

— СССР шатыр-ботыр төрле җөйләреннән сүтелеп таркала башлагач, күп кенә халыклар аптырап, югалып калдылар. Нәрсә эшләргә? Без Кырым татарлары тиз арада, туксан беренче елны ук Милли мәҗлес җыя алдык. Делегатларны мең кешегә бер делегат исәбеннән сайладык. Әмма безне тәүдә Урыс дәүләте, аннан инде Украина хөкүмәте гамәлгә теркәмәде, шулай итеп безнең белән исәпләшергә теләмәделәр. Әмма без бар. Һәм бөтен көчкә кулдан килгәнчә эшләп киләбез. Әлеге көнне Украинага караганда Россия безгә ныграк аяк чала. Тыкшынмаган урыны юк бит инде үзенең. Молдавиядән Днестровьене аерып алган кебек Кырымны да Украинадан аерып алырга уйлады. Кырымда урыслар күпчелек дип. Һәм барысына да соңгы чорда Россия паспортлары таратып чыктылар. Шуларга таянып бәләкәй генә революция ясап Кырымны янадан Россияга кушарга уйлаган иде дә, барып чыкмады. Чөнки монда әле без татарлар бар. Нигә, Абхазияне, Көньяк Осетияне Грузиядан аерып алмадымыни? Алды. Ә Казакъстан алдан күреп уйлый белә, башкаласын күчерде дә куйды. Нигә, Алма-Ата алама идемени? Юк, әлбәттә. Барлы-юклы сәбәпләр табып, Астанага күчтеләр. Чөнки тегендә урыслар житмеш процентка якын иде. Урыс хөкүмәтенең әле һаман да империалистик аппетиты югалмаган, шуна безнең Милли мәҗлес тегенең тамагына аркылы утырды. Шуна да без татарларның Милли мәҗлесенә карата алар тарафыннан төрле провокацияләр эшләнә. Төрле уйдырмалар таратып, безгә пычрак ягалар. Татар милләтеннән булган үз агентларын безнең арага кертеп, таркаулык оештырырга, төрле вак-вак төркемнәргә бүлгәләргә тырышалар. Әмма без андый провокацион төркемнәрне вакытында фашлап, чистага чыгарып торабыз. Бу өлкәдә зур гына тәҗрибәбез дә бар. Шуннан халык та бердәм. Кырым татарлары бүгенге көнне Украина дәүләте чикләрендә үзенең автономиясен булдыру өчен көрәшә. Үз телебездә алты гәзит-журналыбыз чыга. Симферополь шәһәре тирәли илле чакрым радиуста ышанычлы күрсәтә торган телеканалыбыз бар. Көн дәвамында озак эшләмәсә дә, татарча радио каналыбыз да бар, аның эфир вакытын озайтырга тырышачакбыз.


*Милли мәҗлес утырышы бара*

Ә Союз таркалганда Кырым татарларына нәрсә эләкте? Хәтта теге сезгә тараткан, туалет кыягазына да ярамаган данлыклы ВАУЧЕР да тәтемәде. Чөнки СССР дәүләтендә без иң хокуксыз милләт, чеченнар белән иң каты геноцидка дучар ителгән халык идек. Чеченнар үз республикаларын төзи алдылар, ә без — юк. Безнең завод-фабрикаларыбыз да, милли экономикабыз да юк. Хәтта йорт төзеп яшәр өчен дә җирне самозахват белән алырга тиешбез. Үзебезнең тарихи җирләребезне! Күп милләттәшләребез кайта алмый читтә интегәләр. Кайтканнарның да барча мал-мөлкәте читтә торып калды.

Безнең карамакта унбиш милли мәктәбебез эшләп килә. Балаларны дүртенче сыйныфка чаклы милли телдә укытырга тырышабыз. Әлифба һәм башка төрле уку китапларын татар телендә үзебез бастырабыз. Симферополь тирәли яна гына төзелеп килгән авылларны күргәнсездер инде. Барысы да безнеке, безнең милләт кешеләре самозахват белән җир алып, урамнар, авыллар төзеп урнаштылар. Бу акцияләрне Милли мәҗлес оештырып, үзе үк җитәкли. Кырым өлкәсе түрәләре теш-тырнаклары белән каршы торсалар да, берни кыла алмыйлар. Чөнки бу — безнең җирләр. Татар җирләре.

Мин инде Җәвдәт әфәндегә үземне борчыган сорауларны яудырып кына торам. Төрле өлкәдән бирсәм дә, ул барысыннан да хәбәрдар булып, тәгаен җаваплар биреп барды. Милли мәҗлес әгъзаларының килеп туган барча мәсьәләләрне белеп, тикшереп торганлыгы күренә.

— «Башка яклардан сезгә ярдәм итәләрме» диюегезгә шуны әйтергә телим. Әйе, ярдәм итәләр. Кайбер халыкара мәсьәләләрдә Төркия хокукый яклап та, финанс яклап та зур ярдәм күрсәтә. Польша хөкүмәте дә онытмый. Хәтта Финляндиядәге милләттәшләр дә ярдәм кулы сузгалыйлар. Төркия безнең яшьләрне үзенең югары уку йортларында үзе үк стипендия түләп укыта. Татарстан да кайчак искә төшереп куя. Бик тә кыен, тәүге чорда, туксанынчы еллар башында, ярдәм шактый булды.

Җәүдәт әфәнде Кырым татарларына җир бүлеп бирү мәсьәләләрендә җаваплы вазифа били икән. Минем кулымда «Крымскотатар блогы. Исмаил-Бейга 15 ел. Ничек булды?» дигән китап. Дикъкать белән укып утырам. Бу китапта Кырым татарлары ничек итеп депортациядән кайтып, үзләренең авылларын төзүләре турында хатирәләрен бастырганнар. Авылга татар халкының данлыклы улы Исмәгыйль Гаспринский хөрмәтенә аның исемен биргәннәр. 46нчы биттә Иса Пурмамбетов язган мондый юллар бар: «Во время захвата(земли) по поручению руководителя пикета Наримана Ибадуллаева и председателя горисполкома Анатолия Кравченко был командирован в Татарстан, где договорились о поставке 250 тонн картофеля. В том году в Евпатории был неурожай. За два дня с помощью депутата Татарстана Фаузии Байрамовой удалось решить этот вопрос. ...»

Җәүдәт әфәнде белән әңгәмәмне дәвам итәм.

— Әлегесе көндә җинел дип әйтә алмыйм. Халыкның күбесе җирдә эшли. Үзе үстергән яшелчә-җимеш белән базарда сату итә. Берничә ресторан һәм магазин тоткан эшкуарлар бар. Кешеләргә үз өйләрен төзеп керергә төзелеш материаллары җитешми, аларны табуы кыенлашты. Ничек кенә булмасын, халык тырыша инде.

***

Кырым татарларының Милли мәҗлесеннән чыккач, аларның шуннан бик ерак булмаган Милли музеена юл алдым. Музей үзе бик иске генә бер бинага урнашкан. Алгы бүлмәдә жылы: бер читтә мич бик күнелле генә дөрләп утыра. Ташкүмер ягалар икән, Симферополь уртасында әлеге көндә менә шулай яшәп яталар. Музей хезмәткәрләре мине бик җылы каршы алдылар. Һәм мине берничә залда урнашкан экспонатлар белән таныштыралар. Күп әйберләре безнең музей экспонатлары белән бер. Исемнәрендә дә аерма бик әз. Уртада



*Музейда Кырым татарлары киеменә киендерелгән курчаклар*

палас сугу станогы утыра. Минем картәнидән калган станоктан берниндә аермасы юк. Шул ук чыгыр һәм кәҗә мамыгын тетә торган ая да бар. Татар халкының кием үрнәкләре, матур-матур палас һәм тастымаллар эленеп тора.

Экспонатлар күп тә ул, тик урын гына бәләкәйрәк дип уфтанды хезмәткәрләр. Алар янарак кына оешып экспонатлар җыя башлаганнар икән. Тәҗрибәләре дә азрак. Тоташ бер халык өчен шушындый гына музей тоту минем күнелемә авыр тәэсир итте. Безнең Эстәрлебаш районындагы Янгырчы һәм Тәтер-Арыслан мәктәп музейлары баерак та, яхшы биналарда да урнашканнар. Музей эшмәкәрләре белән бик тәмләп сөйләшә-сөйләшә чәй эчеп, җылы гына хушлашып аерылышабыз.

Булыр, булыр әле бу бик тә тырыш һәм күп михнәт, җәберләүләр күреп иң каты геноцидларга дучар булган кардәшләребезнең үзләренең шәп музейлары, театрлары. Мин үзебезнең бай-бай милләттәшләребезнең чиркәү арты чиркәү төзетеп, шунын белән башка милләтләр алдында мактанышканнарын беләм. Ә ерактагы милләттәшләребез булган Кырым татарларына бүген хәтта балалар укыту өчен дәфтәр-китап табу да җинел түгел. Мөгаен, берәр банкта исәп ачып, туганнарыбыз өчен ярдәмгә акча җыя башларга вакыттыр. Ил төкерсә күл була бит.

Музейдан соң бинаның икенче яртысын биләгән «Голос Крыма» гәзит нәшриятына керәм. Монда да бик җылы каршы алдылар.

Сорауларыма Диләрә ханым Челенгарова бик теләп җавап бирде.

— Безнең гәзит 1993 елны иң кыен вакытларда чыга башлады. Тиражы хәзер ун меңнән артык. Аны урыс телендә чыгаруыбызның сәбәбе — халкыбызның күп өлеше үз телендә яза да, укый да белми. Әле дә күпләр сагынып искә алган СССРның безгә карата милли сәясәте инде бу. Көләрсең дә, еларсың да. Россиядә яшәгән татарларны мишәрләргә, керәшеннәргә, болгарларга бүлгәләргә тырышкан кебек, безне дә бүлгәләргә телиләр. Имеш, без татарлар түгел, кырымлылар. Үзегезне «кырымлылар» дип атагыз дип безгә чик аша киңәш биреп яталар. Безне шушы хәлгә төшерүчеләр кем икәнен оныттылар микәнни? Алар әлеге көнне дә безгә төрлечә аяк чалалар.



*Яшьләр Милли мәҗлесе әгъзасы Айдар Җанбетов*

Гәзиттә халык өчен актуаль мәсьәләләр турында язабыз. Халкыбызның үткәнен, тарихын даими искә төшерәбез. Халкыбызны Кырымнан көчләп куып чыгаргач, татар телендәге китаплар китапханәләрдән алып, яндырылды. Архивларда безгә, безнең тарихка кагылышлы бер материал да тапмассың. 20-21нче елларда махсус оештырылган ачлык та татарлардан котылыр өчен генә эшләнде. Ә бит ул елларда Украинада иген уңышы мул булган. Кырымда да ул елларда иген унган. Тик, Идел буенда ачлыктан кырылган халыкларга ярдәм итәбез дип, Кырым татарларының барча үстергән уңышын тартып алалар. 33нче елны Украинада оештырылган ачлыкны әйтеп тә тормыйм, бу турыда күп язылды инде. Безнең халык ул ачлыктан да читтә калмады. Гәзит халыкның бүгенге көне белән, бүгенге проблемалары эчендә кайный. Менә шулай шау-гөр килеп халык белән бергә яшәп ятабыз.

Мин янә Кырым татарларының Милли мәҗлесенә кайттым. Һәм миңа тагы берничә кызыклы шәхес белән очрашып сөйләшергә туры килде. Шуларның берсе Айдар Җанбетов дигән яшь кенә егет. Күп кенә милләттәшләре кебек, тарихи ватаннарыннан читтә, Ташкент өлкәсендә туа ул.. Төп шөгыле — журналистика. Кырым татарлары яшьләр шурасының әгъзасы, Яшьләр шурасы ике өлештән тора. Югары советта барлыгы егерме бер кеше. Югары совет эчендә кече совет бар икән, ул советта җиде кеше. Кече совет төрле оештыру эшләре һәм финанс мәсьәләләре белән шөгыльләнә. Югары совет Милли мәҗлескә ярдәм итә һәм аңа буйсына. Шулай итеп, яшьләр дә Кырым татарларының автономия өчен көрәшендә актив катнашалар. Бүгенге көнне яңа оешып килгән авыл-поселокларда үзләренең бүлекләрен булдыру белән мәшгульләр.

Яшьләр берләшмәләреннән «Кардәшлек» һәм тагы берничә оешма бар. Барлык оешмалар да бергә берегеп, бер-берсе белән киңәшләшеп эш итәләр. Барыбыз да бер максат белән янабыз. Барча булган яшьләр оешмаларын бер үзәккә тупламаска булдык. Безнеңчә, яшьләр шулай уңышлырак, бер-берсе белән ярышып, бер-берсеннән үрнәк алып, өйрәнеп эш итәләр. Үзебезнең милли театрыбыз һәм фольклор ансамблебез эшләп килә. Күп кенә мәдәни һәм

башка чаралар үткәрергә акча житеп бетми. Яшьләр оешмасы да үзебез керткән взноска гына яши.

Кырымга кайткан туганнарыбыз тату-бердәм яшәп яталар икән. Милли мәжлес рәисе Мостафа Жәмилов әфәнде белән, кызганычка каршы, очраша алмадым. Ул Киевка, хөкүмәт әгъзалары белән очрашуга киткән булып чыкты. Әмма мина Милли мәжлеснен бер утырышында катнашырга туры килде. Утырышта яна кайткан милләттәшләргә һәм яна өйләнешеп, башка чыгып, үз тормышларын башларга теләүчеләргә жир бүлеп бирү мәсьәләсе тикшерелде.

Менә шулай яшәп, көрәшеп яталар Кырымдагы милләттәшләребез.

***

Ниһаять, язып бетердем дип шатландым. Ә бит әйтергә теләгән сүзләремнен яртысын да әйтә алмадым. Шуннан эш өстәлендәге барча кәгазьләремне тузган килеш калдырдым да, башка бераз ял булыр дип ишек алдына чыгып киттем. Малларны карап кире керсәм, өстәлдә яткан кәгазьләремне беркадәр туган тиешле танышым укып утыра. Мин керүгә, теге Сталин имзасы куелган яшерен приказны кулына тотып:

— Карале, туганым, Кырым татарлары нинди явыз, мәкерле булганнар икән, — ди бу. — Барча халык фашизм белән көрәшеп ятканда алар, сатлык жаннар, фашистларга хезмәт иткәннәр, — ди тәмам ярсып. — Юньсез халык икән. Шул кирәк аларга. Сталин урынында булсам, мин барысын да стенага терәр идем әле, — ди.

Шаккатмалы хәл. Заманалар үзгәреп, Сталиннын кемлеге ахыргача ачылып беткәч тә, халыкнын шактый өлеше аңа һаман мөкиббән, анын тинсез явызлыкларын хупларга әзер әле.

Апам әйткән сүзләрне кемнәрдер бүген безнен хакта да әйтә алыр иде бит. 1944 елгы кара исемлектә без дә булганбыз. Бөтен СССРга таралган күп миллионлы татарны жыеп алу кыенлыгы гына кулдан тотып кала...

*2011*

**P.S.** Хатирәләрдә хата-фәлән киткән булса, алдан ук гафу үтенәм. Аларны сөйләүчеләр карт кешеләр бит.

Фирдәвес
Гарипова

# АВЫЛЛАРЫБЫЗ ТАРИХЫ

## Мәлбагыш

Мәлбагыш авылы Азнакай районына карый, ул район үзәге Азнакай шәһәреннән 30 чакрымда, тимер юл станциясе Ютазыдан – 60, Чаллы пристаненнән 145 чакрым ераклыкта урнашкан.

1859 ел мәгълүматларына караганда, Югары Якый (Мәлбагыш) авылындагы 82 хуҗалыкта 301 ир-ат һәм 321 хатын-кыз яшәгән. Бер мәчет булган.

Олылар сөйләвенчә, Мәлбагыш авылы моннан 400 еллар элек оешкан. Авылга Яхъя исемле кеше нигез салган, тик аның кайсы яктан килүе билгеле түгел. Шул исемгә мөнәсәбәтле рәвештә авылны башта Якый дип йөрткәннәр.

Соңга таба, бигрәк тә XVIII гасырның икенче яртысында бу якка төрле җирләрдән кешеләр килеп урнаша башлаган. Алар арасында Алатыр шәһәре тирәсеннән килүче мишәрләр дә булган. Кешеләрнең бирегә күпләп күчеп килүен өлкән буын вәкилләре 1773-75 еллардагы Емельян Пугачев хәрәкәте белән һәм бу якларда буш җирләрнең күплеге белән аңлата.

Мәлбагыш авылы 1781 елдан Бөгелмә өязе Микулин волосте Уфа наместничествосына керә. 1804 елдан ул Оренбург губернасында исәпләнә башлый. 1850 елда Самара губернасы оештырыла һәм авыл шул губернага кертелә. 1918 елдан ул Татар-Башкорт Республикасы составында, 1920 елдан Әлкәй волосте Бөгелмә кантоны ТАССР составында була. 1930 елдан Мәлбагыш Азнакай районына карый.

1859 елгы губерна архивы мәгълүматлары буенча авыл турында түбәндәгеләр билгеле: Якый авылындагы 237 хуҗалыкта 645 ир-ат, 695 хатын-кыз яшәгән, 1 мәчет, 1 мәдрәсә, 3 су тегермәне булган.

1872 елда авылның мәчете яна һәм аның урынына яңа мәчет салалар. Ул 1967 елга кадәр торган.

1910 елгы архив мәгълүматлары буенча, авылда 325 хуҗалык булып, аларда 815 ир-ат, 834 хатын-кыз исәпләнгән.

1914 елның язында көчле янгын чыгып, авылның 350 йорты янып беткән.

Авыл исеме каян килеп чыккан? Бу турыда авылның аксакаллары болай фикер йөртә. Мәллә елгасы авылның көньягында 4 чакрым чамасы арырак урнашкан урманнан башлана һәм авыл уртасыннан агып үтә. Әгәр авыл атамасы елгага мөнәсәбәтле рәвештә барлыкка килсә, Мәлләбаш, ягъни Мәллә суы башланган урында утырган авыл дип исемләнер иде. Мәллә суының Ыкка кушылган җирендә урнашкан авыл Мәллә Тамак дип аталган. Ә менә авылның көнчыгышындагы урманнан, берничә тармактан җыйналып Малбагыш дип аталган икенче елга (инеш) тау буйлап күп кенә тугайлар ясап агып төшә дә, авыл уртасында Мәллә суына килеп кушыла. Нәкъ менә елгалар кушылган урында авыл оеша башлый, чөнки тау буенда чишмәләр дә шактый күп булып чыга.

*Дәвамы. Башы 2006 елның 6нчы санында.*

Малбагыш суы буендагы яшел болыннарда, әрәмәле тау буйларында, урман аланнарында борынгыдан ук кешеләр мал (терлек) көтеп, карап, ягъни мал багып йөргәннәр. Шунын өчен ул елга Малбагыш дип аталган. Авыл картлары авылны Мәлбагыш дип түгел, ә Малбагыш дип йөртә һәм әлеге фикерне яклыйлар.

Бүгенге көндә Мәлбагыш авылында ике катлы урта мәктәп, мәдәният йорты, медицина пункты, китапханә һәм мәчет бар.

Авылда ике зират исәпләнә. Мәетләрне шуларның берсенә генә җирлиләр, иске зиратка күммиләр.

Авыл янындагы тауны халык Кызыл тау дип йөртә, Тау артындагы күлне Торна күле дип атыйлар. Монда элек һәр елны торналар кайтып бала чыгара торган булганнар. Якындагы рус авылында руслар белән күрше булып яши торган татарларны мәләкләр дип йөрткәннәр. Шуннан Мәлән чокыры, Мәлән урманы, Мәлән яланы кебек атамалар сакланган.

## Күшәр

Янгыраашлары уйга сала торган, ә килеп чыгышларын аңлату шактый кыен булган атамалар республикабызның һәр районында очрый. Атама борынгырак булган саен, аның мәгънәсен ачу шулкадәр кыенрак. Шушындый атамалар исәбенә Күшәрне кертергә мөмкин.

Күшәр авылы Әтнә районында, район үзәге Олы Әтнәдән 5 чакрымда, җирле үзидарә үзәге Күнгәр авылыннан – 4, тимер юл станциясе Арчадан – 43, Казан шәһәреннән 77 чакрым ераклыкта урнашкан.

Авыл атамасы тарихи-географик, географик-статистик чыганакларда һәм халык авыз иҗаты әсәрләрендә еш кулланыла.

Алат юлы өстенә утырган Күшәр авылы Казан ханлыгы чорында ук булган. Авыл 1602-03 елларны эченә алган Казан өязенең теркәү кенәгәләрендә дә искә алына. 1600 елның сентябре – 1601 елның августы белән Күшәр атамасы И.П.Ермолаев чыганагында да китерелә. 1650 елның 9 апрель датасы белән Күшәр авылы бер тарихи чыганакта искә алына.

Д.А.Корсаков җыентыгындагы исемлеккә Күшәр авылы да кергән, анда 82 йомышлы татар һәм 121 дворовый кешеләр яшәгән. 1761 – 1866 елларда үткәрелгән Генераль ызанлау мәгълүматларыннан күренгәнчә, Күшәр авылында һәм Мукшы пүчинәсендә морза кенәзләре Мөхәммәт һәм Муса Мортазиннар (Яушев балалары), аларга хезмәт итүче дворовый кешеләр, йомышлы татарлар яшәгән.

Ашыт суы буендагы бу авыл элек өч аерым бистәдән торган: Йомышлылар Күшәре, Ясаклылар Күшәре һәм Ташчишмә. Ясаклылар Күшәре икенче төрле Мокша исемен дә йөрткән. Күшәр халкы тимерчелек, балта эше, тегермәнчелек һөнәрләре белән көн күргән.

1898 елгы чыганакта авылда татарлар яшәгәнлеге күрсәтелә. К.П.Берстель Күшәрне болай сурәтли: Күшәр (1нче өлеш), Күшәр (2нче өлеш) – Йомышлылар, Күшәр (3нче өлеш) – Ясаклылар.

Авыл бик матур, тигез җиргә урнашкан. Анын болын-кырлары күп, ике зур урманы бар. Кечкенә урманны Коллар урманы дип йөртәләр. Коллар дигәннән, авылның өлкән буын кешеләре буыннан-буынга бирелгән түбәндәге хәлләрне сөйли. Күшәр алпавыты Әйшә авылыннан коллар алып кайта. Күшәр авылының олы урамы Әйшә урамы дип аталу, һичшиксез, шуның белән бәйләнгән булыр. Ә 1552 елда, Явыз Иван Казан ханлыгын яулап алганнан соң, Күшәргә морзалар токымыннан булган Яуш, Каныш һәм Кадыш исемле аксөякләр килеп урнаша. Алар христиан диненә чыгалар һәм Яушев, Каныше, Кадышев булып китәләр. Соңыннан алар, Күшәрдәге җирләрен сатып, Мәскәү һәм Петербург калаларына күченә.

Авылның көнбатыш ягында болынлыклар җәйрәп ята. Болыннарны ярып Ашыт суы ага. Элек аның суы бик мул булган, берничә су тегермәне эшләгән, ә хәзер елга бөтенләй саегып килә. Шуна да карамастан, Ашытта балык күп әле.

Элек басу уртасыннан Күшәрдән Мөндеш дигән авылга бара торган юл үткән. Ул юл янында, басуның урта бер җирендә "Кәкре каен" дип йөртелгән каен агачы

үсеп утырган. Бу каен янында кешеләр адашып, юл саташтырып аптырап йөргәннәр. Берничә ел элек бу каенны төбе-тамыры белән алып ташлаганнар...

Күшәр атамасы, Татарстаннан тыш, күрше җирлекләрдә дә очрый. Элекке Козмедемьян өязендә Иделдә Күшәр пристане һәм Күшәр сайлыгы булган.

## Кызыл Мишә (Бөкмеш)

Кызыл Мишә авылы Саба районында, район үзәге Сабадан 9 чакрым ераклыкта, җирле үзидарә үзәге Тимершык авылыннан – 4, Шәмәрдәннән – 14, Вятка Аланыннан 64 чакрым ераклыкта урнашкан.

Бөкмеш атамасы тарихи белешмәләрдә очрый.

И.А.Износков бастырып чыгарган белешмәдән күренгәнчә, авыл Бөкмеш (Букмыш), Бөкмеш суы ярына утырган (по речке Букмыш), Тау өстендәге бушлык (Пустошь на горе) дип аталган. Анда 387 ир-ат һәм 386 хатын-кыз яшәгән. 1898 елда басылып чыккан белешмәдә Бөкмеш авылында татарлар көн иткәнлеге әйтелә. К.П.Берстель (1908) белешмәсеннән күренгәнчә, Бөкмеш авылында 1094 татар кешесе гомер кичергән.

Н.Б.Борһанова мәгълүматларына караганда, Бөкмеш авылы халкы күршедәге Курсабаш, Мичәнбаш, Кырбаш, Олыяз, Пүкәл, Өтернәс, Эзмә, Иске Шекше, Яна Шекше, Мишәбаш, Явлаштау, Сәрдә, Иләбәр, Көек авыллары белән Калатау җыены бәйрәм иткән.

Олылар авылны иң беренче булып Сәет һәм Төхфәт исемле кешеләр нигезләгән дип сөйлиләр. Бөкмеш атамасы авылга Кече Мишә елгасының бөгелеп киткән урынына утырган өчен бирелгән. Эзмә авылы белән ике арада зур чирмеш зираты булган.

Кызыл Мишә авылы Кече Мишә суының уң ярына утырган. XIX йөз башларында авылның 60 процент халкы атсыз ярлылардан тора. Зират белән Мишә суы арасындагы яхшы җирләр һәм Шомырт чишмәсеннән Тимершык елгасына таба сузылган урынны (22 гектар) Шаһи бай били.

XX йөз башында авылда кечкенә генә бер мәдрәсә салына. Анда ялланып укыткан хәлфәләр дин сабагына өйрәтә.

1929 елда укый-яза белмәүчеләрне укый-язарга өйрәтү эше киң җәелдерелә. 1929-30 елларда кулак тамгасы тагылган Шәехов Зариф йортын һәм әптек (аптека) очы мәчетен мәктәп итеп җайлаштырып, 108 баланы 4 укытучы укыткан. Мәктәп дүрт класс тәмамлаган 24 укучыны Казан текстиль фабрикасы училищесына (ФЗУ) бирә. Фабрика мәктәпне шефка алып, мәктәпкә радиоалгыч һәм 500 сумлык китапханә бүләк итә.

Бөек Ватан сугышына авылдан 120 кеше китә. Аларның 62се үлеп кала, 29 кеше медаль һәм орденнар белән бүләкләнә.

1963 елда колхоз көче белән авыл электрлаштырыла. 1967 елда авыл дәүләт электр челтәренә тоташтырыла. Ындыр табагындагы, ферма һәм тегермән эшләре электр көче белән башкарыла.

Кызыл Мишә авылы табигатьнең ямьле бер почмагында урнашкан. Авыл янынннан Кече Мишә суы агып уза. Мишәгә Бөкмеш башы елгасы, Иләк елгасы, Иске кала елгасы, Ялгыз имән елгасы, Үләт елгасы кушыла.

*Дәвамы киләсе саннарда.*

# П

**ПОВЕСТЬ**, хикәя һәм роман арасында торган урта күләмле чәчмә жанр. Урта гасыр төрки-татар әдәбиятында ана дини үгет-нәсихәт бирү характерындагы хикәят һәм кыйссалар якын тора. Татар әдәбиятында П. 19 йөзнең 2 нче яртысында формалаша. Жанр мәгърифәтчелек әдәбияты кысаларында гамәлгә куела (татар җәмгыятенең сүз көченә таянып Европа үрнәгендә үсү мөмкинлеге турындагы идея). Иҗтимагый проблемалар күтәрүе, тормышка тирән иҗтимагый-фәлсәфи бәя бирергә омтылуы белән П.: социаль-көнкүреш (Р.Фәхретдиннең «Сәлимә, яки Гыйффәт», «Әсма, яки Гамәл вә җәза»; Г.Гафуровның «Тутам»; Г.Исхакыйның «Кәләпүшче кыз», «Бай угълы»), романтик (Ф.Кәриминең «Морза кызы Фатыйма»), иҗтимагый-тәнкыйди (З.Һадиның «Яңа әсхабе кәһәф», «Җиһанша хәзрәт»), сатирик (Ш.Мөхәммәдовның «Җәһаләт, яхуд Галиәкбәр агай», «Яфрак асты, яхуд Мәкәрҗә ярминкәсе» һ.б.) төрләренә бүленә. 20 йөз башында мәгърифәтчелек карашлары заманга карата тәнкыйди мөнәсәбәт б-н алмашына, чынбарлыкның шартлы моделен булдыру омтылышы барлыкка килә. Аның нигезе булып фантастик кимәлдә тәкъдим ителгән пародия (Ф.Әмирханның «Фәтхулла хәзрәт»), автобиографик мотивлар (Г.Исхакыйның «Зиндан», Г.Тукайның «Исемдә калганнар», Ф.Әмирханның «Тәрҗемәи хәлем») тора. Беренче планга психологик (Г.Исхакыйның «Тормышмы бу?»; Ф.Әмирханның «Хәят»; М.Гафуриның «Хәмитнең хәяты», «Мәхәббәт хатлары»), иҗтимагый (Ш.Камалның «Акчарлаклар») һәм романтик-психологик (С.Җәләлнең «Дим буенда», Г.Исхакыйның «Очрашу, яки Гөлгыйзар») проблематика чыга.

1920-30 елларда татар әдәбияты сәяси һәм идеологик басым кичерә. Күптөрле эстетик омтылышлар янәшә яшәгән чор шартларында соц. идея б-н бәйле яңа әдәби система формалаша. Әйдәп баручы урынны Окт. рев-циясе һәм Гражд. сугышы вакыйгаларына (Г.Ибраһимовның «Кызыл чәчәкләр»; Г.Бәшировның «Сиваш»), коллективизациягә багышланган (К.Нәҗминең «Кояшлы яңгыр», «Якты сукмак»; М.Әмирнең «Агыйдел») героик-романтик һәм героик-трагик П. ала. Соц. үзгәрешләрне ирония белән шәрехләү омтылышы Ф.Әмирханның «Шәфигулла агай» сатирик шаржында, татар П.ның милләт язмышына игътибар бирү ягыннан рев-циягә кадәрге традицияләрне үстерү — Гали Рәхимнең символларга бай романтик рухлы «Идел» әсәрендә күзәтелә. Ләкин бу омтылышлар башкача фикер йөртүчеләргә каршы юнәлтелгән кампания башлангач кире кагыла. Башлыча көнкүреш П. төзелеп ятучы яңа тормыштагы кискен соц. конфликтларны чагылдыру мөмкинлеге тудыра. Әйтик, дини хорафатларга, искергән карашларга каршы чыгып, тормышта үз урынын тапкан авыл хатыны язмышына А.Шамовның «Рәүфә» П.те багышланган. Г.Кутуйның «Тапшырылмаган хатлар» П.ндәге Галия образы мисалында мәхәббәткә, гаиләгә, хатын-кызның җәмгыятьтә тоткан урыны һәм роленә кагылышлы булган искелек б-н яңалык конфликты күрсәтелгән. Соц. җәмгыять төзү процессы, эшче яшьләрнең көндәлек тормышы И.Газиның «Көмеш сулы Нурминкә», «Бригадир кыз» П.да чагылыш таба. Соц. идеяне раслап, язучылар үткәннәргә мөрәҗәгать итә, бүгенге көнне тарихи ретроспективада карыйлар (Г.Ибраһимовның «Татар хатыны ниләр күрми»; М.Гафуриның «Кара йөзләр», «Шагыйрьнең алтын приискасында»), фантастик-романтик формалар кулланалар (Ш.Усмановның «Памирдан радио»). 1921 елгы ачлыкны тасвирлау натуралистик һәм публицистик тенденцияләрне көчәйтә (Г.Ибраһимовның «Адәмнәр»). Житештерү һәм колхоз төзү, Октябрь революциясе һәм Гражданнар сугышы турында язучы проза авторлары әдәби тормышның алдынгы сафына чыга.

1940-50 нче елларда П. жанры сүл-

*Дәвамы. 2005 елның 4нче саныннан басылып килә.*

пәнәя төшә. Бөек Ватан сугышы вакыйгаларын героик-романтик төстә күрсәтү Ф.Кәримнең «Разведчик язмалары», «Язгы төндә» П.дә чагылыш таба. Сугышның көндәлеген тасвирлаганда, автор фәлсәфи гомумиләштерүгә омтыла (конкрет вакыйгалар ике дөньяның бил алышуы төсен ала), фашизмның кешелек өчен фаҗига булуын ассызыклый. Сугыш еллары прозасында лирик тәүбә традицияләре үсеш ала. Мәхәббәт, тугрылык, дуслык һәм хыянәт турындагы Ф.Хөснинең «Йөзек кашы» П.дә лирик-психологик башлам көчле: сугыш кешенең әхлакый пакълыгын һәм намусын сынау аша уздыручы факторга әверелә. Г.Кутуйның «Рөстәм мажаралары» П.дә мавыктыргыч мажаралы форма җиңүгә какшамас ышаныч б-н үрелеп бара.

Сугыш темасы әдәбиятта сугыштан соң да әйдәп баручы булып кала бирә. Н.Дәүлинең «Яшәү белән үлем арасында», «Җимерелгән бастион» социаль-психологик П.дә немец лагерьлары, сугыш елларының фаҗигале мизгелләре тасвирлана. 1960 елларда Ш.Рәкыйпов татар әдәбиятында беренче булып документаль П. жанрында яза башлый. Аның («Чәчәкләр сөйли белә», «Кайдан син, Җан?», «Кызлар-йолдызлар», «Кипарислар җыры» һ.б.) әсәрләрендә чын язмышлар һәм конкрет кешеләр героизмы күрсәтелә. Фронтовикларның тыныч тормышка кайтулары Ф.Хөснинең «Җәй башы» П.дә тасвирлана. 1950 еллар П.те татар авылы тормышын яна яктан ачты.

И.Газиның «Алмагачлар чәчәк ата», Ә.Еникинең «Рәхмәт, иптәшләр» П.дә тормышка искечә һәм заманча караш конфликты совет чынбарлыгында яшәп килгән күп кенә проблемаларны фаш итә. Колхозлар төзү эшенең киеренкелеген, кискенлеген, җитәкчеләрнең тар фикер йөртүләрен, аларның каты бәгырьле булуларын, шәхси байлык туплауга омтылуларын ачып бирү б-н бергә, авторлар бер үк вакытта кешенең тормышны үзгәртә алуына ышанып, фидакарь герой-активист образлары тудыралар (Ә.Еникинең «Саз чәчәге», «Рәшә»; Ф.Хөснинең «Авыл өстендә йолдызлар»).

Татар әдәбиятында П. жанрының чәчәк аткан чоры 1960-80 нче елларга карый. Автобиографик П. активлаша. Балачак темасына мөрәҗәгать итеп, әдипләр милли тарих (бигрәк тә, 20 гасыр башын) һәм тоталитаризм чорының ачы чынбарлыгын тасвирлау мөмкинлекләрен эзли. И.Газинең «Малай чак», Р.Төхвәтуллинның «Җиләкле аланнар», М.Әмирнең «Без бәләкәй чакларда», «Хатирәләр урманы», Ф.Хөснинең «Минем тәрәзәләрем», Ә.Еникинең «Соңгы китап», Г.Бәшировның «Туган ягым — яшел бишек», Г.Минскийның «Яшенле яңгыр», Ш.Маннурның «Агымсуларга карап», Г.Ахуновның «Йолдызлар калка» кебек автобиографик материалга нигезләнеп язылган П.да күп кенә милли, иҗтимагый, фәлсәфи мәсьәләләр күтәрелә.

«Авыл» П.те, тормышка әхлакый-фәлсәфи караш ташлый алуы, халыкның гореф-гадәтләренә мәхәббәте, зирәклеге б-н, соцреализмның схемачылыгыннан котылу чарасы булды. Р.Төхвәтуллинның «Авылдашым Нәби», «Йолдызым», А.Гыйләҗевнең «Язгы кәрваннар», Ә.Баянның «Яшьлегемне эзлим» П. геройлары — буыннарның күп гасырлык тәҗрибәсен саклаучылар, халыкның әхлакый васыятен үтәүчеләр. Алар тормышка, табигатькә, кешеләргә рухсыз, үз ихтыяҗларын гына канәгатьләндерүгә корылган мөнәсәбәткә каршы куелалар. Лирик пафосның тыгызлыгы, символларга мөрәҗәгать итү, тормышны фәлсәфи танып-белү һәм кешенең әхлакый принциплары арасындагы элемтәләрне эзләү П.нең үзенчәлекләрен тәшкил итә. Татар авылының бүгенгесенә эпик караш аша авторларның күбесе 20 гасыр тарихын тулаем күрсәтә алдылар, коллективлаштыру, шәхес культы, көчле кешенең сындырылуын бәяләргә тырышты, татар халкы өлешенә төшкән сынауларга укучы игътибарын юнәлтте (Н.Фәттахның «Кырык дүртнең май аенда», А.Гыйләҗевнең «Өч аршын җир», «Җомга көн, кич белән», Г.Ахуновның «Чикләвек төше»). Геройларын трагик вакыйгалар аша уздырып, прозаиклар кешегә язмышка каршы торырга ярдәм иткән көч һәм кыйммәтләрне барлыйлар (Хәсән Сарьянның «Бер ананың биш улы», М.Мәһдиевнең «Кеше китә — җыры кала», А.Гыйләҗевнең «Яра»). 1970-80 нче еллар татар авылын игътибар үзәгенә куеп, авторлар матди муллыкка омтылу, рухи кыйбланы югалту б-н бәйле яңа конфликтлар таба (А.Гыйләҗевнең «Әтәч менгән читәнгә»). Татар авылының үткәнен бүгенге көн күзлегеннән чыгып яктырту һәм бәяләү аша, П. 20 гасыр тарихына гомуми караш формалаштырды. Нәкъ менә П. беренчеләрдән булып ГУЛАГ темасына мөрәҗәгать итте (И.Салаховның «Колыма хикәяләре »), Бөек Ватан сугышы вакыйгаларын яңадан бәяләргә кереште (М.Юнысның «Биектә калу»). Сәнәгать темасына багышланган П.тә экологик (М.Әмирнең «Балыкчы ялганнары», Г.Ахуновның «Артышлы

тау буенда», Р.Төхвәтуллинның «Агымсу») һәм иҗтимагый (А.Расихның «Ике буйдак», «Сынау») проблемалар заманча көн тәртибенә куелды.

20 гасыр ахырында П.нең төрле стиль агымнарына, үсеш юнәлешләренә бүленүе аның үсеш үзенчәлегенә дә тәэсир ясый. Өлкән буын прозаиклар тормышның иҗтимагый һәм әхлакый мәсьәләләренә мөрәҗәгать итә: Г.Бәшировның «Көзге ачы җилләрдә», «Сарут»; Г.Ахуновның «Этләр патшасы»; Р.Батулланың «Юл буенда зәңгәр чәчәк» һ.б. Җәмгыятьтә дә, кеше күңелендә дә канәгатьсезлек тойгылары көчәя (Ә.Баянның «Урланган ай»; М.Галиевнең «Ерак урман авазы»). Ф.Бәйрәмованың «Болын», «Битлек», «Кем?» экзистенциаль-психологик П.ре һ.б. татар П.нең жанр чикләрен киңәйтеп җибәрә. П.ләр психологизм алымнарын, символлар һәм метафорик образлар кулланунын өр-яңа мөмкинлекләрен ача. Дини һәм мифологик символиканың иҗтимагый тәгаллеккә омтылу б-н кушылуы Ф.Бәйрәмова карашларының фәлсәфи тирәнлеген тәэмин итә («Канатсыз акчарлаклар», «Кыңгырау»). Милли дөнья картинасын сурәтләү омтылышы, милли характерны, милләт образын тергезү 20-21 йөзләр чиге прозасында үзенчәлекле күренеш булды (А.Хәлимнең «Өч аяклы ат», «Татар вакыты»; В.Имамовның «Япон татары»). Н.Гыйматдинова әсәрләрендә шартлылыкның мифологик төре магик, мистик сыйфатлар б-н кушылып, ике төрле тормыш моделе тудыра: «Сихерче», «Ут күбәләге», «Кыргый», «Ак торна каргышы» һ.б. Гыйбрәтле хикәянең (притча) корылыш тәртибенә нигезләнеп, прозаиклар кеше психикасының аң һәм аң төпкеле өлкәләрен тасвирлау объектына әйләндерә (Ф.Бәйрәмованың «Алыплар илендә»; З.Хәкимнең «Курку»; Ф.Садриевның «Рәхмәт, әтием!..»; Разил Вәлиевнең «Эт кояшы» һ.б. Советлардан соңгы җәмгыятьтә кешенең рухи таркалуга йөз тотуы З.Хәкимнең «Кишер басуы», М.Кәбировның «Сары йортлар сере», Фаил Сафинның «Соңгы көз»ендә ассызыклана. Гасырлар чигендә П.тә романтик караш (М.Галиев, М.Кәбиров, Мансур Вәлиев, Ә.Салах); сентиментальлек активлаша (Ф.Яруллин, Ф.Садриев). Бүгенге татар П.нең аерылып торган сыйфаты – фәлсәфи һәм психологик тирәнлеккә омтылу, дия алабыз.

Әдәб.: Татар әдәбияты тарихы: 6 томда. К., 1989-2001; Заһидуллина Д.Ф. Яңа дулкында (1980-2000 еллар татар прозасында традицияләр һәм яңачалык). К., 2006.

*Д.Ф.Заһидуллина.*

**ПОЭМА** (грекч. poiema – ясыйм, иҗат итәм), зур күләмле лиро-эпик жанр атамасы. Эпостан хикәяләү, сюжетлылык, персонажлар системасын, әйберләр дөньясын кабул итә, лирикадан – субъектив кичерешләрне гәүдәләндерү, лирик геройның булуы, чагыштырмача уртача күләмгә һәм шигъри телгә тартылуны алган; П.нең чыганаклары еш кына фольклорга барып тоташа. Төрки-татар әдәбиятында беренче П. – Кол Галинең «Кыйсса-и Йосыф». Гасырлар дәверендә П.да идеологик синкретизм чагылыш таба: этик-дидактик мотивлар фәлсәфи фикерләр б-н, реалистик элементлар – дини-фантастик һәм мифологик элементлар б-н үрелеп бара. Эчтәлек үзенчәлеге һәм сәнгати структурасы буенча, нигездә, П.ның 3 типологик төрен аерып чыгаралар (19 гасырга кадәр төрле күчемле формалар яшәп килгән). Беренче тип – героик П. – халык героикэпик риваятьләренә барып тоташа. Алтын Урда чорында исламны пропагандалауга багышланган дини-мифологик П.лар язылган («Кыйсса-и Авык», «Кыйсса-и Сәкам», «Кыйсса-и Әхтәм»). Икенче тип – эпик-дидактик – халык авыз иҗатының нәсыйхәт жанрларыннан килә (вәгаз, нәсыйхәт, терме, санәт). Бу төр әсәрләрнең идея-тематик үзенчәлеген этик-тематик мотивларының фәлсәфә б-н үрелеп баруы тәшкил итә: кеше яшәеше турында уйланулар, кешенең җирдәге роле һәм максаты, мәхәббәт кичерешләре, яшәү һәм үлем турындагы уйланулар (Харәзминең «Мәхәббәтнамә»се, Хисам Кәтибнең «Җөмҗөмә Солтан»ы). П.ның өченче тибына мәхәббәт-романтик һәм авантюра-новеллистик П.лар керә. Аларда илаһи һәм дөньяви мәхәббәт нечкә, хисчән һәм тирән итеп чагылыш таба (Котбның «Хөсрәү вә Ширин»е, Сәйф Сараиның «Сөһәйл һәм Гөлдерсен»е, Сәйядинең «Дастане Бабахан»ы).

Казан ханлыгы чоры шагыйре Мөхәммәдьярнең «Төхфәи Мәрдан» һәм «Нуры содур» П.лары гуманизм идеяләре һәм дини мотивлар б-н сугарылган. 18 гасырда П. Г.Утыз Имәни иҗатында үстерелә, камилләштерелә («Гаварифез-заман», «Тәнзиһел-әфкяр фи нәсаихел-әхъ-яр»). П.да антиклерикаль һәм урта гасырларга хас булган мәгърифәтчел фикерләр өстенлек ала; традицион романтик күзаллау кысаларында халык мәнфәгатьләреннән ерак торган, үз-үзләре б-н канәгать булган руханиларга карата гаепләү мотивлары барлыкка килә. 19 гасырдан урта гасырлар П.сыннан яңа тип П.га таба күчеш башлана. Фәлсәфи, дөньяга караш б-н бәйле мотивлар Г.Кандалыйның «Сәхибҗамал»

П.да яңгырый. Анда мәгърифәтчел мотивлар, соц.-әхлакый эчтәлек мөселман руханиларының культын тәнкыйтьләү б-н үрелеп бара. Матурлык категориясе илаһи түгел, ә бәлки «җирле» антропологик эчтәлектә алга чыга. Автобиографик билгеләр хас булган лирик герой П.да яңа төсмер ала. Бу үз чиратында кешене тасвирлауга яңа караш барлыкка килүе хакында сөйли.

20 гасыр башы татар поэзиясендә әдипләр мәдәни аспектта яңа баскычка күтәрелә. П. эчтәлек, идея-эстетик һәм сәнгати планда сыйфат ягыннан югары дәрәҗәгә ирешә. Дөньяга кадими карашны һәм мәдәният парадигмасын кире кагу зарурияттеннән чыгу жанрларның үзгәрүенә китерә; модернистлар иҗатында яңа жанр модификациясе барлыкка килә — антижанр-антипоэма. Анда бүтән яңгыраш алган классик шәрык әдәбиятының традицион үзенчәлекләре сизелә. Бу хәл жанрның трансформациясе хакында сөйли: дини-дидактик эчтәлекле сюжет дөньяви фикерләрне җиткерүгә буйсындырыла (Ш.Бабичның «Кандала», «Газазил»е, Г.Сөнгатинең «Хозыр»ы, М.Гафуриның «Адәм вә Иблис»е һ.б.). Ш.Бабичның «Газазил»ендә әдәби пародия алымы файдаланыла, сюжет үзәгендә Ходай Тәгаләгә буйсынмаган өчен оҗмахтан куылу турындагы дини легенда үзгәртелә. П.да табигый рәвештә С.Рәмиевнең гыйсьянчылык романтизмы (кара: Гыйсьянчылык) б-н сатира-юмор, реалистик П. алымнары (Г.Тукайның «Печән базары, Яхуд Яңа Кисекбаш»ы) кушылып китә. Төрле көлү төрләре б-н тулыландырылып, пародия объекты булган дини легенда әүвәлге күтәренке-трагик эчтәлеген югалта, шайтанның Аллаһ б-н иронияле уйнавына кайтып кала. Бу конфликтта ул көлке хәленә кала. Аллаһ һәм шайтан образларында Ш.Бабич дөньяви әдәбиятның мәңгелек темасын тәшкил иткән Яхшылык б-н Яманлыкның кеше күңелендә генә түгел, ә бәлки буыннар, милләтләрнең рухи халәтендә барган көрәшен көлке рәвешендә тасвирлый.

20 гасыр П.да 2 төр күзәтелеп килә: эпик һәм лирик. Беренче төр П.да күбесенчә тарихи, конкрет-көнкүреш вакыйгалары тасвирлана (Г.Тукайның «Печән базары, Яхуд Яңа Кисекбаш», Һ.Такташның «Мәхәббәт тәүбәсе», М.Җәлилнең «Хат ташучы», Ф.Кәримнең «Гөлсем», С.Хәкимнең «Дала җыры», «Шагыйрьнең бала чагы», С.Батталның «Олы юл буйлап»). Лирик П.да лирик башлам, субъектив кичерешләр өстенлек ала (Ф.Кәримнең «Кыңгыраулы яшел гармун», И.Юзеевнең «Өчәү чыктык ерак юлга...», Ә.Баянның «Сәяхәтнамә», Р.Харисның «Рәссам», М.Әгъләмнең «Тукай хатлары» һ.б.).

1920-30нчы елларда П. яңа үзенчәлекләр, үзенчәлекле жанр формалары б-н баетыла: лирик-публицистик (Һ.Такташның «Киләчәккә хатлар»), лирик-психологик (Ә.Фәйзинең «Флейталар»), лирик-фәлсәфи (Х.Туфанның «Ант») һ.б. Беренче планга җәмгыять үсешенең социаль моделенә йөз тоткан концептуаль эзләнүләр чыга, геройлар, социаль төзелеш барышы, үрнәк булырдай шәхесләр б-н кызыксыну арта. Әйдәп баручы принцип буларак кешене җәмгыять тормышында һәм эшгамәлләрдә сурәтләү үзенчәлеге билгеләнә. Бу чор П.сы романтикадан, милли колориттан ераклашып, яңа идея-эстетик үзенчәлекләргә йөз тота. Гыйсьянчылар героик П. формаларына мөрәҗәгать итәләр. Һ.Такташ көрәшне романтик-символик образларда сурәтләргә омтыла. Аның «Җир уллары трагедиясе»ндә дини-мифологик образлар яңадан тергезелә. Конфликтның нигезен трагик мәхәббәт каршылыгыннан бигрәк шәхес һәм җәмгыять каршылыгы тәшкил итә. Х.Туфан П.ларында, чорга авазлаш төстә, эпик башлам, искелекне кабул итмәү һәм яңалыкка өстенлек бирү, социализм төзелешенә тугрылык кебек сыйфатлар өстенлек итә; стиль төрлелеге, лириклыкның, шигъри тәҗрибәнең җитенкерәмәве, лирик геройның эчке дөньясын сурәтләүнең арткы планга калдырылуы күзәтелә. М.Җәлил шигъриятендә лирик-эмоциональ стиль торабара сәнгати тасвирлауның лиро-эпик формалары б-н алыштырыла. Реалистик һәм романтик башламнарның нисбәте беренчесе ягына таба үзгәрә, «романтик реализм» өстенлек итә башлый. М.Җәлил «Хат ташучы» П.сында реализм б-н романтизм синтезының яңа дәрәҗәсенә ирешә. Бу хәл аның бер әсәр кысаларында жанр структураларының төрле төрләрен яраштыра алуы б-н бәйле. М.Җәлилнең «Алтынчәч», Х.Туфанның «Ант» П.лары яңарышка йөз тотулары б-н аерылып торалар. М.Җәлил халыкның милли-азатлык хәрәкәте темасын сурәтли, шартлы алымнар, символик образларга мөрәҗәгать итә. Х.Туфан П.сында кеше кичерешләренең төрлелеген ачу, автор шәхесе, тарих һәм чорның катлаулы проблемалары б-н бәйле рәвештә жанр үсешенең яңа тенденцияләре чагылыш таба; авторның гражданлык позициясе ачык чагыла, илдәге иҗтимагый-сәяси ситуациягә бәя бирелә. Болар барысы да шагыйрьнең эстетик карашларында тирән үзгәрешләр башла-

нуы хакында сөйли. С.Хәкимнең «Пар ат» П.сында автор Г.Тукайның тормышы һәм иҗатына янача бәя бирергә, аның образын хәрәкәттә сурәтләргә омтыла, композиция һәм поэтика өлкәсендә яңалыкларга йөз тота. Гәрчә бер төркем әсәрләрдә С.Хәким Г.Тукай шәхесен абсолют, идеаль югарылыкка күтәргән булса, «Пар ат»та исә лирик герой б-н шагыйрь образының тәңгәлләшүе күренә.

Бөек Ватан сугышы елларында татар әдәбиятында П. жанрының үсеше Ф.Кәрим иҗаты б-н бәйле («Үлем уены», «Партизан хатыны», «Гөлсем», «Партизанка Гөлчәчәккә хат»). Аның «Кыңгыраулы яшел гармун» П.сында метафора һәм символларның тирәнлеге һәм көче зур роль уйный. Романтик символика лирик геройның шәхси кичерешләрен чагылдыруда сәнгати чара булып тора, рухының җиңелмәслеген раслый.

20 гасырның 2нче яртысында да П.ның традицион жанр формалары сакланып килә, ләкин эчтәлеккә килгәндә алар романтик-публицистик пафос, фәлсәфи уйланулар б-н баетылалар. П.да универсаль гомумиләштерүләр барлыкка килә: шагыйрьләрнең Галәмгә карата мөнәсәбәте ачыла, реалистик, романтик, мифологик традицияләр дини-фәлсәфи мотивлар б-н үрелеп китә. И.Юзеевнең «Тынлык белән сөйләшү», «Таш диварлар авазы», «Мәңгелек белән очрашу» романтик поэмаларында образ-символлар күпләп кулланыла, фәлсәфи концепцияләр әдәби материалда тәкъдим ителә һәм яшәешкә мөнәсәбәтле фикерләрне, кануннарны, кешенең Галәмдә яшәвенең мәгънәсен билгеләүгә, социаль-психологик аспектка йөз тоталар. Кеше акылы, кеше рухы космосның салкын тынлыгына һәм җирдә кылына торган фаҗигаларга каршы куела. Бу тенденция И.Юзеев поэмаларының нигезен тәшкил итә. Үзенең «Көмәч пешерүчеләр җыры», «Галиләргә гимн», «Керәшчеләр» П.ларына Р.Фәйзуллин балачак самимилеген, туган як җылысын, ватанга, халыкка мәхәббәтен гәүдәләндергән конкрет туган ил образларын кертеп җибәрә.

П. төрле сәнгати, поэтик чаралар б-н баетыла. Бер әсәр кысаларында реалистик, романтик, мифологик, модернистик алымнар кушылып китә, авторлар төрле бәяләрне берләштерергә омтылалар. Боларга шартлы уен, интертекстуальлек, дини һәм мифологик символларга мөрәҗәгать итү, романтик пафосның реалистик детальләр б-н баетылуы кебек сәнгати чаралар аркылы ирешәләр. Мисал итеп С.Хәкимнең «Кырыгынчы бүлмә»сен, М.Әгъләмовның «Тукай хатлары»н, Р.Харисның «Рәссам»ын һ.б. атап була. Аларда биографик элементлар халык, аның милли үзенчәлеге, үткәне һәм бүгенгесе турындагы уйланулар, кеше һәм яшәү мәгънәсе турындагы фәлсәфи фикерләр б-н үрелеп бара, әдәби мәсьәләләр иҗтимагый-сәяси мәсьәләләр б-н үзара кушылып китә. Р.Харисның «Ат иярләү», «Рәссам», «Ант суы», «Һарут белән Марут» П.ларында интеллектуаль башлам өстенлек итә. Анда идея һәм персонажлар драмасы киңәйтеп тасвирлана, метафорик образлар автор фикерен җиткерүгә хезмәт итә. Интеллектуаль тенденция шагыйрьнең концептуаль-фәлсәфи фикеренә йөз тота, ә ул үз чиратында җәмгыятьнең актуаль проблемаларын сәнгати аспектта чишәргә, кеше яшәешенә рациональ анализ бирергә омтыла. «Рәссам» П.сында сәнгати салонның шартлы-метафорик образы җәмгыять, гомумән алганда, дөнья моделе төсендә тасвирлана. Автор тарихи процессның ерып чыга алмаслык халәтен тасвирлый: рәхимсез шартлар шәхесне бетерә, ә бу хәл яңа җимергеч шартлар тудыра. Р.Харис «Дөньяны кешелекле итү юллары бармы?» дигән сорау куя, һәм кешелек дөньясының җәмгыятьне гуманлаштыру юлларын табуына ышана.

Зөлфәтнең «Йөрәкләрдә үлмәс дастан», Ж.Сөләймановның «Тамырлар», «Ташъязмалар», «Аю каны» П.лары ш.у. интеллектуаль якның өстенлек алуы, образлы фикерләүдә фәлсәфи элементның көчәю б-н характерлана.

Әдәб.: Валитова А. Типология восточной поэмы (Проблемы развития жанра в процессе взаимосвязей тюркоязычных литератур)// Советская тюркология. 1973. №4; Миннегулов Х. Татарская литература и Восточная классика. К., 1993; Шарипов А. Зарождение системы стихотворных жанров. К., 2001; Әдәбият белеме сүзлеге. К., 1990.

*Н.М.Йосыпова.*

*Дәвамы киләсе саннарда.*

# ЧЫН ИҖАТ ҮКСЕЗ БУЛМЫЙ УЛ

Матур кеше иде Флүс абый. Төс-кыяфәтен, килеш-килбәтен искә алсак та, саллы иҗатын күздән кичерсәк тә, каләмдәшләренә, кешеләргә карата мөнәсәбәте хакында фикер йөртсәк тә шушы гади, әмма гаҗәеп күп сыйдырышлы сүзне әйтергә була. Якты, киң күңелле, башкалар иҗатына игътибарлы, кызып киткән, дуамалланып йөргән чакларын күргәнем булмады. Сабыр, эшлекле, һәр минутын мәгънәле итәргә омтылып яшәде. Үзе исән булса, җиң сызганып житмеш еллык юбилеена берәр саллы әсәр язып өлгерткән булыр иде. Арабыздан иртә киткән әдип үзе исән чагында да юбилейларын ду кубарып үткәрмәде, аңа бу эштә ярдәм итәргә атлыгып торучы да булмады кебек... Шулай да алтмыш яшьлек юбилеен туган ягы Мөслимдә зурлап, каләмдәш дусларын чакырып үткәрү насыйп булды, шәхесе, иҗаты хакында ихлас сүзләр ишетеп, бәхеттән күккә ашып йөргән иде.



Аның белән көтмәгәндә генә танышып киттем. Якташым Наис абый Гамбәр «Татарстан» журналында эшли иде, миннән әсәрләремне китерүне сорады. «Сине Флүснең дә күрәсе килә, килсәң, редакциягә керми китмә», — диде. — Флүс Латыйпов дигән язучыны беләсеңдер бит?» Әлбәттә, беләм. Аның «Ак-карага тимәскә» дигән повестен укып, шактый тәэсирләнеп йөргән идем. Үземнең дә шундыйрак бер әсәрем — «Соңгы көз» повестем инде берничә ел киштәдә ята, бастырып чыгарырга бер дә өмет күренми.

Икенче бер вакыт, Казанга килгәч, җай табып Наис абый янына кердем. Ул мине шундук Флүс абый янына алып кереп китте. Наис абый безне таныштырып өлгермәде, мин Флүс абыйга бер тәнкыйть сүзе әйтеп ташладым. «Ак-карага тимәскә» әсәрендә бер сүз урынсыз кулланылган, дидем. Мисалны әйтеп, үземчә язучыны «төзәтеп» куйдым. Флүс абый күзен кыса төшеп, миңа сынаулы караш ташлады да, «Ул сүзне төптән белер өчен сиңа Мөслимдә туып-үсеп, аз булса да Мөслим икмәге ашарга кирәк, энекәш», — диде дә, кәефе киткәнен сиздереп, карашын алдындагы кулъязмага төбәде. Наис абый кычкырып көлде. «Шушы бит инде ул Факил Сафин, Мөслим егете». Флүс абыйның сүрән йөзе кинәт яктырып китте. «Бәй, нигә аны башта ук шулай димисең? Телне белер-белмәс җиен надан белән баш каткан монда. Тагын берсе кереп, җан җәфаларга тотынды дип торам. Сине күрәсем килгән иде. Күз алдыма озын, калын гәүдәле, кырык бишле итек киеп йөрүче бер кеше итеп китерә идем. Баксаң, җыйнак кына гәүдәле егет икәнсең. Ну тавышың кәнишне каты күренә».

Озак кына сөйләшеп утырдык. Аның яныннан чыккач, Наис абый: «Ошатты бит сине. Күңеленә ятышмаган кеше белән сөйләшеп тә тормый ул», - диде.

Флүс абый белән шактый аралашып, гәп корып, иҗатташ дуслар булып яшәдек дияргә дә ярыйдыр. 2001 елда дөнья күргән өч томлыгына сүз башы язуны миннән үтенде. «Синең белән серләребез килешә. Һәр язганыма фикереңне әйтеп барасың. Ихласлыгың өчен хөрмәт итәм үзеңне», — дигән иде. «Саташып аткан таң»

романын язып яткан чагым иде, башка якка борылып карыйсы да килми. Ярый әле, сәбәп табып, баш тартмаганмын. Ул исән чагында әйтәсе сүземне әйтеп кала алдым. Вакытында әйтелгән сүз генә асыл, алдан әйтелсә — көлке, соңга калынса — тәссез...

«Казан утлары» редакциясендә мина берара эшләп алырга туры килде. Флүс абый белән сөйләшеп сүз бетми. Әдәбият, дөнья хәлләре турында, үзе әйтмешли, фәнни-гамәли конференциягә торырлык әңгәмәләр корабыз, гаилә мәсьәләләрендә бер-беребезгә ышанып фикерләшәбез. Башкалар белән алай артык ачылганын сизмәдем. Кайнарланып сөйләшеп утырганда берәрсе килеп керсә, сүзне шундук эш ягына бора. Кайбер кешеләрдә Флүс Латыйфи зарланырга ярата дигәнрәк фикер туса, сәбәбе — кешеләргә ачык булса да, һәркемгә ышанып бетми иде. Бер гәп корып утырганда, моның янә сәбәбенә төшендем.

Әле алтмышынчы еллар уртасында, Казан дәүләт университетында укыганда, ул «Татарстан кооператоры» дигән газетада эшләгән. «Көндез укыйм, аннан төн уртасына кадәр газета редакциясендә, — дип сөйләгән иде ул. — Шулай бер вакыт тулай торакта кулыма бер язу килеп керде. Өндәмә, чакыру, листовка! Ничек килеп эләккәнен әйтә дә алмыйм. Мендәр астына кыстырып куйганнар иде бугай. Укыйм. Башка шаулап кан йөгерә. Анда татар халкының кайчандыр дәүләт тотып яшәве, ирекле, көчле кавем булуы турында язылган. Татарның бердәм булмавы, хыянәт аркасында бәйсезлеген югалтып инде дүрт йөз елдан артык кысымда яшәве бәян ителгән. Татар халкы болай яшәргә тиеш түгел, тарихын кайтарырга, дәүләтчелеген торгызырга тиеш, диелгән. Шулай булмаган очракта, тагын илле елдан татар газиз телен югалтып, халык, милләт буларак яшәүдән туктаячак, дип тә кисәтелгән. Иң беренче мәртәбә Гаяз Исхакыйның «Ике йөз елдан соң инкыйраз» әсәрен шушыннан белдем. Чынлыкта, милли көрәшкә чакыру иде бу. Юка кәгазьгә машинкада басылган әлеге язу бөтен тормышымны үзгәртте. Иң ахырдан: «күбәйтеп, башкаларга тарат» дигән үтенеч... Иң беренче итеп юка кәгазь юнәттем, аннан төннәрен теге өндәмәне күбәйтәм, университетта, тулай торакта, сиздермәскә тырышып, тараткан булам. Ике-өч мәртәбә шулай шома гына үтте кебек. Алдагы сменага килгәч, редакция бушап калганын көтеп тордым да, секретарь бүлмәсенә кереп, машинка артына утырдым. Эш белән мавыгып, ишекнең ничек ачылып киткәнен дә сизмәдем. Кыскасы, мине Черек күлгә алып киттеләр. Кыстылар, малай. Артка чигенер хәл дә юк: өстәл өстендә мин күбәйткән күчермәләр ята. Бер төргәк. Өндәмәнең бер генә нөсхәсе дә читкә китмәгән, монда килеп эләккән сыман. Бәхеткә күрә, университеттан куып чыгармадылар. Ракета гаскәрләрендә хезмәт иттем бит мин, ракеталарга ягулык салу буенча белгеч. Армияга Алабуга дәүләт педагогия институтында укыган җирдән алып киткәннәр иде. Кариб кризисы кызган чор, барлык студентларны да чират белән армиягә алдылар ул чакта. Армиядән кайткач, университетка янабаштан кердем. Шуны да искә төшерделәр. Һәр адымың күзәтеләчәк, дип, кисәтеп чыгардылар. «Боларны нигә язмыйсың?» — дим. Флүс абый ашыкмыйча гына җавап бирде: «Хыянәт», «Бәйсез этләрне атарга» романнары тууга шул хәлләр сәбәпче бит инде. Черек күл мәктәбен үтмәсәм, язучы да булмас идем, бәлки. Һәм үзгәртеп кору чоры килмәсә... Йөрер идем әйбәт журналист булып... Теге чакта аны саткан кешенең исемен дә әйткән иде. Телгә аласым килми, хәзер ул да гүр иясе.

Флүс Латыйфи 1943 елның 3 июнендә Мөслим районы үзәгендә туган. Мәктәптә укыганда ук иҗатка тартыла. «Күңел энҗеләре» дигән кульъязма журналның редакторы була. Урта мәктәптә данлыклы курчак театры бар иде. Флүс Латыйфи шушы театр өчен пьесалар яза, үзе артист булып уйный. Хәтта Мәскәүгә үк барып җитәләр бу театр белән. Бер Мәдәният сараенда аларны, ягъни оста итеп татарча спектакль куйган татар авылыннан килгән үсмер артистларны кытайлар дип белеп, аеруча игътибар күрсәтәләр.

Флүс Латыйфи әдәбиятка ашыкмыйча, өлгереп җиткәч кенә килде дияргә нигез бар. Хикәяләр һәм лирик повестьтан торган «Кырагай» исемле беренче

җыентыгы 1988 елда дөнья күрә, тәнкыйть, җәмәгатьчелек тарафыннан әдәбиятка үткен каләмле, образларга бай, сыгылмалы, шигъри телгә, үзенчәлекле фикерләү сәләтенә ия язучы килүен раслаучы вакыйга буларак кабул ителә. Инде беренче җыентыгын укыганда ук аның язу куәсенә Фатих Хөсни, Хәсән Сарьян кебек тел осталарының шифалы йогынтысын тоясың. Әмма сурәтләүдә, хикәяләүдәге иҗат алымында ул үз юнәлеше белән бара торган әдип. Шул ук елны «Вөҗданыңнан сора» дигән китабы да басылып чыга. Очерк һәм публицистик мәкаләләр туплаган бу җыентык өчен язучы 1989 елда Татарстан журналистларының Хөсәен Ямашев исемендәге премиясенә лаек була. 1992 елда Ф.Латыйфиның повестьлары һәм хикәяләре тупланган күләмле «Ак-карага тимәскә» исемле китабы да укучыларга барып ирешә. Шартлы рәвештә, язучы иҗатындагы башлангыч чорга йомгак дип карарга була әлеге җыентыкны.

Китапка исем биргән «Ак-карага тимәскә» повесте язучы иҗатында аерым урын тота. Күләмле тәүге әсәрләреннән берсе буларак, әдәби эшләнеше ягыннан кимчелекләрдән дә азат түгел иде. Төп герой Рәис Хаков әле схематик дәрәҗәдә, уй-фикерләре калыпланган, эш-гамәлләре әсәр тукымысына табигый үрелеп бармый, күбрәк автор ихтыяры белән хәрәкәт итә. Шулай да яңа геройны эзләү юлында бу әсәр һичшиксез авторның уңышы дип бәяләнергә хаклы. Вакыйгалар үзгәртеп коруга кадәр башланып, бу хикмәтле реформа игълан ителгәннән соңгы ике-өч елны үз эченә ала. Хәзер кайберәүләр: үзгәртеп коруга йөз тоткач та, илдә демократия җилләре исә башлады, тел ачылды, ни теләсәк шуны әйтә, яза башладык дип ычкындыргалыйлар. Алай түгел шул. «Ак-карага тимәскә» уены тормышның бар катламнарына тирән үтеп кереп, бу уенны шулкадәр оста оештыручы номенклатура барлыкка килгән иде. Ул төзек системаны тәшкил итә һәм бу тутыкмас-күгәрмәс чылбырның асыл буынын журналистика, халыкның аның-зиһенен томалап торуга корылган «хәбәрдарлык» чаралары тәшкил итә иде. Уен әле бүген дә аз гына үзгәргән шәкелдә яшәп ята, чәчәк ата.. Флүс Латыйфи үз чорында табу дәрәҗәсенә житкерелгән «радио» дип аталган серле йортка алып керә безне, торгынлык чорының рупоры булган оешманы эчке яктан күрсәтә.

Гаиләдә дә, совет мәктәпләрендә дә (ВУЗны да кертеп) Рәис Хаковны гадел, дөрес булырга өйрәтәләр. Җәмгыятькә иң гүзәл әхлак нормаларына ия булган белгеч кирәклегенә чын күңелдән ышанган яшь журналист радио бусагасын атлап керү белән бөтенләй икенче тормышка килеп элэгә. Аңа хезмәт юлын журналистикада әлифне таяк дип белмәгән җитәкче кул астында башлап җибәрергә туры килә. Басыйров һөнәри яктан надан булса да, системаның тугрылыклы бурзае, аның өчен хезмәткәрләр — көтүдәге сарыклар, партия-совет түрәләреннән калган сөякне кимереп-ялап симергән бурзай бичара «малларны» һәрдаим игътибар үзәгендә тота, ялгыш кына да читкә аяк атлау мөмкин түгел. Рәискә фәкать җитәкченең «особый ышанычын» казанган хәлдә эшләсәң генә хезмәттә һәм шәхси тормышында ниндидер уңышларга ирешү мөмкинлеген искәртеп куялар. Үрнәк тә бар — мондый «ышаныч»ны казанып өлгергән Синәкаев. Авылда туып-үскән, карап торуга сүздән чыкмаска охшаган, тырыш егетне күргәч, Басыйров күңелендә башка уй-ниятләр дә уяна. Үз тирәсендә ниндирәк үрмәкүч пәрәвезе үрелгәнен башына да китереп карамаган Рәис Хаков исә эшкә чума, беренче чыныгу, беренче сабакларны ала. Яшь җан хөрлек тели, эшкә дәрт бар, белем җитәрлек, ник әле ул кем әйткәнгә генә карап торырга тиеш? Үз сүзен әйтәсе килә, җитешсезлекләргә каршы көрәшәсе, сәбәпчеләрен ачып саласы килә дә бит... Сәбәпчесе — коточкыч көчкә ия Система икәнлеген, ә хезмәт вазифасы башкаручы һәркемнең олы бер машинаның кечкенә шөребе икәнен аңлар дәрәҗәдә түгел шул әле ул. Шөреп буласы килмәү, һәр нәрсәнең тамырына төшәргә маташуы «яндыра» инде аны. Тышкы дөньядан өч кат тәрәзә белән аерылган бинада яшь егеткә артык җәелергә ирек бирмиләр, бер-бер артлы җәнҗал-интригаларга алып керәләр, «матур яшәүнең» серен ачып биргәндә дә һаман үзенекен тукып торган киребеткән «хәсрәт журналист»тан үч алу өчен мең дә бер сәбәп табыла. Бер карауга Беляева, Хөснетдинов, Марат кебекләрдән бу дөньяда бер нәрсә дә тормый кебек, менә шуларның тәпиләренә

китереп басып кара әле син, күрсәтерләр алар нинди көчкә, нинди кодрәткә ия икәнлекләрен. Бөтен хикмәт шунда, әсәрдә сурәтләнгән хәлләрнең инде томанлы гына шәйләнә башлаган «торгынлык» дип аталган чорда түгел, үзгәртеп корулар башлангач булуы уйланырга азык бирә. Система бит җимерелмәде, юкка чыкмады, киресенчә, Рәис Хаков кебекләрне сыта, изә һаман яши, фәкать косметик төзәтенү аркасында йөзен-чыраен гына үзгәртте. Без моны белгән хәлдә, теләкне чынга кабул итеп яшәп ятуда. Флүс Латыйфи моны сиксәненче еллар ахырында ук әйтте, кисәтеп куя алды. Повестьта хыянәт темасына да тап булабыз. Сонрак бу тема язучы иҗатында тагын да үстерелде, төрле төсмерләре ачыкланып, тулы бер әсәргә нигез булып ятты.

Татар дөньясын шаулаткан, Флүс Латыйфины икеләнүсез зур әдипләр сафына куйган әсәре 1993 елда Татарстан китап нәшриятында ул чор өчен генә түгел, бүгенге көннәр өчен дә «коточкыч» тираж — 50 000 данә белән басылып чыгып, тиз арада таралып беткән «Хыянәт» романы булды. Роман 2000 елда югары зәвык белән «Мәгариф» нәшриятында кабат басылды һәм ай күрде, кояш алды, таралып та бетте.

Казан ханлыгының мөстәкыйль дәүләт буларак яшәгән соңгы унҗиде елындагы гаять четерекле вакыйгаларны, ике яшь йөрәкнең кайнар мәхәббәт тарихын, югалту ачысы кичергән, әмма бер-берсенә тугрылыклары, батырлык, кыюлык күрсәтүләре нәтиҗәсендә кавышу бәхетен тапкан егет белән кызның катлаулы мажараларын тирән психологик кичерешләр аша зур осталык белән тасвирлаган бу әсәр укучылар тарафыннан бик җылы каршы алына.

Беренче карашка сүз мәхәббәт хакында барса да, күтәрелгән проблемалар гаять саллы, әһәмиятле. Хыянәт нигезендә гомерләр кыела, мәхәббәт мәхшәргә әйләнә, дәүләтләр юкка чыга. Хыянәт белән табылган бәхет бәхет дип аталырга хаклымы, ул озын гомерле була аламы? Әсәрне укыганда шундый сораулар бер-бер артлы туып тора, уку барышында, һәркем үз чамасыннан чыгып, аларга җавап та таба. Әсәр хакында әдәбият белгече Х.Әшрәфҗанов болай дип яза: «Романда тарихи шәхес булган Кол Шәрифкә зур урын бирелә. Ул рухани җитәкче буларак кына түгел, ә олуг галим, ватанпәрвәр, Казанны саклаучыларның, азатлык көрәшенең идеологы буларак та күз алдына килеп баса. Аның Иван IV гаскәрләренә каршы көрәшне җитәкләве тарихи чыганаклар белән раслана. Башка тарихи шәхесләр (Сафа Гәрәй хан, Чапкын морза, Япанчи би, Камай морза, Иван IV, Адашев һ.б.) вакыйгаларда катнашсалар да, әсәрнең төп герое — сәүдәгәр Сәет-Углич сәүдәгәре Савелий Кузьмичның мәхәббәт язмышы белән Казанга килеп төпләнгән, мөселман диненә күчкән төпчек улы Санька (Александр) Булгаков. Чор вәзгыяте, сулышы, тарихи колорит аның уй-кичерешләре, гамәлләре аркылы бирелә. Икенчедән «Хыянәт» — югары дәрәҗәдә психологизм белән сугарылган тарихи роман. Өченчедән, акрынлап традициягә әверелә барган Казан-Мәскәү мөнәсәбәтләрен бәян итүгә төп игътибар бирелми, ул, ике дәүләт идеологиясенең каршылыклары буларак, күпмедер дәрәҗәдә ике бертуган Василий һәм Сәет (Санька) мөнәсәбәтләрендә чагыла. Тышкы-сәяси вакыйгалар белән мавыкмыйча, Казан өчен 1552 елның көзендә барган сугышны сурәтләү, хәтта аның нәтиҗәсе белән түгел, ә дәвамы белән әсәрне тәгаллү дә үзен бу очракта тулаем аклый.

Хыянәт. Бу сүзнең мәгънәсе романда төрле масштабта, төрле яссылыкта чагыла. Исем җисемгә туры килә. Бу — Саньканың мәхәббәт хакына үз диненнән, иленнән, әти-әнисеннән, туганнарыннан, ахыр чиктә үзе тәрбияләнгән идеологик мохиттән ваз кичүе дә, Камай морзаның ватанын сатып дошман ягына чыгуы да, әсәр ахырында ике бертуганның бер-берсен һәлак итүе дә.

Әсәрнең символик һәм мәгънәви бөтенлеген тәэмин итүче чикләре, башы һәм ахыры сәүдәгәрлек тамгасы белән бәйләнә; вакыйгалар тамгадан башлана, тамга белән тәгалләнә. Бу фалны Казан өчен барган көрәшнең тәмамланмый калуы белән бутамаска кирәктер. Х.Әшрәфҗановка өстәп шуны да әйтәсе килә: «Хыянәт» романында колорит башка факторлар — кием-салым, көнкүреш әйбер-карасын, дәүләт төзелеше, идарә итүнең ханлыкка хас сыйфатларын белеп сурәтләү ярдәмендә

дә ирешелә. Автор бу мәсьәләне җентекләп өйрәнгән, чорны «вак-төяк» детальләр ярдәмендә дә ачып булуын оста итеп күрсәтүгә ирешкән. Тагын игътибарга лаек нәрсә — автор тарихи документларны яхшылап өйрәнгән һәм аларны әсәр канвасына урынлы кертеп җибәрә. Кыскасы, роман бөтен булмышы белән Казанны яклаучы каһарман бабайларыбызга, кыю йөрәкле, сөя дә, сөйдертә дә белгән, кирәк булса яуга ташланып ил бәйсезлеге хакына үзләрен корбан итүдән курыкмаган хатын-кызларыбызга дан җырлый, хыянәт юлына басканнарга нәфрәт, каргыш буларак кабул ителә.

1993 елны әдипнең тагын бер китабы 50 000 данә тираж белән басылып чыкты. Анысы — «Чура Батыр» дастаны. Ф.Латыйфи, әдәбиятыбызда беренче тапкыр буларак, Добруҗа татарларының халык авыз иҗатына мөрәҗәгать итә, Румыниядә аеруча киң таралган «Чура Батыр» дастанын Казан татар әдәби теленә күчерә, Румыниядә яшәүче милләттәшләребез тарихына, аларның бүгенге яшәеш вәзгыятенә багышланган «Бер ананың игез уллары» дигән күләмле мәкалә яза. Әлеге китап әнә шул тәрҗемә һәм мәкаләне берләштерә. Китап бигрәк тә галимнәребез тарафыннан игътибар үзәгенә алынды, дастанны фәнни өйрәнү юлында мөһим вакыйга буларак бәяләнде.

Язучының Казан университеты галиме Ринат Якуш белән иҗади хезмәттәшлектә язылган «Тамга», «Игезәкләр», «Соңгы кисәтү» дигән фәнни-фантастик повестьлары татар әдәбияты өчен чыннан да яналык иде. Катлаулы, мавыктыргыч сюжетка корылган әсәрләр укучыны маҗаралары белән генә түгел, бәлки бүгенгене үткәннәргә тоташтыручы хыял һәм чынбарлык турында фәлсәфи уйлanулары белән дә җәлеп итә. Повестьлар бай, йөгерек тел белән язылган, җинел укылулары белән дә үсмерләрнең яраткан китапларына әверелделәр. Повестьлар шул ук елны рус теленә дә тәрҗемә ителә барды һәм, ниһаять, 1996 елда берьюлы ике телдә — татар һәм рус телләрендә «Тамга - След» исеме астында аерым китап булып басылып чыкты. Әдәбиятта шундый «мөгез» чыгарырга һәвәс сирәк язучыларның берсе икәнлеген тагын бер мәртәбә раслады.

Язучы һәм публицист Ф.Латыйфи татар яшьләренең «Сәләт» хәрәкәте белән тыгыз бәйләнештә торды, балалар һәм яшьләргә милли тәрбия бирүдә актив катнашты, аларның милли үзаңын үстерү юнәлешендә нәтиҗәле эшләде. 1995 елдан алып шактый еллар балаларның җәйге «Сәләт» лагерьларында «Татар дөньясы», «Татар теле һәм әдәбияты» дәресләре алып барды. Милләтебез, туган телебез һәм татар дәүләтчелегенең үткәне, бүгенгесе һәм киләчәге хакында уйланулар белән сугарылган әдәби-публицистик китабын «Сәләт» фонды 1998 елда аерым китап итеп бастырып чыгарды. «Уянып киләбез... Уяныйк та җиң сызганып эшкә тотыныйк. Безнең өчен беркем дә хыялларыбызны тормышка ашыру юлында эшләп йөрмәс. Барысы да үзебезгә бәйле, үзебез эшлик!» — дию белән әдип мең мәртәбә хаклы иде.

1999 елда язучының күләмле тагын бер әсәре — «Ишелеп төшкән бәхет» романы «Казан утлары» журналының 5-6 саннарында басылып чыкты. Әдәби җәмәгатьчелек романга унай бәя бирде. Язучы үзе бүгенге әдәби барышны күздә тотып болай дигән иде: «Әле һаман да «су күп кушылган», күпсүзлектән җәфа чигүче романнар язу дәвам итү белән бергә, тыгыз концентрацияле, катлаулы сюжетлы, аз сүзле, әмма сурәтләү ягыннан киң колачлы романнар күренә башлады". Һәм бу анлашыла да, чөнки заман үзгәрде, югары тизлек, компьютер заманы килде, дөньяны мәгълүмат ташкыны басып китте. Кешенең бишәр йөз, алтышар йөз битлек, хәтта меңәр битлек романнар укып утырырга вакыты да, түземе дә һәм теләге дә юк. Инде килеп, яна романы хакындагы уйлары белән дә уртаклашу кирәклеген тоеп, укучыларга берничә сүз әйтүне кирәк тапты: «Ишелеп төшкән бәхет» роман-эксперимент ул, безнең традицион татар романнарында булмаганча, дөньяны эре штрихлар белән колачларга тырышып карау. Татар бәхете кайда? Татарстанда бәхетлеме ул? Чит илләргә күчеп киткән, качып китәргә мәҗбүр ителгән татарлар бәхетлеме? Беренче карашка мәхәббәт һәм Ватанга тугрылык хакында тоелучы роман тукымасына урыс дәүләтенең татарга карата

гасырлар буе дәвам иткән мәкерле сәясәте яшерелгән. Ничек тә булса татарның тамырын корыту, аның генофондын юкка чыгару сәясәте ул. Укыган кешеләр ана үз бәяләрен бирер дип беләм». Бәхет эзләү дигәннән, әле тәүге китапларында ук бу теманы ныклап өйрәнү юлына баскан иде автор, хәзер тагын да тирәнрәк, фәлсәфирәк яссылыкка күчерә ул теманы. Моның белән ул үзенең әдәбиятка очраклы килеп кермәвен, ул гына өйрәнә ала һәм югары әдәби кимәлдә укучыга житкерә алырлык фикер байлыгы барлыгын раслый. Әйе, язучы татар халкын бик бәхетле итеп күрәсе килә, аны төрле тормышчан, әмма әдәби кануннар жирлегендә туган ситуацияләргә куеп карый. Халык вәкилләренә хас сыйфатларны барлый, шәхесне сындырып сыный, милләтнең ныклык шкаласын билгели кебек. Ә моны белү, минемчә, бик кирәк.

Әдәбият галиме Рифат Сверигин роман турында болай дип язды: «Ишелеп төшкән бәхет» романы — интеллектуаль проза дип аталган тармакның бер чагылышы. Андыйларны заман романы дип тә атыйлар. Вакыйгаларны бәйләү алымы бик үзенчәлекле: элекке «Идел-Урал» яшьләр оешмасының сәркатибе Әмиржан Акчура, совет солдаты Хафиз Сабиров һәм махсус бүлек майоры Гыймаев 1945 елда Чәнчүн шәһәрендә очрашканда өчесе өч вазифа башкара. Менә шул кешеләрнең балалары 1972 елның җәендә Казанда, шәһәребезне шаулаткан Америка күргәзмәсендә очраша. Аларның берсе Нью-Йорктан күргәзмәне алып килгән, электрон җиһазлар буенча эксперт Илдар Акчурин, икенчесе — Казан фәнни-тикшеренү институтларының берсендә эшләүче фәнни хезмәткәр Сирин Сабиров, һәм өченчесе — аларны карап, мәгълүматларны тиешле оешмаларга житкереп йөрүче елгыр егет Дамир Гыймаев була. «Алар өчесе дә өч сыйфатта иде һәм, табигый ки, араларында дустанә мөнәсәбәт була алмый иде. Инде менә 27 елдан соң аларның балалары изге Казан туфрагында. Алар да бүген өчесе өч сыйфатта. Ләкин аталарының кайчандыр очрашулары хакында белмиләр һәм кайчан белүләре икеле. Дөнья дигәнең шундый сәер һәм катлаулы инде ул», — ди автор бу хакта әсәрдә. Әсәрнең нигезенә шундый очраклы роман ситуациясе салынган. Ул уйлануучан, анализлап укучан китап сөючеләргә атабрак язылган. Дөньялар үзгәрә-үзгәрә, дип сөйлибез — шулаймы икән соң? Дөрес, бу 1945-1972 еллар арасы. Ә тоталитар режимнан демократик дип аталганына күчкәндә нинди үзгәрешләр булды? Һәм бу үзгәрешләр кем файдасына бара? Гади халык файдасынамы? Флүс Латыйфи укучыны уйландыра торган әсәр ижат иткән».



*«Казан утлары» хезмәткәрләре һәм редколлегия әгъзалары. Алда – Флүс Латыйфи. 1998 ел.*

Флүс Латыйфиның «Бәйсез этләрне атарга» дигән гыйбрәтле роман-нәсере дә әдәбиятта яңалык буларак кабул ителде. Әсәр сугыш елларында туган һәм балачаклары сугыш, сугыштан соңгы авыр елларга туры килгән замандашларына атап язылган. Монда инде без Мәһдиевчә жор теллелеккә, нечкә лиризмга, халыкчан фәлсәфәгә тап булабыз. Шушы зур булмаган әсәрдә язучы чорның бөтен катлаулылыгын, каршылыгын, гади кешеләрнең күңел байлыгын, түрә кыяфәтле бәндәләрнең жансызлыгын аңнарга үтеп керерлек итеп тасвирлый алган. Тормышта еш кына үткән дәверне сагынып искә алучылар белән очрашып торабыз. Әйтерсең

илне, халыкны тезләндергән, мылтык көпшәсе аша күзәтеп торган система коллары булып яшәмәгәнбез дә, әсәрдә сурәтләнгән вакыйгаларның күпчелегенә шаһит түгел идек. Әйтерсең, ул заманнарда барысы да ал да гөл булган. Алай түгел иде шул. Әсәрне укыгач, тагын бер мәртәбә җаннар өшеп куя, ул чорлар әйләнеп кайта гына күрмәсен иде...

Флүс Латыйфи чын мәгънәсендә хикәяләр остасы да. Хикәяләре үзләренең тормышчан булулары, җыйнаклыклары белән күңелне җәлеп итәләр. «Кырагай», «Истәлекле көн», «Көмеш беләзек», «Җирәнкәем» һ.б. әсәрләрендә өлкән буын, җәмгыять, милләт, табигать алдында кешенең җаваплылыгы, дуслыкка һәм мәхәббәткә тугрылык, туган җирне зурлау кебек мөһим әхлакый проблемалар күтәрелә.

Флүс абый миңа язылася әсәрләре хакында иркенләп сөйләргә ярата иде. Соңгысында сугыш чорында бер кешенең авыл халкы өчен тоз эзләп табу вакыйгасы турында гыйбрәтле хикәят сөйләп алды. «Кайчан язарга тотынасың инде?» - дидем. «Тәрҗемә вакытны ала. Башлаган романны төгәлләсәм...» Ул Рауль Мирхәйдәров әсәрләрен зәвык белән татар теленә тәрҗемә итте. Тәрҗемә күп вакытны ала, дөресен әйткәндә, зур иҗатчы булып танылган әдипнең мондый эшкә тотынуына гаҗәпләнеп тә куйдым. Тәрҗемә, уйлавымча, яшь вакытта, иҗатка керешеп килгәндә, каләмне чарлау өчен әйбәт, ә инде өлгергән әдипнең җегәрен ала, эздән чыгара ул. Мина шундый шәп тоелган тоз вакыйгасы кәгазьгә төшми калды ...

Флүс Латыйфи озак еллар «Казан утлары» журналында баш мөхәррир урынбасары булып эшләде. Журналның абруй-дәрәҗәсен төшермәс өчен бөтен көчен куйды. 1990 елдан Язучылар берлеге әгъзасы, 1993 елда аңа Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре дигән мактаулы исем бирелде.

Әдип Габдулла Тукай исемендәге дәүләт премиясенә тәкъдим ителгән иде. Алу насыйп булмады. Ул ашкынып яшәде, иҗат итте. Уй-ниятләр белән янып йөргәндә, авырып китте. Көчле, нык рухлы кеше иде Флүс абый, авыруга бирешмәскә тырышты. Тик язмыш аңа янадан иҗатка, яраткан коллективына кайту мөмкинлеген бирмәде. 2010 елда вафат булды, җаны-тәне белән береккән Мөслим туфрагында җирләнде.

Әдип үзе вафат булгач та аның иҗаты белән кызыксыну кимеми. Чын иҗат үксез булмый ул. Була алмый, чөнки ул халыкның уй-фикерен, омтылышларын чагылдыра, аны алга әйди, киләчәккә чакыра, тормышта урынын табарга өнди, яшәргә тиешлеген раслый. Флүс Латыйфиның барлык әсәрләре дә әнә шундый.

**Факил САФИН,**
*филология фәннәре кандидаты.*

# Рифкать Закиров

*Рифкать Закиров (1938-2007) – «Шахтер моңы», «Йөрәк уты», «Җан җылысы» һ.б. китаплар авторы. Асылда ул лирик шагыйрь. Шигырьләрендә милләт язмышы, ятимлек ачысын киң яктырта.*

## Без уянсак кына

**Ни күрдек без яшьли бәбкә көтеп,**
**Ни белдек без олы яшькә җитеп?**
**Тик Мәскәүне бөек Мәккә итеп,**
**Яши бирдек оеп — мәрткә китеп...**

**Инде күпме юллар узып та без**
**Нигә бүген һаман ут йотабыз?**
**Чөнки туган телне онытабыз**
**Һәм барабыз юкка чыгып та без!**

**Бала санга сукмый ана сүзен,**
**Артык күрә икән «мама» сүзен,**
**Аның кулларына каласы көн**
**Булмас микән безгә караңгы төн?!**

**Ни булса да безгә барыберме,**
**Бәхет үзе иңгә сарылырмы?**
**Татар һаман читкә агылырмы,**
**Монда җуйган... читтә табылырмы?!**

**Юкмы әллә бездә зыялылар,**
**Ник маңкортлар белән «дәү абзыйлар»,**
**Түрә булып, түргә оялыйлар**
**Һәм талыйлар малны, оялмыйлар?!**

**Байлык бетсә, бирә халык табып:**
**Ачлы-туклы эшләп, арып-талып...**
**Ә тел бетсә инде — халык та юк,**
**Халык бетсә инде — тарих та юк...**

**Авыр хаталарын кичәгенең**
**Төзәтмибез тизрәк нигә бүген?**
**Без битараф булсак моңа бүген,**
**Була харап, димәк, ничә буын?!**

**Инде шушы чорда яшәп тә без,**
**Кулыбызда форсат бар чакта без,**
**Ник үз бакчабызга таш атабыз —**
**Айну-уянудан баш тартабыз?**

Алсу күзлек киеп күзебезгә,
Кырын карап туган телебезгә,
Чабатаны элеп түребезгә,
Юкка гына йоклап йөрибез лә!..

Без уянсак кына, ышаныгыз,
Балкыячак якты кыйблабыз.
Яңарачак рух һәм иманыбыз,
Уянырга вакыт! Уяныгыз!!!

## Кичке моң

Батамын мин уйга зәңгәр таңда,
Ятам моңга чумып, кич җитсә.
Гәрчә кеше булып яралсам да,
Төштә генә яшәү кешечә.

Уйга түгел, суга чумар идем,
Булсам җофар яки сусар мин.
Моң-дәрьядан йөзеп чыгар идем,
Төнбоектай шиңеп сулармын...

Ут белән су арасында яшим,
Йотып яшем, назга сусап мин.
Күзем карасында уйный яшен:
Куе кара төндә — учак мин!

Керер идем кеше арасына,
Тарсыналар кермәс борын ук.
Утырмагач һичкем арбасына,
Беркайда да миңа урын юк.

Тай типмәгән юкса башыма да,
Әмма уйлап куям юк-юкта:
Әллә кулны селтәп барсына да,
Кайтып китим микән «төп йортка»?

Гомергә дә уйдан чыгасым юк,
Тыным бетеп, сулыш буылып:
Тар бүлмәдә ятам уйга чумып,
Ком-таш түгел, тоташ моң булып...

## Шагыйрьләр юлы — киек каз юлы

Гомерем үтә тар бер «читлектә»,
Сайрый чикерткә шунда кич-иртә;
Ут дөрли эчтә: мин көн күреп тә,
Өлгермим һич тә — төн килеп җитә.

Тилмереп-җирсеп, гел нидер көтеп:
Гомерем буе күңелем китек...
Үзәгем кыл кук өзелеп китеп,
Йөрәгем тотып, куям дерт итеп.

Көннәрем моңсу, төннәрем тынчу,
Борчу артыннан киләдер борчу;

Йөрәгем йончу, сорадым мин су, —
Ут йоттыралар... Ходаем, бир су!

Ут төртүче күп, су сибүче юк,
Дөрләп кабынсам, сүндерүче юк.
Ялгыш абынсам, кул сузучы юк,
Таеп егылсам, торгызучы юк.

«Кит!» диюче күп, «кил» диюче аз,
Чит күрүче күп, үз күрүче аз...
Юл кисүче күп, юл бирүче аз,
Сихерчесе күп, терелтүче аз...

Елатучы бар, юатучы юк,
Таш атучы бар, ашатучы юк.
Картайтучы бар, яшәртүче юк,
Җан алучы бар, яшәтүче юк!

Күктә йолдызлар булса никадәр,
Миндә борчулар аннан күп мәгәр!
Әгәр кемсәләр моны белсәләр,
Кимсетмәс иде мине бу кадәр!

Минем шуңа да каным кыза да,
Йөрәгем яна, җаным сызлана:
Сыймыйм кысама — тыным кыса да,
Күңелдә ярсып давыл кузгала!

Каным саркый да җан ярасыннан,
Яшен атыла күз карашымнан;
Мин шунда гүя яңадан туам:
Сабый баламы... шагыйрьме булам!

Тик кем булсам да, нарасый сыман:
Йә бер ятсынам, йә бер ымсынам...
Пәйгамбәрне дә мин буйсындырам,
Үзем Ходайга гына буйсынам!..

Киң кочагымны киереп ачып,
Кочам Дөньяны, күкләргә ашып:
Орган–сукканны тоямы гашыйк, –
Сөям мин аны тилереп–шашып!

Һәр таңда — гамь дә, ямь дә өр–яңа,
Чык булып айның моңнары тама.
Йолдызлар сүнә, нурлары яна...
Шагыйрьләр үлә, җырлары кала!..

Йөзне аз юды җылы яз тыны,
Бугаздан буды черек баз дымы.
Булырмы гүрем сөю–наз тулы, —
Барасы юлым — Киек Каз Юлы...

...Шагыйрьләр юлы — гасырлар юлы!



*«Аккош күле»ндә яшәүче язучылар янына Башкортстаннан кунаклар килгән. Сулдан уңга – Зәки Нури, Сара ханым (А.Әхмәт хатыны), Абдулла Әхмәт, Рәисә Ишморатова, Мостай Кәрим, Кадыйр Даян, Хәсән Туфан, Риза Ишморат, Шәраф Мөдәррис. Үткән гасырның 60нчы еллар башы.*



*Шагыйрь Мөдәррис Әгъләмов. Үткән гасырның 60нчы еллары.*



*Татарстан язучыларының XI съездында тәнәфес вакыты. Алгы планда язучы Ибраһим Салахов. 1989 ел.*



*Бөек сынчы-рәссам Бакый Урманче «Казан утлары» журналында кунакта. Сулдан уңга – Рабит Батулла, Рашат Низамиев, Ринат Мөхәммәдиев, Сәмига Сәүбанова, Рәдиф Гаташ, Кояш Тимбикова, Тәслимә Сибгатуллина, Роза Сөләйманова, Ренат Харис, Җәүдәт Миңнуллин, Фәүзия Бәйрәмова, Зиннур Мансуров, Мөдәррис Вәлиев, Солтан Шәмси. Өстәл түрендә утыралар – Бакый Урманче һәм аның хатыны Флора Әхмәтова. 1987 ел.*



*Композитор Фәрит Яруллин. Мәскәү консерваториясе студенты. 1933 ел.*



*Язучылар Кукмара районының Чарлы урта мәктәбендә. Сулдан уңга – Илдар Юзеев, Шаһинур Мостафин, Рашат Низамиев, Рафаэль Сибат. 2000 ел.*

# ИРТӘДӘН КИЧКӘ КАДӘР

*Истәлекләремә баш булып бара торган бу сүзләр бертуган апам Ләбибә Ихсанованың язылачак соңгы китабының исеме иде. Сиксән ике яшен тутырган көннәрдә яңа повесть яза башлады да, үзе, чоры турындагы язмаларына вакыты калмады. Минем: «Повестька караганда истәлекләр язу укучы өчен кирәклерәк, файдалырак булыр иде», — диюемә ул: «Балалар укырлык әдәби әсәр, гыйбрәт, акыл алырлык әсәр язасым килә, үсмер малайларның бүгенге хис-хасиятләрен язарга кирәк дип уйлыйм», — диде. Шулай итеп, язылачак повесть Ләбибә апа өстәлендә, ә мин аның «Иртәдән кичкә кадәр» ни эшләгәнен барлап утырам...*

## Иртәләрен, кичләрен...



*Бертуган Ләбибә һәм Венера Ихсановалар. 1975 ел.*

— Венера, исәнме! (телефоннан тавышы нигәдер тоныграк ишетелде.)

— Авырып торасыңмы әллә, Ләбибә апа?

— Юк ла, йөрим әле шунда өстерәлеп...

— Йөргәч әйбәт инде ул, ятып тормыйсың икән ич, — дим шаяртыбрак.

Соңгы вакытларда сәламәтлеге нык какшады. Алты ел элек бер бөерен алганнар иде, гомеренең күпме калганын да чамалый иде, алай да рухи ныклыгы аяктан екмый килә әле, Аллага шөкер, өенә барсам да озаклап сөйләшеп утырабыз, телефоннан да сөйләшеп туя алмыйбыз. Апа белән сеңел якынлыгы гына түгел бу, бу — җәмгыятьтә озак еллар бергә янәшә эшләгән, уртак фикере, уртак дуслары, уртак кайгы-шатлыклары булган ике кешенең тирән дуслыгы да. Очрашып сөйләшкән чакларда без бүгенге вәзгыять турында, язучыларның яңа китаплары хакында фикер алышабыз. Мин аңа дөнья хәлләре турында сөйлим (начаррак ишетә башлады), Сомали пиратларының безнең диңгезләрне кулга алулары турында әйтәм. Ләбибә апа бу хәбәргә балаларча шакката:

— Чынлапмы, хәзер дә бар микәнни ул пиратлар? — ди, күзләре очкынлана, — менә повесть язарга тема. Балалар егылып укыр иде: хәзер чит илгә күп йөриләр бит, бер үсмер шул карабта булды ди... Күңеленнән ул инде повестьның кысасын да сызып куя.

Сөйләшеп сүзебез бетми: татар радиосының бүгенге хәле, киләчәге турында да кайгыра ул, икебезнен дә яраткан шагыйребез Рөстәм Мингалимнең сәламәтлеге турында сораштыра, ничек итеп аңа ярдәм итәргә булыр икән дип уйлана, хатын-кыз язучыларның хәл-әхвәлен сораша.

Бу очрашулар, сөйләшүләр Ләбибә апаның соңгы көннәренә кадәр шулай бик якын хәлдә, туганлык белән һәм бер-беребезнең кадерен белеп үтә иде. Соңгы очрашу бик авыр булды. Ул инде урын өстендә, җәйнең түзә алмаслык эссе көннәре. Әле җилләткечне куеп, әле салкын япма ябып, мин аның янында утырам. Ник бер ыңгырашсын — шул кадәр сабыр булды ул.

— Бик авыр хәлем, Венера, китәрмен инде...

— Юк әле, Ләбибә апа, көн эссегә генә шулайдыр, — дим. Ул мине хәлсез кулы белән үзенә тарта.

— Әллә бәхилләшәсен инде, Ләбибә апа, — дим куркып.

— Мен бәхил, сенлем, мен бәхил...

Китте. Минем әнием урынында калган бертуган апам, татар балаларының яраткан язучысы дөньядан китте.

Вафатының нидән икәнлеген белү өчен аны моргка (бу сүзнен татарча әйтемен белмим икән) алып киттеләр. Кабул итеп утыручы табиб белешмә тутырганда Ләбибә апаны алып килгәннәрен белгәч шаккатты.

— Ләбибә апамени, Ихсановамы? — дип кабат-кабат сорады. — Без бит аның китапларын укып үстек, малайлар жыелышып тау куышлары эзләп йөрдек, — диде. Ахырдан, «Без аның жанын борчып тормабыз инде, болай да беленә нидән үлгәне, алып китәрсез, урыны жәннәттә булсын!» — диде.

Өлкән яшьтәге бу ир-егетнен язучыга чиксез хөрмәте дип кабул иттем мин бу гамәлне.

Соңгы юлга озатканда кеше күп булды. Жәй уртасы, язучыларның күбесе шәһәрдә түгелдер дип уйлаган идек, зур ишегалдын тутырып Ләбибә апаны хөрмәт иткән язучылар, журналистлар, бергә гомер кичергән таныш-белешләре, туганнар жыелган иде. Язучылар берлеге идарәсе рәисе М.Мирза, Халык шагыйрьләре Ренат Харис, Роберт Миннуллин озату сүзләрендә язучы Ләбибә Ихсанованың татар милли тормышында тоткан күренекле урынын сөйләделәр, бөтен ижатын балаларга багышлаган әдибәне хөрмәт белән, яратып искә алдылар.

Ләбибә апа жизнәбез Шәрәф Мөдәррис янында, бер чардуган эчендә мәңгелек йокыга талды. Кабер ташына тыйнак кына итеп: «Шагыйрь Шәрәф Мөдәррис. Язучы Ләбибә Ихсанова» дип туган-үлгән еллары күрсәтелгән такта элende.

Урыныгыз жәннәттә булсын, безнең кадерле жизнәбез белән сөекле апабыз!

## Тирән сулар тын алалар...

Бу юллар Ләбибә апага багышланган мәхәббәт шигыреннән алынды. Мина калса, Ләбибә апаның холкын, тормышын билгеләгән тирән бәяләмә бу...

Ләбибә апаның архивын ике машинага төяп өемә алып кайттым. Үзенең васыяте шулай иде. Өем-өем папкаларда хатлар, кульязмалар, төрле жыелышларда сөйләгән чыгыш-докладлары, рецензияләр, көндәлеккә язып барган уй-фикерләре... Ниләр генә юк, никадәр фикер байлыгы, әдәби осталык, әхлак-тәрбия турында уйлану... Балалардан килгән хатларны аерым саклаган. Уфадагы дуслары С.Кудаш, М.Кәрим, Г.Рамазанов, Н.Нәжми хатлары — аерым куелган, үзе язган хатларның күчермәләре калын папкада... Төгәлләнми калган язмалары юк, әдәби әсәрләре соңгы елларда (2001-2005) аерым китап булып «Мәгариф» нәшриятында дөнья күрде.

Язучы соңгы көннәренә кадәр аек акыл белән бүгенге тормыш турында уйланды, кимчелекләрне йөрәге белән кабул итә алмады.

Менә көндәлектән юллар: Татар радиосын ябалар дип ишеттем. Дөрес булса, коточкыч хәл бит бу! Һәр татар гаиләсе иртән торуга Казанны тынлый иде бит, һәр кухняда радиоалгычтан татарча жыр, тапшыру тынлыйлар иде. Татарстан гына түгел, күрше өлкәләргә бигрәк тә тансык иде Казан. Ул Туфаннар, Разилләр, Робертларның көче житми микәнни бу башбаштаклыкны бетерергә, депутатлар бит алар, закон чыгаручылар! (Шөкер, моннан 5-6 ел элек язылган борчулы фикерләр яхшы якка үзгәреп килә, депутатларыбыз да милләтебезне кайгыртып күп эшлиләр). Жәя эчендә язганнарыма мин әле тагы шактый сөенечле эшләрне өстәр идем, кызганыч, Ләбибә апа аларны укый алмый инде.

Сөйләшүләребезнең берсен мин язып куйганмын.

— И-и-и, Венера, элекке тормыш бөтенләй бетте бит, күз алдына да китерә алмый идек бит болай булыр дип.

— Рухи ныклык сынды бездә, дөньяга, тормышка ышаныч, өмет сүнде халыкта, — дим.

— Мин сугыш елларында авылыбызда бригадир ярдәмчесе булып эшләдем бит. Хатыннар, яшь кызлар ни авыр булса да күңел төшенкелегенә бирелмиләр иде. Сугышка китүчеләрне авыл очындагы Аерылу тавына кадәр олысы-кечесе жыелып

озата иде. Китүчеләр, җинеп кайтырбыз, йорт-җирне таратмагыз, исән-имин торыгыз, — дип китәләр иде. Калганнар исә еламый-сыкранмый саубуллашалар да, мөлдерәмә тулы күз яшьләрен өйләренә кайткач кына түгәләр иде.

— Без әнинең шулай елаганына бик аптырый идек, ныгытып авырып китә иде әни авылдашларын сугышка озатканнан соң.

— Әни бик авыр кичерә иде шул андый аерылышуларны. Бөтен авыл халкы диярлек әти белән әнинең укучылары иде бит. Аларны Фаиз абый, Гыйлем апа дип бик зурлыйлар иде. Әти-әнигә һәр кешесе якын иде авылның. Сугышның үлемсез булмаячагын алар күбрәк беләләр иде бит, шунлыктан авыррак та кичергәннәрдер инде аерылышуны.

Боларны нигә әйтәм, рухы нык иде бит халыкның. Басуда эшләү дисеңме, ындыр табагындамы... Берзаман Хәтимә апа иреннән хат алган, пластунский шуабыз дип язган, ди. Миннән сорый, «Ләбибә, син беләсеңдер инде, нәрсә диган сүз соң бу?» — ди. Мин мәктәптә хәрби дәрес укытам, пластунскийның ни-нәрсә икәнен шуышып күрсәттем. «И Ходаем, Берлинга кадәр шулай үрмәләп, түшләрендә шуышып барсалар, минем Миннегалиемнән нәрсә генә калыр микән, болай да бетәшкән, ябык иде», — ди Хәтимә апа уены-чыны белән. Ул арада түбән очтагы Диншат апа сүзгә кушыла: «Сөяге кайтса да ярар диярсең әле, әнә Закирәнең Нарифына таракунный килде бит». «Парахунный диген, җүләр», — дип көлешәләр. Мин төзәтәм, похоронный ул, кайгы, үлем хәбәре, дим. Күп кешегә килде бит ул кара кәгазьләр авылда. Гали абзыйларның әзмәвердәй биш малае сугышта юкка чыкты, бер Нәсимәсе исән иде, ул да вафат инде...

— Венера, әллә нәрсәләр сөйләп ташладым. Уйлап-уйлап утырам да, тагы бер уйлап куям дигәндәй. Көне буе берүзем бит мин, песием белән икәү, балаларның үз эше, кич кенә җыелабыз. Быел Розалия (килене) өч җиргә эшкә керде, мескенем, берсеннән кайта, икенчесенә китә. Ленар унберне бетерә бит, укырга кертәсе бар, ирле-хатынлы акча җыялар, җан көчләрен, йөрәк суларын сыгалар бит балалар, нинди хәлгә калды бит ил. Уку, эш, ял элек бит закон белән ныгытылган иде. Укымасаң, эшләмәсәң, син җәмгыятьнең чит-ят кешесе идең. Хәзер — хет өеңдә бот күтәреп ят, хет кеше үтер, тала — синең хакта беркем кайгырмый да, борчылмый да. Синең беркемгә дә кирәгең юк. Дөрес түгел бит бу, Венера. Менә без икебез дә бөтен гомеребезне кеше җанын тәрбияләүгә багышладык, җәмгать эшләрен эшләдек, без күнелебез, йөрәгебез белән тырыштык бит. Балалар әхлаклы, тәрбияле булсын, ил тотрыклы булсын дип тырыштык. Бөтенесен бер мизгелдә чәчеп бетерделәр дә җыеп ала алмыйлар хәзер. Элеккене гаепләп кенә хәзергегә мәхәббәт тәрбияләп булмый. Ай-һай авыр хәлгә калды ил. Инде безне милләт буларак та бетерсәләр...

— Ул чаклы ук кайгырма әле, Ләбибә апа, яшьләр кайгырсын, безнең гомер түгәрәкләнеп килә инде, беребез сиксәнне, икенчебез житмешне уздык...

— Шулаен шулай да...

Бүгенге әңгәмәбез шушы урында өзелде. Өйләрнең салкынлыгы, быелгы грипның хәтәрлеге турында бер-ике сүз алыштык та, очрашуга вәгъдәләшеп саубуллаштык.

Менә шулай дөнья гаме белән яшәп ятканда икебезгә дә күтәрә алмаслык кайгы килде. Ләбибә апаның өлкән улы Әнвәр, биш айдан соң минем ирем Васил көтмәгәндә гүр иясе булдылар. Ул көннәрне искә алу бик авыр. Баланы югалту дошманына да килмәсен икән. Ләбибә апаны кызганып, хәленә керергә тырышып никадәр «акыллы» сүз сөйләсәм дә күзеннән яшь кипмәде, йөрәк канын сыга-сыга ничә көннәр, ничә төннәр үткәрде. Ул Әнвәрнең әйбәтлеген, ана җанлы бала булуын, гаиләсе өчен тырышып яшәвен искә төшерә дә сөйли-сөйли уйга кала, төсе-кыяфәте белән Шәрәфенә ошаган өлкән улының һәр сүзен, һәр гамәлен күнеленнән кичереп, «ай-һай авыр, башларымны кайларга куйыйм икән», — ди торган иде.

Көн артыннан көн үтә, инде бераз тынычлана дигәндә минем иремнең кинәт үлеме аны тагы аяктан екты, кан басымы күтәрелеп, ятып кына тора башлады. Василне бик ярата иде ул. Кичтән генә телефоннан сөйләшеп хәл белешеп алганнар иде, иртән, йөрәге туктаганын ишеткәч, егылып китә язган. Елыйбыз да елыйбыз. Ялгыз калгач та, очрашкач та күздән яшь китми.

— Болай булмый, Венера, хәсрәттән янып бетәбез бит, үзебезне кулга алырга

тырышыйк әле. Асия Фәридовна кызы үлгәч әйткән иде («Азат хатын» журналының баш мөхәррире булып эшләгән А.Ф.Хәсәнованың унике-унөч яшьлек кызы үзләре күз алдында Казан суына батып үлгән иде), «Кызым үлгәч көн саен хәлдән тайганчы өй эше эшли идем, идән юам, кер уам, кайгы белән кара-каршы, күзгә-күз калырга курка идем», — диде. Кеше янына чыгарга кирәк, редакцияләргә бар, сөйләш.

— И Ләбибә апа, кеше күзенә күренерлегебез калдымени инде. Бер көнне урамда күптәнге танышымны очраткан идем: «Хәлеңне сорамыйм, йөзеңнән күренеп тора», — диде.

— Юк, алай димә, әни булса, «җебеп утырмагыз әле», — дияр иде. Үлгән артыннан үлеп булмый бит, яшәргә кирәк...

Әйе, әни исән булса, бөтен кайгыларыбызны үз йөрәгенә алыр иде...

## Без, без, без идек...

Очрашканда без еш кына әти-әнине, туган-кардәшләрне искә ала торган булып киттек.

Безнең әти ягыннан нәсел тамырлары бик еракка тоташкан. Ерак туганнарыбызның берсе Фәрт ага Гасыймов, Татарстан үзәк архивында эшләгән кеше, әниләргә безнең шәҗәрәне бирде. Менә ул: Аккылыч, Күбек, Әбәк, Мөхсин, Габдрәхим, Ихсан, Сәйфетдин, Фәләх, Зәки, Фаиз (Ләбибә, Ренат, Венера, Роберт). Аккылыч бабай борынгы болгар сакчыларыннан булгандырмы, Татарстан куенына сеңеп утырган Нократ аланы (Киров өлкәсе) татарлары болгар кавеменнән булганмы — болар безгә караңгы. Илебезнең аксакалы, атаклы рәссам һәм сынчы Бакый ага Урманче Ләбибә ападан: «Сез йөз-кыяфәтегез белән болгар татарларына тартым, шәҗәрәгез билгеле түгелме?» — дип сорагач, Ләбибә апа нәсел агачыбызны күрсәткән икән, исе-акылы китте ди рәссамның. Минем портретымны язганда да Бакый ага еш кына авылыбыз, андагы көнкүреш, тормыш хәлләре турында сораша иде.

— Сезнең авыл Шөн исемле бит әле, — ди ул, — Сөн сүзенә бик якын бит бу, шул яклардан килделәрме икән әллә?

— Безнең авылның инеше дә Аллавык дип атала. Әллә, мин әйтәм, шул яктан килгән кешеләр тын гына аккан мул сулы инешне күргәч, «Алла, Ык бит бу!» дип әйттеләр микән, авылларына да Ык якларындагы Сөн авылы исемен биреп, «Шөн»гә әйләнде микән?..

— Бик мөмкин, бик мөмкин, дустым, — ди Бакый ага (шулай дустым дип әйтә торган матур гадәте бар иде хөрмәтле аганың), әгәр шәҗәрәгездәге һәр буынны илле-алтмыш яшь кенә яшәгәннәр дип уйласаң да сезнең нәселнең тарихы 1400-1500 елларга барып тоташа икән бит.

Ихсановлар Татарстанда әлләни күп түгел. Булган кадәресе барысы да безнең туган кебек тоела миңа. Шунлыктан, инде шактый олыгайгач, күргән-белгән кешеләр шәҗәрә белән мавыга башлагач, без дә өлкән Ихсановларны барларга керештек.

Әтиебез Ихсанов Мөхәммәтфаиз Мөхәммәтзәки улы хәзерге Киров өлкәсенең Нократ Аланы районында, Түбән Шөн авылында мулла гаиләсендә туган. Зәки бабай алыптай зур гәүдәле, күркәм холыклы, мәһабәт кеше булган, үзеннән соң бик зур китапханәсе, көндәлекләре калган. Әниебезнең бертуган абыйсы Фатих мулланы Соловкига сөргәч, ул китапханәнең күп өлеше юкка чыга, исән-имин калганнарын сугыш елларында дәфтәр итеп кулланалар, аннан да калганын алтмышынчы еллар азагында Идел комнарында кызынып сәламәтләнергә килгән Нәкый ага Исәнбәт җыештыра (Нәкый аганың соңгы хатыны Нәҗибә апа Ижау мулласы кызы, Фатих мулланың балдызы. Икесе дә мәрхүм инде, искә алуыбыз рухларына дога булсын).

Ихсанов фамилиясе безнең нәселдә дә күп түгел, әнинең бертуган энеләре Зәкиев булып йөриләр. Күренекле (бу урында мин ничек языйм икән дип уйланып торам, чөнки академик Әбрар ага Кәримуллинны күренекле язучы дип, милләтнең күренекле юлбашчысы дип язсаң да күп түгел) бер вакыт миңа «без бер нәсел кешеләре бит, Ихсанов Мөхәммәтгата минем әни ягыннан бабам була», диган

иде. «Әнием Сафия Мөхәммәтгата кызы. Бабам Мөхәммәтгата (Зәки мулланың туганы) гаделсезлеккә түзә алмый торган кыю кеше була. Мин дә шулай, күрәсез, бу — геннар аша киләдер. «Урта Тигәнәле бәете» бар бит әле. Халык санын алу вакытында бабам шул ызгышларда катнашкан. Аны чыбык белән суктырганнар, муллалыктан алганнар. Гражданнар сугышы вакытында Урта Азиягә китеп, басмачы үзбәкләр ягында сугышкан. Бунтарьлык, бәлки, мина бабам каны аша килгәндер». Истәлекләрендә Әбрар ага Ихсанов Мөхәммәтгатаның Истанбулда, Каһирәдә укып кайткач Чәбия-Чүрчи авылында (хәзерге Саба районы), XX йөз башында земская школа ачуы турында яза. Шунда соныннан татарның күренекле галиме Мөхетдин ага Корбангалиевтә безнең әтиебез укый. Әти Мөхетдин ага дип бик еш искә ала иде, вафатын ишеткәч бик кайгырганы исемдә калган. Шул белеме белән әтиебез Казан университетының биология факультетын читтән торып укып тәмамлый һәм кырык елдан артык урта мәктәпнең химия-биология укытучысы булып эшли.



*Әтиебез Мөхәммәтфаиз белән әниебез Гыйлминаз. Уртада – сигез яшьлек Ләбибә. 1931 ел.*

Әнинең әтисе Зәки мулла Түнтәр мәдрәсәсен тәмамлап Түбән Шөнгә указлы мулла булып билгеләнә. Әниебез бик горурлана иде бабайның указлы мулла булуына, «сез указлы мулла оныклары, акыллы, тәртипле булыгыз, мулла нәселенә тап төшермәгез», — дия иде.

Әти-әни динне бик яхшы белсә дә безгә өйрәтмәделәр, заманы ул түгел иде. Аның каравы безгә әни Тукай шигырьләрен өйрәтте. «Су анасы», «Шүрәле», «Кисекбаш»ларны, балалар өчен язылган кыска шигырьләрен без 4-5 яшьтән үк өйрәнгән идек. Без диюем, игезәк туганым Ренат белән ярышып өйрәнә идек без шигырьләрне, аннары әнигә сөйләп күрсәтә идек...

Алай да әни мина җае чыкканда, сүз уңаенда Фатиха, Колһуалла догаларында менә болай әйтелгән дип аңлата иде. Үзе Балтач районының Смаел авылында ишле гаиләдә тугызынчы бала була. Укып чыккач, әни Нөнәгәр авылында мәктәп ачып укыта башлый. Шунда әнине Малмыждагы рус-татар мәктәбенә укырга бирәләр һәм яшь укытучыны (ниндидер бер юньсез түрә үзенә карата алмаганга үч итеп) Киров өлкәсенең иң ерак авылына җибәрәләр. Ямыл дигән кечкенә авылда әни мәктәп ачып укыта башлый һәм, әтине өйләндерер вакыт җиткәч, Зәки мулла шул тирәдәге күркәм кызларны кунакка дәшеп, әнине килен итеп төшерәләр.

Әтиебез салмак, басынкы, әниебез ут, ялкын иде. Бик булган, тегәргә-чигәргә оста, ир-ат эшенә дә башлап йөри, бик күп чәчәкләр үстерә иде. Безнең өй тирәсендәге чәчәкләрне күрергә кичке якта авыл кызлары-киленнәре махсус килә торган иде. «Гыйлем апа, безгә дә бир әле чәчәк орлыкларын», — диләр иде. Әнидән күреп өй алларына янбакча ясаучылар, өйләрен гөлгә-чәчәккә күмүчеләр күп булды.

Фаиз абый... Гыйлем апа... Бөтен гомерләрен авыл халкын тәрбияләүгә биргән бу шәхесләр безгә әти-әни генә түгел, чын мәгънәсендә укытучы, өйрәтүче, остаз булдылар. Ике мәхәлләле, урта мәктәпле зур авылда әти-әнидән белем һәм тәрбия алмаган кеше калмады. Хәзер дә бик зур ихтирам белән искә алалар, догадан калдырмыйлар аларны.

Истәлекләр... Ләбибә апа белән без шулай юанабыз хәзер. Әти-әни исән чакта нишләп күбрәк сорашмадык икән, авыл тарихын, кешеләрен алардан да күп белүче юк иде бит, дибез.

## Илһам чишмәләре...

Ләбибә апаның язучы, минем журналист булып китүебез кайсы чишмәләрдән башланды икән? Әниебездән! Тормышны, табигатьне өзелеп яраткан әниебез туган телнең бөтен матурлыгын безгә өйрәтергә тырышты. Ул үз чорының бик күп шагыйрьләренең шигырьләрен яттан белә, гарәп-фарсы әйтем-мәкальләрен сөйләмендә еш куллана, матур жырлый (әти шәп итеп гармун, скрипка уйный иде), яшьрәк чакта (мулла килене булса да) авыл сәхнәсендә спектакльләр куюын сөйли иде. Безне дә күп укырга, шигырь яратырга әниебез өйрәтте.

Ә бәлки туган ягыбызның гүзәл табигате илһам биргәндер Ләбибә апага...

Без ике малай, ике кыз Киров өлкәсенең Нократ елгасы буенда үстек. Идел (Нократ-Вятка елгасын бездә шулай дип йөртәләр) авылыбыз итәгеннән генә агып китә дә биек таулар, кара урманнар арасына кереп югала. (Үсә төшкәч ул тауларның безнең Ярмәкәй калкулыгы, кара урманнарның күрше Толлы авылы таллыклары икәнен белеп, Иделебезнең житү кызлар кебек йөгереп-агып Камага кушылганын күреп балачак хыялының шулай гади генә чишелешенә сәерсенгән идем.)

Бездән (ягъни миннән һәм игезәгем Ренаттан) нәкъ ун яшькә өлкән булган Ләбибә апага эне-сеңелен бәла-казалардан саклау эше йөкләтелгән булгандыр, үзебезне белә башлаганнан бирле ул безгә кырыс, бер дә безнең белән уйнамый торган олы бер кеше булып күренә иде. Бигрәк тә идән юганда ачулы була торган иде ул: шаярып-уйнап өйне туздырмасыннар өчендер инде, безнең өчебезне (кечкенәбез Роберт) өч почмакка утыртып, селкенергә дә рөхсәт бирми иде. Кая ул идән кипмичә юган идәндә йөрү! Без караваттан урындыкка, аннан казан өстенә, мич башына күчә-күчә ишек төбенә килеп житә идек һәм, апабызны сөендереп, урамга чыгып чаба идек. Бер сөйләшеп утырганда шуларны искә алдык та, Ләбибә апа «Мин үзем дә уйнарга бик ярата идем шул, — дип куйды көлеп.

Чынлап та, Ләбибә апа әти-әнинең көтеп алган икенче баласы булганга (апабыз Мәсгудә ачлык елны яше тулганда үлгән), аның бөтен теләген үтәгәннәр. Уйныйсы килгәндә уйнаган, ашыйсы килгәндә бөтен тәмле аңа булган. Ләбибә исемен аңа бабабыз Зәки мулла кушкан. «Казан каласында Ләбибә мәктәбе бар, бик затлы мәктәп, кызлар укыта, шуның укытучысының исемен кушам», — дигән. Ләбибә апа да әсәрләре, ижаты белән данлыклы Ләбибә Хөсәениянең тоткан мәслəген, хезмәтен дәвам иттерде дип уйлыйм мин.

Сүзем сиксәнне узган апамның бала чагы турында иде бит әле. Минем күз алдымда инде олыгайган булса да күзләрендә шаян очкыннар кимемәгән, кайгы-хәсрәттән йөзе жыерчыклар белән тулса да үзенә бер нур бөркеп торган, иннек-кершәнне яшьтән үк яратмаган кадерле-газиз бертуганымның бала чагы искә төшә.

Безнең дөньяга килүебез әти-әнигә бик сөенечле булса да (Ләбибә апа белән безнең арада өч туганыбыз юк кына авырулардан бик яшьли үлеп киткәннәр) Ләбибә апа өчен алай ук зур куаныч булмагандыр дип уйлыйм. Нәкъ ул туган көндә, августның 23ендә тугангадыр, өчебезнең туган көн дә бергә бәйрәм ителгән. Бездән нәкъ ун яшькә өлкән апабыз уйныйсы килгәндә дә урамга чыгып йөгерә алмаган. Кушбишектә яткан ике тиктормас төенчекне йоклатырга, бишек тирбәтергә тиеш булган. Хәер, безне тирбәтә-тирбәтә әллә ничаклы китап укыган ул, жырлар-бәетләр көйләгән, такмак чыгарган. Бәлки, апабызга язучылыкның тәүге орлыкларын салучы без булганбыздыр әле, Ходай Тәгалә ярдәме белән безнең аркылы аңа ижат итү теләге килгәндер?! Бу чаклысын мин хәзер генә, үзем дә татар журналистикасында илле еллап эшләгән кеше буларак фаразлыйм. Минемчә, Ләбибә апаның язучы булып китүенә авылыбыз Түбән Шөннең кешеләре дә йогынты ясагандыр, мөгаен. Күршеләребез Шәмсехәяттәй, Мәһирәттәй, Диншат, Әсмабикә апаларның безнең өйдә кич утырып йон эрләүләре (сугыш алды елларында жиделе лампа бездә генә иде), төрле кызык хәлләр, әкиятләр, бәетләр сөйләүләре, әниебезнең искиткеч матур мәкам белән аларга «Сак-Сок» бәетен, «Йосыф-Зөләйха» кыйссасын сөйләп күрсәтүен, әтиебезнең әле гармун, әле скрипка алып уйнавын, күршеләребезнең тыелып кына жырлауларын тыңлап үстек без.

Ләбибә апа мәктәптә укыганда ук яза башлаган. Сонрак, инде үзебез хәреф таный башлагач, ак келәттәге китап-дәфтәрләр арасыннан без Ләбибә Ихсанова,

Ләбибә Шунская, Ләбибә Вятская дигән авторның кулъязмада бик күп шигырьләрен, хикәяләрен табып укый идек, һәм аларны язучы нәкъ менә безнең апабыз булуына чиксез горурлана идек.

Сез игътибар иттегезме икән, аның әсәрләренең төп геройлары гел малайлар бит. Ләбибә апаның холкы да ир-егетләргә тартым дип уйлыйм мин. Кечкенә чагында түбән очның үз яшендәге малайлары аның дуслары булган, әбәкле, качышлы уйнаулар, чана шуулар, хәзер инде исемнәре дә онытылган башка төрле уеннарның үзәгендә нәзек-озын кара-чутыр кыз Ләбибә булган. Малайлар аны «Торна, челән» дип үчекләгәннәр, ул үзе дә җавапсыз калмаган, абыйсы булмаганлыктан, аңа үзен-үзе якларга туры килгән. Холкында тәрбияләнгән шушы кыюлыгы аңа тормышта күп төрле авырлыкларны җинеп чыгарга ярдәм иткән.

Урта мәктәпне Ләбибә апа Кукмарада тәмамлады. Каникулга кайткан араларда ул безгә яңа укыган китапларының эчтәлеген сөйли иде,пионер, комсомол оешмаларының нәрсә икәнен аңлата иде. Безнең үзебез генә белгән антыбыз бар иде. Берәр нәрсә турында ант итәргә туры килсә, «Ипидер», «Ике күзем чәчрәп чыксын» ише антлар урынына без «әти-әни хакы өчен» дип әйтә идек. Безнең өчен шушы антны бозудан да куркынычрак нәрсә юк иде. Әйткән эшебезне үтәмәсәк, ялган сөйләсәк, әти-әниебез шунда ук үлеп китәр төсле тоела иде. Һәм шушы изге антны безгә Ләбибә апабыз өйрәтте. Ул безгә әти-әнине яратырга, үзебезне начар гадәтләрдән саклап калырга ярдәм итте. Ләбибә апаның әсәрләрендә дә кечкенә геройлары өлкәннәргә, бигрәк тә әти-әниләренә шәфкатьле, ихтирамлы.

Сугыш чыгасы елда Ләбибә апа безнең мәктәптә пионервожатый булып эшли иде. Аннары аны хәрби дәресләр укытучысы итеп куйдылар. Үзе белән уйнап үскән егетләр сугышка китеп беткәч, Ләбибә апа авыл малайларының бердәнбер дусты булып калды. «Кәҗә үзәне»ндә, Ярмәкәй тауларында, Ышна буйларында кышкы бураннарда сугыш уены уйнап кайтуларын әле дә хәтерлим. Малайларның «фашистлар» булып уйнарга теләмәүләрен, «партизаннар сугышын», «тел» алуларын, үзенең «генерал» булуын сөйли иде апабыз шул карлы-бозлы «сугыш кыры»ннан кайткач. Тирән чокырлар, куе куаклыклар белән капланган киң үзәннәр эчендә авыл малайлары үзләреннән әлләни зур булмаган вожатый апаларыннан илне саклау, дошманнарга нәфрәт дигән беренче төшенчәләрне алганнардыр.

Колхоз комсомол оешмасының да секретаре Ләбибә апа иде. Төнге дозорларга чыгулары, концертлар куеп, акчасын фронт файдасына бирүләре, тагы әллә никадәр эш башкарулары турында хәзер инде әби-бабай булган элекке комсомоллар әле дә сагынып сөйлиләр.

Малайчарак булып үскән ул безнең. Кыска киселгән чәч, эскәк тимәгән куе каш, сөрмәсез кара күзле, янып тора торган чиста йөзле житү кыз, әтинең күн пальтосын киеп, каешларын портупея итеп буа иде дә, «Сугышка китәм, очучы булам», — ди торган иде. Әтиебез ул вакытта урын хастасы, аны сугышка алмадылар (юлда үлә бит бу, дигәннәр каралырга баргач). Шуна күрә Ләбибә апа безнең гаиләдән сугышка мин барырга тиеш дип бик адарынган булган. Ләкин теләге ни сәбәптәндер үтәлмәгән. Илне яклый алмый калу ачысы аның күңелендә, бик тирәндә әле дә саклана булса кирәк.

Чаңгы, тимераяк шуарга, фото ясарга өйрәнгән беренче кыз да авылда Ләбибә апа булган. Әниләрдән сорамыйча гына бер дәфтәрне күрше малаеның тактадан үзе ясаган чаңгысына алыштырып кайткач, әни бик ачулана кызын. Чаңгы шуасы килгәне өчен түгел, сорамыйча дәфтәр алганы өчен ачулана. Ә бер атнадан әтиебез аңа өр-яңа фабричный чаңгы алып кайтып бирә. Җилдән житез итеп шуарга өйрәнә ул. Биек тауның иң текә ягыннан, бары тик малайларның да иң кыюлары гына шуып төшә торган ягыннан шуарга тәвәккәлли ул һәм... ничек әле исән кала, калын кар катламы чаңгысы-ние белән мәтәлчек атып тәгәрәгән кыю кызны йомшак итеп инеш ярына сузып сала. Шуннан соң чаңгы сорамый инде Ләбибә апа. Сынган чаңгылары келәт астына яшерелә, ә тәвәккәллек, кыюлыгы кала: тормышның теләсә нинди авырлыгын җиңеп чыгардай кеше булып житлегә ул. Ләбибә апаның дуслары аның гармун уйнаганын белмиләр. Казаннан каникулга кайткан араларда

ул әтинең тальян гармунын ала иде дә, башын кыңгыр салып, бик тырышып озын, моңлы көйләр уйный иде. Сугыш еллары иде шул, ачлык, хәсрәт еллары. Күңеле тулган минутлары булгандыр, мөлдерәмә күз яшьләрен күрсәтмәс өчен шулай аска карап, күзенә төшкән кыска чәчен җыймыйча уйнагандыр ул.

Сугыш башлангач Лубян эшчеләр поселогына күчеп килгән Воронеж урман институтына укырга керде Ләбибә апа. Безнең авылдан әллә ни ерак түгел, 10-12 чакрымлап кына, кайтып йөрергә дә җайлы булыр дип уйлагандыр инде.

Тик сугыш Воронеждан читенгәч, беренче курс белән бишенчеләрне кире үз шәһәрләренә кайтарырга булганнар. Ләбибә апа Казан университетының география факультетына китте. Авылыбызны урап аккан Идел-су, хәтфә болыннар, кара урман белән ерактагы күксел таулар әйдәгәндер кыз баланы бу факультетка керергә. «Көмеш елга», «Җир астында җиде көн» исемле повестьлары нәкъ менә шул табигать тәэсирендә язылганнар бит.



*Казанга килеп, университетка укырга кергәч. 1943 ел.*

Студентлык еллары, сугыш авырлыгы, ачлык — ул вакыттагы егерме яшьлек кыз күңелендә якты да, шомлы да истәлекләр калдырган. Беренче лекцияләр, гомуми торакта филология факультетының татар бүлегендә укучы кызлар белән яшәү, беренче әдәби тәҗрибә, татар язучылары белән танышу, Шәрәф Мөдәррис... Өйләнешү, балалар табу һәм эш, эш, эш... Ул елларны Ләбибә апа «Кемгә сөйлим серләремне» дигән китабында язып чыкты. Ә менә, аның җылысын, кадерен һәм ярдәмен татып-тоеп яшәгән сеңлесенә, әдәбият һәм журналистика өлкәсендә шактый тәҗрибә туплаган кешегә Ләбибә апаның соңгы елларын, гомеренең кичкә авышкан елларын язарга калды.

Ләбибә апа ... апа... Никадәр кадерле, якын булгансың икән син безгә. Булган идең дип язасым килми...

Тагы бер истәлек:

Бергә уйнап үскән дуслары Гафинең үле хәбәре килгән. Аңа беренче тапкыр яратуын белдергән Габделбәрнең менә кайчаннан хаты юк... Гармун сирәк уйный иде ул, инде онытыла да башлагандыр, эшләп арыган бармаклары инде гармун телләрен бик җитез барламыйлар, алай да күңеле бик ташыганда, үзебез генә булганда кулына гармун ала да әкрен генә җырлый:

## Олы юлның тузанын да...

Ләбибә апа җырга-моңга гашыйк кеше иде. Җыр ишетсә, шунда ук кушыла, бигрәк тә элеккерәк җырларны, яшьлеге җырларын ярата иде. Минем ирем Васил бик оста гармун уйный иде. Ләбибә апа, безгә керсә (берара без бер үк йортта, күрше фатирларда тордык) Василдан гармун уйната, үзе җырлый иде:

Уфа юллары пыяла,
Таш булса таймас иде.
Яна минем йөрәккәем,
Син булсаң, янмас иде...

Җизнине ул сагынып яшәде. Ләкин гел аның турында гына уйлап, гел елап, юксынып утырырга мөмкинлеге булмады. Кырык яшьтән өч бала белән тол калу аңа балаларны кеше итәргә кирәклеген йөкләде. «Үземне гаять авыр йөк тартып тауга менгәндәй хис итә идем», — ди ул елларны искә алып. Менеп житте тауга Ләбибә апа, өч баласы да югары белем алып, үз милләтебез белән гаилә корып матур балалар үстереп яшәшләры. Әнвәре генә, төсе-бите белән җизнине хәтерләткән олы улы Әнвәре генә дөньядан иртә китте...

## Кадер...

Жизнидән соң Ләбибә апа кияүгә чыкмады. Сораучылар булды, бик әйбәт кешеләр сорады аны. Әхмәт абый Исхак минем аркылы да Ләбибә апага сүз салды, үзе дә шактый озак көтте Ләбибә апанын ризалыгын. Габдрахман ага Минский, Шәйхи ага Маннурның өметләре Ләбибә апада иде. «Өч балам белән...» дия иде апа. «Үз йөгем үземә артык түгел», — дия иде. Чыккан булса, тормышы жиңелрәк, яктырак булыр иде дип уйлыйм. Сибгат ага Хәким Маргелан шәһәреннән кайткан бер хәрби кешегә дә димләп караган, ул абый Австриягә өйләнеп китәргә тиеш булган икән... Чыккан булса... кем белә инде... Балаларына ул әти дә, әни дә була белде. Сабырлыгы, тырышлыгы, кеше арасында ким-хур булмыйм диюе аны әдәп-әхлак кысаларында тоткандыр инде. Әдәбиятыбызның иң күренекле шагыйрь-язучыларының Ләбибә апаны соравы, гомер юлдашы итеп алырга теләүләре минем апамның әйбәтлеген раслаучы дәлил түгелмени?! Ләбибә ападан җаен туры китереп сораган идем:

— Ләбибә апа, жизнидән бик иртә калдың, сораучылар да күп булды үзеңне. Нигә берсенә дә чыкмадың? Нинди үкенечең кала бу тормышта? — дидем.

Ерактa, бәлки, ялгыз яшәгән озын гомеренә карaптыр, ул әкрен генә: «Үкенечем шул, ир кадерен күрә алмадым», — диде. Мин аны бик тирән аңладым.

Алай да, сөенеченәме, көеноченәме дигәндәй, жизни үлгәннән соң аны яратып, мәхәббәтен җиткереп, җавап көтми яшәгән бер шагыйрь булган (Ләбибә апаның сере булганга, мин аның исемен язмаска уйладым). Зур шагыйрь, фронтовик, хатыны үлгәнгә берничә ел үткәч, ул Ләбибә апага яратуын язган.

Ләбибә апага уңай җавап бирмәгәне өчен үпкәләп, шулай да яратуы көчле (җавапсыз мәхәббәт) икәнен белдергән шигырьләр бер конвертка салынган да, өстенә: «Бу шигырьләрне юк итәргә базмадым, үз гомерләре белән яшәсеннәр инде», — дип язып куелган. Булган бит, аны кадерләп, үз итеп, якын күреп яшәгән кеше булган бит! Тол хатынның монсу күңеленә кояш нуры, җылы яктылык бирүенә мең рәхмәт сиңа, шагыйрь!

И син, изге мәхәббәтем.
Дөрлисең дә артасың син,
Ни кадәре читкә каксаң,
Шул кадәр үк тартасың син.
Синдәй якын берәү дә юк.
Сине шундый сагындым мин.
Өметем — ут, яшәвем — ут,
Ышан, шулай кабындым мин.
Җырларыма юлдаш бул син,
Юлдаш бул син теләгемә.
Бөтен олы хисең белән
Куч син минем йөрәгемә!

.........................

Карашыңнан, күзләреңнән,
Сулышыңнан аңлыйм сине,
Якын итәм һәм күңлеңә
Ут давылы булып керәм.
Һәммәсен әйт яшермичә —
Инде сүзне сиңа бирәм.

Бу шигырь астына Ләбибә апа болай язып куйган:

Һай бу йөрәк, бер дә тыңламый бит,
Белми янган утка төшәсен.
Сөя икән — ул соң гаепләме?
Җавап көтми — нәрсә эшләсен.

Беренче карашка артык сабыр, артык әкрен күренгән Ләбибә апаның бөтен авырлыкларны җиңеп барырга ярдәм итүче нык холкы бар иде. Эшлим дигәнен эшләр, әмма кеше күзенә күренеп мактанып йөрмәс. Үзе генә белгән тормыш режимы ана бер көн дә калмыйча казна хезмәтендә эшләргә мөмкинлек бирде. Ул «Ялкын» журналында баш мөхәррир, китап нәшриятында мөхәррир, «Казан утлары»нда җаваплы сәркәтип булды, «үзе бушка, үзе туйганчы» җәмәгать эшләрен жигелеп тартты, ничәмә-ничә балалар язучысына остаз булды. Хезмәтен бәяләделәр. Татарстанның һәм Россиянең атказанган мәдәният хезмәткәре исеменә лаек булды. Ә никадәр яна әсәрләр... Кайсын гына алып карасаң да балалар мавыгып укырлык,

андагы геройларга охшап төрле уеннар оештырып йөрерлек китаплар язды ул. Гомуми тиражы миллионнан арткан ул китаплар ярты гасырдан артык ничә буын яшьләрне тәрбияләде. Өйдән-өйгә, әнидән-бабаларга күчкән китаплар, таушалып бетеп укылган китаплар күп булмый. Балалар язучысы Ләбибә Ихсанова әнә шул бәхеткә иреште.

Ләбибә апаның ин сокландыргыч сыйфатларыннан берсе — кешеләрне яратуы. Йөзләгән очеркларында ул хезмәт кешеләрен мактап язды, аларның матур гадәтләрен-сыйфатларын күрсәтте. Геройлары — укытучылар, табибәләр, күпер салучылар, сәнгать кешеләре... Үз гомерендә аның бер генә дә дошманы булмады. Дөрес, эшләгәндә ана үпкәләп, йомшак әсәрләрен журналда бастырмаган өчен кинә тотучылар булгандыр, ләкин аларга да орылып-бәрелми, күңел төшерерлек сүз әйтми иде ул. Язучы дусларының иҗатлары турында матур-матур рецензияләр яза, авторларның шатлыкларын уртаклаша, уңышсызлыкларына борчыла. Аның менә шулай кешеләргә игътибарлы, ярдәмле һәм таләпчән булуы, кеше язмышына беркайчан да битараф калмавы әсәрләрендә дә үзәк урында иде. Бакчасындагы һәр үсемлеккә йөрәк жылысын биргән кебек, ул үзенең нәни геройлары дөньясында яшәде, алар өчен борчылды, алар өчен шатланды. Әгәр шулай булмаса, «Саралан малайлары», «Наил белән Фаил», «Ана кондәлеге» повестьлары укучыларның яраткан китабы була алыр идеме икән?



*Ире Шәрәф Мөдәррис белән. Узган гасырның 50нче еллары*

Ләбибә апа алтмыш-житмешенче еллардагы өлкән язучыларны еш искә ала, аларны сагынып сөйли. Ибраһим Гази, Мирсәй Әмир, Хәсән Туфан, Әмирхан Еники, Гомәр Бәширов, Нури Арсланов — болар һәркайсы Ләбибә апа күңелендә тирән эз калдырган язучылар. Аларның яшьләргә карата бик сак, игътибарлы, ярдәмле булуын, әдәбиятның илаһи зурлыгын, телнең бөтенлеген, бөеклеген саклауларын сөйли. Шушы елларда Ләбибә апа ныклап торып яза башлады. Белмим, ничек өлгергәндер ул: үзе радиокомитетта эшли, бер-бер артлы өч баласы туды, өй тулы кеше була, ризыкны кибет-базардан эзләп сатып аласы. Кунак-төшемгә табын жәясе. Ләбибә апа ин бәхетле, ин якты еллары итеп нәкъ менә шул елларны искә ала. Хәсән Туфан белән якыннан танышу-дуслашу, Башкортстандагы татар язучылары, Казакъстан әдипләре белән аралашу ул елларда минем дә киләчәгемне ачыкладылар булса кирәк. Мин Казан университетының татар теле һәм әдәбияты бүлеген тәмамлап гомеремне журналистикага багышладым. «Яшь ленинчы» газетасын әр-янадан ачып, эшлекле коллектив туплап яшь язучы-шагыйрьләргә кин мәйдан ачтым, соңрак «Азат хатын» журналының баш мөхәррире булып хатын-кызлар мәнфәгатен кайгырттым. Егерме сигез ел ике матбагада баш мөхәррир булып эшләп лаеклы ялга чыктым, «Халыклар Дуслыгы» ордены белән бүләкләндем, башка дәүләт бүләкләре алдым. Мин жизнәм белән Ләбибә апага язмышыма юл салганнары өчен чиксез рәхмәтле.

Минем хәтеремдә жизнәбез Шәрәф Мөдәрриснең Әми тавы чокырында ярны ишеп үзе салган кечкенә генә өе, шул өй тулы язучылар, шагыйрьләрнең шау-гөр килеп әдәбият турында сөйләшүләре калган. Без ул елларда туганым Ренат белән Казан педагогия училищесында укый идек һәм дүрт ел буе шушы кечкенә өйдә кин күңелле гаилә куенында яшәдек. Жизни белән апа безгә ризык кына түгел, рухи азык та бирделәр. Беренче тапкыр мин шушы гаиләдә әле солдат шинельләрен дә салып өлгермәгән Хатип Госман, Халикъ Садрый, Гамир Насрый, Атилла Расих, Риза Ишморат, Фатих Хөсниләрне күрдем. Аларның әсәрләрен тынлап, иҗади бәхәсләрен ишетеп яшәдем, татар һәм рус әдәбияты, дөнья классиклары әсәрләрен өйрәндем. Гажәеп якты, мавыктыргыч, кин офыклы дөнья иде ул.

...Кич, кич якынлашып килә. Кояшлы иртәләре, жилле-давыллы көннәре белән гомер үтеп бара. Инде менә сиксән алты да тулды. Аллага шөкер, бу көннәрне күрермен дип уйламаган иде ул. Сугыш елларындагы үлем-китемне күп күргәнгәме, ул нигәдер үз гомерен ниндидер бер вакыйгаларга бәйләп чикли иде.

Бервакыт Гомәр ага Бәширов сорый икән:

— Ләбибә, син ничә яшькә кадәр торырга өметләнәсен?

— И Гомәр ага, сиксәненче елларда коммунизм буласы бит, шуны күрәсе иде, — ди Ләбибә апа. Бу — житмешенче елларда, Ләбибә апага 50 яшьләр тирәсендә була.

— Әз, бик әз куясың вакытыңны, — ди Гомәр ага, — мин үзем бер туксанга житәргә исәплəп торам әле. — Шөкер, Гомәр ага йөзе тулганда (99нчы яшендә —ред.) фани дөнья белән саубуллашты. Ләбибә апа аннан соң ике мең елны тәмамлап, өченче меңгә керүне күрсәм иде, диде, аннары — Казанның мең еллыгын! Теләге үтәлеп тора тагы, рәхмәт яугыры...

Соңгы вакытларда сәламәтлеге какшады. Еш кына кан басымы күтәрелә, аяклары авырта, күзен яры каплый башлады. Шулай да һәр иртәдә эш планын барлап куя, үзен көчләп булса да өстәл артына язарга утыра.

— Мин бу көннәрдә урамда утырып керергә өйрәндем әле, диде бер баруымда. — Күрденме, безнең ишек алды нинди матур. Оя-оя итеп утыртылган каеннар арасына матур эскәмияләр куелган, кечкенә өстәлләр бар. Карт-коры, минем яшьләрдәге әбиләр шунда чыгып утыралар, дөнья хәлләрен сөйләшәләр. Ник бер гайбәт, ямьсез сүз булсын шунда. Алар барысы да бер-берсен беләләр, күпер төзүчеләр өчен махсус салынган йортлар икән монда, бергә эшләгән, бергә ялга чыккан кешеләр тора. Сания дигәне бакчасыннан кайтышлый һәрберебезгә берәр генә булса да жиләк бирел китә, икенче берсе аптекага барып күршесенә дару алып килә... Шуларны язам әле. «Әбиләр чуагы» дигән очерк яза башладым. Никадәр рух ныклыгы, күңел пакьлеге, милли горурлык аларда! Язучының хезмәте нәкъ менә шулар үрнәгендә башкаларны тәрбияләү бит!

— Ә повестең? Балалар өчен повесть башлаган идең бит?

— Анысы торып тора әле. Нигәдер күңелем сүрелде. Китапларымны чыгара алмаганга күңелем төштеме шунда, әллә вакыт житеп киләме...

— Ашыкма, Ләбибә апа, кич житмәде әле, Әмирхан ага әйткәндәй, кояш баешы гына...

Ләбибә апаның ике томлык сайланма әсәрләре үзе үлгәч чыкты. Каты тышлыкта, берничә повесть кергән бу китапларны кулыма алып еладым. Ничек күрәсе килгән иде бит, ничек көткән иде бит ул китапларның чыгуын Ләбибә апа! Нишлисең, хәзерге дөнья-вәзгыятьтә жиде елдан соң чыгуына да рәхмәт әйтергә генә кала.

Бөтен ижади гомерен балаларга багышлаган язучы Ләбибә Ихсановага туксан ел тулды. Ап-ак чәчле, нурлы йөзле Ләбибә апа күңелебездә якты елмаюы белән озак сакланыр әле, ул китапларында яшәр...

**Венера ИХСАНОВА**

**Редакциядән:** *Татар матбугатында озак еллар җаваплы вазифалар башкарган авторыбыз Венера ханым да 80 яшен тутыра. Милләтебезне уятуда аның эшчәнлеге аерым бер урында тора. Сиксәненче елларда ук, совет-партия карарлары милләтләр хокукын чикләгән чорларда «Азат хатын» журналында бер-бер артлы милли кыйммәтләребез турындагы мәкаләләре дөнья күрде. Журналның тиражы тиз арада ярты миллионга кадәр (480 мең яздырып алучы) җитте.*

*Сезне олы бәйрәмегез белән тәбриклибез, хөрмәтле Венера апа, сау-сәламәт бәрәкәтле гомер кичерүегезне телибез.*

## Парчалар

***

**Ата улны, ана кызны**
**Белә торган замана:**
**Аерым фатир, иномарка**
**Ал балаңа! Зарланма!**

***

**Әй, дусларым, әйтер сүзем**
**Сезгә шуннан гыйбарәт:**
**Йолдызлар бит атна саен**
**Җиргә факс җибәрә.**
**Язмышыбыз — гороскопта**
**Факста язылганча.**
**Йолдызлар да «грамотный» —**
**Бар да хәзер заманча!**
**Безне алар ышандыра:**
**Фаразлар бар да дөрес!**
**Мөгез чыгарып йөрмә, ди**
**Сак бул син, «Кәҗәмөгез».**
**«Арыслан», син тычкан түгел**
**(Моны һәркем дә белми!)**
**«Кыз» икәнлегеңне, кызым,**
**Беркем исбатлап бирми.**
**«Кысла», артыгын кысылма,**
**«Чаян» сиңардан гарык.**
**Бертуктаусыз койрыгыңны**
**Селкетеп торма, «Балык».**
**«Кучкар», учлап байлыгыңны,**
**«Игезәкләр»гә тоттыр.**
**«Сукояр», син «Үлчәүләр»гә**
**Суыңны үлчәп йоттыр.**
**«Укчы» белән «Үгезбозау»,**
**Сезгә ниләр язылган?**
**Шикләнмәгез, аларга да**
**Буп—буш сүзләр табылган!**

***

**Гашыйк итмә, пужалысты, яшьлек үткән,**
**Йөрәк инде почти йоклап киткән...**
**Башларыңны әйләндерер җавап сүзләр**
**Әллә кайсы почмакларга качып беткән.**
**Пужалысты! Каннарым да ташмый күптән,**
**Чыга алмыйм элеккечә тирән көрттән.**
**Зәпәрәйне зәпчәст итеп онык сүткән...**
**Гашыйк итмә! Тәннәрем дә арып киткән.**
**Ике күзлек элеп йөрер чаклар җиткән,**
**Калган чәчкә ап—ак оннар еллар сипкән.**
**Гашыйк итмә, пужалысты, пинсәм беткән...**
**Күңел марҗа, урыс сорый... Тинтәк икән!**

***

**«Тиле бәрән, сарык, сыер»,**
**Тагын бик күп хайваннар.**
**Ире Якупны шулай дип**
**Тиргәде Шәмсекамәр.**
**Хайван белән хайван яши,**
**Дип уйлап куйды Якуп.**
**Икенче көн эштән кайтты**
**Чыбыркысын шартлатып...**

**Люция ӘБЛИЕВА**

## «Ошадың әле...»

Алтмыш бернең башы. Казан университетының бер төркем читтән торып укучылары кышкы сессиягә җыелганнар. Яшәүләре — «Казан» кунакханәсендә. Биредә әле күптән түгел генә Уфадан Казанга күчеп, «Азат хатын» («Сөембикә») журналында җаваплы секретарь булып эшли башлаган Хәсән Сарьян да яши.

Бер кичне яшьләр «очрашуны юар өчен» икенче каттагы ресторанга төшкәннәр. Ә анда бер өстәл артында дүрт ир-ат кәеф-сафа кылып, шау килеп сөйләшеп утыра. Сарьянга танышлар икән, ул:

— Әйдәгез, егетләр, чын шагыйрьләр, язучылар белән таныштырам, — дип иптәшләрен тегеләр янына алып килә. Әдипләр, һәрберсе урыннарыннан кузгалып, кул биреп үзләре белән таныштыра башлаганнар:

— Мин — Нур Гайсин булам...

— Ә мин Әнвәр абыегыз Давыдов...

— Зәки абзагыз Нури...

Иң соныннан яшьләр белән өстәлнең арткы башында эре кыяфәттә утырган Шәрәф Мөдәррис кузгала, шулай ук кул биреп күрешә һәм һәр егеткә сорау белән эндәшә:

— Син кем инде, энекәш?

— Мин, абый, Аскыннан. Рәиф Әхмәтов. Район газетасында эшлим.

— Ә син?

— Атым — Нурулла. Башкортстан Югары Советы Президиумында эшлим.

— Ә сине кем дип белик?

— Мин — бөек мишәр халкының данлыклы улы Артур Елховский, — дигән уртача буйлы, озын чәчле, бар йөзенә көләч кояш кебек елмаю җәелгән егет.

— Әт-тәт-тәт-тә, — дигән гаҗәпләнеп Шәрәф Мөдәррис. — Шапырынасың түгелме соң?

Егет, елмаюын бераз авызлыклап:

— Андый гадәт бар. Шапырту түгел, шаярту бу!

— Үзем дә шуны сизенәм. Шулай да, энем, кем соң син? Кайларда эшлисең?

— Мин, абзый, бораулаучы, ягъни нефтьче. Әлегә!

— Ә, алайса, мин нефтьчеләрне белмим, — дигән Мөдәррис, арты белән борылып.

— Ә син, абзый, үзең кем буласың? Исемеңне әйтмәдең бит әле, — дигән бераз үпкәле егет, кабат шаярту дулкынында.

— Мин — Шәрәф Мөдәррис, — дигән шагыйрь горур кыяфәт белән. — Танып кал абзаңны: Шәрәф Мөдәррис!

— Мө-дәр-рис? Гаҗәп. Нефтьчеләр дә андый шагыйрьне белмиләр. Юк, юк, белмиләр...

— Ка-ак?

— А вот так! Син бит менә нефтьчеләрне белмисең. Синең каршыңда, абзый, бөтен Союзга даны таралган бораулау остасы, Социалистик Хезмәт Герое Мөгаллим Гыймазовның иң яраткан, иң уңган бораулаучысы басып тора. Ә син: «Белмим», — дисең. Факт?

— Ну, малай, усал икәнсең. Усалның да усалы! Һы! Чыннан да мишәрме син?

— Мишәр.

— Әйтәм аны! Шәрәф абзыеңның цыраена царт иттереп цирттең.

— Үзең ацуны китерәцең бит.

— Ярар, үпкәләшмик, дуслашыйк. Син — мишәр, мин — мишәр. Аня, Зәки белән Әнвәр дә мишәрләр. Безгә ачуланышу килешми. Шулай бит, Зәки?

— Шулай, шулай! — ди Зәки Нури, Шәрәф Мөдәррис кебек үк Чүпрәле мишәре.

— Зәки, сал энекәш белән икебезгә! Әйдә, энем, утыр яныма, кабыйк! Ошадың бит әле син мина...

Әдипләр белән яшьләр, ике өстәлне бер итеп, тәмам үз булып, дуслашып, күнелле сөйләшеп, шигырьләр укып кич буе бергә утыралар. Табын түрендә танылган шагыйрь Шәрәф Мөдәррис, аның уңында Хәсән Сарьян, сул (йөрәк) ягында исә «усал» бораулаучы егет — «Артур Елховский» (булачак журналист, язучы Әсгать Салах), аның янәшәсендә олпат гәүдәле шагыйрь Зәки Нури, аннан башкалар...

Әнә шул аерым истәлекле, сокланггыч жылы кичә егетләрнен күнел түрендә гомергә сакланып калган.

## Аккош тәпие

Язучы Фәнзаман Баттал яшьлегендә Минзәлә районы газетасында эшләгән. Еш кына ул колхоз-совхозларга барып, алдынгы авыл хуҗалыгы хезмәткәрләре турында мәкаләләр, очерклар язган. Шулай бер колхозга баргач, яшь хәбәрче үзе кебек үк яшь һәм чибәр бозаулар караучы кыз белән танышкан, аның турында язарга мәгълүмат туплаган. Ә кич белән клубта болар тагын очрашканнар, бергә биегәннәр, җырлаганнар, уйнаганнар. Фәнзаман кызның җылы кулларын тотып аны өенә озата кайткан. Тик бозаулар карый-карый кытыршыланып, кибешеп беткән кулларын кыз, уңайсызланып, хәбәрченең кулларыннан тартып-тартып ала икән. Моны үзе дә чамалаган егет:

— И-и, Саимә, кулларың бигрәк матур, гел аккош тәпиләре кебек, — дигән шаярып. Бу мактау сүзләренә бик сөенеп, кыз тыйнак кына:

— Алай ук түгел лә инде, — дигән.

Чынында исә гел күлдә, сазлыкта гомерен үткәреп, шунда туенып яшәгән аккошның тәпиләре тәмам яргаланып, кытыршыланып бетә һәм аккош үзе сокланггыч кош булса да, тәпиләренә артык ис китәрлек түгел икән.

## «Син иденмени ул?»

Әлфия Авзалова төркеме Әлмәткә гастрольгә килгән. Чыгышларын төшемлерәк итү ниятеннәндер, Әлфия «Әлмәт таңнары» редакциясенә кергән, үзләре турында газетада хәбәр бирүне сораган. Редакциядә мондый кадерле кунак сирәк була — мөхәррир чәй куеп җибәргән. Чәй артында сөйләшә-сөйләшә болар яшьлекләрен искә алганнар.

— Исеңдәме, Әлфия, Илһам белән 1960 ел җәендә Актүбәгә килгән идегез. Минем анда яшәгән, буровойда эшләгән вакыт. Концерттан соң син клубтан чыктың да, миннән Нефтьчеләр урамын сорадың. Мин сине озата бардым. Син ул урамда бик якын туганнарың яшәве турында әйткән идең...

— И-е, малакаем. Апа белән җизнәй яшиләр иде анда. Мәрхүмнәр инде, бик игелекле кешеләр иде. Бер егет кисәге озата барганын хәтерлим. Син иденмени ул?

— Әйе, мин идем.

— И-и, малакаем, нишләп соң син минем чыкканны көтмәдең?

— Соң, син бит «Мине көт!» димәдең.

— И-и, малакаем, егет кеше барыбер көтәргә тиеш, әйткәнне көтеп торырга түгел иде инде...

— Мин тәрәзәгезгә караштыргаладым. Туганнарың сине сыйларга тотындылар. Концерттан соң ачыккан идең ахры — бик тәмләп ашый башладың. Минем дә үлә язып ашыйсы килеп китте. Карап-карап тордым да, ашханә ябылганчы дип шунда чаптым. Ач кешедә кызлар кайгысы буламыни? — дигән Әсгать Салах.

— И-и, малакаем. Насыйп булмаган инде, — дигән Әлфия. — Насыйп булмаганны басып булмый, диләр бит...

**Әсгать САЛАХ**

Ictimagi-mədəni tormışıbızdan
Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

*Казан шәһәрен төрки дөньяның 2014 елгы мәдәни башкаласы дип игълан итү белән бәйле рәвештә оештыру чаралары турында*

Халыкара төрки мәдәният оешмасы (ТЮРКСОЙ) әгъзалары булган илләр Мәдәният министрлары даими советының чираттагы XXX утырышы Казан шәһәрен төрки дөньяның 2014 елгы мәдәни башкаласы дип игълан итү турындагы карары нигезендә, «Казан — төрки дөньяның 2014 елгы мәдәни башкаласы» программасы кысаларында тантаналы чаралар әзерләү максатында карар бирәм:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына ике ай вакыт эчендә:

«Казан — төрки дөньяның 2014 елгы мәдәни башкаласы» программасы чараларын әзерләү һәм уздыру буенча оештыру комитеты төзергә һәм аның составын расларга;

үткәрү вакытын, җаваплы башкаручыларны, финанслау күләмнәрен һәм чыганакларын күрсәтеп, төп чаралар планын эшләргә һәм расларга, шулай ук аны гамәлгә ашыруны контрольдә тотуны тәэмин итәргә.

2. Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары башлыкларына, федераль башкарма хакимият органнарының Татарстан Республикасы буенча территориаль органнарына, җәмәгать берләшмәләренә һәм оешмаларга «Казан — төрки дөньяның 2014 елгы мәдәни башкаласы» программасы чараларын әзерләүдә һәм уздыруда актив катнашырга тәкъдим итәргә.

3. Республика «Татмедиа» матбугат һәм гаммәви коммуникацияләр агентлыгына, «Яңа Гасыр» телерадиокомпаниясе» ачык акционерлык җәмгыятенә, республика һәм җирле гаммәви мәгълүмат чараларына «Казан — төрки дөньяның 2014 елгы мәдәни башкаласы» программасы кысаларында уздырыла торган чараларны киң яктыртуны тәэмин итәргә.

4. Әлеге Указ рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты**
**Р.МИҢНЕХАНОВ.**

## АКАДЕМИКЛАР ХИСАП ТОТТЫ

15 майда ТР Фәннәр академиясенең гомуми җыелышы булып узды. Аның эшендә ТР Дәүләт Киңәшчесе Минтимер Шәймиев, Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин, төрле тармак министрлары, ВУЗ ректорлары катнашты. Академиянең еллык эш хисабы белән Академия президенты Әхмәт Мазһаров чыгыш ясады. Аның сүзләренчә, татар халкының тарихын, мәдәниятен өйрәнү 12 өстенлекле юнәлешнең берсе итеп кертелгән. «Безнең Академия өчен бу юнәлеш аеруча мөһим. Чөнки дөньяның 125 Фәннәр академиясе арасыннан фәкать без генә 8 миллионлы татар халкының тарихы, теле, мәдәнияте белән комплекслы шөгыльләнәбез», — диде Әхмәт Мазһар улы. Ул шулай ук ТР Фәннәр академиясе составында күп профильле фәнни учреждениеләр эшләвен, аларның киң спектрдагы тарихи, филологик, Ислам дине мәсьәләләрен өйрәнүен искәртте. Яшьләрне фәнгә җәлеп итү буенча да күп эш башкарыла. Талантлы яшьләр һәм балаларның «Сәләт» оешмасы фәнни-укыту комплексына әверелде һәм 1 ел эчендә 50 социаль проектны тормышка ашырды.

Фәннәр академиясе җыелышында Татарстанның фән үсешенә үзеннән зур өлеш керткәне өчен Минтимер Шәймиевкә алтын медаль тапшырылды.

Шулай ук, бу утырышта Татарстан Фәннәр академиясенең яңа әгъзалары сайланды.

## ҖЫРЧЫБЫЗ УҢЫШЫ

Татарстанның атказанган артисты Динә Гарипова үткән шимбә кичендә Швециянең Мальме шәһәрендә үткән 58нче «Евровидение» халыкара җыр бәйгесе финалында 5нче урынга лаек булды.

Ул швед продюсеры Габриэль Аларес Иоаким Бьонберг һәм Леонид Гуткин иҗат иткән «What if» дип исемләнгән җырны башкарды. Динәнең чыгышын көчле алкышларга күмделәр. Финалда җәмгысе 26 җыр башкарылды. Тамашаны 120 миллионнан артык телевизор караучы тамаша кылды.

Ә Динә Гарипованың шундый абруйлы бәйгедә беренче бишлеккә керүе безнең өчен зур дәрәҗә, әлбәттә. Динә Гарипова финалда иң көчле тавышлы, иң ихлас җырчыларның берсе иде.

## МӘСКӘҮДӘ КИТАП ТӘКЪДИМ ИТҮ

Мәскәүдә Халыкара язучылар берлэлеге йортында язучы, Татарстанның Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты Ринат Мөхәммәдиевнең «Свои люди» дигән җыентыгын тәкъдим итү булды. Язучы турында күренекле шагыйрь Иван Переверзин тәфсилле сүз әйтте. Россия Язучылар берлеге сәркәтибе, шагыйрь һәм тәрҗемәче Николай Переяслов әдәбиятлар дуслыгының әһәмиятен ассызыклады, язучыбызның бу юнәлештә керткән өлешен хуплады.

Мәҗлестә шулай ук шагыйрь һәм драматург Анатолий Парпара, профессор Абдулхан Әхтәмҗан, сатирик язучы Марсель Сәлимов, Татарстан морзалар оешмасы вәкиле Илдар Үтәмишев, шагыйрь, 1нче ранг капитаны Әхәт Мөхәммәтев, дипломат Йолдыз Хәлиуллин һәм башкалар язучы, җәмәгать эшлеклесе Р.Мөхәммәдиевнең эшчәнлеген, иҗат юнәлешләрен тирән анализладылар.

## ИҢ ЯХШЫ 100 ТАТАР ӘСӘРЕН САЙЛЫЙЛАР

Татарстанда иң яхшы 100 татар әсәрен сайлау башланды. Аларны Галимҗан Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты, Татарстан Милли китапханәсе, Татарстан китап нәшрияты һәм Язучылар берлеге вәкилләре сайлаячак. Исемлеккә әсәрләрне сайлап алу шартларын да Тел, әдәбият һәм сәнгать институты әзерләячәк. Исемлеккә кергән әсәрләрне рус, инглиз телләренә тәрҗемә итәчәкләр һәм Интернет челтәренә урнаштырачаклар. Бу республиканың әдәби мирасы кинрәк танылу алсын өчен эшләнә.

## ФЕСТИВАЛЬГӘ ӘЗЕРЛЕК

Быелгы Казан мөселман киносы фестивале 5-11 сентябрьдә узачак. Анда 25 илдән 130 гариза кабул ителгән инде. Фестивальгә тематикасына туры килгән сыйфатлы фильмнар гына уза. Бу юлы да Алжир, Мисыр, Албания, Бельгия кебек илләрдән яхшы картиналар булыр дип көтелә. Фестивальгә килгән фильмнар арасында мәңгелек тема — мәхәббәт, тормыш мәгънәсе һәм асылыбызга кайту мәсьәләләре яктыртылырга, алар мәгънәле булырга тиеш.

## «ХӘЗИНӘЛӘР» 3нче УРЫНДА

Режиссер Дмитрий Коробкин төшергән «Сокровища О.К.» фильмы кинотеатрларда күрсәтелә башлады. Rentrak мониторинг компаниясе мәгълүматларына караганда, әлеге фильм кинозалларга тамашачыларны җыю саны буенча Россиядә 3нче урында тора. Ул әлегә Американың «Железный человек — 3» боевигы һәм үзебездә төшерелгән «Легенда 17» фильмыннан гына калыша.

## ХЕЗМӘТЕНӘ КҮРӘ ХӨРМӘТЕ

Күпьеллык нәтиҗәле хезмәте һәм Татарстан Республикасының полиграфия тармагын үстерүгә лаеклы өлеш кертkәне өчен «Татмедиа» ачык акционерлык җәмгыяте филиалы — «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы» генераль директоры киңәшчесе **Әхмәтҗанов Ислам Галиәхмәт улына** Татарстан Республикасы Президентының Рәхмәте белдерелде.

***

Нәтиҗәле хезмәтләре һәм гаммәви мәгълүмат чараларын үстерүгә зур өлеш кертkәннәре өчен Республика «Татмедиа» матбугат һәм гаммәви коммуникацияләр агентлыгы хезмәткәрләре: эшләр идарәсе башлыгы **Әхмәтова Эльвира Фәнис кызына**, җитәкче урынбасары **Беломоина Нурия Абдулла кызына** Татарстан Республикасы Президентының Рәхмәте белдерелде.

***


Татар фольклористикасы өлкәсендә күпьеллык нәтиҗәле фәнни эшчәнлеге һәм халык иҗаты үсешенә лаеклы өлеш кертkәне өчен Татарстан Фәннәр академиясенең Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты халык иҗаты бүлеге баш гыйльми хезмәткәре **Мәхмүтов Хуҗиәхмәт Шаһиәхмәт улына** Татарстан Республикасы Президентының Рәхмәте белдерелде.

*Тышлыктагы сурәтләр*

*Тышлыкның беренче битендә:* «Сабан туе». **Ф.Халиков** картинасы.

*Тышлыкның дүртенче битендә:* язучы **Ибраһим Биектаулы**.

# ХУШЛАШУ СҮЗЕ



Татар әдәбияты зур югалту кичерде. Шагыйрь һәм прозаик, Татарстан Республикасының Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт бүләге иясе, Татарстанның халык шагыйре **Әхсән Баян** (Әхсән Фәтхелбаян улы Баянов) озакка сузылган каты авырудан соң вафат булды.

Ул 1927 елның 8 декабрендә Башкортстанның Илеш районы, Әшмән авылында дөньяга килә. 1947-1950 елларда район үзәге Югары Яркәйдә мәдәният йортының сәнгать житәкчесе булып эшли. Шунда эшеннән аерылмыйча гына урта белем ала. 1951 елда Казан дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты бүлегенә укырга керә. Укуын тәмамлагач, озак еллар журналистлык хезмәтендә була: 1956-1962 елларда «Социалистик Татарстан» (хәзерге «Ватаным Татарстан») газетасы редакциясендә башта хәбәрче, аннары әдәбият-сәнгать бүлеге мөдире, 1962-1966 елларда «Казан утлары» журналы редакциясендә жаваплы сәркәтип, 1977-1981 елларда журналның баш мөхәррир урынбасары булып эшли.

Ә.Баян — иң әүвәл шигъри әсәрләре белән танылган әдип. Ул — 20дән артык шигырь китабы авторы. Аның күпсанлы лирик һәм фәлсәфи-публицистик шигырьләре, балладалары һәм «Яшел мәйдан» (1957), «Дингез шавы» (1958), «Мират» (1959), «Сез анларсыз мине» (1963), «Сәяхәтнамә» (1969), «Кышкы чәчәкләр» (1974) кебек поэмалары, үзе яшәгән заманның характерлы билгеләрен, яшьтәшләре буынының романтик уй-хисләрен, өметләрен сәнгатьчә гәүдәләндерүдә үзенчәлекле ижат тәжрибәсе буларак, XX гасырның икенче яртысындагы татар поэзиясе хәзинәсендә лаеклы урын алып тора.

Ә.Баян — проза һәм драматургия жанрларында да житди уңышка ирешкән әдип. Тоталитар система тудырган буталчык замандагы татар авылы хәлләрен һәм андагы кешеләрнең катлаулы көнкүреш мәшәкатьләренә баткан перспективасыз тормышын киная катыш әдәби чаралар ярдәмендә нечкәләп гәүдәләндергән әсәрләре («Тау ягы повесте» (1972), «Аязучан болытлы һава» (1978), «Мәңгелек бәхәс» (1986), «Су өсләрендә пароход» (1997) һ.б. ) әдипнең ижади фантазиясенең колачын һәм тематик диапазонын билгели.

Ә.Баян сайланма повестьлары тупланган «Урланган ай» исемле китабы өчен 1999 елда Татарстанның Г.Тукай исемендәге Дәүләт бүләгенә лаек була.

Ә.Баян — әдәби ижатын жәмәгать эшләре белән тыгыз бәйләп алып барган язучы. Ул озак еллар Татарстан Язучылар берлегенең идарә әгъзасы (1974-1999), Әдәби фонд идарәсе рәисе (1989-1999) булып торды, жәмәгать тәртибендә «Казан утлары» һәм «Идел» журналлары редколлегиясендә, Язучылар берлегенең кабул итү комиссиясе составында эшләде.

Әхсән Баянның ижаты һәм хезмәтләре хөкүмәтебез тарафыннан югары бәяләнде. Ул — «Почет Билгесе» ордены кавалеры (1977), Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе (1988). Татар әдәбиятын үстерүдәге зур казанышлары өчен аңа 2004 елда «Татарстан Республикасының халык шагыйре» дигән шәрәфле исем бирелә. Әдип 1965 елдан СССР (Татарстан) Язучылар берлеге әгъзасы иде.

Әхсән Баянның якты исеме күңелләребездә һәрвакыт сакланыр.

**Р.Миңнеханов, М.Шәймиев, Ф.Мөхәммәтшин, И.Халиков, А.Сибагатуллин, Р.Вәлиев, Р.Миңнуллин, Р.Корбанов, Р.Харис, Г.Родионов, Р.Фәйзуллин, Р.Гаташ, З.Мансуров.**

# ТЕЛНЕ, МИЛЛӘТНЕ САКЛЫЙК ДИСӘК

Мөхтәрәм каләмдәшләр!

Хөрмәтле укучыларыбыз!

Сер түгел, матбугатыбызны халыкка тарату елдан-ел кыенлаша бара. Моның заман үзгәрешләренә бәйле, бездән генә тормаган житди сәбәпләре барын сез үзегез дә яхшы беләсез. Әмма без, сәбәпләрне ачыклаудан, акланудан бигрәк, иң әүвәл авыр хәлдән бергәләп чыгу юлларын эзләргә тиешбез. Мәсьәлә үтә мөһим: сүз туган телебезне ничек тә саклап калу һәм үстерү турында бара. Ә тел, мәгълүм булганча, милләтне милләт иткән төп билге, төп күрсәткеч. Телнең сакчысы — халык, бигрәк тә аның үз тарихын белгән, киләчәге турында уйланган зыялы катламы. Телнең яшәү даирәсе — гаилә, мәктәп, хезмәт-эш урыннары, сәхнә-театрлар, тамаша-концерт заллары, базар рәтләре... Әмма затлы классик телнен нигезе-бишеге — ул әдәбият һәм матбугат. Халыкның гасырлар буе җыйналып, чарланып килгән асыл җәүһәрләре — аларда. Газета-журналларыбызны, шул җөмләдән, бер гасырга якын тарихка ия иң өлкән әдәби журнал, халкыбызның рухи мирасын барлаучы төп басма булган «Казан утлары»н саклыйсы, үстерәсе, күтәрәсе иде. Моны, әлбәттә, редакция хезмәткәрләре көче белән генә башкарып чыгып булмый. Сезнең дә, хөрмәтле авторларыбыз һәм укучыларыбыз, хәлне аңлап, бу үтә кирәкле һәм савaплы эштә актив катнашуыгыз сорала. Теләгәндә һәм чынлап торып тотынганда сез дә яхшы ук булыша алыр идегез. Үзегез яшәгән төбәктәге халыкка — туганнарыгызга, дусларыгыз-танышларыгызга, хезмәттәшләрегезгә аңлатып мөрәҗәгать итсәгез икән. Татар теле һәм әдәбияты укытучылары бу эштә һичшиксез катнашырга тиешләр. Алар үзләре генә дә берничә данә яздырта алсалар да, журналның тиражы шактый ишәер иде! Киләчәккә өметебез булган яшьләр дә бу хәрәкәттән читтә калырга тиеш түгел дип уйлыйбыз. Безгә хәзер бердәм һәм бербөтен булып, милли матбугатны саклап калу кыйммәт!

Шунысын да исегезгә төшерәбез: вакыт аз калып бара, язылу 25 июньгә кадәр генә дәвам итәчәк.

*Сезнең теләктәшлеккә һәм ярдәмегезгә ышанып,*

**Равил ФӘЙЗУЛЛИН,**

*Татарстанның халык шагыйре,*

*«Казан утлары» журналының баш мөхәррире.*

Язылу бәясе Татарстанда аерым абунәчеләр өчен — 297 сум 54 тиен (индексы 73210), юридик затлар (оешмалар, предприятиеләр) өчен — 333 сум 90 тиен (индексы 16262).



Ибраһим Биектаулы

КАЗАН УТЛАРЫ
QAZAN UTLARI
ОГНИ КАЗАНИ

Ежемесячный литературно-художественный
и общественно-политический журнал
(на татарском языке)